ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# Казан утлары

1.2013



# БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ
## 20 еллыгы уңаеннан
## Татарстан Президенты
## Рөстәм МИҢНЕХАНОВ котлавы

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Моннан 20 ел элек халкыбызның ана телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, мәдәниятен саклап калу һәм үстерү, республикабыздан читтә яшәгән милләттәшләребез белән икътисади, мәдәни бәйләнешләрне барлау һәм ныгыту максатында Бөтендөнья татар конгрессы оештырылды һәм аның I съезды узды.

Тарих бизмәненә салсаң, 20 ел ул әллә ни күп тә түгел кебек, әмма шул вакыт эчендә һәр адым, һәр уныш, һәр җиңү күп көч һәм тәвәккәллек, ә кирәк чакта кырыслык та таләп итүен искә алсак, бу чорның, һичшиксез, зур тарихи сәхифә булуы аңлашыла. Шушы дәвердә Бөтендөнья татар конгрессы абруй казанды. Бүген аның белән Россия Федерациясе субъектларында да, чит илләрдә дә санлашалар. Конгресс татар авыллары, эшмәкәрләр, хатын-кызларыбыз, галимнәр һәм мөгаллимнәребезгә кагылышлы мәсьәләләргә һәрчак игътибарлы булды, милли һәм дини бәйрәмнәребезне оештыруда зур көч куйды. Башкарылган матур эшләр барысы да — Бөтендөнья татар конгрессы коллективының тырыш хезмәте нәтиҗәсе.

Җир шарының төрле почмакларына таралып яшәгән халкыбыз бүгенге көндә дә борынгы бабаларыбыздан мирас булып калган телен, моңын, күркәм бәйрәмнәрен, матур гореф-гадәтләрен саклап, аларны үстерә барып, олы бер милләт булып яши икән, монда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының да өлеше гаять зур.

Бөтендөнья татар конгрессы — милләтне туплаучы үзәк. Ул халкыбызның берләшү теләген, өметен, ышанычын һәм көчен гәүдәләндерә. Аның V съезды безгә уртак фикергә килеп, милләтебез алдында торган бурычларны барлау, бергәләп хәл итү юлларын билгеләү өчен дә кирәк. Киләчәктә дә татарлар күркәм эш-гамәлләре белән башка халыкларга үрнәк булып, борынгыдан килгән югары әхлагын саклый килеп, тарихта лаеклы урын алыр, дип ышанам.

Хөрмәтле милләттәшләр! Күп гасырлы тарихы булган татар халкы бүген үзенең телен, гореф-гадәтләрен, моңын, яшәү дәртен югалтмыйча яши икән, димәк, киләчәгебез өметле. Без бергә һәм бердәм булырга тиеш!

# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

# 1
**(1083)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рафикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары — 562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге — 562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр — 562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*
**Факс** — (843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рәниф ШӘРИПОВ. Бу Яңа ел. *Шигырь.* ....... 5
Хисам КАМАЛОВ. Сугыштан кайткан сөю. *Кыйсса.* ....... 6
Мөхәммәт МИРЗА. Бербөтенлек хакның таләбендә. *Шигырьләр.* ....... 51
Әсгать САЛАХ. Аккан сулар... *Яшьлегем хатирәләре.* ....... 57
Марат КӘРИМОВ. Кайларга чабасың, гомерем... *Шигырьләр.* ....... 117
Сирень ЯКУПОВА. *Хикәяләр.* ....... 123
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Җаным ирек, хөрлек тели. *Шигырьләр.* ....... 134

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Азат ЗЫЯТДИНОВ. Буыннар язмышы. ....... 138
Айдар ХӘЛИМ. «Мин гаделлек җиле...» ....... 145
Резеда ГАНИЕВА. Рухи-әхлакый янарышка таба. ....... 153

**ТАРИХ**

Тәэминә БИКТИМИРОВА. Татарстанда ачлык фаҗигасе. ....... 160

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....... 171

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Алмаз ХӘМЗИН. Яратабыз сине, Әлфия апа! ....... 174

**ИЛДАР ЮЗЕЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Ленар ШӘЕХ. Илдар абыйлы вакытлар... ....... 178
Илдар ЮЗЕЕВ. Тирәкләрем, нигә боектыгыз?.. *Шигырьләр.* ....... 183

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. ГУЛАГ тоткыны. ....... 185

«Казан утлары» архивыннан. ....... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....... 191

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Журнал выходит один раз в месяц

«Проза и поэзия»: повесть Х.КАМАЛОВА «Любовь, пришедшая с войны»; воспоминания о юности А.САЛАХА; рассказы С.ЯКУПОВОЙ; стихи Р.ШАРИПОВА; М.МИРЗЫ; М.КАРИМОВА; И.ГИЛЯЗОВА.
«Литературная критика»: А.ЗИЯТДИНОВ. «Судьба поколений»;
Р.ГАНИЕВА. «На пути духовного возрождения»;
А.ХАЛИМ. Статья о творчестве поэта Фарита Габдрахима.
«История»: статья Т.БИКТИМИРОВОЙ «Голод в Татарстане».
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Наши юбиляры»: А.ХАМЗИН. «Мы Вас любим, Альфия апа!»
«80 лет со дня рождения Ильдара Юзеева»: Л.ШАЕХ «Воспоминания о Ильдаре Юзееве»; стихи И.ЮЗЕЕВА.
Г.ГУМЕРОВ. «Узник ГУЛАГа».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зима»; ученый Дамир ИСХАКОВ.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and Poetry»: story by H.KAMALOV «Love which came from war»; memories of youth by A.SALAH, stories by S.YAKUPOVA;
poems by R. SHARIPOV; M.MIRZA; M.KARIMOV; I.GILYAZOV.
«Literary Criticism»: A.ZIYATDINOV. «Fate of generations»;
R.GANIEVA. «Way of spiritual rebirth»;
A.HALIM. Article about creativity of poet Farid Gabdrahim.
«History»: article by T.BIKTIMIROVA «Famine in Tatarstan».
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
«Our anniversaries»: A.HAMZIN. «We love you, Alfia apa!»
«80th anniversary of Ildar Yuzeev»: L.SHAEH «Memories of Ildar Yuseev»; poems by I.YUZEEV.
G.GUMEROV. «Prisoner of GULAG».
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Winter»; scientist Damir ISKHAKOV.

The magazine edits monthly

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 29.12.2012, график буенча 29.12.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2. Тираж 4049.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.

Рәниф
Шәрипов

## Бу Яңа ел

Бу Яңа ел... Шик-шөбһәләр югаладыр,
Яңа елда яңа өмет уянадыр,
Искеләрен еллар кая куылардыр,
Ниләр алып килер икән бу Яңа ел?

Барыбыз да өметләнеп юанадыр...
Яңа өмет тимер түгел, пыяладыр,
Ул кайвакыт төшеп китеп уаладыр,
Абынырлык таш булмасмы бу Яңа ел?

Өметләрнең кайберләрен тыялардыр...
Буш өметтән барыбыз да моңаядыр,
Хөр бәрәкәт эстәп кемгә Ил таяныр?
Тагын өмет алып килә бу Яңа ел.

Бар ул Бәхет, йөри адашып каядыр,
Зиһененә, тәүфыйгына Ил таяныр,
Үз язмышын тырыш кулларына алыр,
Өметләрне өзмә генә, и Яңа ел!

Башыбызда төрле уйлар чуаладыр,
Өметләр дә төрле төскә буяладыр,
Яше-карты бәйрәм итә, куанадыр,
Мәрхәмәтле булчы безгә, и Яңа ел!



Хисам
Камалов

# СУГЫШТАН КАЙТКАН СӨЮ

КЫЙССА[1]

***

Паровозны запас юлга керттеләр. Бу зур гына узловой станция. Мәгариф водокачка, пикгауз, складлар яныннан үтеп вокзал янына килде. Арттарак базар булырга тиеш иде. Шул якка чыкты, әмма ул юк. Буш лавкалар-өстәлләр генә. Баганаларга, коймаларга язулы кәгазьләр ябыштырылган: «Абый, әни бу шәһәрдә юк. Лена», «Мин әтиемне эзлим. Аның фамилиясе...», «Мин Германиядән кайтканда эшелонда сеңлемне югалттым. Исеме... Аны тапмыйча бирелән китмим. Катыс», «Мин әниемне эзлим. Фамилиясе Сауитина...»

Мәгариф паровозга кайтты. Баскычтан будкага, аннан тендерның бер ягында инструментлар өчен бүлмә итеп эшләнгән тамбурга узды. Теге медсестралар төшкәннәр. Ипатов хатыны һәм Буханько күнелле генә сөйләшеп утыралар. Машинист ярдәмчесенең кабактай түгәрәк башы җилкә өстендә тәгәрәп йөри кебек. Иңенең әле бер ягына ава, әле икенче иңенә күчә. Ул юмагайланып, җирәнгеч ялагайлана иде. Ничек тә хатынны үзенә каратырга тырыша. Сүзне ир белән хатын мөнәсәбәтенә китереп тери. Хатын да шомарган ише күренә. «Не люби шутя, а шути любя»,— дип үзен йолт кына алып булмавына ишарәли. Бәясен күтәрә. Буханько бу хатынның нинди икәнен чамалаган инде. Ә хатын үзен бик җитди — эшлекле итеп белдерәсе килә. Буханько аның мин-минлеген купайта, синең кебек хатыннар белән яшәргә була, ди-ди шуклана. Күренеп тора, сез ирне ир итеп тора торганга охшыйсыз, сез ирне картайтмыйсыз, аңа бәла китермисез...

Буханьконың юмалану, мактау сүзләре хатынны үсендереп җибәрде, ул кәперәйгәндәй булды, чыраена үзенең бәясен белү чалымнары чыкты. Ул матур, бераз көдрә чәчләренә көрән беретын янтайтыбрак рәтләде. Сыгылмалы сынын күрсәтү өчендерме, зәңгәрсу шароварын җилфердәтеп,

[1] Журнал варианты.

Хисам КАМАЛОВ (1926) — *Татарстанның халык язучысы; «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым», «Теләнмәгән күз яше» һ.б. күпсанлы шигырь һәм проза китаплары авторы. Казанда яши.*

теге почмакка атлап барды да, тиз генә борылып, кире килеп чүмәште. Буханьконың сүзләрен чынга алуы, ана тулысы белән ышануы сизелә иде. Узгынчы, ялган тулы сүзләрдән тәэсирләнүе аның типик хатын-кыз һәм сай табигатьле икәнен белгертә иде. Буханько һаман үзенең тукынуын белә, хатынны мактап сайрый: мәгънәле кинаяләр ясый.

— Мин пэпэже түгел,— дип куйды хатын чәч алкаларын матур селкетеп. Аның очлы ияге бераз горурлык белән күтәрелеп торды. Буханько моны уенга борды һәм үзе дә уен белән әйтте:

— Аңлыйм, сезнең кебек укымышлы хатын-кыз аңдыйга бармый инде.

— Мин химтехникум бетердем,— дип хатын ике учы белән кабарынкы, сөйкемле битләрен сыпыргалап алды. Ялганлаганда артык кызарып китмәдем микән дип үзен барлаган шикелле тоелды. — Мин лабораториядә ассистент булып эшләдем. Шунда бер галим үлеп минем арттан йөрде. Ял саен чәчәк һәм шоколад бүләк итә иде. Ләкин хатыны белеп, скандал чыгарды. Житәкчелек каршына куйды. Шаһитлары бүлмәдәш иптәш кызларым иде...

— Көнчелектән инде! Сез чибәр, сөйкемле! Матурларның көнчеләре күп була ди.

Буханько тагын хатынның мин-минлегенә жим ыргытты. Хатын моңа шунда ук чиртте:

— Матурларның бәхетләре булмый диләр...

— Бу көнче күбәләкләр сүзе генә. Матурларга бәхет үзе килә. Матурларны бәхет көтеп тора...

— Тормышта алай ук түгел түгелен,— дип уфтанды хатын һәм әллә сусынны китерә торган биек күкрәкләрен белдерәсе килепме, учы белән сыпырып-сыпырып алды. — Ир-ат хәзер ышанычлы түгел. Хатын-кыз бик күп, ирләр аз. Шунардан файдаланалар...

— Хатын-кыз ул койма буенда үскән кура жиләге инде,— дип шаяртты Буханько хатын горурлыгына тимәслек итеп кенә көлеп. — Тулып кызарып пешкән. Менә-менә коелырга тора. Аны ничек өзеп капмыйсың ди?

— Өзеп карамасаң, дурак буласың, ә? Шулаймы? Ирләр теләге рәхимсез!— дип хатын да челтер-челтер көлеп алды. — Күкеләр!

—Үзегез яшь, ә ир-ат халкын белеп бетергәнсез,— Буханько күзләрен майландырып һаман хатынның салпы ягына салам кыстыра.

— Һәр ир-ат миндә аласы нәрсәсе бар шикелле жанга тукына. Уф!

Хатын тагы тырпаеп торган күкрәкләр өстеннән учын йөртте. Гүя Буханьконың шул күкрәкләргә төбәлгән карашын сыпырып төшерә иде.

— Дөрестән дә, ир-атның синдә аласы нәрсәсе бар бит, ә?

— Әллә ир-ат миңа бирәр нәрсә биреп куйганмы? Юк!

Хатынның матур чыраенда житдилек чалымнары куерды. Буханько моңа тиз генә жавап таба алмыйча, кабактай киң маңгаенда жыерчыклар уйнатып-уйнатып торды.

— Алла шулай яраткач, нишлисең инде,— диде кулларын жәеп. — Ирләрне сораучы-теләнче, хатыннарны бирүче иткән...

— Теләнүче һәрчак гужлана, комарга бирелә, үз-үзен белештерми! Аңа алырга гына булсын, аннары — ник янмый шунда!?

— Әйе, ирләрдә охотниклык бик көчле инде.

Буханьконың тавышы тонықланды.

— Кая инде ярату, хисләр турында сөйләргә? Аучыда нинди хис, ярату булсын? Аңа корбан гына кирәк...

Хатын Буханьконың түбәнгә төбәлгән чыраена туры карап торды. Сүзләре моңа нинди тәэсир итте икән дип кызыксына иде шикелле. Буханькога

өметен суза мәллә? Булмас димә. Ул, Ипатовның хатыны булып яшәп, аның холык-фигылен белеп бетергән. Перспективасы бармы-юкмы икәнен дә чамалаган булырга охшый. Ипатов ерак китә торган түгел. Холкы да утырып җитмәгән: тупаслыгы еш кына бүтәннәргә тиеп, аның тормышын күңелсезлиләр шикелле.... Буханько сүзне бүтән эзгәрәк борды:

— Кайбер хатын-кызга ир кирәк, ә кайберсенә ир түгел, яшәү чыганагы гына кирәк...

— Билгеле, шулай. Хатын-кыз тормыш оясы кора. Ирнең гомерен мәгънәле итә, киләпкә сала, яшәү рәхәтен тудыра...

— Ирне яшәү чыганагы итсә, яшәү рәхәте булмый инде, юк!— диде Буханько эчке елмаю белән.

Ул хәзер чамалады инде, бу хатын «дешевка» түгел, ансат кына кулга төшмәячәк. Хәер, күп сынаганы бар, кешеләр сүздә бер төрле булса, гамәлдә шуның капма-каршысы килеп чыга. Хатын-кыз еш кына кагылгысыз «неприступный» булып кылана гына. Әзрәк өметләндереп, вәгъдәләр белән ышандырсаң, кыссаң-кочсаң, балавыз кебек эри дә төшә үзе...

Ул арада Ипатов путевка алып менде. Барыбыз да үз урыннарыбызга бастык. Паровоз бер-ике минут тормозларга пар кудырды да кузгалып китте. Рельслар тигез кыр буенча сузылган. Озакламый тар юлга төштек һәм паровоз тигезлекне бик нык арттырды.

Топорово станциясендә призывниклар полкы төялгән вагоннарны тагып алга, Көнбатышка таба киттек.

Мокрыда бригада алмашыныр дигәннәр иде. Ләкин ул хәл булмады. Машинистка нидер булган, аны госпитальгә салганнар. Юлны үзебезгә дәвам итәргә куштылар. Подсобкада ашап-эчкәч, бераз хәл кереп китте. Америка колбасасы бик тәмле тоелды. Ләкин туклыклылыгы аз икән, күп тә үтми тамак ачты. Мин физик эш эшлим бит, ташкүмер кантарларын колун белән ваклап торам. Ныклап ашау кирәк. Әмма каян аласың аны? Һаман ачлы-туклы көе эшлисең. Кемгә зарлана аласың? Зарлансаң, әһә, бу властьны яратмаучы эчке дошман икән дип тегендә озатырга да күп сорамаслар.

Брест янындагы Муховец станциясенә икенче көнне кич килеп җиттек. Эшелонны исән-имин тапшырдык. Бу бик зур узловой станция. Биредә комендатура, тимер юл милициясе, административ биналар. Ашханәсе дә бик шәп иде. Талоннарны кисеп тәмле аш һәм котлетлы макарон алып тамакны ныгыттык. Тулай торак барагына да бик чиста бүлмәләргә урнаштык. Эт булып арылган. Күпме йоклаганыбызны сизмәдек тә. Сигезтугыз сәгатьтән безне уяттылар. Юлга әзерләнергә кирәк иде. Тиз генә тамак ялгап чыккач, паровозга килеп, эшкә тотындык. Иң элек күмер складына бардык. Йөзләгән стрелалар аша күчә-күчә килеп җиттек. Унике тонна күмер тиешле. Аны кое сиртмәсе шикелле бер озын агач башына беркетелгән козлуга салып тендерга бирәләр. Күмер тузаны бик әшәке нәрсә: әллә ничә кат кием аша тәнгә үтә. Күзәнәкләрне томалый, шуңа тән кычыта. Бетләгән шикелле булып йөрисең, әледән-әле җилкәләреңне селкетеп торасың.

Күмердән соң водокачкадан унсигез тонна су алдык. Үзебезнең элекке урынга кайтып начальниклар боерыгын көтә башладык. Шул ачыкланды: без 1941—42нче елларда Германиягә эшкә җибәрелгән хатын-кызларны эшелон белән алып китәргә тиеш икән. Смоленскига чаклы. Станциядән өч-дүрт чакрымда озын-озын бараклар, аларны Германиядән кайтарып монда туплаганнар. Хәзер тикшерү, сортировка бара. Эш катлаулы, тагы өч-дүрт тәүлеккә сузылачак ди. Комендатура хезмәткәрләре көне-төне өзлексез эшлиләр.

Германиядән кемнәр ничек булып кайта? Бу бик четерекле нәрсә иде. Мәгарифне кеше белән бәйләнешле һәр эш, хәл кызыксындыра иде. Ул, комендanttан рөхсәт алды да, сортировочныйга барды... Анда мәхшәр, ыгы-зыгы, кычкырышу-елаш бер дә тынып тормый... Һәрбер кайтучыдан әллә ничә кеше сорау ала, шулар буенча документ тутыра. Нечкә иләк аша уздыралар. Шунсыз мөмкин дә түгел. Бу бик мөһим чара. Немец вербовать итеп безгә шпионнар җибәрү ихтималы юк түгел. Мәсьәлә катгый куелган. Кайтучыдан сорау алу өстенә, әллә ничә гариза да яздыралар. Кайсы яшь кенә булса да, грамотасыз иде. Мәгариф шундыйларга гариза язарга булышкалады. Сорау алып, карточка тутыручылар барысы да диярлек кече лейтенант погоны таккан чибәр кызлар. Энәдән генә төшкән яңа яшькелт гимнастерка, җилкә аша партупея, киң каеш белән билләрен буып куйганнар. Шундый ук яшькелт юбканы тезләреннән үк иплe генә өскә күтәреп кигәннәр. Чын хром итекләр тулы балтырларын кысып тора. Бөдрә алкалы чәчләрен түгәрәк итеп күтәргән, бик килешеп, ягымлы йөзләрен тагын да матурлый төшкән. Хәрби кием уртача матурны да гүзәл итеп күрсәтә икән... Мәгариф бу берсеннән-берсе матуррак кызларга сокланып туя алмады. Болар белән дуслашкан, йөрешкән егетләр нинди бәхетле кешеләр икән? Аның белән бу кызлар арасы мәңге үтеп чыга алмаслык упкын. Ул үзенең нинди түбән торуын хәзер аеруча бер ачыну белән тойды, әлеге түбәнчелектән шушы кызлар дәрәҗәсенә гомердә дә күтәрелә алмаячак. Алга таба да һаман таптaлу астында яшәр микән? Яшьтән уку тимәде,тормыш ничек тели шулай изде. Өстәвенә бу татар булулык һәрчак аякка салды булды. Тигезлек диләр, нинди ялган, кешедән көлә торган сүзләр! Әгәр рус булсам, болай көн-төн кара тузан сулап, корым төкерер идемме? Менә төнлә йөткертә башлады. Врачлар ничектер җәлләпме: үпкәң йомшак-көчсез, дип ычкындырдылар...

Кызларга карап Мәгариф дөньясын онытa язды. Менә, өстәл янына килеп баскан бик матур киенгән таза гына кыздан, лейтенант кыз сорау алып, документ тутыра. Кыз русчаны оныта язган икән... Башта немецча сөйләп алды да, рус сүзләрен сайлап-сайлап аңлатырга тотынды:

— Мине немецлар алып киткәндә сигез яшьтә идем. Хәзер унөч белән барам. Мин кечкенә чакта башта әтине, аннан әнине милиционерлар алып киткән. Мине әби үзенә алган. Әти-әни шул җирдән юкка чыкканнар. Немецлар килгәндә без пионер лагеренда идек. Шуннан барыбызны да машиналарга төяп алып киттеләр. Төнлә берничә малай качкан дип сөйләделәр. Сумы шәһәрендә вагоннарга утырттылар. Ашарга өләштеләр. Аннан бик озак бардык. Ун көнләп булырга тиеш. Франция чигендәге бер станциядә безне хуҗаларга бүлеп тараттылар. Мине ирле-хатынлы кырыс кыяфәтле немецлар алды. Балалары юк икән. Башта, билгеле, бик авыр булды. Ләкин немецлар бик сабыр холыклы булып чыкты. Иң элек өйдәге һәр нәрсәнең исемен, нигә кирәк булуын аңлаттылар. Шактый кырыс рәвештә. Мин белмичә тәртелеп калсам, бер дә чигенмиләр, үзләренекен итми калмыйлар. Ашау-эчү әйбәт, өс-башымны янарттылар. Хуҗаны трудармиягә алдылар. Ул шунда һәлак булган. Без зур өйдә хуҗа хатын белән калдык. Бик эшчән, уңган кеше. Мине үзенең кызы шикелле күреп, бик күп нәрсәләргә өйрәтте. Укырга-язарга, арифметикага өйрәтте, биология буенча да дәресләр бирде. Аннары машинада тегү, чигү серләренә төшендерде. Өстемдәге һәр киемне үзем тегәм... Йорт янында зур гына бакча. Анда кызыл карлыган, алма, груша, виноград үсә. Яшелчә дә күп утырта идек. Ел тәүлегенә җитәрлек. Кечкенә трактор бар иде. Җир эшләрен шуның белән башкарабыз...

— Ул сине кол шикелле эшләткән, эксплуатацияләгән инде,— дип бәлдерде аннан сорау алучы лейтенант кыз.

— Юк, без икебез тигез диярлек эшләдек,— диде немецлашкан кыз. — Авыр күтәртмәде, көчем беткәнче эшләтмәде. Һәр нәрсәдә чама-чикне белә иде. Һәр эштә төгәл, үлчәүле... Мине, әйтәм бит, үз кызы шикелле итеп өйрәтте, күнектерде.... Шуның өчен мин кире аның янына — Луиза Тизиль янына китәрмен дип уйлыйм. Чөнки туган җиремдә беркемем дә юк. Анда кошмар, хәрәбәгә кайтып мин үләрмен. Юк, мин кире китәм.

— Нигә шунда гына калмадың соң?

— Американнар көчләп диярлек җыйдылар, машинага төяп озаттылар. Качып калырга башка килмәгән, ялгышканмын. Һәм хәзер генә аңладым. Мин бит инде немка, русны яратмыйм мин...

— Баракка кайтып тор, үзебез чакырырбыз,— диде лейтенант кыз тегенә. Рус немка матур калын иреннәрен кинаяле бөгелгәләп китте.

Чираттагы хатын керде. Кочагына нидер күтәргән. Өстәлгә китереп куйды. Биләүгә төргән бала икән. Йа, Ходай! Нәрсә инде бу әкәмәт? Бала тып-тын, бер шыңшып карасынчы. Барча биографик «данныйларны» сөйләп, кәгазьгә теркәгәч, сүз балага килеп терәлде.

— Кемнән?

Лейтенантның йөзенә бернинди гаҗәпләнү, сәерсенү чалымы чыкмады.

— Немецтан,— дип хатын башын аска иде, гөнаһ өстендә тотылган кебек гаять уңайсызланды, бөрешеп килде.

— Көчләдемени?

— Юк...

— Үзең теләпмени?

— Юк...

— Алайса ничек булды?

— Мин бик ач идем, үләр хәлгә җиттем. Ул мине ашатты, тәрбияләде. Киемнәр бирде. Үлемнән алып калды. Аңа ничек карыша аласың? Шуннан булды инде....

Хатынның тавышы бер өзелеп, бер ялганып барды.

— Исем-фамилиясен, адресын беләсеңме?

— Адресын белмим, исем-фамилиясе менә бу кәгазьдә язылган.— Хатын лейтенантка рәсемле открытка сузды. Ул американнарда пленда булган.

— Хәзер нишләргә уйлыйсың?

— Немецтан туган балаларны Союзга алып кайтырга ярамый,— диләр. Калдырам, анда көн күрсәтмәүләре билгеле инде...

— Дөрес,— дип лейтенант хатынны хуплады. — Илне фашист балалары белән тутырып булмас. Һәм тагын бер кәгазьгә кул куйдырды да медпунктка барырга кушты.

Хатын биләүне җәһәт кенә күкрәгенә кысып ишеккә юнәлде. Ул баладан болай ансат кына котылуына сөенә шикелле иде. Бу хәвефле йөк аны бәхетсез итәчәк. Яраткан кешедән тапкан баласын болниста калдыручылар бар. Ләкин бу эшкә аны нужа мәҗбүр итә инде. Нужага каршы торырлык бер чарасы юк. Нужа үзенең котылгысызлыгы белән адәм баласын таптый, рәхимсез изә.

Тагын бер хатын бала күтәреп керде. Биләвен өстәл өстенә куйды. Тукта, ходавәндә, биләү эчендә кап-кара бала ята! Негр баласы бит бу... Барча формаль сораулар-җаваплардан соң, хатын үз хәлен бәян итте.

— Без бер заводта эшләдек. Негр Джон вольнонаемный иде. Миңа эштә зур ярдәм итте. Материаль яктан да булышты. Без уртак тел таптык. Американнар безне азат иткәч, Джон мине үз квартирасына алды. Бергә яши башладык. Ул миңа өйләнәм диде. Америкага алып китәм дип өметләндерде. Әмма бер көнне кинәт юкка чыкты. Өйдә чемоданы юклыгын белгәч

кенә, аның качканын аңладым. Күршеләр дә белгәннәр. Мине квартирдан кудылар, репатриантлар барагына урнашырга мәҗбүр булдым...

— Ни өчен чит элемент белән женси мөнәсәбәткә кердең, ә? Шуны аңларлык та башың эшләмәдемени?

Тикшерүче лейтенант кызның тавышы кырыс иде.

— Сознательность булмаган инде,—диде гөнаһын тулысы белән үз өстенә алгандай. — Дүрт класс белән соң?

— Ә моны нишләтергә уйлыйсың?

Лейтенант авызын ачып иреннәрен кыймылдатып яткан балага ымлады.

— Белмим инде нишләргә дә...

Ул башын иеп тирән уфтанды.

— Өйдә кемнәрең калган иде?

— Әти, әни, сеңел... Алар исәнме-юкмы, белмим. Бу «бүләк» белән бусагага якын җибәрмәячәкләр...

Хатынның күзләренә мөлдерәп яшь тулды. Менә тамам, менә тамам дип дерелдәп тора. Хатын күзен сөртергә уйламады да.

— Баланы калдырырга туры килер.

— Калдырырга? Ничек? Кем имезер, кем карар, ә? Нинди әкәмәтләр сез?!

Хатынның гаҗәпләнүдән кашлары маңгаена менде, күзләре шар булды.

— Нәрсә син берни белмәгән кебек кыланасың?— дип тавыш күтәрде тикшерүче лейтенант кыз. — Әллә Союзны кара-моралар белән тутырыр идеңме? Сознательностең кая?

— Юк, сабыйны жәлләп әйтүем,— диде хатын гаҗизләнеп. — Миннән башка бетәр ул. Кара булса ни, җан иясе бит...

— Нигә элегрәк уйламадың шул хакта?

— Башта уйламыйсың бит аны. Ир кочагында чакта. Мин Джонны яратам дип белдем. Уф, бу бер йодрык чаклы гына тере йомгак шулай әрәм булыр инде. Юк, ул миннән башка тернәкләнмәс...Гөнаһы минем өстә булыр, ул гөнаһны ничекләр күтәреп йөрерсең?.

— Анда махсус «Дом ребенка» бар, берни дә булмас. Мондый уйнаштан туганнар анда йөзәрләп. Калдырырга ризамы?

— Ризамы дип, йөрәктән өзеп калдырам инде, илгә чит балаларны кертмиләр дисең бит,— дип хатын башындагы бик матур күрән беретын рәтләштереп алды.

Тикшерүче әлеге хатынны баласы белән медпунктка озатты...

Мәгариф тә бүлмәдән чыкты, сәгатенә карап алды. Әбәдкә соңга кала язганмын ди-ди станциягә таба йөгерә-атлый китте.

Әбәдтән соң штабның Ленин почмагында политзанятиегә җыйдылар. Сүз Черчилльнең күптән түгел сөйләгән речө турында бара иде. Ул әйткән: «Әгәр Советлар үзләрен тиешле дәрәҗәдә тота белмәсәләр, Европа аны йөгәнләү чарасын табар...» дигән.

Бу совет кешеләренең горурлыгын рәнҗетә торган, бигрәк тә Совет «верхушкасы»ның ачуын кабарта торган фикер. Теге паровозны тикшерергә кереп, Ипатов белән сүзгә килгән лейтенант кызып сөйләде. Черчилль, диде, Совет армиясенең Бөек Ватан сугышында җиңүен киметергә тели, әһәмиятен төшермәкче була. Ә 1942 елда немецлар Лондонны «ФАУ»лар белән бомбага тотканда, ул бүтәнчә сайрый иде. Хәзер әнә атом бомбасына таяна ул, шуның белән өркетә...Ләкин атом бомбасы бездә дә булачак, иптәшләр. Безгә һәрберебезгә дә политик уяулыкны көчәйтергә, сизгер булырга кирәк. Таркауланып, эшкә салкын карау булмасын. Безгә янаган

капиталистларга үзебезнең югары аңлылык, политик уяулык белән җавап бирик...

Тагын берничә юлчы йодрык төйнәп ялкынланып сөйләде. Поездларның йөк ташу планын үти алмауларының сәбәпләрен ачты. Планны үтәмәү ул капиталистлар тегермәненә су кою белән бер...

Аннан Буханько торып басты. Эшли башлавына кайчан гына, ә үзен нинди кыю тота. Нәчәлникләр күзенә чәчрәп керә. Үзен күрсәтер өчен генә сөйли кебек. Юк, тукта. Нәрсә ди? Без һәр җирдә уяулыкны арттырырга тиешлебез. Германиядән бик күп чит элементлар кайта. Алар капитализм пропагандасы белән агуланганнар. Сак булырга, үзебезнең сәяси аңыбызны көннән-көн күтәрергә тиешбез. Ничек итеп? «Правда» газетасын көн дә укырга кирәк. Мин «Правда» газетасын яратып укыйм. Күп нәрсәләр аңлыйм. Ә менә безнең машинист Ипатов газетаны кулына да алып карамый. Мин аңа «Правда»ны бирәм, ә ул: «Брехунец»,— дип кулын гына селти. Ипатовта сәяси аңлылык җитенкерәми шикелле. Ул немец паровозларын мактый, безнең паровозлар патша заманындагы кебек, ди...

— Алдама!— дип кычкырды Ипатов. — Мин сине «Брехунец» дидем. Әнә шуны үзең исбат иттең. Ялганлап. Гаебеңне бүтәнгә сылыйсың. Алай барып чыкмас, иптәш Буханько. Мине тимер юлда күптән беләләр... Ә мин сине намуслы дип, ялгышканмын! Булдыксыз — хөрәсән икәнеңне политик ширма белән капламакчы буласың!..

— Ипатов, җитте!— диде җыелышны алып баручы капитан парторг.

Ул өстәлгә каләм очы белән сугып шыкылдады. Аның ике яңагында бүлтәймәләр кыймылдады. Аңа хәзер үк бу инцедентны бетерергә, очкынны сүндерергә кирәк иде. «Правда» газетасын «Брехунец» дип атау чынга китсә, бик зур сәяси скандал кузгатачак. Бу гаять куркыныч хәл. Парторгның үзенә дә эләгәчәк. Ипатов партиядә булмаса да андый сүзләр өчен бөтен биографиясен бозачаклар. Шуңа парторг бик җитди төс чыгарып ныклы тавыш белән әйтте. — Юк, Ипатов авызыннан андый мәгънәсез сүз чыкмас! Әйе, чыкмас!

Иптәш Буханько бераз кызып китте. Кызган чакта шундый чатаклык җибәрәсең. Ипатов партиягә чын күңелдән бирелгән, үз эшен намус белән башкара. Ротада аны шулай дип беләләр һәм хөрмәт итәләр...

Парторг Буханьконың да күңелен күрергә теләп, аның яңа эшче булуын һәм үзенең сәяси-аң дәрәҗәсен күтәрү өстендә эшләвен әйтте. Ул депода үзен яхшы яктан гына күрсәтте, диде. Күп тә үтмәс, Буханько яраткан һөнәрен камил үзләштерер һәм паровоз рулен үз җаваплылыгына алыр. Без аңа бик нык ышанабыз. Бүгенге чыгышы аның эш өчен януын күрсәтә...

Парторг җыелышны шулай тәмамлады...Алар җыелыштан бергә чыктылар. Шпалларга баса-баса вак адымнар белән атладылар. Шпал арасы гади адым өчен тар, ике шпал арасы зур адым өчен артык киң иде. Шуңа әле бер шпал арасы вак адым, әле сузыла биреп ике шпал арасын атлыйлар. Мәгариф бусагалы юлны өнәмичә, читтән атлый. Ипатов шпаллар буенча бара, чырае җитди, уйчан. Күз кабаклары шешенке, җыерчыкларга күмелгән. Иреннәре тартылган. Янак чыгымнарында ялкындай кызгылт таплар типкән. Ә Буханьконың табак битләрендә ригаяле әчке көлемсерәү җәелгән. Гүя ул малай ниндидер шуклык эшләгән һәм шуны тануын белгертеп көлемсери. Ипатовны болай гына тәнкыйть итте ул. Бу дусларча шуклану гына иде. Эчендә аның бернинди ачу, катлау юк бит! Бары чын күңелдән янындагы иптәшеңне яхшылыкка өндәү генә. Очраклы гына шулай килеп чыкты. Мин депода эшләгәндә иптәшләрне чеметкәләп ала идем. Алар бер ачу тотмыйлар. Чөнки миндә явызлык, начар теләк юк: еракка китә торган исәп тә, үзенә очко эшләү дә...

Буханько юмакайланып Ипатовка якынрак килеп атлый башлады. Аның аңлашасы, арада туган киеренкелекне йомшартасы килә иде. Чөнки бер будкада инне-ингә терәп эшлисе. Бер-беренне ярты сүздән, яки ымнан аңлау булмаса, паровоз чаклы зур машинаны идарә иткәндә бәла-каза килеп чыгуы бар.

— Ни, Семен, миңа бик нык ачуын килдеме? Мин теге, простойлык белән генә бит? Мин туры кеше, шул бәлам минем, ә? Туры туганына ярамый, ди. Теге ни бит... ә?

Ул гозерле сөйләнеп атлый, Ипатов аның сүзләрен ишетми һәм ул Буханьконы күрергә дә теләмәгән кыяфәт белән бара. Буханько исә аның саен үртәлгәндәй, үзенен изге ниятле булуын аңлатмакчы була.

— Иптәш Сталин әйтә, тәнкыйть һәр эштә алга хәрәкәт иттерүче көч, ди. Мин шуннан чыгып кына. Ә син бөек юлбашчыбыз сүзләренә каршымыни? Юк, мин моңа ышанмыйм. Син каршы түгел, бары тәнкыйть өчен балаларча үпкә тотасыз гына. Юк...

Ипатов башын икенче якка каратып бара, ул яны белән Буханьконы инкарь иткән төстә атлый. Ана гәүдәсен дә бормый, бик усал кыяфәт белән хәрәкәт итә. Болар бергә ничек эшләр икән? Бер будкада? Паровозны ничек җигәрләр? Бер-берсен аңламыйча авария ясаулары бар. Нәчәлникләр боларның дошманлашуына әһәмият бирмәделәр. Бәлки махсус дошманлаштырганнардыр әле. Чөнки бу чик буе. Ике дусның, сүз берләшеп, паровоз белән Польша җиренә чыгып китүләре ихтимал. Андый хәлләр булгалаган. Польша ягында шуны гына көтеп торучы бандалар турында сөйлиләр...

— Семен, мин сиңа үчтән түгел, бары иптәш Сталин сүзен гамәлгә ашыру йөзеннән генә. Неужели юлбашчы сүзләрен кабул итмисез, ә?— Буханько Ипатовның бер алдына, бер артына төшә иде. Ахырда Сталин исеме аны йомшартты кебек. Бу бер үк вакытта куркыта һәм хөрмәтләргә мәҗбүр итә торган исем. Ипатов, йомшый баруын белгертеп, кырын барудан туктады.

Ул арада Ипатов үзе белән йөртә торган хатын — Инна килеп чыкты. Паровозга часовой куйдылар, ул мине куып төшерде, диде иркәләнгән тавыш белән. Ул санпропускникта душ кереп чыккан, чистарынган, чәч бөдрәләрен беретыннан чыгарып маңгаена сипкән, иреннәрен буяган. Искерәк трофейный бәрхет жакет һәм зәңгәрсу шаровардан. Урта буйлы йомры гәүдәсе Ипатов белән Буханько арасында бөтерелә. Әле Семенга ялагайлана, әле Буханькога. Бу берничә көндә ул Буханьконың көчле, елгыр икәнен чамалап өлгергән иде инде.

Алар, тегене-моны, юк-барны сөйләнә-сөйләнә, ашханәгә таба юнәлделәр. Ашханә урман кырыендагы баракларда иде. Буханько шунда кинәт: «Мин хәзер»,— диде дә, болардан аерылып депо бинасына таба чапты. Рельс арасын сикереп кенә үтә иде, ул ничектер янтаеп йөгерүче көнгерәне хәтерләтте. Бу депода да танышлары бар микәнни дип гаҗәпләнде Мәгариф. Бик елгыр адәм күренә. Иннаның аңа ярарга тырышып сагызлануы тикмәгә булмаска тиеш.

Бүгенге көн талонын кистереп Ипатов ашлы һәм боткалы булды. Иннаның талоны юк иде. Ипатов аны үз иждивениесендә тота. Рас хатын кочагына кирәсең икән, түләргә мәҗбүрсең. Һәр ир хатын-кыз өчен түли инде. Ипатов буфеттан Инна өчен печенье һәм томатлы килькига акча тотты. Мәгариф итле бәрәңге белән компот кына алды. Буханько да килеп җитте, кулында кара сумка иде. Ул тиз генә үз порцияләрен алып, иптәшләре янына утырды. Ипатов килька консервасын ачты. Инна чәнечке белән ашарга кереште. Үзе исә ашын шобыр-шобыр чөмерә иде. Буханько алдына куйган сумкасыннан шешә башы калкытты. Сюртугын шытырдатып кубарды,

шешәне кыегайтып стаканга салды, өстәл астыннан гына Ипатовка сузды. Бу тәүлек эчендә юлга чыгасы юк иде, шуңа бу ачы су бик мач кына иде. Буханько Иннага да стаканны тулыр-тулмас итеп бирде. Баш тартыр дип уйлаган иде Буханько, ләкин көткәне акланмады. Инна стаканны бик чөс кенә авызына каплады. Хәтта йөзе дә чытылмады. Ашаудан туктап торды. Ашап тәмен бетермим әле дип сөйләнде. Буханько компоттан бушаган Мәгариф стаканына ике илле чамасы гына тамызды. Татарлар эчмиләр, диде ул, ә син, кяфер, Аллагыздан курыкмыйсынмы? Буханько үзенең зирәк сүзләреннән рәхәтләнеп көлде. Бүтәннәр аңа кушылып, кешнәшеп куйдылар. Буханько тулыр-тулмас стаканын алгарак сузды да:

— Семен, мировойга салыйк, ә?— диде төче телләнеп.

Тегесе ашау белән булышып, ишетмәгән булды. Югыйсә, күз кырые белән күреп, колак очы белән ишетеп тора. Озак эндәшмәгәч, Инна анын беләгенә төртте:

— Әнә, мировойга эчик, ди!

Ипатов, читкә караган килеш кулын селтәде дә, стаканны алды. Чәкәштеләр һәм су урынына эчеп куйдылар. Буханьконың тук симез битләрендә канәгатьлек нурлары бии иде. Ул сумкасыннан бер төргәк алды да Иннага сузды.

— Бүген синең туган көнең бит! Менә, котлыйм!

Ә Инна гаҗәпләнүдән телсез калгандай булды. Кинәт айнып киткән кебек иде. Ул берни белештермәгән кыяфәттә төргәкне сүтте. Аннан бик матур яшькелт трофейный кофта килеп чыкты. Инна бу хәлгә ышанмыйча Буханькога карады, монын серен белмәкче иде. Шулай да хатын-кыз булуы төртеп чыкты, ул кофтаны иненә, күкрәгенә куеп күз үлчәве белән маташты.

— Крепдешин! Бу ничек инде?! — Ул каушаган карашын Буханькога төбәде. Шаяртадыр дип моңа һаман ышанмый иде. Буханько эндәшми генә елмайган килеш серле карап тора. Инна моның артында нидер булырга тиештер дигән серле күзләре белән Ипатовка ым кагып ала. Ник дигәндә, Инна аныкы бит әле. Аңа Ипатов хуҗа. Менә Иннаның Ипатовка булган таянычы селкенеп куйды кебек. Ипатов моңа ничек карар? Хәер, Инна ирекле хатын, шулай да намус дигән нәрсә дә бетеп җитмәгән, Ипатов аны ашата-эчертә, шуның бәрабәренә Инна аңа хатын булып тора. Тәнен бирә. Ир-атка бары тән генә кирәк. Хисләр турында сүз куерту урынсыз эш. Алар очраклы гына юлда бергә туры килделәр. Инна, иптәшләреннән калып, бер караңгы станциядә адашып йөри иде. Ипатов аны үз будкасына алды. Икенче көнне алар уртак тел таптылар. Инна гореф-гадәт, хорафатлардан азат батыр хатын икән. Ирләргә ни кирәген белгән. Ачы тәҗрибә өйрәткән аны. Шуңа күрә арада каршылыклар булмады. Икесе дә яхшы аңлый: бу хәл бары вакытлыга һәм ирекле. Беркемгә беркем дәгъва белгертеп, «права качать» итә алмый.

— Миңа гына үлчәп тегелгәндәй... — Инна бу әйбергә сокланып, шатланып бетә алмый. Ләкин кинәт кофтаны өстәлгә куйды. Йөзе җитди, борчулы чалымнар белән тулды. Шикле уе эшли башлаган төсле иде.

— Коля, минем түләргә акчам юк шул,— дип үкенеч тулы йөзе белән үзенең хуҗасына — Ипатовка томырылды. Хуҗага әлеге хәл бик тиз барып җитте, ул җилкәләрен селкетеп алды.

— Миндә дә юк, узган атнада гына өйгә перевод салдым... Сүзен тагын ышанычлы итәр өчен: — Их, кофтасы бигрәк шәп икән!— дип өстәде, телен шартлатып куйды.

Буханьконың көлемсерәгән битләре тагын да яктырып китте.

— Мин бүләк итәм, бүләккә акча алмыйлар,— дия-дия җинүле, канәгать кеткелдәде.

Ипатовның акчам юк дигән сүзләре Мәгарифне шаккатырды. Ул аның акчасы күп булуын белә иде. Чөнки Ипатов спекуляция белән шөгыльләнә. Польшада һәм чик буе станцияләрендә әйбер-кара бик очсыз. Ипатов шуларны чемодан тутырып ала да, безнен эчкәре ерак станция базарларында бермә-бер кыйбатка шудыра. Бервакыт Брест — Муховец күпере аша Перекоп станциясенә үттеләр. Безнекечә кин тимер юл шунда чаклы бара. Россиягә китәсе поезд составларын Пшендеш дигән веткада төзиләр... Урман эчендә бер таланып бетмәгән усадьбага тап булдылар. Ипатов йөзләп кул сәгате сирмәде. Мәгариф тә кесәләренә сәгатьләр тутырган иде. Ләкин үзебезнең якка чыккач, барысын да Ипатов талап алып бетерде. «Тебе не положено, — диде. Я за тебя отвечаю!» Менә нәрсә әйтә аласың. Татар булганга күрә шулай иткәндер инде. Мәгарифнең юашлыгы чыраена язылган инде. Өлкән брат кайда да үзенең өстенлеген күрсәтергә күнеккән... Ипатов хәзинә, акча тулы ике чемоданын тормоз будкасының тимер тартмасында яшереп тота. Ничек шуны Инна бер дә чамалый алмаган. Бигрәк беркатлы, тирән уй йөртә белми торган. Тормышның бары өске йөзеннән генә шуып йөрүче җилбәзәк зат икән...

Инна, бүләккә сөенеп, бик зур рәхмәт инде, бер дә көтмәгән идем, диде. Аннары хуҗасына ялварып карап:

— Семен, син дә рәхмәт әйт!— дип озын керфекләрен аңа текәде.

Ул Ипатов белән Буханько арасындагы киеренкелекне сизгән иде булса кирәк. Ләкин Ипатов Иннаның сүзен чынга алмады, бары битләрендә җыерчыклар хәрәкәтләнде, көлемсерәгән кебек итте, башын читкә борып, папирос кабызды.

Буханько да «Казбек» тартмасы чыгарды, бер хуш исле папирос алып капты. «Казбек» папиросын бай кешеләр генә тарта иде.

Торакка кайттылар. Урман буенда трофей вагоннардан кечкенә бер поселок сыман нәрсә төзелгән. Пассажир вагоннарын тәгәрмәчләреннән алып тезгәннәр. Аларга депо паровозларыннан җылы керткәннәр. Күперләр, юллар салуда эшләүчеләр шунда яшиләр икән. Күпчелек вагоннарда хатын-кызлар, кайберләрендә балалар да күзгә чалына иде.

Бүлмәләр, ишекләр юк. Һәр бүлемдә аслы-өсле дүрт кешелек урын. Плацкарт вагонындагы кебегрәк. Ипатов белән Инна бер бүлемгә урнаштылар. Урын иркен иде. Буханько белән Мәгариф икенче бүлемгә күчте. Мәгариф өске сәкегә үрмәләде.

Иртән Ипатов тавышына уянып китте. Инна Буханько кочагында ята иде. Төнлә Ипатовны йоклаткан да, Буханько янына кергән икән. Әнә чәчләре тузып, күлмәге сыерылып менгән дә, шәрә итләч ботларын ачкан. Ипатов бүлем бусагасында басып тора, тешен кысып, ачу белән ысылдый:

— Син, курва, дешевка, нәрсә эшлисен, ә?

Ул скандал чыгармаска итә сыман иде. Инна аның йомшак ягын чамалаган, ахрысы, мендәрдән башын күтәреп, торып утырды, чәчләрен төйнәштерә башлады. Ә Буханько аңа аркасы белән яткан, әллә ишетми, әллә юри кылана.

— Семен, син мине гафу ит, зинһар, ә?— диде Инна еламсыраган калтыраулы тавыш белән. — Шулай килеп чыкты. Нишләргә соң инде?..— Үзе зур йомарлам күкрәкләрен лифчигына тутыра. — Ирләр барысы да эт, талыйлар! Ничек каршы торыйм?!

Ул ачыргаланып еларга тотынды.

— Син сука, ашаган табагына кәк иттең!

— Юк, юк,— дип җылак чәрелдәде Инна. — Син мине ач паекта тоттың, берни бирмәдең. Үзең миннән көн дә ләззәт алдың. Син үтә саран адәм. Синең белән бер хатын да яши алмаячак!

Шунда Буханько уянды һәм боларга таба борылып утырды.

— Ипатов, син Иннага тимә, ул хәзер минеке!— диде бик тыныч, гүя хуҗаларча. — Инна, җылама! Ну! Ну!

— Ничек синеке? — Ипатов кычкырып җибәрүен сизми дә калды. Шунда тавышын әкренәйтте. — Син таптыңмы аны? Менә әзергә — бәзер, ә? Нинди ертлач! Инна!

— Кулыңда тотып тора алмадың, брат, үзең гаепле!

Буханько аякларын сәкедән салындырып утырды да төшә башлады. Әйтерсең лә берни дә булмаган, гүя ялгыш кына берсенең пилоткасын икенчесе кигән.

— Инна, минем яхшылыкларны аяк астында таптадыңмыни?

Ипатовның эшне зурга җибәрәсе килмәве йөзенә чыкты. Ул кимсетелгән кеше кыяфәтендә яны белән басып тора иде. Төсендә гаҗизлек һәм гаделсезлекне кичермәү чагыла. Мәгариф аны җәлләп, йөрәге сулкылдап куйды.

— Синнән бер яхшылык та күрмәдем,— диде Инна куркудан тыелып.

Ул турсайган, йомры бит очлары кызарган.

— Тьфү!— дип Ипатов усал итеп кулын селтәде. — Фахишә! Фахишә генә шулай иманыңнан ваз кичә! Тьфү!

— Ипатов, җитәр, карганма!

Буханько, күн итекләрен киеп, чәчен кечкенә тарак белән тарарга кереште. Ул үзен җинүчегә тиңли һәм скандалга катнашырга теләми. Үзен андый эштән өстен саный шикелле иде.

— Мин Иннаны паровозга кертмим, рейска алмыйм!

Ипатов китәргә итте, нигәдер үзен тыеп торды.

— Мин аны ашханәгә урнаштырам, тамагы да тук булыр.

Буханько Иннага чын хуҗа булган төстә әйтте, чәчен төзәткәч, тарагын ана сузды.

Инна чәчен тарый Ипатовка кырын карап, башын горур тотып:

— Бик исем китте синеңише саран бакага!— дия иде шикелле.

Ипатов таптанып торды да, сәндерәдәге Мәгарифкә ияк какты:

— Әйдә, киттек!

Мәгариф чалбар-гимнастеркасын кигән иде, аска сикерде дә, аягына кирзаларын эләктерде, яшел бушлатын, пилоткасын кулына тотып, машинист артыннан иярде. Алар станциягә штабка юнәлделәр. Бераздан борылып карады, Буханько белән Инна да чыкканнар. Сөйләшә-сөйләшә рельслар буйлап атлыйлар иде.

Мәгариф көтте: Ипатов бик нык тузынырга тиеш хәзер. Буханьконы напарник итеп алмавы ихтимал... Инна нигә алай эшләде икән? Теге кофта өчен Буханькога бурычын тәне белән түләргә теләгәнме? Юк, алай булмас төсле. Буханько Иннаны берәр ничек мәҗбүр иткән булуы бик мөмкин. Чөнки бу кеше бар төштә дә җинүчән ертлач, алга чыгарга омтылучан зат иде.

Өйлә вакытындарак рейска чыгарга боерык булды. Репатриатлар тикшерү аша уздырылып вагоннарга урнаштырылган. Хәзер вагоннарны бергә җыеп, эшелон төзергә һәм юлга чыгарга тиешле.

Тормоз будкасына эшелон төзүче тимер юл лейтенанты кереп басты. Нечкә, үткен, ничектер астан гына йөри торган сыбызгы тавышы белән паровозда идарә итә башлады.

Ипатов белән Буханько бер-берсенә тырпу торалар, сүз катмыйлар. Ипатов кына кирәкле кранны борырга, йә реверсны чигендерергә артыгы белән кычкырып Буханькога команда бирә иде. Поездны Калинковичи юнәлешенә бара торган юлга кертеп җибәрделәр.

Көзге төн тиз карангылана. Ярый әле аккумуляторлар яхшы эшли, көчле лампочкалар юлны яктыртып бара. Мәгариф үз эшен яхшы белә, кувалда белән күмер кантарлары вата, улакка тутыра. Буханько шуларны соскы көрәк белән чумырып алып топкага ыргыта. Башта ул, бу эш минем бурычка керми дип, мыгырданып маташкан иде. Бүген исә үзе бик теләп эшли, хәтта Мәгарифкә булыша, күмерне улакка тутыра иде. Бу ни хикмәт? Тизәген дә бизмәнгә салырга яратучан Буханькога ни булган? Ипатовтан бераз шүрли дисәң инде, бер дә охшамаган.

Офык буенча кызгылт тасмалар сузылып, яктыра башлаганда шыр ялан кырда яна төзелеп яткан бер станциядә мәҗбүри туктарга туры килде. Вагонда ике хатын үлгән иде. Санитарлар носилка белән мәетләрне вагоннан чыгардылар. Нишләтергә? Биредә куеп калдырыр җир юк. Юл эшендә эшләүче эшчеләрне уятырга, кабер казуларын үтенергә-ялварырга туры килде. Юлдан ерак түгел бер калкурак урынга аннан-моннан чокыр казыдылар. Икесен дә шул чокырга салдылар... Тормыш бик рәхимсез шул, берни дә кыла алмыйсың. Теге чик буе сортировочныенда кайбер хатыннар биләүдәге бәбиләрен калдырганнар иде, менә биредә кайсыларыдыр үзләре җир астына кереп калды. Гомер агышы белән бер бәндә дә ярыша алмый. Шуна күрә язмыш иркенә буйсына.

Яна төзелеп яки рәткә китерелеп ята торган кечкенә станцияләрдә дә тукталыш ясарга әйтелгән иде. Ник дисәң, бу хатын-кызлар 1941—42 елларда шушы тирәдәге авыллардан, поселок-шәһәрләрдән җыеп Германиягә эшкә куылганнар. Тукталыш саен төркем-төркем булып вагоннан коелалар. Өс киемнәре бик чуар. Кайсыларында немец солдатының зәңгәр френче, дагалы кыска кунычлы күн итек. Безнең солдатлар киеменнән булганнары да бар. Күбесе шаровар йә чалбар кигән. Чит илдә хатын-кызлар чалбар кия диләр. Шул модада, имеш. Билгеле, андый нәрсә юк, кем ни юнәткән, шуны кигән. Совет ягында аларга Америка җибәргән иске киемнәрне дә биргәннәр.

Хатын-кызлар вагоннан төшкәч, як-якларына сәерсенеп карап, үзләренең туган станцияләрен танырга тырышалар. Барча нәрсә җимерелгән, хәрабә хәлендә ята. Ваклынып беткән кирпеч өемнәре. Бер тимер юл тупигында янган паровозлар тезелеп калган — кызгылт-соры тутык белән капланганнар. Борынгы эре динозаврларның катып калган сыннары хәтергә килә. Бер егермеләп булыр. Бу тирәдә сугыш бик каты булгандыр, күрәсең.

Төрле вагоннардан хатын-кызлар кычкырышып иптәшләрен эзли. Ләкин аларга беркем җавап кайтармый. Ачы аваз һавада асылынып кала. Алда аларны ни көтә? Биредән автомат, этләр белән озаткан чакта алар яшь-яшь, яна гына дөньяга күзләрен ача башлаган садә, саф гүзәл затлар иде. Ут кебек тере, һәрберсендә йөз елга җитәрлек тормыш ялкыны дөрләп торган, дөньяны яңартучылар, баетучылар, яшәртүчеләр иде алар. Җанлы чәчәкләр... Йа, Хода! Өч-дүрт ел эчендә бу илаһи затлардан берни дә калмаган. Алар барысы да танымаслык булып үзгәргәннәр. Кырау суккан чәчәкләрдәй кара янып көйгән йөзле; бөкшәйгән, бетәшкән гәүдәләләр. Фашистлар аларның җилеген суырып бетергән. Ул кан эчкечләргә ни житмәде икән? Нинди сәбәпкә таянып, безнең илгә басып кергәннәр? Нинди хаклык дәгъвалап, чит җирне яулап алуны дөрес дип тапканнар. Шуна ышанганнар, бүтәннәрне ышандырганнар. Ышанычлары булмаса, бу тикле кан коя алмаслар иде алар.

Еш тукталып, «встречный»ларны көтеп-көтеп тора-тора бара торгач, шактый көннәр үтте. Калинковичига барып житә алмадык. Халык вагоннардан төшеп бетте.

***

Алдагы станциягә үтеп, анда хәрби җиһаз төягән эшелонны алып кире кайту ягына чыктык. Эшелон секретный иде, көндез туктап торабыз, карангы төшкәч кенә хәрәкәт итәргә рөхсәт бирәләр. Уңай ягы шунда, көндез будкада ашап-эчеп, йоклап алабыз. Кайчак бишәр-алтышар сәгать эләгә. Адәм баласы өчен йокы ризык кебек зарури... Алда шактый вакыт бар иде, шуңа Буханько чыгарган шешәдән бераз эчеп куйдылар. Ипатов аракы күрсә, тыелып кала алмый иде. Шул йомшаклыгы бар. Буханько моны сизеп алды һәм шул йомшак-салпы якка салам кыстыра. Сумкасында һаман шешә йөртә. Каян ала торгандыр? Кулда бер ярты 300 сум тора. Ул каяндыр чумырган булырга тиеш. Бик үткен, блатной кеше. Әнә ни принципиаль Ипатовны кулына алды. Шул аракы белән. Ипатов аракыны җинә алмас дәрәҗәгә җиткән икән. Хатын булып торган Инна Буханькога күчте. Ипатов берничә көн усалланып, өзгәләп ташлар дәрәҗәдә кара коелып йөрсә дә шул чакта да Буханьконың шешәсеннән баш тартырга көче җитмәде. Аракы шайтан түгел диген, алар арасындагы дошманлыкны йомшарткannaн-йомшарта бара иде. Менә бу юлы да эчеп алгач, кызып сөйләшә башладылар. Кайчак, менә хәзер сугышалар инде болар дип торасың. Юк, стаканга эчемлек салгач, Ипатовның батырлыгы шинә дә куя. Шулай да һаман Иннаны авызыннан төшерми.

— Чынын әйт әле, үзе хыянәт иттеме, әллә синең кысу аркасындамы?

Ипатов папиросын кабызып, күзләрен кыса төшеп, Буханькога сынап карап тора башлады. Буханько җайга җавап кайтармыйча, карашын читкә алып уйланып торды.

— Әгәр мин хәерче булсам, Инна минем кысуга карар иде микән? Ә? Ничек уйлыйсын?

Буханько туры карамады.

— Ну, хәйләкәр төлке үзең дә! Хатын сайлар байны, ир-ат сайлар сауны, дигәннәр борынгылар. Шул инде.

Ни исең китте, аяк асты тулы хатын-кыз бит.

— Юк, Инна бөтенләй башка,— диде Ипатов үкенүле-хыялый төстә. — Хатыннар күргәнем булды. Әмма мондый нәгыз татлыны очратканым юк иде. Туктале, ни сәбәпле син үз иптәшеннең хатынын тартып аласың, ә? Нинди интерес, ә? Холкың шундыймы? Иптәшеңне кимсетү сиңа рәхәтлек бирәме әллә?

— Семен Алексеевич, нинди кимсетү! Нинди сүз ул? Просто шулай килеп чыкты!

Буханько иптәшен кимсетү турында башына да килмәгән төстә аклана башлады.

— Миңа Инна кирәк түгел, пожалыста, үзеңә булыр!

—Юк, бу хыянәттән соң кирәк түгел,— диде Ипатов ышанычсыз гына.

— Алай димә, Семен Алексеевич, сиңа Инна бик ошый икән бит. Татлы дисең, димәк, син аны тән белән яратасың. Тән белән яратканны ир-ат алай ансат кына ташлый алмый. Үземнән әйтәм, син дә шундый зат күренәсең...

— Тән яратуы хәтәр, әйе,— дип ияген селкеде Ипатов. — Син сволочь бу нәрсәләрне каян беләсең, ә? Син бит миннән яшьрәк?

— Акыл яшьтә түгел, башта, Семен Алексеевич!

— Ул курва Иннаны инде ничә көн оныта алмый интегәм бит, Буханько, аңлыйсыңмы шуны, юкмы, ә?

— Бик нык аңлыйм, хәлеңә керәм.

— Иннаны миңа кайтарасыңмы, ә?

— Хыянәттән соң кирәк түгел дигән иден бит?
— Шайтан алсын, синең аста укасы коелмагандыр әле?
— Ләкин ул сиңа кайтыр микән, вәт мәсьәлә?
Буханько телен шартлатып куйды.
— Неужели син аны шул тикле әсир иттең инде?
— Юк, Инна үзе әсир булды. Синнән башка берәү дә кирәкмәс, диде.
— Вәт сука, ә?
— Юкка кайгырма, Семен Алексеевич, Иннадан йөз тапкыр әйбәтрәге, татлысы муеныңа килеп асылыныр, әйткән иде диярсең.

Буханькога сөйләү җиңел, ә Ипатов Иннаның татлылыгын, нәзакәтлелеген күңелендә яңартып иза чигә. Үзе дә аптырый: яшь чакта да аның җанын болай Инна кебек уеп алган хатын-кыз очрамады. Барысы да була иде дә, бернинди эз калдырмый бетә иде, була да югала. Ә менә Инна белән бетмәде, югалмады. Ни хикмәт бу? Юк, моны аңлатуы кыен. Мин нишли алам соң? Инна белән сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Ни үкенеч, мин әшәке сүзләр белән аның дәрәҗәсен төшердем, җанын кимсеттем. Этләр ана этне бер очракта да тешләмиләр икән. Нигә мин үземнең җаным теләгән зат өчен көрәшмәскә тиеш? Сизәм, миңа Иннадан башка бик авыр. Эчүгә салышып түбән тәгәрәвең бик ихтимал. Менә нәрсә куркыныч. Иннадан башка миңа перспектива юк. Бу аферист Буханькодан Иннаны тартып алырга, үземә каратырга кирәк. Буханько тотнаксыз, ышанычсыз адәм. Иннаны файдаланыр да, бер станциядә алдап калдырып китәр... Иннаны ничек ышандырырга?.. Карале, нинди оят бит, мин әллә тилердемме, Иннаның хыянәтен гафу итеп ятам! Үз бәямне төшерәм, горурлыгымны аның аяк астына салам. Ни булды соң? Мондый капкынга эләккәнем юк иде әле, шайтан алгыры...

Ипатов папиросын тәмләп суыра-суыра уйларының очына чыгып җитә алмады, паровозны әзерләргә сигнал булды.

Башта складтан күмер алдык. Буханько бик каударланып чапты. Алдан киндер капчыклар әзерләгән икән, күмер төяүче күрмәгәндә, шуларны шыплап тутырып, тендерга менгерде. Мәгариф аңа һаман булышты... Ягулык кайда да кирәк. Бигрәк тә урман булмаган шыр кырда утыручы станцияләрдә сораучылар күп була. Буханько ул күмерне йә аракыга алыштыра, йә акчага ычкындыра иде. Ипатов аның бу эшенә каршы төшеп караган иде дә — җиңелде. Буханько аның алдына мөлдерәп торган шешә чыгарып утырта. Һәм шуның белән Ипатов капитуляциягә бирелә.

Водокачкадан су алгач, юлга чыктылар. Күпме сәгатьләр баргач, алдагы разъездда «Стоп» сигналы булды. Германиягә продукт илтә торган поездга бандитлар һөҗүм иткән. Рельсларны сүтеп куеп, поездны туктатканнар, машинистларның берсен үтергәннәр. Он төягән вагоннарны запас веткага керткәннәр, шуннан машинага төяп алып киткәннәр. Әмма икенче машинага төягәндә милиция отделениесе килеп җиткән. Караңгы төндә тота алмаганнар ди... Шуны әйтергә кирәк, Беларусь җирендә бик күп бандалар чуала. Кайсыларын немецлар калдырган дип тә сөйлиләр. Ни әйтсәң дә дүрт ел оккупациядә булганнар. Совет властена каршы диверсия эшләре алып баралар. Аларның үзәге Польша урманнарында, ди. Союзга кушылырга теләмәүче, Белоруссия аерым мөстәкыйль дәүләт булсын дип дәгъва итүче бандалар да бар, имеш.

Разъездда байтак торылды. Монда кешеләр землянкаларда яшиләр. Юллар төзәтәләр, шитовой бараклар салып яталар. Кая карама — бар төштә дә землянкалар, бараклар.

Буханько әле анда, әле монда чапкынлый. Каяндыр кешеләрен табып, биш-алты капчык күмерен озатырга өлгерде. Ул бик тынгысыз кеше.

Нәрсә булса да эшләмичә, нәрсә булса да тапмыйча, юнәтмичә тора алмый. Сөйләшә дә белә, өләшә дә белә. Кайсын көйли, кайсын чөйли. Сатулаша башласа, отмый калмый.

Менә юлны бик тиз төзәтеп өлгерделәр. Чөнки һәрбер разъездда тимер юлчылар ротасы урнашкан. Аларны тревога белән кузгаталар. Бертуктаусыз эшләтәләр...

Без хәрби эшелонны Брест—Муховецта тапшырырга тиеш. Ул-бу булмаса, бүген кичке уңайга барып җитәрбез, мөгаен. Ләкин һәр разъезд саен берәр хәл чыкмый калмый. Менә япа-япан разъездга килеп тукталдык. «Встречный»ны көтәбез. Вокзал дигәне кечкенә такта йорт. Шуның тирәсендә кешеләр тыз-быз, ыгы-зыгы килә. Тегендәрәк ватылган танклар, машиналар өелеп ята. Аның тирәсендә кемнәрдер кайнаша. Безнең белән янәшә юлга алама киемле хатын-кызлар, скелет кебек ябык ирләр белән тулы вагоннар килеп туктады. Германиядән репатриантларны алып кайталар икән...

Буханько һәм мин паровоз көпчәкләренең буксаларын озын саплы чүкеч белән ачып май салып йөрибез. Паровозның икенче ягында эшне бетереп бу ягын карый башладык. Шулчак шаулаша-шаулаша берничә хатын-кыз һәм икенче вагоннан берничә егет безнең янга килеп басты. Буханькога таба елыштылар, иелеп-иелеп аңа карыйлар.

— Ни кирәк сезгә? — Буханько эшеннән туктап боларга карады. — Тартыргамы?

Ул кесәсеннән тәмәке пачкасы чыгара башлады. Бер чандыр яңаклы егет Буханьконың чыраена йөзе белән терәлә язып:

— Син Грибковмы?— дип сорап куйды.

Төркемдәге бер тар йөзле хатын:

— Грибков үзе, полиция начальнигы! Фашист прислужнигы!— дип чәрелдәде.

Буханько берни булмагандай ригаяле елмаеп маташты, тәмәке пачкасын егетләргә сузды.

— Мин Грибков түгел, ялгыштыгыз ахрысы. Әйе, була торган хәл,— дип бик тыныч кына үзенең маслёнкасы белән чүкечен җирдән алды да, читкә атлады. Шунда шау-шу купты:

— Син Грибков! Точно! Без ялгышмыйбыз!— дип кычкырдылар.

— Кырык икенче елда Ушан станциясендә безне Германиягә озаткан полиция начальнигы син идең. Аягым тубыктан киселгәч, мин синең янга приемга кердем. Син типкәләп чыгардың. Эшелоннан калдырмадың. Ничек мин ялгышыйм?

Какча егет бик сабыр һәм ышанычлы сөйли иде. Җыелган халык аның сүзләрендә хаклык барын чамалады. Тагын бер-ике хатын-кыз бик төгәл фактлар белән Буханьконың йөзенә бәрделәр.

— Юк, мин Грибков түгел,— диде Буханько һаман елмаеп. Куеныннан документлар чыгарып тегеләргә сузды. Анда язылганнарны теге какча кычкырып укыды һәм ничектер ышанычын югалта барган шикелле булды. Тавышы йомшады, бер Буханькога, бер военный билеттагы фотога карап-карап ала иде.

— Фамилиясен үзгәрткән,— дип мыгырданды какча.

— Оскорблять итмәгез!

Буханько усал итеп карады, документларын тегенәрдән йолкып алды да, чүкече белән маслёнкасына иелде. Аның болай да кызыл чырае җаны чыгардай булып бүртенгән иде. Шул мәлдә җир астыннан калыккан тимер юл милиционерлары килеп басты. Какча эшне аңлатып маташты. Милиционерлар Буханькога төбәлделәр.

— Ул саташа, иптәш лейтенант,— диде Буханько бу хәлгә бер әһәмият бирмәгән төстә. — Сез аның кыяфәтенә карагыз.

— Юк, синең фамилияң Грибков, точно!

Какчаның борын яфраклары селкенде, күзләрендә черек утыдай зәгыйфь чаткылар күренде. Лейтенант Буханьконың документын алды һәм үзе артыннан барырга кушты. Анарга какча, тагы берничә кеше иярде. Арырак карьер чокыры буенда өч товар вагоны тора иде. Аның икесе СИЗО, берсе милиция бүлеге икән.

Буханько озак тормады, ничектер гаепсезгә гаепләнгән кыяфәт белән әйләнеп кайтты. Ипатовның сораулы-шикле карашын күреп, дәшми кала алмады:

— Дистрофия, ычкынганнар....— диде ул бармагын чигәсендә бөтереп. — Түбәләре шуышкан...

Кузгалырга сигнал булды. Барыбыз да үз урыннарыбызга бастык. Ипатов парны күбрәк туплау өчен механизмнарны эшләтергә керешге. Егерме минуттан семафор ачылды, без разъездны калдырдык.

Брест—Муховецка житкәндә, сызылып кына таң атып килә иде. Биредә тагын тикшерәләр. Безне өченче юлга кертеп туктаттылар. Димәк, тиз генә җибәрмәячәкләр. Ачык платформадагы сакчылар да җиргә сикереп төшеп, чәй өчен кайнар су алырга йөгерделәр. Без вокзалга, диспетчерга кердек. Анда билгеләнгәч, ашханәгә киттек.

Будкага кайтып ял итәргә идәнгә сузылышып яттык. Ә Буханько:

— Мин хәзер киләм,— дип каядыр китеп барды.

Без йоклап торгач та, ул юк иде әле. Шул китүдән Буханьконы ай күрде, кояш алды. Кузгалыр вакыт житкәч, Ипатов комендантка бу хәлне хәбәр итте. Нинди кеше булып чыкты әлеге Буханько? Фамилиясен алыштыруы, полициядә немецларда хезмәт итүе әллә хакмы?

Эшелонны күпер аша киң юллы кечкенә разъездга хәтле алып килеп, исән-имин тапшырдык. Армеецлар андагы җиһазларны тар юллы платформаларга күчерә башладылар. Мостик куялар да тәгәрәтеп бик тиз урнаштыралар...

Без Польша жирендәге беренче разъезддан атлар төялгән эшелон алып китәргә тиеш. Немецлар безнең илдән талап алган малларны кире кайтарырга мәҗбүрләр. Кешедән тартып алынган әйберне иртәме-соңмы иясенә кире бирергә туры килә. Гамәли дөньяның бер язылмаган законы бу. Гөнаһлы, кырын эшләрең өчен кайчан да булса барыбер түлисең инде.

Атлар төялгән эшелон кич килеп житте. Унжиде вагон, һәр вагонда алты-сигез ат икән. Биш солдат — ат караучы, сержант — ветсанитар, ә лейтенант — ветврач икән. Алар артта бер жирдәрәк вагонга урнашканнар. Атлар бүген әзрәк ашатылган, эчертелгән. Эшелонны бер-ике тәүлек эчендә тиешле урынга илтеп житкерергә кирәк. Разъезд, станцияләрдә тукталу булмаска тиеш. Һәр төштә семафор ачык, яшел ут...

Атларны үзебезнең киң рельслы вагоннарга күчерергә тотындылар. Платформалар биек, жайлы, кечкенә мостик куялар да атларны алып чыгалар. Бу вагоннарга кертеп бәйлиләр...

Төн болытлы, караңгы иде. Ипатов белән будка идәненә черем итәргә яттык. Бик эссе булганга ишек ачык калды. Ат кешнәгән, конюхларның сүгенгән тавышларын тыңлый-тыңлый оеп киткәнбез... Бервакыт каты шартлау тавышына уянып киттем. Дөм караңгы, күзгә төртсәң дә бернәрсә күренми. Ишек ачыклыгында ут нурлары сызыла, арттан чатыр-чотыр аталар. Нәрсә бу? Идәндә мүкәләп капшанам, кулым Ипатовның башына тиде һәм бармакларымның ябышкак куе нәрсәгә юешләнгәнен тойдым. Аңа дәшәм, берниди өн юк. Ни эшләргә белмим. Шулчак якында гына автомат

уты күзне чагылдырды, аякларга ни беләндер суктылар һәм муен тамырын нидер яндырып алды сыман һәм анымны җуйганымны да белмәдем...

Иртән мине паровоз будкасыннан алып носилкага салганда аңыма килдем. Әйттеләр: эшелонга ниндидер бандитлар һөҗүм иткән. Ат караучылар, санитарларны үтереп, барча атларны алып киткәннәр. Польшада күп кенә банда төркемнәре чуала, алар Германиядән Россиягә юнәлүче байлык төягән эшелоннарны җибәрмиләр, ди...

Госпиталь. Сайкинны операция өстәленә сузып салдылар. Битенә марля кисәге яптылар. Шул марляга, борын турына, сестра яшел тамчылар тамыза... Мәгариф йоклап китте. Әллә нинди рәхәт йокы иде. Ниндидер төш күрәме? Менә теге Инна дигән түгәрәк битле хатын аңа хәйләле күз кыса. Нәрсәгә ишарә итә ул, Мәгариф һич төшенә алмый. Башның кай төшедер эшләми ахрысы, шуңа мин Иннаны аңлый алмыйм, дигән уй баш миендә чагылып уза. Шунда Ипатов әллә каян килеп чыга да Иннага бармак яный:

— Чамала, яшьләрне аздырма! Ут белән уйныйсың түгелме?— ди.

Каядыр юк була. Буханько күренә. Иннаның мул күкрәкләрен учына ала да:

— Ничә кило булыр болар?— дип, көлә дә көлә. — Юк, үзеңә кара, кайсыбыз сиңа ошый, шуны ал? Ипатовмы, минме? Сайла, оттырма. Миңа барыбер... Мин синең куеныңа теге авырудан куркып кердем. Ипатов сынаган... Сифилислы хатын-кыз күбәйде. Европадан алып кайталар... Менә сиңа культуралы Европа! Һәртөрле бозыклык шулардан...

Операция озакка сузылды... Бервакыт аның яңагына кемнеңдер йомшак учы ипле генә китереп сукты. Төш бүленде. Бер яңакка, икенче яңакка. Һаман кулы катылана, сугуы да көчлерәк була бара иде... Ниһаять, Мәгариф күзләрен ачты. Мөлаем елмаеп торган сестраны күрде.Ул да теге Инна кебек түгәрәк битле, мул күкрәкле, тулы тәнле иде... Аякларының икесенә дә тимер челтәр шин куеп марля белән чорнаганнар. Носилка белән палатага китереп бер караватка яткырдылар.

Бу авыр яралылар палатасы икән. Сигезләп яралы ята. Мәгариф белән янәшә караватта соңгы чиккә җиткән лейтенант — тавышы-тыны юк, сулыш алганы да сизелми. Ул байтактан һушына килә алмый икән. Аңы юк, ә йөрәге эшли. Һаман укол ясап торалар. Уколны да сизми. Белми. Ике яңагы да воронкаланып эчкә баткан. Борыны сөяккә генә калган, җансыз әйбер кебек тырпайган. Йомык күзләре маңгай чокырлары белән генә шәйләнә. Кара чокырлар кара күзлек кигән сыман тоела иде. Сестра укол ясый да яралының пульсын тикшереп утыра. Эмаль савыттагы шприцын алдына куеп, хәлен чамаламакчы була. Бик дикъкать биреп карый. Әйтерсең, бу лейтенантны терелтер өчен барысын да бирергә әзер кебек тәэсир кала. Сестра шыпырт кына Мәгарифкә әйтә: бу лейтенант Польшадагы бер тимер юл поселогының коменданты булган. Җирле халыкка күп игелекләр эшләгән. Аны хөрмәт иткәннәр. Ләкин кара эчле дошман затлар да табылган. Һаман да милли нигездә инде. Милләтчелек бик хәтәр нәрсә. Ул һич тә бетми. Милли хис тормышны боза торган мәкерле көч! Дөньяны явыз болгатып тора. Кешеләр арасына дошманлык тарата... Кыскасы, лейтенантка хаиннарча почмактан аталар...

Мәгарифнең колагы ишетми башлады. Хәле бик кискен генә начарланган иде. Шуны сестрага әйтергә кыюлыгы җитмәде, әллә бу чибәр алдында каушап калды инде, шайтан белсен. Башы чатнап-чатнап ярылырдай булып сызлый. Аяклар ут эчендә кисәү булып яналар шикелле. Кымшатыр хәл юк. Авыз эче кипкән, телне әйләндереп булмый. Борыннан чыккан сулыш тыны иреннәрне пешерә.

Ярты төн узгач, Мәгариф авыртуларга чыдый алмыйча, ыңгыраша башлады. Ул ыңгырашудан үзен күпме тыеп көчәнсә дә, хәзер чыдамы төкәнде. Шулай да сестраны дәшәргә оялды. Үлеп ята торган лейтенант белән чагыштырганда аның яралары ул хәтле баш китәрлек түгел бит. Шул сәбәпле сестрага ялынасы килмәде. Әллә егетлек горурлыгы жиңде инде, белмәссең. Чибәр кыз алдында әллә ничек каушап каласың, нигәдер оялта да. Оят авыртудан көчлерәк, ахрысы?

Аның ыңгырашуын ишетеп, сестра үзе килеп житте. Кулын тотып, пульсын санауга ул барысын да аңлады. Тән температурасы кырыкка житеп бара иде... Сестра тиз зиһенле, өлгер икән, шунда ук хәлне жиңеләйтә торган укол алып килеп, Мәгарифнең беләгенә кадады. Икенче беләгенә тагы шприц белән дару жибәрде. Аның кырына утырып торды. Морфий бирелгәннән соң барча яралылар бик рәхәтләнеп йоклыйлар иде. Мәгариф хәле жиңеләя башлавын колагы ишетүеннән, авыз эчендә теле әйләнүеннән сизде. Шунда хәле жиңеләйде, яралары кисеп сызламый башлады. Сихәт чагындагы халәткә кайткан сыман сизде. Шунда анарда үз янындагы кешеләр белән кызыксыну туды. Зиһене бераз ачылган шикелле булды. Ихтыярыннан тыш, сестрага рәхмәт әйтте, сораулар бирергә жөрьәт итте. Кыз бер дә авырынсынмыйча жавап бирә иде. Авыруның хәле аруланасын өчен, ул көчен дә, сүзен дә кызганмый. Үзен йөдәтеп, газаплап бетергән яралылардан бер дә туймаганы, бизмәгәне сизелеп тора иде. Моның өчен кеше түгел, әүлия булырга кирәк инде. Эчендә, жанында тирән миһербанлык сыйфатлары булмаса, болай сабыр, яралыларның мең төрле капризларына чыдап бетә алмас иде. Нииндидер тәмам гарык булганлык, бизелгәнлдек һәм шуннан килеп туа торган салкынлык, битарафлык кыяфәтенә чыкмый, беленми калмас иде. Юк, андый нәрсәнең төсмере дә сизелми. Ул Мәгарифне үз жаваплылыгына йөкләтелгән яңа бурыч, яңа төзәтү объекты итеп карый иде...

Исеме Надия, фамилиясе Шамкина икән. Мәгариф аның татар кызы булуын ничектер хисе белән тойган кебек булган иде. Ләкин бу хис баш миенә барып житмәде, шуңа аңын да биләмәде. Эчтә сүнеп калды. Фикер булып төйнәлмәде. Хәзер сиземләве дөрескә чыкканга сөенде Мәгариф һәм Надиянең бер дә жиксенмәвен чамалап, шыпырт тавыш белән сөйләшүен дәвам итте. Алар русча сөйләшәләр иде. Надия Казанда туган, руслар арасында үскән. Рус мәктәбендә укыган. Татарча начар белә, шулай да һәр сүзне аңлый, кайтарып әйтергә тартына. Шуңа сөйләшкәндә битләренә унайсызлану алсулыгы чыга. Русча гына жавап кайтара. Мәгариф татарча сөйли, ә Надия русча әйтә. Шулай татарча-русча аңлашалар. Мәгариф үзенең рядовойдан икәнен әйткәч, Надия ышанмыйча, аңа карап торды. Ялганламыймы? Якташ дип аңа ябышучылардан гарык булып беткән шикелле иде... Сүз шунда өзелде, Надияне икенче палатага чакырдылар.

Ул йоклап киткәнен сизмәде... Күпмедер вакыттан морфийның тәэсире бетте, яралары жанны телеп-телеп сызлый башлады. Әлек аңа гел чуан чыга иде, аның сулык-сулык килеп авыртуы әле һаман да онытылмый. Чуан тулганда шулай итә. Хәзер менә шул авырту янаргандай булды. Яра шешә, үлек жыя ахрысы дип уйлады ул. Моны врачлар яхшыга саный. Ягъни организм авыру белән актив көрәшә.

Янәшә караваттагы яралының да морфий тәэсире бетте, ахрысы, ул, уянып, ыңгыраша башлады. Каты яралы өлкән лейтенант. Өченче көн, уколдан соң, бер-ике минут сөйләшеп алганнар иде. Ике аягы да тездән өстә яраланган. Бот сөякләре чәрдәкләнгән. Ул гипста ята. Ябык яра. Эчтә нинди процесс барганын чамалау кыен. Ачык калган тубыклары зәңгәрләнә башлаган. Үлгән кешенеке кебек. Аякларымны сизмим ди ул аңына килгән

чакларда. Күп вакыт аңын җуеп ала. Нindидер яңа укол белән аны һушына китерәләр... Ул штрафной рота белән командалык иткән... Солдат каны командирларны бернигә дә өйрәтми, менә кайда трагедия дип сөйләнә ул... Үзең дә күп башларны харап иткәнсеңдер, мөгаен, диләр аңа палатадагы яралылар.... Өлкән лейтенантның ак мендәрдә яткан тубал чәчле башы калкып куя, ул терсәкләренә таянып, бу сүзләрне кем әйткәнен белергә тели. Аңа сынап карап тора, шикчел күзләрен як-якка күчереп, нидер әйтмәкче була. Терсәкләрен ычкындыра, башы мендәрне яньчеп эчкә чума. Юк, дип мыгырдый ул мендәр чокырыннан башын күтәрмичә, мин, киресенчә, солдатларны ничек тә сакларга тырыштым. Шуның өчен өстәге начальстводан эләгә иде. Званиене дә күтәрмәделәр. Орден да эләкмәде — сугышчыларны саклаган, барча операцияләрне төгәл исәпләп, аз югалтулар белән үтәп чыккан өчен. Ләкин яхшылыкны аңлыйлармыни? Яхшылык эшләмә, сине начар димәсләр, ди бит.

Бер биеклеккә һөҗүм иткәндә кискен хәл туды. Атакага барганда көтелмәгән җирдән немецлар ата башлады. Сугышчылар снаряд чокырларына төшеп сыендылар. Мин: «Алга!» дип приказ бирәм, кымшанмыйлар. Вакыт уза. Немец пулеметы тынган арада алга ыргылырга мөмкин. Юк, тыңламыйлар. Мин орденарецыма атакага күтәрелергә боердым. Ул куркып калды, боерыкны үтәүдән баш тартты. Мин аңа пистолет белән янап, приказны кабатладым. Ул миңа автоматын борып очередь бирде. Мин җиргә аудым. Ул үзен белештермәстән калкынган иде. Шул минутта аның чигәсенә немец пулясы килеп тиде. Ул да минем янга авып төште. Миңа башын борып карады да тынып калды. Болай әйбәт, тырыш егет иде. Кызу канлы булуы бер дә беленмәгән иде. Кискен минутта әнә бөтенләй икенче кешегә әйләнде дә куйды. Һәм адәм баласы хәлиткеч моментта үзгәрә, «нутросы» ачыла...

Тавышы йокылы иде һәм ул шунда ук тынды, озын-озын итеп борыны сызгырганы гына ишетелде.

Мәгарифнең хәле әйбәтләнә бара иде. Беренче перевязка моның шулай булуын күрсәтте. Канлы ярага ябышып каткан марляны кубарганда күзләреннән утлар очты. Әмма врачлар яраны күреп шатландылар. Яра тоташ сары үлек белән капланган иде. «Яхшы! Ну, молодец!»— диештеләр. Кичен температурасы күтәрелде, ләкин иртәнгә бетте диярлек. Температурасы төшкәч, тамагына да аш үтә башлады.

Әмма штрафной рота командирының хәле начарланганнан-начарлана бара иде. Ул хәзер бары морфий белән генә тора, уколның көче бетүгә, уяна да, кычкырырга тотына. Бирмичә торсалар, бик каты сүгенә. Начальникларны чакырта... Менә госпиталь начальнигы — зур, таза гәүдәле, тәэсирчән мәһабәт чырайлы кеше, аның караваты янында басып тора.

— Ике аякта да гангрена,— диде рота командиры кипкән иреннәрен ялый-ялый. Ул көч-хәл белән генә сүзләрен әйтә. — Нигә дәваламыйсыз, ә? Мать вашу!..

— Ничек алай әйтә аласыз? Сез нәрсә? Сезгә көн саен биш-алты укол ясала...

Яралының дәгъвасыннан, нахаклыгыннан начальникның йөзенә гаҗәпләнү, аптырау чалымнары чыга.

— Сез миңа кирәкле дарулар бирмисез, әйе. Нигә гангрена бер дә аруланурга бармый, ә?

— Гангренага каршы дару юк, шуңа берничә препарат кулланыла...

— Ә пенициллин нигә бирмисез?

— Ул дару гангренадан түгел, шуның өстенә ул юк та бездә. Китермиләр...

— Пенициллин сездә бар, беләм мин. Аны миңа бирергә сезгә рөхсәт итмиләр. Тәгәл шулай!

— Сез ни сөйлисез?

Начальникның киң җилкәләре җыерылды, йөзенә юмакайлык, ярарга тырышу төсмерләре чыкты. Йомшак кына елмая-елмая караватка якынрак килде. Яралы ниндидер яшерен дөреслекне ачып салган шикелле иде. Хәзер шуны ничек кире кагарга, яралыны ничек ышандырырга белмәү аның кыяфәтендә чагылып китте.

— Кем рөхсәт итмәгәнен дә беләм...

— Юк, юк, иптәш өлкән лейтенант, бу сез түгел, сезнең авыруыгыз сөйли. Безне беркем тыя алмый. Менә пенициллин вәгъдә итәләр. Ләкин, әйтәм бит, ул гангренага һич ярамый...

— Ярый, бик ярый, мин томана кеше түгел. Миңа пенициллин бирергә рөхсәт итмиләр. Мин НКВД начальнигына гариза язам... Мин иптәш Берия ведомостенда торучы кеше. Сез минем гомеремне ничек тә саклап калырга бурычлы...

Өлкән лейтенантның хәле бетте, ак мендәр өстендәге киң маңгайлы, тирән караңгы күз чокырлы башы бер якка янтайды. Йөзендә чиксез рәнҗү һәм каһәр уку җыерчыклары...

— Паникага бирелмәгез, өлкән лейтенант,— диде госпиталь начальнигы юмалаган тавыш белән. — Без сине терелтербез, китәргә ирек бирмәбез. Юк! Тыныч булыгыз! Без синең гомерең өчен җаваплы! Каушамагыз! Хәзер сиңа морфий бирерләр. Тынычланырсың!

Ул ишеккә таба борылды, яралы тагы нәрсәдер әйтер дип куркып, тиз-тиз атлап чыгып китте. Сестра килеп яралыга укол кадады. Өлкән лейтенант нидер әйтмәкче булган иде, теле көрмәкләнде, сүзен аңларлык түгел иде. Күзләре йомылды. Тирән күз чокырлары кечкенә генә ике кара өн сыман куркыныч булып тора иде.

Морфий тәэсире кимегәч, ул һушына кайта һәм ялварулы ыңгыраша:

— Товарищ Берия, не дай умереть! Дорогой Берия, дай мне лекарства! Я преданный партиец. Я сын партии! Лаврентий Павлович, не убивай меня! Не убивай... А-а-а-а!..

Берничә сестра йөгереп килеп җитте, ана тагы морфий уколы ясадылар. Штрафной командиры тынып калды. Мәгариф штрафнойның әйткәннәрен аңлап бетерми иде. Ни өчен НКВД начальникларына мөрәҗәгать итә? Дарулар шулар рөхсәтеннән тора микәнни?

Штрафниклар турында төрле гаҗәп хәлләр сөйлиләр иде. Имеш, бер яңгырлы караңгы төндә траншеяда сакта торучы егермеләп немецны суеп чыкканнар. Шул вакыйгадан соң немецлар алгы сызыкка штрафниклар килгәнен чамаласалар, сугышсыз-нисез позицияләрен ташлап китәләр икән. Булса да булыр, штрафниклар бик аяусызлар, бернидән курыкмыйлар: «Йә пан, йә пропал» принцибы белән сугышка керәләр, ди.

Берничә көннән штрафной командиры дөнья куйды. Морфийлы йокысыннан уянмады. НКВД аны үлем тырнагыннан йолырга әллә теләмәде, әллә нәрсә. Һәрбер үлем тирән сер инде. Адәм баласы үзенә боерганны үтәгән, хәзер аның кирәге беткән. Дөнья бу, ә яшәү кануннары рәхимшәфкать белми.

Тышта яңгыр коя. Җил белән тәрәзәгә бәреп ява башлады. Ярыклардан палатага юеш саф һава тулды. Сулыш алуы бераз җиңеләйгәндәй итте.

Мәгариф тәрәзәгә карап ята. Бу яклар үзенә бер төрле икән. Яңгыр калын, авыр булып ява. Өстән чиләк белән коеп торган кебек. Тиз генә туктамый. Белоруссия белән Польша чикләре диңгезгә якын, ди. Кыш та монда йомшак була икән.

Тәрәзә янындагы караватта ятучы яралының хәле начарланды. Хәер, ул сугышта яраланмаган, сугыш башында ук әсирлеккә эләккән. Концлагерьда фашист хирурглары аңарда төрле тәҗрибәләр ясаганнар. Һаман газаплап торганнар. Башта әз-әзләп венасыннан канын алганнар. Организм яңа канны күпме вакыт эшләп чыгара, алынганны нинди микъдарда тутыра. Ашау нормаль булганда организм элекке кадәр канны ничә көн тутыра? Ашау рационында май, углеводлар булмаганда кан ничек, күпме вакытта нормальләшә... Аннары арка миеннән пункция белән сыеклык алып каһәрләгәннәр. Шуңардан аның күз кабаклары ачылып ябылмый торган булып калган. Акылына зыян килгән. Күзләре имәнгеч. Киң шәрә маңгаена ике зур пыяла тәнкәләр ябыштырып куйган шикелле. Керфек, бәбәкләре селкенми, җансыз карый. Тәнендә карга чукырлык та ит-сут юк. Ашаганы йокмый. Аның авыруын белмиләр. Ул кибә дә кибә. Фәкать венасына кан җибәргәндә генә җан керә, аңына килә. Ләкин җибәргән канны организмда нәрсәдер бик тиз ашап бетерә икән. Ә госпитальгә яңа кан китермиләр. Сестралар да бирә алмыйлар. Алар кан бирә-бирә үзләре чиргә сабышып, какшап беткәннәр. Сугыш чорындагы энтузиазм сүнгән. Җиңү килгәч һәркем үзен, алдагы көнен исәпли башлаган...

Каяндыр юнәтеп аның венасына ике йөз илле грамм кан җибәрделәр. Авыру аңына килде, теле ачылды.

— Мине үзем белән бергә булган иптәшем сатты,— диде йомычкадай юка, сыек учы белән башын сыпыра-сыпыра. — Немецларга мине спортсмен дигән. Мине эксперимент ясарга калдырдылар, аны эшкә озаттылар. Адәм баласы алдакчы, икейөзле, шкурник... Әһ-һе...

Менә ничә көн инде госпитальгә кан китермиләр. Авыру төпчеккә генә калган шәм кебек, менә сүнәм, менә сүнәм дип тора. Ул берни таләп итми, үлеме белән килешкән. Ярдәм итмәсләрен дә белә. Зәгыйфьләнгәннән-зәгыйфьләнә. Авыру инде аңын җуеп ята... Ләкин янына килеп караучы да юк, барысы да өмет өзеп, кул селтәгәннәр. Әллә нинди билгесез авыру... Иртәнгә инде ул бөтенләй сүнеп калган иде. Чыраенда ниндидер балаларча канәгать елмаюга охшаган чалым катып калган. Газаплардан котылу, аны бүтән җәзалый алмауларына сөенү төсмере сизелә иде.

Яшь организм булгангадыр, Мәгарифнең яралары тиз төзәлә. Ул «судно», «утка» сорап ятарга бик кыенсына иде. Шул бәладән котылу әмәлен тәки тапты: тезләре белән йөрергә кереште. Тез башлары суелып чыкты, әмма хаҗәтенә үзе йөрде. Надия апа укол кадаганда терсәккә куя торган клеёнка тышлы мендәрчекләр табып китерде. Шуларны тез башларына беркетеп бәйләгән иде, аяк табаннарыннан бер дә ким түгел, тезләр белән дә йөреп була икән. Палатада караватлар кырыйларына тотынып та, болай да әйбәт хәрәкәтләнә башлады. Кемгә су, кемгә судно алып бирергә дә иренми...

Ярасы көннән-көн әйбәтләнә баруына һәм исән калуына эчтән генә куанып, ваемын бушайтып яши иде. Дөрес, теге төнге һәлакәт вакытында бәлагә эләккән Ипатовны еш исенә төшерә. Атыш тавышына уянып, караңгыда идән буйлап мүкәләгәндә аның кулы ябышкак сыеклык белән чыланган иде. Ул аның Ипатов башыннан аккан кан икәнен соңрак искәрде. Хәзер дә ул кан аның кулларында буялган килеш тора шикелле. Шунда үзе дә өнәмәстән, учларын бер-берсенә ышкып алгалый. Тизрәк кулны юасы килә башлый. Ипатов әйбәт кеше иде бит, сугыш тәмугыннан исән-имин чыгып, тыныч көннәрдә харап булды. Язмышның кискен борылышларын алдан бер дә чамалау мөмкин түгел.

Төзәлеп чыккач нишләргә булыр икән дип ул алдагы тормышы турында уйлана. Аяклары элеккеге кебек булырмы, юкмы, демобилизация чутына куярлармы? Әллә нестроевойга чыгарып армиядә калдырырлармы? Юк,

ана инвалидлык биреп, кайтарып җибәрерләр. Надия сүз уңаенда шулайрак сөйләнде. Синең кебекләргә инвалидлык бирәләр, ә инвалидның льготалары байтак. Хәзерге өзек вакытта бик кирәк ул ташламалар. Эшкә урнашырга, квартира алырга... Синең баш төртер җирең юк бит... Әлегесе бушка ашап-эчеп, бушка киенеп, хөкүмәт җилкәсендә яту. Бу хәл озакка бармас. Үз көнемне үзем күрә башларга кирәк булыр. Мена шул вакытта нәрсә эшләрмен? Биредә госпитальдән тыш тормыш ансат булып тоела. Ләкин бу алдаучан тойгы гына. Тормыш тәртәсенә бер җигелсән, тыпырчына алмыйсың, авыр йөкне җиңең өзелергә җитеп тартырга мәҗбүр буласың... Шулар хакында уйлаганда Мәгарифнең аркасы салкынаеп чымырдап куя, маңгаена бөрчек-бөрчек тирләр бәреп чыга. Армиядә командир нинди приказ бирсә, шуны үтисең, башка нәрсәләрдә эшең юк. Берни өчен җавап тотмыйсың. Отчёт бирмәү яшәүнең иң рәхәт вакыты. Ләкин рәхәт күпкә бармый. Хисап бирергә тормыш мәҗбүр итә. Чөнки эшләгән кырын эшләрең кире үзеңә кайта. Сине артыннан килеп тотып ала.

Поездга бандитлар һөҗүм итү вакыйгасы бәлки шуның белән йомылыр дип өметләнгән иде Мәгариф. Юк, кая сиңа! Аны бер дә күздән ычкындырмаганнар икән. Мәгарифне особый отделга чакырып керткәч, ул шуңа төшенгәндәй булды. Анда особисттан башка трибунал оперуполномоченные да бар иде. Ул кызыл кенәгәсен ачып, Мәгарифнең битенә терәлердәй итеп якын күтәрде. Мәгариф каушавыннан берни укый алмады. Фамилиясен ул үзе әйтте: Каймакчи Павел Платонович. Түгәрәк чырайлы, җиз чәчле, битләре бераз алсуланып тора, шуңа сары кашлары беленми дә диярлек иде. Әмма берни белгертми торган кыяфәтендә ниндидер үзенә тарта торган мәһабәтлек бар шикелле.

Каймакчи хәлне аңлатты. Бер эшелон ат урлануы (107 баш ат) болай гына үтә алмый. Бу гадәттән тыш хәлне трибунал тикшерә. Безнең армеецлар катнашкан эш. Ни сәбәпле шул хәл килеп чыккан? Билгеле, бер эш тә сәбәпсез булмый. Ни өчен нәкъ менә шул төнне эшелонга һөҗүм итәләр? Бүтән вакытта түгел? Бандитлар эшелонның Союзга җибәрелүен каян белгәннәр? Сообщниклары булуы бәхәссез. Кайда алар — Польша ягындамы, әллә безнең арадамы? Станциядәме? Дейспенгерскийда яшеренмәгәнме? Әллә паровоз машинистының яшерен элемтәләре булганмы? Ипатов барахольщик идеме әллә? Әйбер җыярга яраткандыр, мөгаен. Ә?

Аңа Ипатов турында белгәннәрен сөйләргә куштылар. Мәгарифнең русчасы сай, өзек-төтек иде. Шулай да үзе күргәннәрне әйтеп чыкты. Каймакчи чыгып китте дә, Надияне алып керде. Ул тәрҗемәче булды. Мәгариф татарча-русча Надиягә аңлата, Надия үз сүзләре белән тикшерүчегә төшендерә. Каймакчи Надиягә бик йомшак итеп эндәшә, алар танышлар — дуслар шикелле, бер-берсенә карап сүзсез нидер аңлашалар. Надиянең бит уртасында чокырчыклар пәйда була һәм Каймакчиның чыраена нур аттыра, тавышы тагын да ягымлылана иде.

Надия тәрҗемәсе аша берничә хәлгә ачыклык керткәч, Мәгарифне җибәрделәр. Каймакчи кисәтте: ачыклыйсы нәрсәләр күп, син уйлан, хәтереңә төшер, диде. Тагы очрашырга әзер бул...

Мәгарифне курку биләп алды. Шөбһәле уйлардан башы тубал булды. Минем ни гаебем бар икән? Шайтан алгыры!

Кичен Надияне стерильняда дежурга калдырдылар. Движок эшләми. Палаталарга кырыклы лампалар керттеләр. Ә стерильняда керогазларны худка җибәрергә туры килде. Бу арада тотмаганга керогазлар юньләп янмыйлар, төтенлиләр. Надия, аптырагач, Мәгарифне алып килде. Сүзгә, сөйләргә саләте булмаса да, кул белән эшләргә бик чөс ул. Ни тотса, шуны булдыра. Кайсын корымнан чистартты, кайсының насосын төзәтеп, май өстәп керогазларны

яндырып җибәрде. Надия алар өстенә кырыйлары сай гына бөкләнгән корыч поднослар куйды, стерильгә су салды һәм инструментларны кайната башлады. Берәр керогаз тәтенләсә, Мәгариф аны бик тиз төзәтә иде. Надия нурлы, мөлаем йөзе, тылсымлы ачык кыяфәте белән рәхмәтен белдерә. Рәхмәт белән тун тышлап булмый, Надия моны яхшы белә һәм бер почмакта яшереп кенә стаканга спирт салып бирә. Менә монысы инде бигрәк мач, спирт артыннан конфет кабып куйгач, Мәгариф кәефләнеп учы белән иреннәрен сөртеп ала. Рәхмәт әйтә. Күзләре елт-елт итә башлый. Эчтән сизә, теле чишелә, сөйләшәсе килә. Чөнки эчен авыр пошаман басты, җанын нидер тырнап тора иде. Трибунал дигән сүз үзе генә дә аның котын алды. Эчен кырган шул мәсьәлә хакында Надия белән сөйләшергә тели иде. Кызның якташ һәм милләттәш булуы мона хокук бирә дип уйлады ул. Сорау алганда Надия һаман Мәгарифне яклады. Әллә аңлап, әллә Надиянең холык-фигыле гаделлектә идеме? Холкы шундый икән, артында берниндн исәп-хисап юк. Ул Мәгарифне яралы булган өчен якларга тырышты шикелле.

— Нишләп бу вакыйганы трибунал тикшерә икән?— дип Мәгариф тезләренә басып торган җирдән капылт кына урындыкка менеп утырды, шин куеп марля белән бәйләгән тубыклары һавада асылынып торды. Надия пар бәреп торган корыч подностан пенцит белән инструментларны эмаль кастрүлгә бушатты. Икенчеләрен кайнатырга куеп, өстәл янына килеп утырды. Аның мул күкрәкләре өстәл өстенә салынгандай булды. Мәгариф шуларга күзе төшкәнгә уңайсызланып, карашын читкә алды. Кызның исә эчтән җавап эзләгәне йөзендәге шәүләләрдән сизелә иде. Ә Мәгариф үз фикерен тагы ачыклый төште:

— Трибунал политик гаепләләрне генә хөкем итә дип белә идем мин.

— Сугышта һәрбер хәл политика аша гына бәяләнә, минемчә,— диде Надия русча-татарча сүзләрне бергә кушып.

Мәгариф кызның сүзләрендә тәҗрибәлелек чалымын чамалады һәм ни әйтергә белми, фикерен җыеп торды.

— Минем ни гаебем булсын инде,— дип кулын селтәде.

Кызның ирен кырыйларында: нинди беркатлы кәбестә син дигән елмаю төсмере беленде.

— Һи-и,— диде бик ихлас булып,— гаепләргә теләсәләрме? Юктан да таш капчыкка кертеп утырталар...

Надия егетнең агарып киткәнлеген күрде, артык ихласланып куркыттым ахры дип уйлады. Егет, аның сызылып киткән матур килешле кашларына, алгарак чыгып торган кечкенәрәк калын иреннәренә нииндидер коткару көткәндәй карап каткан иде. Үзенең гаебен кайтарырга теләп, әллә болай җәлләп, Надия Мәгарифкә тагын спирт салып бирде. Егеткә кыюлык кергән кебек булды, ул башын турайтты.

— Юк, бер гаепсезгә батыра алмаслар,— дип учы белән һаваны ярып алды.

— Бик кайгырма әле, үзем сөйләшеп карармын,— диде Надия нииндидер власте бар кеше сыман. — Юкса сине бутап бетерерләр...

— Лейтенант Каймакчи әллә синең танышмы?

Мәгарифтә нииндидер өмет чаткысы сызылды.

—Яралангач, бездә төзәлеп чыкты. Мин карадым аны. Ул миңа бурычлы. Үзе шулай әйтә...

— Нинди кеше соң ул?

— Нинди дип, шартлар нинди булса, кеше шундый була инде, ә.

Надиянең матур кашлары мангаена сикереп менде, ул сер бирергә, ачылырга теләми, болай да артык беркатлыланып китүенә эчтән үзен битәрли сыман тоелды.

— Хәл-обстановка ничек кушса, шулай була, дисеңме?

Мәгарифне бу фикер бик кызыксындырды. Бу хакта еш уйлана иде. Хәл-обстановканы яхшы кеше яхшыга бора, начар кеше начарга бора.

— Бәлки,— диде Надия керфекләрен түбән төшереп. Егетнең текәлүен кире каккандай биек күкрәкләре өстеннән учын шудырып алды.

— Ә Каймакчи хәл-обстановканы унайга бора торганмы, кирегәме?

— Тик унайга гына хәл итәргә тырышучан.

Мәгарифнең эче кырудан туктаган кебек булды. Надиянең, үзем сөйләшеп карармын, дигән сүзе аңа көч өстәгәндәй итте.Ул керогазларга май өстәп, янә көйләп җибәргәч, Надия аңа палатага кайтып ятарга кушты.

Яткач та тиз генә йокы алмады. Трибуналның бик аяусыз хәтәр булуын һаман ишетеп тора ул. Аңа әләккән кеше котыла алмый диләр. Баш миендә уйларны кайната торгач, Надиянең үзем сөйләшеп карармын, дигән сүзе һәм шул сүздән эченә җылы керүе балалык һәм сай йөзүлек булып тоела башлады. Тагын эчендә корт җанланды, җанын кетер-кетер кимерергә тотынды. Нишли ала соң ул? Берни эшли алмый. Бары шул бер генә: җебеп төшмәскә, каты торырга кирәк.

Ә Надиянең дә борчу-хәсрәтләре баштан ашкан вакыты иде. Эш шунда, Надия лейтенант Каймакчи белән бик якынайган һәм бу якынаю тирәнгә киткән иде. Бу хәлне Надия абайламый да калды, башы, җаны рәхәт томан эчендә йөзде. Акылы гадәти эзеннән читкә тайпылган сыман иде. Ничек болай булды әле бу?

Яралы Каймакчи Надия карый торган палатада ята иде. Ул армия штабындагы трибунал оперуполномоченные икән. Бер җинаятьчедән сорау алганда, теге котырынып китеп, Каймакчига ташланган. Җиң эченә яшеренгән тимер кашык сабы белән муен тамырына китереп кадаган. Күп кан аккан, яра йокы артериясенә туры килгән. Хәле авыр иде. Врачлар, сестралар бар көчкә тырыштылар. Аның сәламәтлеген госпиталь начальнигы үзе күзәтеп торды. Температурасы нормага керде, кризис узып бара иде. Врачлар перевязочныйда яраны бәйләргә дип ачкач, аптырап калдылар. Яра өстендә бернинди үлек юк, ул шикле кызарып тора. Бу начар симптом иде. Врачлар сер белгертмәделәр, битләренә бәйләгән марля өстеннән күз чалымнары белән аңлаттылар. Болай яра төзәлүгә таба бара, дип оперуполномоченныйны тынычландырдылар да, яңа дарулар сөртеп бинтладылар. Яңа чит ил даруына өмет бар иде. Ләкин ул акланмады. Яралының температурасы күтәрелде, хәле начарланды. Яраны тагын ачтылар, тагын яңа дару куйдылар. Хәле җиңеләймәде. Ярада «заряжение»— сепсис процессы башланган. Моңа каршы кулланыла торган дару госпитальдә генә түгел, гомумән, юк иде. Баш врач хирург, сестраларны үз кабинетына җыйды. Чыраенда борчылу һәм курку да сизелә иде. Яралы бит тегенди-мондый гына зат түгел, трибунал әгъзасы. Чынында баш врач үзенә страховка булдыру өчен персоналны шаһит итәргә тели иде. Ул сак, һәр адымда страховка булдыра.

Киңәшә башладылар. Һәр врач-хирург үзенең тәҗрибәсеннән чыгып сүзен әйтте. Яңадан операция ясарга кирәк дип тәкъдим иттеләр. Яра эчендә инфекция калган булган, бөтен бәла шуңарда, имеш. Икенчеләре операция ясарга ярамый, диделәр, чөнки яра нерв җепселләренә бик якын. Йөздән бер миллиметрга ялгышсаң, «летальный нәтиҗә» булачак. Юк,бу эшкә беркем дә башын тыкмас.

Озак бәхәсләшә торгач, врачлар кан салып карарга дигән фикер ягына авыштылар. Баш врачның аксыл мәһабәт чырае сорыланды, калын кашлары җыерылып кырыс сызыклар белән карага коелды. Кан юклыгын беләсез, диде борын эченнән мыгырданып, базалар бетерелгән, бер тамчы да кан

китерелми. Ләкин яралының гомере өчен без җаваплы. Ул-бу булган очракта бездән сораячаклар. Йә, кайсыгыз 250 грамм кан бирә ала? Кемдә I группа? Мин бирә алам, минем бавырда яшерен цирроз... Ул калын кашлары астыннан врачларның чырайларын күзәтеп чыкты. Берсе дә юмартланырга ашыкмый иде. Кискен сызык алдында һәрберсе сәбәпләр артына поса. Сугыштан исән калгач, яшәү эгоизмы белән тулганнар. Иң хәтәр елларда без үз бурычыбызны намус белән үтәдек, әмма хәзер сәламәтлегебез белән тәвәккәлли алмыйбыз... Алда авыр, катлаулы тормыш көтә. Врач-хирургларның кыяфәт-чырайларына шул язылган иде. Гадәттә канны хатын-кызлар бирә иде. Ләкин бер-берсеннән уздырып зарланырга тотындылар. Баш врач башын тәрәзәгә таба борды. Үзләрен генә кайгыртучы эгоистлардан йөз чөергән кебек итте. Байтак уйланып торды. Бер врач та җаваплылык хисен күрсәтмәде. Дүрт ел буе үлем астында эшләп тәмам таш кешеләргә әйләнгәннәр. Чөнки барысы да шактый өлкән яшьтәгеләр. Таушалганнар, эчтән какшаганнар. Баш врач карашын сестра Надия Шамкинага юнәлтте. Ул болар арасында иң яше, тулы таза гәүдәле, янып торган чырайлы, тик йөрәге генә кайчак үзен сиздереп алгалый. Моны баш врач белә иде, шулай да соңгы өмет белән аңа карады.

— Кызым,— диде ул,— син ничек? Юк, мин сине мәҗбүр итмим. Һич тә. Әмма чарасыз хәл бит, ә?

Баш врачның кече күңел белән гозерләнеп дәшүеннән Надиянең бит очларына алсулык йөгерде. Ул тегеләр кебек икейөзләнә белми, сәбәп артына да посарга ояла. Ничек моңа каршы килеп булсын инде? Аның үзенең язмышы да хәзерге көндә баш врачтан тора бит. Надиягә медицина өлкән сержанты званиесе бирергә тиешләр иде. Звание өчен түгел, баш врач сүзен аяк астына салмас өчен ул кан бирергә риза булды.

Барысы да иркен сулап куйды, жилкәләреннән бурыч төште.Алар аласы йөкне фидакарь сестра үз жилкәсенә алды. Кешеләр менә кискен хәл өстендә сынала. Кайбер врачларның чырайлары яктырды. Шулай булмый ни, моментны оттылар бит. Ә Надия алар уенда оттыручы булып теркәлде... Әмма Надиянең башына андый уйлар килмәде, ул кемнедер коткарып калу һәм шуңа үзеннән өлеш кертүе белән горурлану белән тулган иде.

Операция ясый торган бүлмәдә аның венасыннан 250 грамм кан алдылар. Бераз күз аллары караңгыланып торды. Баш врач аңа берничә плитка шоколад бирде, кайнар чәй китертте. Шулар белән ризыклангач, Надиягә хәл керде. Аңа өч көн ял бирделәр. Ул квартирына кайтып китте...

Шул сәгатьтә үк аның канын Каймакчига салдылар...

Ял көннәре туры килеп, Надия эшкә атнага якын торгач кына чыкты. Билгеле, килү белән Каймакчиның хәлен белеште. Баш врач үзе очрады:

— Кызым, чын күңелдән рәхмәт сиңа,— диде, ничектер бүләк тапшыргандагы кебек тантаналы төстә,— оперуполномоченный лейтенантның хәле әйбәт якка үзгәрде. Тьфү, тьфү, күз тимәсен! Моның өчен сиңа награда булмый калмас!..— диде дә, ашыга-ашыга узып китте.

Баш врач һәркемгә яхшы булып күренергә тырыша торган кеше иде. Теле белән сине эретергә мөмкин. Әмма синең файдаң тиярлек булмаса, синең өчен бармагын да кыймылдатмаячак. Хәзер ул үзе өчен куркыныч беткәнгә сөенгән инде, ләкин шул халәтен бик нык яшерә. Һәр җайны тота, һәр элмәктән бер төк калдырмый ычкынырга маһир. Әгәр персоналдан берәрсе бәла-казага тарыса да, ул ярдәмгә ашыкмый. Моның күләгәсе миңа төшүе мөмкин дип, бик әдәпле, ихтирамлы рәвештә читкә тайпыла.

Госпиталь Смоленск янында торганда Надия палатасында бер лейтенант яраларын төзәтте. Сестраны бик ошатты ул. Эчеп алган чакларында Надияне бер почмакка кысрыклап үзенең тойгыларын белгертергә тотына. Терелеп

чыккач, алгы сызыкка озатылганчы, частный квартирада яши. Һәр көн Надияне сменадан каршы алырга килә, фатирына озата. Күп тә үтми, китәр вакыты җитә. Һәр көнне эчкән була иде. Сүз арасында: «Надия, мине сугышта барыбер үтерәләр, бәхил бул, адресны беләсең, сенелгә хат яз, яме!»— дип монсуланып сөйләнә. Надия аны чынлап җәлли иде. Иртәгә китәсе көнне бик нык эчкән килеш Надияне фатирына алып кайтып гасыйпларга тотынды. Тәмам котырган иде. Надия бар көченә каршы торды. Үкерә-үкерә елады, ялварды. Аякларын кочаклап үтенде, гозерләнде. Кычкыргалап куйды. Нык акырырга, буза куптарырга оялды. Лейтенант бик көчле иде, ике кулын бергә китереп тотты, теше белән киемнәрен ертып, аерып бетерде. Бүредәй кызга ташланды, ерткычтай кыҗрап теләгәнен алды...

Надия канлы яшь коя-коя баш врач каршына килде. Лейтенантның бу эшен фаш итүне үтенде... Баш врачның йөзендә мөлаемлык, хәленә керү нурлары чыкты, ә күзләре як-якка тиз-тиз йөренә иде. «И-и, кызым,— диде төче тавыш белән,— сез бит дуслар идегез, ә? Сезнең дуслар булуыгыз бөтен кешегә мәгълүм. Лейтенант мине көчләде дисәң дә ышанмаячаклар. Чөнки дуслар арасында андый хәлләр нормаль күренеш... Бу хакта син чәчелеп йөрмә, бары үзеңне генә хурлыкка калдырырсың»...

Баш врач озак үгетләде. Бу хәл тегендә ишетелсә, анарга да начар булачак иде. Ә баш врач үз хуҗалыгын «шито-крыто» итеп тотарга ярата. Ул Надияне «сознательностена» тукынды: ул ут эченә бара, Ватан өчен шунда гомерен куя. Ять-яшь көе... Ә син шундый ерунда белән дәгъва кубарасың. «Совестно» түгелме? Бер якта кешенең барча яшәлмәгән гомере, икенче якта синең шушы бәлаң. Менә икесен үлчәүгә салып кара. Әгәр намусың бетмәгән булса... Әйе, бу зур кабахәтлек, мораль бозыклык. Армиядә ул булмаска тиеш. Без фашистлар түгел. Әйе! Ләкин семья гарипсез булмый. Бу гарип күренеш... Нишлисең, сугыш! Сугыш һәркемнең нәрсәсен булса да тартып ала. Берәү гомерен югалта, кемдер честеннән мәхрүм кала... Ләкин мондый эш болай гына үтми, лейтенант җәза алачак! Бу мәсьәләдә закон каты...

Шулай теле белән сыйпап, юмалап һәм куркытып чыгарып җибәрде. Ә бер бүлмәдә яшәүче хатын-кыз врач Мария Аркадьевна, аны юатам дип, ярасына тоз сибә. Биредә хатын-кыз заты кагылгысыз булып кала алмый. Физически мөмкин түгел. Аны ир-ат халкы барыбер сындыра. Яхшылык беләнме, көч беләнме, алтын тау вәгъдә итепме, мең төрле хәйлә-мәкер кулланыпмы, ир-ар үзенекен алмый калмый. Әмма табигать хатын-кызны бик көчле һәм яшәүчән итеп яраткан. Агачны сындырып, тәмам ботарлап бетерәләр, әмма ул тагын яшәрә, яшелләнә, үсә. Хатын-кыз да шулай, сындырылса да ялгана, элекке хәленә кайта. Берни булмаган кебек яшәреп, чәчәк атып яши башлый. Нәрсә югалттың син? Уза торган чагың туры килмәгән, анысы бер бәхет. Авырга узсаң да баш китәрлек эш түгел. Күпме андыйлар. Дөнья тулы. Башта без узмасыннар өчен хатыннарга укол бирә идек. Кайбер хатын-кызлар уколдан качып, кемнән булса да авырга узалар. Авырга уздымы, тылга озаталар. Кайберәүләр шулай сугышка якын җирдән тизрәк таялар иде.

Син яралыларны артык җәлләгәнсең, артык простойлангансың. Галилегеңне, йомшаклыгыңны күрсәтеп, моны «алып була» дигән өмет уяткансың, шулай үзеңне үзең тоттыргансың. Әйе! Менә аң бул, артык галиләнергә, үзеңне аяк астына салырга ярамый. Яралыны җәлләп йомшама, ачылып елмайма. Җитди һәм кырыс, гадел бул. Шул чагында абруең да югары булыр, сиңа кул салырга дип күзләрең майландырмаслар...

Лейтенант Каймакчи тәмам терелеп чыккач Надия артыннан йөри

башлады... Надия, син мине үлемнән алып калдың, мин сиңа чиксез бурычлы, дия-дия, үзенең тойгы-хисләрен белгертә. Купшы сүзләр күп сөйләми, аңа төрле бүләкләр ташый. Иң кәттә француз хушбуйлары, бизәнү әйберләре, шоколад-мармеладлар. Надия башта бүләк-күчтәнәчләрне авырыксынып кабул иткәләде, ләкин күпкә китә башлагач, туктады. Чөнки бу хәл үзенне Каймакчига бурычлы итүгә китерә дип уйлады. Аз-азлап аның иркенә бирелә бару кебек мин-минлегенә тия иде. Каймакчи гажәпләнде, мин ихлас күңелдән генә бит, диде. Миңа синнән берни дә кирәкми...

Аның тавышы кимсенүле чыкты. Матур мөлаем чыраенда нindидер эчке канәгатьсезлек шәүләләре йөрде... Надия сүзне икенчегә борып алып китте. Воронеждан эвакуация вакытында Каймакчиның хатыны һәм кечкенә кызы калуын белә иде. Каймакчи күптәннән инде шуларны эзләтә.

— Ну, ничек соң, дип сорады Надия, — туннельнең ары башында әзрәк яктылык беленмиме?..

— Дүрт-биш җирдән җавап килде, берсендә дә өмет юк, — дип Каймакчи тирән сулады. Кара замш пальто өстеннән кигән соргылт партупеялары шыгырдады, целлулоид ак якасы имән муенына батып керде.

— Тагын нишләргә уйлыйсың?

Надия бу сүз авызыннан чыкканга сискәнеп китте. Чөнки Каймакчи аны икенче төрле аңлавы мөмкин иде. Әмма ул берни сизмәде шикелле.

— Өметне өзмәсәң, һаман нәрсәгәдер ышанып көтәсең...

— Аңлыйм, ышаныч булмаса да күңел көтә...

Надия үзенең эчке фикерен яшерер өчен сүзне урау юлга алып керергә тырыша иде. Чөнки бу чибәр, юаш чырайлы лейтенант аның зиһенен чуалтты, әллә кайчан томаланып торган хисләрен кузгатты. Ниятләрен алга чыгарды. Сугыш бетте, хәзер барысы башка эзгә күчәчәк. Ирексездән алдагы тормышын турында уйландыра. Нәрсә булыр, тагынниләр кичерергә язгандыр. Шик-шөбһә тулы пошаман һаман эчтән тырнап тора иде. Күңел ихтыярдан тыш үзенә нindидер иш, терәк эзли. Барыбер үз оянны кормыйча булмас ахрысы. Менә лейтенант аны ошата бугай. Әмма белеп булмый. Яшь организмның үзенә капма-каршы җенескә тартылуы гынамы, әллә ихлас хисләр дулкынымы? Мария Аркадьевна аңа акыл биреп кенә тора, ошаган кешене генә түгел, үзенне яраткан кешене эзлә. Син яраткан кеше сине яратмавы ихтимал. Аңлыйсыңмы, сине яратмаган кешегә чыгуның ничек буласын?.. Башта яратмасаң да, тора-бара яратып китәсең, диләр бит, дип каршы төшә Надия. Юк, ди тәҗрибәле Мария Аркадьевна, башта ук яратмасаң бары хәлгә ияләшү генә була...

— Бу расположениедә әле торасызмы?— Надия беләсе килгән нәрсәсенә якынаерга исәпләп, сүзне тагын урау юлга кертмәкче булды.

— Әле ул-бу ишетелми, кем белсен...

Каймакчиның интонациясе ышанычлы түгел сыман иде, ул нидер белә, ләкин төенне чишми дип уйлады Надия.

— Шулай да тыныч тормыш турында исәп йөртәсездер, ә?

— Армиядән китәргә ният юк болай.

— Ә демобилизацияләсәләр?

— Ул чакта эш катлаулана...

Каймакчиның партупеялары тагын шыгырдап куйды. Надия анардан: ә син алга таба нишләргә җыенасың, дигән кызыксыну ишетергә теләгән иде. Ләкин андый өметле сүз чыкмады. Димәк, хатыны һәм кызы табылуына ышана. Шуңа исәп тотмый. Перспективада мин юк. Мин вакытлы күңел юаткыч, уенчык кына... Шулай дип егеткә булган хисләре башына суккандай итә.

Әңгәмә корып биләмдә йөрүләр байтак булды. Ләкин барысы да дуслык

чикләреннән узмый иде. Аннары һич көтмәгәндә паровоз кочегары Сайкин эше килеп чыкты. Сорау алганда Каймакчи үзенә ярдәмгә Надияне дә чакыра. Бергә-бергә закон статьясы куйган сорауларга җавап әвәлиләр. Чөнки дәлилле протокол таләп итела. Формальлекне үтәмичә һич мөмкин түгел. Формальлелек икенче яктан караганда гаделлек ул. Ә Каймакчи кечкенә нәрсәгә дә зур җаваплылык белән карый. Бу карьерага хилафлык китермәскә тырышу гына түгел, ә һәр эшне җиренә җиткереп, пөхтә итеп эшләргә күнеккәнлектән булса кирәк.

Төрле мәкерле, адаштыра, бутый торган сораулар биреп интектереп бетергәч, Сайкинга палатага кайтырга кушалар. Сайкин тезләре белән идәнне кыштырдатып ава-түнә атлый. Особый отдел сержанты да чыгып китә. Икәү генә калгач, Надия үзенең Сайкинга булган хәерхаһлыгын белгертә, эчендәге гуманлыгы алга чыга. Сайкинның гаебе юк шикелле күренә ана. Каймакчи ручка белән шытыр-шытыр язудан туктый, шәмәхә карага буялган бармак битләрен сөрткәли. Сабыр гына аңлата. Надия аның сабыр-тигез холыклы булуына соклана иде.

— Бу зур, четерекле эш,— дип сөйли, чыраена ягымлылык нуры чыга. — Надия янында ул һәрчак яктырып китә. — Өстәгеләр кызыксына. Бу диверсияне поляклар Советларга каршы эшләгәнме? Әллә бу бер бандит төркеменең үз мәнфәгатьләре өчен поездны талавы гынамы?

— Поляклар безне ни өчен өнәмиләр соң?

— Аның тамыры тирән, безгә мәгълүм түгел.

— Сайкинны нишләтергә уйлыйлар?

— Тикшерәбез, ни килеп чыгар инде?

— Син аны батыру ягында түгел шикелле?

— Дөрес сизәсең, Надия, мин аны ничек тә якларга тырышам. Ләкин минем дә начальнигым бар. Аңа отчёт бирергә кирәк. Әйтәләр, әгәр йокламаган булсалар, шау-шу кузгалу белән поездны алып китәргә мөмкин булган, диләр.

— Иң элек паровоз будкасына атканнар бит. Сайкин бүген шулай диде.

— Әйе, әнә шул версиясендә нык торсын, син аның колагына киерт. Гел бер үк сүзләрне кабатласын. Юкса үзен дә, безне дә бутый. Юкса постта йоклаганнар дип бәйләнәләр. Нишләргә соң?

—Яралануына сылтарга, саллы аргумент бит?

— Мин шуны дәлиллим, исбатлыйм да. Юкса Сайкинны монда тотмаслар иде. Дезертирлык «тегеп»...

Каймакчиның бу яхшылыгына Надия ихлас сөенә, аңа чын рәхмәтләр белән елмая-елмая, эшенә ашыгып чыгып китә. Каймакчи протоколын кабат карап чыга, төзәтә, начальникка күрсәтерлек дәрәҗәгә китерә. Кәгазьләрен сары портфеленә сала да кайтырга кузгала.

Ә Надиянең кичке сменасы бетүгә госпитальгә килеп җитә ул. Кызны фатирына чаклы озата бара. Караңгы урамнардан атлыйлар. Бу ничектер җимерелми калган тимер юл поселогы. Биредә немецларның зур госпитале булган. Ашыгыч чигенгәндә барча җиһазлары белән диярлек калдырып сызганнар. Урман буенча озын-озын бараклар. Анда пересыльный пункт булган. Немецлар пычракны яратмыйлар. Юлга вак гравий таш җәйгәннәр. Баскан саен шыгырдап аяк тавышы әллә каян ишетелә иде.

Сайкиннан бергә сорау алулар, үзеннән-үзе килеп чыккан аралашулар Надия белән Каймакчины бер-берсенә һаман якынайта иде. Алар бер-берсенең холык-фигылен, кайбер гореф-гадәтләрен белделәр. Бу хәл исә яшьләрне бер-берсенә бәйли барды. Шул ук вакытта терелеп килгән Сайкин да Надиягә битараф түгел. Кечерәк-кечерәк җиз самоварлар шикелле

керогазларны һаман төзәтеп тотарга кирәк. Надия завхоз старшинага ялынмый, Сайкинны гына жигә. Чөнки Сайкин бу эшкә үзе атлыгып тора, бу эшләрне башкарсам миңа жинеллек килер, гаебемне ярлыкарлар дигән бик беркатлы уй белән тырыша ул. Керогазларны рәтләп бетергәч, өстәлгә беләкләре белән таянып, Надиянең эшләгәнен карап, хәрәкәтләренә сокланып утыра. Спирт салган микстураны бармаклары белән тотканда кулы калтырап китә. Надия күреп ала да мөлаемланып әйтә:

— Әллә син эчәргә өйрәнеп киттен инде?

— Юк,— ди Мәгариф тавышсыз көлеп. — Син биргәнгә күрә генә, юкса авызга ала торган нәрсәм түгел...

Уңайсызланудан аның янак аслары кызара.

Икесе бергә нindидер канәгатьлек белән көлеп алалар. Сайкин киткәч, Надия уйлана: нинди чибәр егет, йөз, бит, кыяфәте белән ничектер Каймакчига охшаш. Икесенең чырайларында хәерхаһлар нуры бар. Татарлар моны иман нуры диләр. Юк, бу Сайкин үз хатынына беткәнче тугрылыклы ир булачак. Кай жире беләндер әнисенең кече энесенә охшаган... Тугрылыклы ир... Кызлар танышканда моны да исәптә тоталар, ди. Егет минем эчкә үтәрлек итеп карый, нәрсәгәдер өмет итә инде. Якташ та булгач. Микстураны авызына чемкәйтеп куйгач, аңа әз генә кыюлык керә. Мәгънәсез сүзләр ычкындыра. Мәгънәсезлеген соңыннан аңлап хәтәр уңайсызлана ул. Ә эчмәгәндә авызыннан бер сүз чыкмый. Бары калын иреннәрен жәеп елмая да елмая.

Бер көнне Каймакчи Надиягә зур гына картон тартма калдырып киткән. Өйдә Мария Аркадьевна үзенең йөргән кешесе белән генә иде. Надия кайтуга майор чыгып китте.

— Әллә комачауладыммы?

Надия шинелен сала-сала Мариягә карады.

— Юк, юк. Безнең эш беткән иде инде,— диде Мария озын чуар халатының чабуларын эләктерә-эләктерә. Надия өй киемнәрен киде һәм картон тартманы өстәлгә куеп, бәйләгән жепләрен пычак белән кисте. Эчен ачып, Мария белән бүләкләрне ала башладылар. Барысы да трофейный хатын-кыз әйберләре. Шомырт чәчәгедәй ак челтәрләрдән берничә бюстгалтер; ак, зәңгәр, кара ефәк комбинацияләр. Тагын, бик күп, бик затлы, хатын-кыз өчен алыштыргысыз көн дә кирәк нәрсәләр... Аста тагын кечерәк тартма килеп чыкты. Монысы америка халкы бүләге иде. Тышына язылган: «Героическому русскому народу!» Анда ике махровый сөлге, әллә ничә төрле конфетлар. Кәтүкләр-жепләр, энәләр, челтәр бәйли торганнарына кадәр тутырганнар. Майор Мариягә дә америка бүләге алып килгән икән. Тиз генә плитәдә чәй кайнатып алдылар да, кучтәнәчләр белән чәй эчәргә утырдылар.

— Кочагыңа зондаж ясый, ахры, лейтенант Каймакчи, ә?

Мария конфетларны кырт-кырт китерә, чәен чөмерә.

— Менә аңа,— дип йодрыгын өскә селтәп куйды Надия.

— Алай итмә,— диде Мария. — Бәлки исәбе житдидер?

— Синең майорыңның исәбе ничек соң?

— Аның семьясы бар. Мине канаты астында тота. Юкса, ир-ат атакасыннан кая керергә белмисең.

— Яратамы?

— Син инде бигрәк, үзең дә беләсең, ир-атка хатын-кызның тәне генә кирәк. Жаның ни — аның анда эше юк. Табигать шулай яраткан инде, берни эшли алмыйсың.

— Ир-атта үрчетү инстинкты бик көчле инде.

— Ә хатын-кыз репродуктор, ягъни үрчүче, яңаны тудыручы...

— Бу бүләкне ни белән бәхилләрмен, менә шул эчне тырный,— дип куйды Надия.

— Һи-и, исен китмәсен лә, ирләр хатын-кызларга бүләк бирәләр инде ул. Электән килгән...

— Юк, шулай да унайсыз...

Әллә син неврастеникмы, ә? Неврастениклар шулай үзләрен юк нәрсә өчен дә бурычлы саныйлар...

Ә Каймакчи һаман бүләкләр китерә. Надиянең бик нык каршы торуын белә һәм ул өйдә юкта калдырып китә иде.

Надиягә медицина өлкән сержанты званиесе бирделәр һәм кадровый итеп калдырдылар. Шул унайдан Каймакчи юка, йон английский материядән тегелгән гимнастерка, юбка калдырып киткән иде. Киеп карамый чыдый алмады. Үзенә үлчәп теккәннәрмени, ятып, килешеп тора. Балтыры кунычына сыймаганга, тәбәнәк үкчәле туфли киеп йөри. Синең аяк тавышынны әллә кайдан таныйбыз, диләр яралылар.

Каймакчи тагын көрән берет, көрән замж куртка бүләк итте. Надия нишләргә белмәде, бик нык борчылды. Ул һәрчак үзен берәрсенә бурычлы итүдән курка иде. Әллә ул чынлап та неврастеник микән? Каймакчи мине бирелергә кысса нишләрмен, ничек баш тартырмын? Күпме бүләк алганнан соң, ә?

Шул хакта Мария белән сөйләште.

— Һай, алла,— диде Мария бер дә хафаланмыйча. — Исең киткән икән, бирел. Югалып калма. Уйнамаган кеше отмый.

— Язылышмыйчамы?! Юк, мөмкин түгел!

— Бергә булырга нияте бардыр бәлки?

— Әйтеп бетерми. Семьясы оккупациядә югалган. Ул кеше күнелемә бик ошый, мин аны яратып киттем ахрысы. Һаман аның турында гына уйлыйм.

— Алайса, кочагына кертми булдыра алмассың.

— Куркам шул... Авырга узып куйсаң?.. Тьфу, тьфу!

— Мин сиңа ничек сакланырга кирәген өйрәттем бит. Ни югалтасың син?..

Мария, рус кешесе, бу мәсьәләгә аек, реалистик карый. Молодец ул. Үзе әйтмешли, тиешлесен алмыйча калдырмас. Ә Надия ана телен начар белсә дә, татар рухы белән тәрбияләнгән. Андый эшләргә җиңел генә бара алмый. Аны эчтән нидер тота. Эчке киртәләрне атлап чыгарга кыймый. Шуның аркасында күп кенә җәй-рәхәттән мәхрүм кала иде. Бу халәтне ул аңлый, ләкин үзен берни эшләтә алмый изалана, борчыла. Һәр адым аңа авыр бирелә. Башында гел Мария сүзләре яңгырый: ни югалтасың син?.. Шулай да теге бүләкләр җилкәсенә төшкән бурыч кебек эчен кимерә... юк, мин болар өчен генә тугарылырга тиеш түгел. Ул барыбер язмышын минем белән бәйләмәячәк. Мина карата хисләре тирән һәм житди булса да! Хисләр, күпме ихлас һәм тирән булмасын, озакка сузылмый. Сабын куыгы кебек тиз юкка чыга. Хис бүген булса да иртәгә бетәргә мөмкин. Хискә исәп тоту, хискә таяну суга таяну белән бер.

Бервакыт җиңелчә генә сухое вино эчкәләп, сәрхушләнеп утырдылар. Каймакчи Надияне үзенең казармадагы ялгыз бүлмәсенә алып килгән иде. Әле шукланып, әле житдиләнеп күп нәрсәләр турында гәп барды. Каймакчи әллә шәрабтән, әллә кызның мөлаем түгәрәк чырае, сусыл иреннәре, алга ыргылып торган күкрәкләре тәэсиреннән кайнарланып, Надияне коча, үбә башлады. Үзе сөйләнде:

— Надия, син мине әллә нишләттең, йә Алла, болай булганым юк иде, — дия-дия изәрдәй итеп үзенә кыса. Надия аның үбүләренә салкын гына җавап бирә.

— Син мине алмыйсың бит, алмыйсың,— ди иреннәрен читкә тайпылдырып.

— Дөресен әйткәндә, белмим,— ди Каймакчи ияк кагып. — Яратам, шуны гына беләм. Ышанасыңмы?

Ул тән төсле үтә күренмәле нечкә оек кигән Надиянең җанны кытыкларлык матур тезләренә учын куя. Уфтана, монсулана, нәүмизләнә. Надия ни дип әйтергә белми, күзләрен түбән төшерә. Егетнең ялганламавын тойган шикелле була. Аның ниятен ачык белә, хайвани хискә бирелмәвен, аек уен җуймавын искәртә. Шунда баш миен тырнап: нәрсә югалтасың син, дигән сүзләр чалынып уза. Егет тә кызышып китеп, Надиянең кофта төймәләрен ычкындыра, йөзен ике күкрәк арасына яшерә дә үбә дә үбә. Аның күз яшьләре агып төшкәнен Надия күкрәк очлары юешләнүдән тоеп ала. Хисләре ихлас икән дип, үзе дә тезгенен бушайта. Егет кызның йомшап төшүен тиз сизеп алгач кулларына ирек бирә. Надия билбавының (зинарының) ничек чишелүен абайламый кала...

Аннары икесе киң караватның ике ягында тынып яттылар. Надия кулындагы сәгатенә карап, китәр вакытны чамалады. Торып, тиз-тиз киенде. Ә уйларында һаман каршылык: «ир куенында булу шулай була микәнни? Мин берни дә тоймадым кебек. Аякларым белән бернинди ирлелек, канәгатьлек тә сизмәдем. Нәрсәсе бар моның? Һи-и-и! Гаҗәп. Әллә беренче кушылу шулай төерле була микән? Әллә мин аңа туры килмәдемме? Мария әйтә, андый хәлләр була, ди...»

Каймакчи аны озатып куйды. Кичке шәфәкъ кызыллыгы урман артында буйдан-буйга сузылган. Нарат, чыршы ябалдашларын алсу төскә манган. Алар сүзсез генә атладылар, ниндидер гөнаһ кылгандай, бер-берсенә туры карарга унайсызланалар иде.

Варшавага командировкага китәсен Каймакчи бер иптәше аша Надиягә җиткерде.

Бераз вакыт үтте. Надия һаман куркып, шикләнеп йөрде. Үз-үзенә дикъкать итеп, эчке халәтенә барча әһәмиятен туплады. Шикләнүләре нигезсез түгел сыман иде. Мария өйрәткән саклану чаралары аны алдады микәнни? Тагын бер атна үткәч, үзенең шикләрен Мария Аркадьевнага чиште. Ул Надияне үзенең врач бүлмәсенә алып кереп тикшерде. Бүтән врачлардан да каратты.

Чынлап та Надия авырга узган иде. Аның башы әйләнде, ул үз-үзен белештермичә Каймакчи янына чапты. Ләкин ул кайтып җитмәгән икән.

... Надия Каймакчиның тезләренә утырган килеш, ике кулы белән муеныннан кочып алып үкси-үкси елады. Егет аны юатырга итеп нидер сөйли, ә кыз әйткәннәрне кабул итәсе килмәгән төстә иде.

— Иртәгә язылышырга барыйк,Павел? Мине хур итмә, ә?

— Безне язмаячаклар, юләрем, уйлашыйк әле.

— Язалар, мин генералга үзем керәм. Ул мине белә. Мин караган аерым палатада ятып чыкты....

— Сабыр, Надия, нигә шул тикле куырырга?

Каймакчи Надияне алдыннан төшереп, янына утыртты. Надия битләре буйлап аккан яшьләрен әле бер, әле икенче учы белән сыпырып алгалый.

— Юк, сабыр, димә! Иртәгә — и бетте! Мине кемгә санныйсың син? Үзең яратам, диден. Яраткан кешене болай хур итәләрмени?

— Бернинди хурлык юк...

— Мине «пэпэже» иттереп калдырырга телисеңмени? Юк, барып чыкмас. Павел, зинһар мине рәнҗетмә.

— Ярар, чарасын табарбыз. Борчылма, трагедия ясама.

— Трагедия ясама, имеш. Әйтерсең, бер мин генә гаепле? Әшәке ирләр

шулай хатын-кызны гына гаеплиләр. Әйт әле, мона син дә гаепләме?

— Гаепле, гаепле, Надия, мин үз өстемнән гаепне төшермим.

— Димәк, язылышырга барабыз?

Надия башын кыйшайтып өмет тулы күзләрен егеткә төбәде. Чыраенда беткәнче ана бирелгәнлек житдилеге иде. Каймакчи уйга калды, куллары тезләре арасына төште, кашлары жыерылды, матур төз борыны, ирене кырыйларында нәүмизләнү сызыклары чыкты, калын иягендә кызга карата ачу килү шәүләләре биеде.

— Минем таныш врачым бар,— диде ул Надияне иркәләгән тавыш белән. — Ике-өч укол белән барысын бетерә...

— Үзем дә уйлаган идем, Павел,— дип Надия башын түбән иеп. Аның иреннәре, ияге дерелдәде. — Врачлар карады. Противопоказана дип таптылар. Ышанмасаң, менә заключениесе.

Ул гимнастерка кесәсеннән кәгазь алып Каймакчига сузды.

— Минем йөрәк дефицитлы икән... Әгәр ясатсаң, тормышың белән саубуллаш, диделәр. Син дә мине үтерергә телисенме?

Надия ике учы белән йөзен каплады да, елагына буылып бөгелеп төште. Аның аркасы дерелдәп чәчен селкетеп тора. Каймакчи да тәмам бетеренеп, ни кылырга белми, бөрешеп калды. Менә уйсыз хисләр комарына бирелү, ваемсыз шатлык нинди бәла китереп чыгарды. Һәр рәхәтнең бер михнәте була дип белми әйтмәгәннәр. Нишләргә бу яклаучысыз кыз белән? Мин ничек кенә намуслы булсам да аны үзем белән бәйли алмыйм. Физически дип әйтерлек бу мөмкин түгел. Эшем буенча да, хәлем буенча да...

Алар үлгән кыяфәткә кереп озак кына дәшми утырдылар. Надиянең башында алдан сизү инстинкты туктаусыз эшли иде. Ул Каймакчиның аны ташлап китәргә ниятләвен чамалады, тойды. Ул тураеп утырды, Каймакчиның ярым үлек кыяфәтендә булуын күрде дә, йөрәгендә жәлләү хисе уянды. Катгый карарга килгәч, тәвәккәлләп әйтеп куйды:

— Мина берни эшли алмасаң, Сайкинга ярдәм ит. Ул чиста биография белән калсын?!— диде Надия.

Аның сүзләреннән Каймакчи жанланып китте, чыраена өн кергәндәй булды.

— Бик рәхәтләнеп, Надия! Ышан, мин моны булдыра алам!

Үзе Надияне күзәтте һәм аның йөз-бит сызыкларында Каймакчины бәлаләмәү, барысын да үз өстенә алу билгеләре күргәндәй булды.

— Надия, син бик яхшы кеше...

— Йә, юмалама!— дип сүзен бүлде Надия һәм нык карарлы төстә урыныннан торды...

Бер-ике көннән Каймакчидан записка килде: «Надия, гафу ит, минем семьям табылды. Алар Ашхабадта икән. Мин назначение алып шунда киттем...»

Надия моны көткән иде, бәгыре телгәләнсә дә, кайгыга бирелмәскә тырышты.

Сайкин терелеп, үз аяклары белән йөри башлаган иде. Стерильнәда, төнлә үзләре генә калгач, уйный-шаяралар. Надиягә жинел булып китә. Сайкинның колагына кадәр чумып үзенә гашыйк булуын ул әллә кайчаннан бирле тоеп йөри инде.

Төнге сменадан соң бер иртәдә ул Сайкинны үз фатирына алып кайтты. Мария шул йөреп торган майор белән Берлинга киткән иде. Майорны шунда күчергәннәр икән.

Надия Мәгарифне үз куенына бик теләп кертте. Аның алдан сизенүе алдамады. Надия чын ир кеше белән тирән һәм татлы канәгатьлек кичерде. Карасана, оялчан егетне! Оялчанлык көчле дәрт билгесе, икән!

***

Казанга кайткач, Надия Мәгарифне тимер юл типографиясенә урнаштырды. Шуннан редакция эшенә күчерделәр. Русча эшләве авыр иде, татарча чыга торган многотиражкага эшкә керде.

Мәгариф бер рационализатор турында мәкалә язып газетда чыгарган иде. Тирене киптергәндә кадаклар белән кагып тарттырып такта өстенә беркетәләр. Бу исә тиренең сыйфатын төшерә, чөнки тире кадак белән тишкәләнә. Бер слесарь тарттырып кую җайланмалары — каптырмалар эшләгән. Җайланма һәр яктан әйбәт: эшне дә тизләтә, сыйфат та арта. Уйлап табучы тире эшкәртүдә ике-өч норма бирә. Сыйфат аркасында күпме тире әрәм ителми янга кала. Экономия була...

Уйлап табучы кытайчарак чырайлы, кысык күзле, көтек борынлы, урта буйлы. Какча гәүдәле Нөркәев дигән егет иде. Күзләре елык-елык килеп тора, үзе дә елгырга охшаган. Яңа бистәнең Урал урамында яшиләр икән. Әтисе сугышта үлгән, абыйсы үткән ел армиягә алынган. Әнисе исә ларекта сыра сата, ди. Шулай икәне күренә дә, егетнең өс-башы әйбәт, сүзгә дә кесәгә керә торган түгел. Коллективта да абруе бар. Газетада яктыртылырга хаклы...

Язганчы Мәгариф Тарик Фәррахович белән киңәште. Редактор үзенә һәр нәрсәне белгертеп торганны, аның төпле сүзен алганны, шуның буенча эшләгәнне ярата иде. Үзе эшне бик өнәми, әмма өйрәтергә атлыгып тора. Өйрәтүдән канәгатьлек таба. Берничә кешегә (газета эшчеләренә булмаса да) киңәш бирсә, кәефе күтәрелә, йөз грамм салган шикелле була, яхшыра, вак-төякне күрми. Бу йомшаклыгын белеп алып, ялагайлар аның тирәсендә бик күп әйләнәләр. Тарик Фәррахович тагын да үсенеп йөри... Мәгариф аның кәефе әйбәт чакка туры килде. Алдагы ялагай яңа гына чыгып киткән ахрысы. Мәгарифне үз урынына калдырмасмы? Ул шуңа бик өметен суза, һәрчак җаена ятып кына тора иде. Бүтән куштаннарга нәфрәтләнсә дә, үзе ялагайланган чакта рәхәт хис кичерә ул. Тарик елмаеп сөйләшсә, бигрәк тә. Гәрчә ул аның елмаюына ышанып җитмәсә дә... Тукта, ул үзе дә ялагайлана түгелме соң? Ялагайлардан көлә, әмма үзе Тарикка ярарга тырыша. Тикмәгә түгел, Тарикны Татиздатка алалар икән. Син лирикага бирелүчән, диде. Бу юлы җылы сүзләрне җәлләмә... Мәгариф тә бу сүзләрдән дәртләнде. Кара, ул хуплаганны ярата икән... Дөрестән дә, мәкалә җылы чыккан иде. Фабрикада укыганнар һәм әле һаман да укыйлар дип ишетелде. Җитәкчеләр газетада укырлык, кызыксынырлык мәкаләләр булуын таләп итәләр иде... Менә булды... Мәгариф үз мәкаләсенең кулдан-кулга күчеп укылуына канәгать калды һәм җитәкчелек тарафыннан хуплау көтеп йөри башлады. Бу хакта Надиягә дә тиште. Мәгарифнең русчадан үрлисе, редактор буласы килә иде. Газетадагы бар текстны үзем язам бит, неужели шуны белмәсләр икән дип хыялый йөз чыгарып сөйләнә ул. Тарик Фәррахович берни язмый, бары тик политик хата китмәсен дип кенә кайгырта. Шуның өчен генә текстларны укырга мәҗбүр.

Мин сине җәллим, ди Надия иренең битеннән учы белән сөя-сөя. Нигә син шулай уңышсыз кеше икән, ә? Нindидер сөйкемсез сөягең бармы әллә? Минем өчен синнән дә әйбәт, ипле кеше юк. Тик кайчак кызып китеп кенә эчне пошырып куясың. Монысы шул безнең татарлыктандыр инде. Тигез салмак холыклы була белмибез...

Юк, мин үземне уңышсыз кеше димәс идем, дип Мәгариф хатынына каршы төшә. Иң элек мин сиңа тап булуым белән бәхетне койрыгыннан эләктердем. Син булмасаң Каймакчи мине штрафбатка җибәрә иде. Кичә Надия госпитальдә төнге дежурда булып кайтты. Шул арада юксынырга да өлгергән. Надия ана көннән-көн кадерлерәк була бара иде. Нилектән?

Хисләр һаман тирәнәяме? Әллә бу әз генә көнчелек галәмәтеме? Әллә малай тапканга күрә Надия тагын да җан пәрәсенә әйләнде инде? Белмәссең, аның бар нәрсәсе дә үзенә тартып тора.

— Минем сүздән чыкмасаң, унарсың, — дип Надия аны янагыннан сөйде дә, теге якта уянган бала янына ашыкты.

***

Мәгариф чираттагы номерга яңа башлар уйлап, язып утыра иде. Тарик Фәррахович үз бүлмәсенә чакыртты. Ни булды икән, дип Мәгариф күңеленнән генә үзенең гаепләрен барларга кереште. Башлык тикмәгә генә дәшми. Эштә бер хатасыз гына мөмкин дә түгел. Уй дәрьясыннан ихтималларны уздырып бетерде һәм шелтә ишетерлек берни дә тапмады. Димәк, теге рационализатор турындагы материалны мактарга җыена булыр. Шулай мәкаләне кулдан кулга йөрткәннәре турында ишетелгән иде. Редакторның ул мәсьәләдә колагы бик сизгер.

Тарикның йөзе бик тирән борчулы җыерчыклар белән тулган иде. Әллә берәр политик хатага охшаш нәрсә киткәнме? Тарик кызыллыкны үзенә кыйбла иткән кеше. Шушы кыйбла алган кешеләрне үстерәләр, күтәрәләр. Ул үзенең өченче сизгерлеге белән сизә һәм үз кыйбласына икеләтә, ягъни арттырып тугрылыклы була белә иде. Бу аның һәр реаль хәлне тасвирлый торган тәгъбиргә гаять саклык белән килүендә, тәфсилләүне, тәгаенлекне яратмавында чагыла. Конкретлыктан һәм кимчелекләрне әйткән мәкаләләрдән бик курка ул. Ләкин бу кызыллык кыйбласы аның табигатеннән килми. Шуңа күрә бу ясалмалылыкны һәрдаим саклап кала алмый. Рольне алып баруы аңа гаять авыр шикелле. Моны аның өмете өзелгән төстәге бит сызыкларыннан чамаларга һәм күрергә була иде. Җитешсез якларны бер-ике сүз белән әйтеп үткән материал булса, шуны чыгарырга куркып, әле шуны күтәреп парткомга керә, әле тагын бер башлык янына бара, кат-кат килештерә, турылаштыра. Нәтиҗәдә мәкаләнең бер җегәрлеге, яшәүчәнлеге калмый. Мәгарифнең моңа бик эче поша, аның бар җаны мондый кызартуга каршы күтәрелә. Әмма бу хисен эченә йомарга мәҗбүр. Чөнки ул ният беркемдә дә теләктәшлек тапмаячак. Әнә Тарик та үзендәге тормышчанлык хисен томалап күнел барышка кулай итеп корган: һәрчак һәр эштә, һәр сүздә кызыллыкны гына алга сөрергә, шуны гына белергә. Ялгышмассың һәм унарсың. Ә нигә соң моңа каршы эчтә протест күтәрелә? Шул хисне ничек басарга? Тарик әнә ул хисен җиңгән һәм хәзер аңа унайлы булырга тиеш.

— Син, егет, тагын безне утырттың,— диде Тарик тузгак чәчле башын күтәреп. — Миңа синең өстән жалоба, понимаешь. Нигә тикшереп язмадың?

— Ничек инде,— диде Мәгариф тамак төбенә учын куеп.

Ул бүген галстук тагып килгән иде. Кәефе дә әйбәт, күтәренке. Шуңа редактор әйткәннәр аңа барып җитми торды.

— Үзе белән күзгә-күз сөйләштем.

— Нәркәев сүзләренә ник ышандың, ник тагын тикшермәдең?.. Иптәшләре белән сөйләшергә иде, бригадир белән.

— Барысы белән дә сөйләшеп чыктым. Хикмәт нидә соң?

— Синең Норкәевең уйлап табучы түгел икән, ул аны икенче берәүдән урлаган, үземнеке дип әйткән...

— Юк, мөмкин түгел, Тарик Фәррахович, нәрсәдер бутәнчә монда..

— Менә рационализаторның үзеннән жалоба. Парткомга китергән. Унлап имза...

— Шулай ук булыр микәнни?— диде Мәгариф һаман ышанмаганлыгын белгертеп.

— Нәрсә, мин шаярып утырам что ли?

Тарик тавышын күтәреп кычкырып салды, йөзе ачулану төсмерләре белән тулды.

— Нишләргә соң миңа?— дип Мәгариф кинәт тыңлаучан, барысын да эшләргә әзер төскә керде.

— Жалобаны ныклап тикшерергә, гаепләне ачыкларга, утлы табага бастырырга...

— Аңлыйм, Тарик Фәррахович, хәзер үк шул эшкә алынам. Менә сиңа Нөркәев, ә? Нинди фәрештә кыяфәтле егет...

— Шайтан һәрчак фәрештә кыяфәтендә йөри бит,— дип Тарик Мәгарифкә карап алды, артыграк сүз ычкындырдым дип үз-үзенә ачуы килеп куйды.— Ярар, син шау-шусыз гына. Артык күпертмә...

— Намуссызны фаш итәргә.

— Намуссызны түгел, гаепләне,— дип басым ясады редактор. — Кискенлек беркемгә дә файда китерми. Кырт кисмә. Өйрәнергә вакыт.

— Караклык эшләгән бит ул, шуны йомып калдырыргамы? Юк, Тарик Фәррахович...

—Юк, йомарга димим, ә нигә шауларга, ду кубарга? Кирәкмәс... Тегендә өскә ишетелергә мөмкин.

— Аңлыйм, Тарик Фәррахович...

Мәгариф аның йөзеннән «бар» дигән боерыкны күреп, ишеккә таба борылды.

Тире эшкәртү фабрикасы зират янында ук иде. Аңа дамбадан барырга кирәк. Мәгариф бинадан чыккач, шул якка илтә торган тыкрыкка таба урам аша үтә башлады. Әллә каян Дәрия килеп аның беләгенә ябышты. Чатта көтеп, сагалап торган ахрысы.

Дәрия Мәгарифнең авылда яшь чакта йөргән, балалык юләрлеге белән вәгъдәләшкән кызы иде.

— Хыянәтче, нигә сүз куешкан җиргә килмәдең?— диде ул озын керфекле күзенең кырые белән аңа карап.

Дәрия сүзләре Мәгарифнең күңеленә шырпы кебек кадалса да, ул эндәшми генә атлый, як-ягына караштыра: матур кыз белән култыклашып барганны күрсәләр, Надиягә бик тиз җиткерерләр. Надия бу арада аңа нигәдер дикъкатен арттырган төсле йөри. Бозылышыр өчен күпме кирәк? Әллә бу Дәрия безне көйсезләргә телиме? Кая, ничек башына килә? Аның хәле начар, ә кул сузар кешесе юк. Нишләсен? Безне күргән кеше аңлыймыни ул? Менә хикмәт нәрсәдә... Мәгариф һаман эндәшми бара иде.

— Ник дәшмисең?— дип Дәрия аның беләген ычкындырды, ул сизгер зат, дәшмәвеннән нәрсәдер чамалап алырга өлгерде.

— Дәрия, син гаепләргә ашыкма,— дип аңлатырга кереште ул, кызга таба борылмыйча атлавын дәвам итеп. — Шәһәрдә башкачарак бит. Торабара аңларсың әле...

— Ярар анысы...— дип Дәрия ачулы тавыш белән аның аклануын өзде. — Мине торфка вербовать итәләр, аңлыйсынмы? Ничек итсәң ит, алып кал, Мәгариф!

Дәриянең тавышы ялварып-еламсырап чыкты. Мәгариф моңа бер дә гаҗәпләнмәде. Гүя алдан сизенгән булган кебек иде.

— Ничек итеп алып калырга? Өйрәт,— диде Мәгариф кыз хәленә керергә, ярдәм итәргә әзер тавыш белән.

— Министерствода берәр танышың юкмы?

— Мин блатлы була аламмыни, Дәрия? Неужели минем характерны бераз чамаламыйсың?

— Аның өчен дә характер кирәкмени?

— Мин — сина, син — мина, дигән йола хәл итә бит шәһәрдә, авылдагы кебек түгел. Намус дисең, анысы да биредә башкача. Мин беркемгә дә файда итә алмыйм, шуңа күрә бүтәннәрдән дә сорарга базмыйм. Менә ничек бит! Шәһәрдә яшәү үзенә аерым төрле, Дәрия. Белерсең әле...

— Теләсәң нишләт, мине җәһәннәмгә җибәрмә! Мәгариф! Элекке дуслык хакына!

— И, Дәрия, нишли генә алам соң мин? Юк бит!

— Ярдәм итәргә теләгең бар икән, ни булса да эшләрсең.

— Ну, әйт, ничек итеп, ә? Бик телим, бар йөрәгем белән, Дәрия. Ләкин...

— Кемгә булса да кияүгә чыгарга риза, Мәгариф. Ишетәсеңме? Сугыш инвалидына, хет берәр картка, исерек башка...

—Тукта, Дәрия, ни сөйлисең, килешмәгәнне?

Мәгариф бик гаҗәпләнеп кызга карап алды. Юк, Дәрия ялганламый, сүз булсын өчен генә сөйләми, ә бик мөшкел хәлгә калып, бүтән чарасы булмаганга ачыргалана. Ул аны кызның мөлдерәмә тулган һәм менә-менә түгелергә житкән күз яшьләреннән чамалады. Йөрәге өзелеп, кызны жәлләү хисе белән тулды. Узган ел да, быел да шундый хәлләр булгалады: чибәр татар кызлары юк-бар кешеләргә кияүгә чыгып, вербовкадан котылып калганнар. Әйе, бу хакта бик ачынып та, гыйбрәт өчен дә сөйләнделәр. Бер авыз сүз русча белмәгән, чит-ят жирдә нишләмәк кирәк дип, авыл кызларын кызгандылар. Өф-өф итеп кенә үстерелгән, ата-анасына бик кадерле иркә Дәрия анда тел белмәгән көе бик газапланыр, интегер. Кыз моны үзе дә сизә һәм әнә нинди чиктән ашкан сүзләр сөйли. Шундый ук башсызлыкка барыр микәнни? Элек Дәрия алай түгел иде. Үзгәргән.

— Ярдәм итмим дисең инде,— дип үпкәләде Дәрия.

Ә-ә, үпкәләве элеккечә калган — нинди мөлаем ул. Шәп үпкәләүче, турсайган матур иреннәре һәм читләшү тулы күзләре белән хәтеренә төшә иде ул аның. Аннары язмыш Мәгарифне шактый нык дөмбәсләде: үткәннәрне оныт, оныт, дип башына суга килде. Язмыш шулай Дәрияне оныттырды. Ул күргәннәр әти-әнисен оныттырырлык булды. Ярар, үтте инде...

— Җанымны аяк астыңа салырга әзер, Дәрия, чын менә! Ләкин ничек итеп? Әйтәм бит, мин блатлы була белмим.

— Танышларың бардыр, алдама,— дип Дәрия тавышы белән дә рәнҗүен белдерде. Алма кебек аксыл битенә әз генә алсулык чыкты һәм тагын да матур булып китте.

— Жир упсын, Дәрия!

— Хатының Казанныкы. Булмый калмас...

— Хатынга ул хакта әйтә алмыйм, ялынырга тагын! Мина иң авыр нәрсә ялыну, йөз суы түгү!

— Үз хатыныңа инде йөз суы түгү саналмыйдыр.

— Мин аңа болай да бурычлы, шуңа үземне уңайсыз тоеп яшим, Дәрия. Син аңламассың да...

— Әйткән идең... Ничек диләр әле, юләр хатынын мактар...

— Кайчагында ата казга да жизнәй дип дәшәсең, тормыш ул кырыкка бөгә.

— Бик хатынша булгансың күренә...— диде Дәрия көлгән ише итеп.

Ул Мәгарифнең һәр сүзенә шырпы кадарга гына тора. Эчендәге рәнҗүен шуның белән чыгармакчы була. Мәгариф моны аңлый, үзен Дәрия алдында гаепле санаганга күрә, дәшми, сабыр итә. «Шырпыларны» буена сеңдереп бара иде.

Алар тимер юл дамбасыннан шактый озак бардылар. Сукмак ташлы, атлау

өчен җайсыз иде. Дәрия нидер өметләнеп бара, Мәгариф ничек тә ярдәм итәр дип уйлый һәм кая алып барганын да белешми, аңа тагылган нәрсә кебек, бер адым калмый. Кыз үзенә килгән бәлане аңа ачып салды. Сүзләр бетте.

***

Цех стеналары биек. Зур тәрәзәләре дә түбә астында ук булган бер катлы барак кебек ачык бинада иде. Зур гына проходной, өстәл, урындыклар. Өстәл турындагы стенада телефон. Бер агач аяклы хәрби киемле картрак кеше трубканы колагына тоткан да игътибар белән тынлый. Керүчеләргә кул ымы белән утырырга куша. Ул бер сүз дә әйтми трубканы куйды да боларга борылды. Мәгариф документын сузды, карт карады да кире бирде һәм ияге белән эчкә үтәргә мөмкин дигәнне аңлатты. Дәриянең бирердә көтеп торачагы сүзсез дә аңлашыла иде.

Озак та үтми, Мәгариф Нөркәевне алып чыкты. Аңардан әче тире исе килә иде. Бер почмакка барып сөйләшә башладылар.

Нөркәев табак битле, чепи күзле, кыска кылыч борынлы чибәр генә егет иде. Сүзләре авызыннан тәгәрәп-тәгәрәп чыга шикелле, ак тешләре арасында бөгелгән теле күренеп-күренеп китә. Ул әлеге җайланманы үзем уйлап чыгардым, диде, ә каптырмаларны минем сорау буенча шул дус егет — Кирәкмәсов Миньяр эшләп бирде ди.

— Менә ул мин уйлап чыгардым, ә Нөркәев миннән урлаган дип жалоба язган. Кемдә хаклык? — диде ипле тавыш белән Мәгариф. Нөркәев Дәриягә күз төшереп алды, йөзенә уңайсызлану, оялу төсмерләре чыкты. Йөзен караңгыландырып җибәрде. Ул җилкәләрен селкетеп куйды, ягъни белмим, кем хаклыдыр, үзегез хөкем итегез дигән кебегрәк нәрсә аңлашылды.

— Миньяр кем ул сиңа?

— Без дуслар, бер тирәдәрәк йөрибез,— диде Нөркәев.

Итләч маңгаендагы юка соры кашлары җыерылып кушылгандай булды.

— Беренче булып идея кем башына килде?— Мәгарифнең йомшак тавышында нindидер шаяру тоны да бар сыман иде. Ул килеп чыккан конфликтны шау-шусыз хәл итәргә тели, тирәнгә керүдән читләшә.

— Тиреләр белән мин интегәм, конешно, каптырмалар булса иде дип иң элек мин хыялландым. — Нөркәев нигәдер күзләрен читкәрәк алды, шикләнгәндәй тагын Дәриягә күз агы белән ялтырап куйды. Мәгариф аның сүзләренә ышанып җитмәде, йөзенә дә шул төс чыкты. Ул тезенә учы белән суккалап торды: нindидер карарга килә алмый иде.

— Уй төште дә башыңа, шуны Кирәкмәсовка әйттең, шулаймы?

Мәгариф конкрет хәлгә якынаерга тели иде.

— Әйе,— диде Нөркәев ничектер битарафрак төстә. Ул үзенең бу эшен чәчрәп чыгып якламый, шуның белән шикләнебрәк урын калдырган шикелле була иде.

Мәгариф жалоба бирүченең шәхесе турында белешә башлады. Ни өчендер фамилиясе бик сәер тоелды. Ул табылдык икән, кемдер трамвайда калдырып киткән. Өч-дүрт айлык чагында... Исеме-ние юк. Балалар йортында шундый фамилия биргәннәр. Кирәкмәсов...

Фамилиядә түгел, хикмәт кешенең үзендә,— дип мыгырданды Мәгариф урыныннан кузгалып. Аның кая барырга теләвен Нөркәев белеп алды һәм торып басты. Мәгариф аңа бераз гына көтеп торырга кушкан иде, Нөркәев вакытым юк, диде. Бик хәстәрле төстә сәгатенә карады... Бригадир ачулана торгандыр инде дип цехка керә торган ишеккә юнәлде. Аның тизрәк китәсе килгәнлеге аңлашылып тора.

Мәгариф Дәриягә көтәргә кушып, чыгып китте.

Озак та үтми, Киръкмәсовны ияртеп кайтты ул.

Дәрия Кирәкмәсовка бик кызыксынып карады: боек, нурсыз тоелган сөнек йөзен күреп, аны жәлләде. Ул ямьсезрәк йөзле, янак сөякләре ике якка тырпаеп тора, ияге алга калыккан, күзләре төссез — болганчык шикелле иде.

— Нөркәев әйтә, идеяне мин бирдем, ди...

Мәгариф һаман каршылыкны шау-шусыз йомуга тугрылыклы калып, иплэп кенә сөйләшергә теләде.

— Мин алар эшләгән жиргә кергән идем, вижу... — диде Кирәкмәсов татарча-русча сүзләрне бергә аралаштырып. — Кадак кагып интегәләр... Шунда ук башыма тарттыру каптырмалары турында уй килде. Мин станокта каптырмаларга охшаш бөгәлжәләр ясадым...

— Әйе, шуннан?

— Эшләп китердем дә Нөркәевкә бирдем. Ул шунда ук тирене каптырмалар белән тарттырып куйды да кыра башлады...

— Тагын?

— Нәрсә тагын? Шул инде, бүтән юк.

Мәгариф Кирәкмәсов ягына авышты. Дәлилләре көчлерәк булдымы? Нөркәевнең дә дәлилләре бар. Тик ул сүзгә саранрак. Әмма рационализаторлыгы өчен премия алган, ә Кирәкмәсовка берни дә юк. Менә гаделсезлек кайда. Премияне бүлешкән булсалар, жалоба язылмаган булыр иде. Адәм баласын шул акча харап итә. Боларның икесен бергә очраштырырга, татулашырга кирәк.

Шулчак Мәгариф, әйдә, дигәнне белгертеп, Дәриянең жиңенә кагылды. Проходнойда кешеләр күбәя иде. Смена тәмамланган икән.

Аларга Кирәкмәсов та иярде. Плотиннан Тукай урамына чыктылар. Мәгарифнең башында Наполеон планнары йөгерешә: Дәрия белән икесен килештерергә дә, язылыштырырга боларны. Кирәкмәсов өйләнмәгән. Яна бистә мәчетендәге тулай торакта яши...

Дәрия бая теләсә кем белән язылышырга риза, кеше тап дип колагына тукый-тукый үтенде, ялварды: «Торфта ФЗӨдә бандитлар арасында мин бетәчәкмен, әйе, чын шулай... Яшь башым зерәгә харап булачак. Кемне булса да тап, мине алып кал. Әгәр сәбәпсез торфка китми калсам, мине төрмәгә ябачаклар. Безгә махсус аңлаттылар, егерме өченче статья диме? Торфка киткәнче, төрмәгә керергә риза диләр кайбер кызлар. Чөнки бер авыз русча белмиләр. Шул куркыта... Безне крестьян йортына китереп тутырдылар. Беркая жибәрмиләр, саклыйлар. Мин тәрәзәдән качып чыктым...» — диде. Чынлап та, торфта Дәрия харап булачак. Ничек бу егеткә сыларга үзен? Әмма егет йомшаклардан түгел шикелле. Характеры сизелә. Болай тыштан ятышсыз тоела, ә эчтән әйбәт булырга охшый. Хәер, детдом балаларының холык-фигыльләре йогышсыз була, диләр.

Урам чатыннан борылып бер сыраханәгә керделәр. Мәгарифнең хатыныннан яшереп тота торган утызлыгы бар иде. Шуңа өч кружка сыра, йөзәр грамм акны һәм капкаларга коры-сары алды. Кирәкмәсов моны көтмәгән иде, йөзендә жылы төсмерләр күбәеп китте. Сыра яна һәм жылы иде, тамакта әчесе дә беленми, тәмле. Дәрия бер капкач та йөзен чытты, кружканы читкә этәрде. Мәгариф аны кыстап карады: син нәрсә сырадан да куркып, пешмәгән кызлар кебек утырасың диде. Кирәкмәсов буфетка папирос алырга киткәч акны да эч, кыюлык өчен әйбәт була, аңлыйсыңмы дип тагын да ачыграк әйтте. Менә бу егеткә тагыл һәм ычкындырма, төшенәсеңме? Бу синең жаең, ычкындырма, үкенерсең. Кем синең белән болай кинәт кенә язылышырга барсын? Дураклар юк. Ә танышлык белән барысы да өметле була. Кызларның

егетләрне кулга төшерүләре, аулаулары хәзер модада ул. Кыю, тәвәккәл бул, шунда эшең уңар...

Кирәкмәсов буфеттан авызына папирос кабып килгәч, Мәгариф Дәриянең бәласен сөйләп бирде. Кинәш итү, ярдәм сорау формасында бик кайгырып тасвирлады. Кирәкмәсов: «Шулаймыни?»—дип Дәриягә карап алса да, әллә ни кызыксыну белгертмәде. Тиз кымшана торган зат түгел ахрысы, арткы исәбе көчле дигән уй килде Мәгарифкә.

Алар чыкканда якты иде әле. Сүзләр өзек-өзек кенә булды, ялганып китмәде. Кирәкмәсовның йөзе моңсуланган, күз шулпаларында ниндидер эчке уйларга чуму, бу төштән каядыр еракларак киткәнлеге чагыла иде. Әллә Нөркәев турында, дустының хыянәте хакында исенә килеп, җаны кешеләрдән бизенгәнме?

Татарстан урамы чатына хәтле аны-моны сөйләшкәләп бардылар. Трамвай тукталышына килеп бастылар. Дәрия егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап-карап ала. Йөзләреннән аларның кәефләрен, уйларын чамаламакчы була иде. Кирәкмәсов өметле түгел сыман. Башта ана ниндидер ышаныч белән яктырып караган Мәгарифнең дә йөзе сүрелде.

Алтынчы трамвай килә иде. Кирәкмәсов кисәк кенә Дәриягә якынрак килде:

— Әйдә безнең торакка, бер егет белән таныштырам...

Дәрия, курку катыш сагаю белән, Мәгарифкә карап, таяныч эзләде. Мәгариф үзе дә бераз икеләнебрәк калган шикелле, ни дип әйтергә дә белмәде. Ахырда:

— Әйдә, мин дә барам,— диде ул, Дәриянең беләгенә тотынып.

Тулай торак киң генә мәйдан уртасына салынган ике катлы мәчеттә иде. Мәчет үзе болай бик зур икән. Һәр ике катта да хатын-кызлар яши торган бүлмәләр генә. Озын киң коридор. Мәчетнең икенче ягында кушып салынган бүрәнә бинада егетләр, ир-ат халкы урнашкан.

Тупсаны атлап керүгә, Дәрия үзенең авылдаш апасын очратты. Алар бик сагынышкандай күрештеләр. Апа Дәрияне үз бүлмәсенә кыстаган чакта Кирәкмәсовның җилкәсенә дә тәкәллефсез учы белән суккалап алды. Алар яхшы танышлар гына түгел, араларында нидер булган да төсле иде. Чөнки төксе чырайлы Кирәкмәсов шундый җылы итеп елмаерга мәҗбүр булды — бите, күзләре очкынлы нур белән тулды. Бу минутта Мәгариф үзенең биредә артык булуын сизде дә тиз-тиз саубуллашып кире борылды. Дәрия аның китеп баруын сизмәде, апасы белән сөйләшүгә йотылган иде...

Икенче көнне Дәрия Мәгариф янына тагын килде. Ул бик борчылган, боек иде. Матур иреннәре турсайган, очкын чәчеп торган күзләре сүнек, йөзе дә өшәнеп киткән... Бүлмәдә бүтән берәү дә юк. Дәрия, өстәлгә башын салып, еларга тотынды.

— Ни булды тагын? — Мәгарифнең тавышында Дәрия мәшәкатеннән туя башлаганлык сизелеп китте. Тик кыз моны абайламады. Бераз күз яшен койгач, җиңеләеп киткәндәй башын күтәрде, чәчләрен рәтләде, ак челтәрле кулъяулыгын бит өстендә уйнатып алды. Мәгариф, һаман аңа текәлеп, соравына җавап көтә иде.

—Таныштырдылар. Бер егетме-ирме белән шунда, — диде укшыган кебек авыр көрсенеп. — Шактый озак утырдык, аннары бер каморкага алып керде. Бүген бирел, иртәгә язылышырбыз, ди. Эт сыңары, эт сыңары! Күренеп тора, мыскыл итмәкче. Язылышмаячак. Юк!

— Синең затлы кыз икәненне борыны сизгәндер...

Затлы белән затсызны аера белә торган борын түгел ул! Кеше бәхетсезлегеннән файдаланмакчы...

— Вакытлыча гына дип кем язылышсын инде, Дәрия?

— Әллә мине бөтенләйгә алса да ярамаслыкмы? Ый-ый-ый!— Дәриянең буасы тагын ерылып китте. Тыела алмый еларга тотынды. Бераздан үзен көчкә тыеп әйтте:

— Нинди хурлык, нинди страм! Уф, уф! Шундый көннәргә каласымны белсәм...

— Алай ук авырга алма әле, берни дә булмаган бит,— диде Мәгариф.

Алар бер-берсенә карарга уңайсызланып уйга калдылар. Берничә минуттан Дәрия урыныннан кузгалды.

— Бу ир-ат гел алдарга гына тора икән,— диде. Тавышы калтыраулы иде. — Барысы өчен дә мин сине каргыйм, Мәгариф, күз яшем сиңа төшсен... Сине генә...

— И, Дәрия, каргап ни файда?— диде Мәгариф бер дә ачуланмыйча. — Син затлы, чиста кыз, молодец, үзеңне саклый аласың. Барысы да әйбәт чыгар. Менә ир-ат белән мөнәсәбәттә сабак алдың, хәзер инде акыллырак бул. Берсен дә якын җибәрмә! Таш кебек каты тор! Сүзләренә, иркәләүләренә ышанма! Кичәге хәл сиңа ачы тәҗрибә! Каргасаң, каргарсың, Дәрия, ә мин сиңа чын күңелдән яхшылык кына телим...

— Синең теләгең белән нишлим, нишлим?— дип өзгәләнде кыз һәм Мәгариф янында бүтән кала алмаслыгын белгертте дә, өметсез ым белән кулын селтәп, ишеккә омтылды.

Мәгариф Дәриянең атып яраланган кош шикелле кызганыч булып чыгып китүенә әрнеп калды. «Сине каргыйм»,— дигән сүзе колагында яңгырап, күңелен тырный башлады. Җанына нindидер таш килеп яткандай булды. Сулыш алуы авырлашып торды, тын юлына каты әйбер тыгылган кебек тоела, авырттыра иде... Тукта, мин дингә ышанмый торган кеше, әллә каргышка ышанаммы? Күз яшьләрем сиңа төшсен, имеш! Сүзләр генә бит ул. Нигә миңа каргыш төшсен? Юк! Шулай да нигә мин эшләремне онытып шул хакта уйланам? Нигә мине Дәриянең ул сүзләре какшаткандай итте әле? Нидән өректем мин? Минем ни гаебем бар? Ә гаебем булмагач, ник үз алдымда акланып маташам? Әйе, ни генә булса да күңелдәге таш утырып калды. Әллә аны эзләп барып, тагын сөйләшергәме? Ул миңа бар йөрәге белән рәнҗеде инде. Югыйсә, шундый сүзләр әйтмәс иде. Юк, динне танымасам да, каргышка ышанам ахрысы? Моны үзем дә белми йөргәнмен. Кемнеңдер миңа рәнҗү саклавы, эчтән генә каһәрләве ничектер җанга ипсез, җайсыз. Нindидер бурычымны түләмәгән кебек күңелне чәнчеп тора. Тынгылык бирми. Тынычсыз җан белән көн итүе авыр. Моны иң якын кешеңә дә әйтеп булмый. Эчтән үзең генә көйрисең, сызасың. Ул сызлавык кебек бер минутка да сине калдырмый... Әллә Надиягә әйтеп карарга мы? Ул берәр справка-фәлән эшләп бирә алмасмы? Ләкин көнләшергә тотыныр инде. Бигрәк тә кыз бала икәнен белгәч... Болай да соңгы вакытларда мине бик тикшерә башлады әле. Әз генә, вакытында өйгә кайтып өлгермәсәң отчет алырга тотына. Сорау алудан тәм таба кебек. Башка ирләрнең дә хатыннары шулай шикелле. Надия яшьтән ир-ат халкы белән эш иткән, аларны артык нык белә һәм бер дә тәкәллефләнеп тормый. Ир-атны ул үзеннән түбәнрәк итеп күрә сыман тоела. Мине ул бары үз калыбында гына тотарга тырыша кебек. «Ир-атны йөгәндә тотмасаң, ул ялгыш юлга керергә генә тора»,— дип ычкындырды беркөн. «Атның да йөгәнен салдырмыйлар. Ычкындырсаң, ат шунда ук уҗымга керә...» Чынлап та, кайбер ирләр хатын-кыз йөгәнендә интегеп, бик зарланалар. Мөстәкыйльрәк булырга тырышучылардыр, мөгаен. Ләкин хатын-кыз янында мөстәкыйль, бәйсез булып булмыйдыр. Табигать үзе сине аңа бәйләп тудырган икән, нишләмәк кирәк. Йөгәнләвенә дә чыдарга туры килә.

Нөркәевне туры китереп булмый, нигәдер арт тайдырып йөри. Әллә

үзенең гаебе барын аңлап, оятыннан шулай качамы? Ничек тә Кирәкмәсов белән икесен кара-каршы очраштырасы бар. Шунсыз кем хаклы, кем хаксыз булуын аңлау кыен. Болай сөйләгәндә, икесе дә үзләрен хаклыга чыгаралар. Бер-берсен гаеплиләр. Күз артында гаепләү авыр түгел. Барыбыз да читкә китеп кемне дә булса яманларга яратабыз. Ә күрешкәндә шул ук кешегә елмаябыз, яхшы булып күренергә тырышабыз. Адәм баласы шундый инде, яшереп торасы юк. Хәтта дус кешеләр дә берәр эштә маңгайга-маңгай килсә, бер-берсен каралтырга тотыналар. Шуңа күрә дуслык ул — бары тышкы, шартлы нәрсә генә. Мәгариф моны үз җилкәсендә татып белде.

***

... Бер көнне сыйланып кайтканын сизде дә Надия төпченә башлады. Кайда булдың, акча каян алдың, дип сораштыра иде. Чөнки балага манный юнәтергә акчасы җитмәде. Бу айда Надия үзенә эчке күлмәк алган иде, шуңа күрә бик кысанга туры килгәндер. Мәгарифкә тагын ялганларга кала; Кирәкмәсовны сыйлаган акча төп «бюджеттан» түгел, ә премиядән яшереп калынган иде... Мине бер таныш эшче егет сыйлады, дидем. Шунысы гаҗәп, Надия тикшерә башласа — миңа бик читен. Нәрсәдән бу? Бар җаным шуңа каршы тора? Мин бит начар юлда йөрмим, хәрәмләшмим. Ә нигә аның сынап, шикләнеп сорауларына җавап бирүе авыр? Надия бәлки мине яратканга күрә шулай итәдер. Мин шуны аңлап җитмимме? Аның төпченүләрен «җанда актарыну» дип кабул итәм, һәм барча вак-төякне ишетү миңа кыен. Нәрсә бу? Надия чын күңелдән мине кайгырта, ә мин шуңа бар җаным белән карышам. Надиянең мине сакларга тырышуын, бары яхшы теләктән чыгып юк-бар нәрсәләрдән араларга итүен, кечкенә генә эчке ирегемә хилафлык дип кабул итәмме? Ахрысы, шулай. Надиядән тыш минем бер серем дә булмаска тиешме? Әйе, Надиягә әйтми торган бер уем да булмасын. Мин шулай телим. Һәм үземә шулай дип тукыйм, Надия тикшерә, отчет сорый башласа, эчемдә ачуым кайнап чыга, көчкә тыелып калам. Кайчак тыелып та калып булмый, кычкырып җибәрәм. Тәмсезләшергә туры килә. Миндә үз ягымнан нигәдер аны тикшерергә, теге яки бу нәрсәләре белән кызыксынырга бер теләк тә уянмый. Ә бит ул госпитальдә төнге дежурларда була, шунда кунып кала. Анда барысы да ир-ат халкы гына. Надиянең буй-сыны, йөзе-бите, ягымлылыгы нindидер үзенә тартучан көчкә ия. Рядовойлар булмаса да, яшь лейтенантларның аңа өмете сузылуы мөмкин. Мин исә барысына да битараф йөри бирәм. Әллә мин аны тирәннән яратмыйммы? Юк, яратам, ул иң якын кешем. Тик кешенең күңеленә керергә кыенсынам мин, моны начар эш дип карыйм һәм үз эчемә тукынганны да шуңа күрә яратып бетермимдер. Ир үзенең хатыны каршында күңеленең төбенә чаклы ачылырга бурычлымы? Әгәр шулай икән, мин моны булдыра алмыйм. Минем үземнең генә беркемгә дә ачылмый торган җан почмагым, «серле ящигым» булырга тиештер бит?! Әгәр Надиянең дә шундый үзенә генә газиз «серле ящигы» булса? Булсын, аннан ни зыян?..

***

Бусаганы атлауга үзәк өзгеч күренеш: Надиянең күзеннән яшь ага, ә төреп кочагына тоткан бала кычкырып елый иде. Ул эштән кайтышлый баланы яследән ала чыккан. Ә бала ач, имә алмый, елый гына. Мәгариф тиз-тиз чишенеп кулын юды һәм баланы алып юатмакчы булды. Сөтем беткән, ашатырга әйбер дә юк, дип пышылдады Надия.

Ничек беткән дип аптырады Мәгариф?! Мондый хәлләрне ишеткән булса да ул ышанмый торды. «Әллә узганмын инде?»— дип тагын да серлерәк итеп пышылдады Надия.

Мәгариф ана текәлеп карап катты, хатыны әле генә әйткән нәрсәнең галәмәтләрен Надиянең төсеннән чамаларга һәм, әгәр тапса, ачуланырга иткән шикелле иде. Бала һаман елый. Анын авазы астында Надия иренә карап: «Нигә шаккаттың, үзең бит, тыела белмисең»,— дип пышылдаудан ачыграк тавышка күчеп әйтеп куйды. «Кара, ничек курыктың, ә?»

— Монысын тәрбияләргә әмәл юк та...

Мәгариф баланы тирбәтә-тирбәтә идән буйлап йөренә башлады. Надия утырган килеш күкрәкләрен күлмәк эченә җайлап маташты, учы белән юеш битләрен сөрткәләде.

— Нишләргә инде, балага ни ашатырга?— дип Надия урыныннан авыр гына кузгалды. Аннары ипигә шикәр комы кушып чәйнәп марля кисәгенә тутырды, шуны балага каптырды. Бала елаудан туктап, шул ризыкны тырышып-тырышып суырырга тотынды.

Бала зәңгәрсу йөзле, ябык, көчсез иде — ашау җитми, нишләмәк кирәк. Бу тере валчыкны җәлләүдән йөрәге өзелеп төшә язды.

— Әллә макаронныйга йөк ташырга керим микән? Кич белән өч-дүрт сәгать эшләп кайтырга була, ди. Эшләгән өчен кайчак он да биреп куялар икән...

— Белеш соң...— диде Надия моңсу күзләрен баладан ала алмыйча. — Ярап куяр иде, анда манныйны да юнәтергә була, ди.

Бала йоклап китте, ләкин йокы аралаш имезлекне чуп-чуп китереп суырып алгалый иде. Юк, аның өстенә карап тору мөмкин түгел. Мәгариф карашын читкә алып, мич буендагы сандыкка килеп утырды да, тезләренә таянып, уйга калды. Надия, бар нәрсәдән өметен өзгән, читләшкән төстә, баланың имезлеген авызыннан алып, банкага салып куйды. Йоклаганда тынчыгуы бар иде. Ул Мәгарифкә дә өмете акланмаган, бизгән чырай белән күз кырыен төшереп алды да, караваткa килеп утырды. Икесе дә кайгылы уйга чумып, бер-берсенә карамыйлар, дәшмиләр. Авыр тынлык бала өчен тере кайгы белән тулган күңелләренә шырпы шикелле чәнчеп кадала, бимазалый иде.

— Бездә Таҗиева Динә исемле сестра эшли иде,— дип тынлыкны бозды Надия. Авыр кайгыдан әз генә булса да җанны арындыру өчен ни булса да сөйләшергә кирәк иде. — Шуңа бер бай тормышлы хатын килеп, биш йөз сум акча, он биргән, үзенә аборт ясарга тәкъдим иткән. Динә риза булган. Бик көчле уколлар белән эшен башкарган. Аннан икенчесе шулай ук зур бүләкләр, акча биреп укол ясаткан. Ләкин уңышлы булып чыкмаган. Бик авырайгач, ашыгыч ярдәм килеп алып киткән. Саклап калганнар. Ләкин укол ясаучыны әйттергәннәр... Таҗиевага биш ел биргәннәр, ди.

— Әллә сиңа да әйтеп карадылармы?— диде Мәгариф дәшми утыру җайсыз булганга күрә генә.

— Ничек кенә әле,— диде Надия кулларын күкрәкләре өстенә кушырып куеп. — Берсе ун кило манный ярмасы күтәреп килгән. Сумкасыннан алып күрсәтә — мине үчекләгәндәй. Менә ничек! Әтисе наркомнар столовое мөдире диме. Әй, чибәр, тулышып торган кыз. Миңа манный ярмасы кирәген дә белгәннәр бит! Шунысына чаклы исәпләгәннәр. Әлбәттә, мине яхшы белгән кеше аша эш йөрткәннәр. Менә нишләргә? Әллә бу бала бәхетенә тәвәккәлләп караргамы микән дим? Мин аның рәтен беләм болай...

Ул авыр итеп сулады, башын бер яккарак матур итеп кыйшайтып, Мәгарифкә карап тора башлады. Мәгариф аны шаярып сөйләшәме дип торса, ул чынлап икән. Надия бала өчен әллә нинди тәвәккәллеккә дә барыр шикелле тоелып китте. Чөнки аның йөзендә эчке уйлары тартышуның шәүләләре чагылып-чагылып куя кебек. Надиянең тиз, әмма ныклы карарга

килүчән бер чалымы бар. Мәгариф аның шул чалымына һәрчак каршы төшә, сакта торган шикелле ашыгыч адымнардан аны йола тора иде. Бу юлы да Мәгариф катгый булды.

— Башың ике түгелдер, ут белән шаярма,— диде каты гына итеп.

— Бәлки шома гына үтәр иде әле, ә? —Ун кило бит, юләр... Ун кило!

Надиянең иреннәрендә, күзләрендә шул манный ярмасына бик нык кызыгу, шуңа омтылу сизелеп китте.

— Юкка тәмгы сузма, бүтәннәрнеке үтсә дә, безнеке үтми. Үзең үк әйткәнең бар, нигә безгә гел кирегә килеп тора икән бу дип...

— Җан тели дә язык җибәрми шул,— диде Надия уфтанып һәм коридордагы керосинкага куйган бәрәңгесен карарга чыгып китте.

Мәгариф әтисе ягына узды. Ул ах-вах килеп диванда ята иде. Улын күрүгә зарланырга тотынды. Бүген керосинга бик озак чират торган, анда да бер канистр гына биргәннәр. Чират аркасында кемнендер җидесен үткәрү мәҗлесенә бара алмаган. Бер сүзеңдә тормасаң, кешеләр сиңа кул селти башлый, диде ул еларга җиткән тавыш белән. Үзенең мәҗлестә Коръән уку вазифасын бик тә изге эш итеп саный инде. Шул чаклы ышанса ышаныр икән кеше. Билгеле, бу ышануда тамак өлеше дә бардыр. Хәзерге вакытта бу да бик мөһим нәрсә. Һәр көнне диярлек ул ашта, сыйда. Тамагы тук йөри. Тамак бәрабәренә хәзер әллә ниләргә ышанып, әллә ниләргә табынырсың.

Мәгариф ана иртәгә утын белешергә Усиягә барырга кирәклеген әйткән иде. Фатыйх хәзрәт кинәт тузынып китте:

— Юк, юк, — диде, ул сеңер белән сөяккә калган кулларын селкеп. — Әнә таш язарга күпме заказ китерделәр.

Тәрәзәдән күренеп торган кечкенә утынлык янындагы цемент тутырган кәгазь капчыкларга ишарәләде. Ул бер дә кул кушырып утыруны белми. Цементтан плитә коеп, шуның өслегенә мәрхүмнәрнең исем-фамилиясен гарәп хәрефләре белән язудан шактый күп төшерә. Нигәдер шушы эшне күбрәк өни ул. Мәгариф кесә төбе коргаксыган, бик аптыраган чакларда, горурлыгын җиңә-җиңә, аның катына бара. Картның кесәсендә һәрчак акча өзелми. Бу акчаны алу Мәгарифкә гаять авыр, чөнки дин аша кергән, ягъни кешеләрдән хәергә алган сумнар алар. Динне ул бары акыл өйрәтү һәм кешеләрнең наданлыгыннан явызларча файдалану дип кенә карый. Шулай да әтисе биргәнне алмыйча да хәле юк. Хәлләр бик каты китереп кысса, берни эшли алмыйсың. Бала бар, хәзер чыгымнар шактый арта башлады. Надиягә кышкы пальто кирәк. Әнә хәзер каракүл тиресеннән яка куялар. Каян аласың аны? Хакы бик хәтәр. Надия кемнән ким? Аның да каракүл якалы пальто киясе килә. Карт үзе сөйләнеп торды, бер бай гына тормышлы кешегә ашка барган икән. Хуҗа Кирленторгта эшли, ди. Ике каракүл яка табып бирергә вәгъдә иткән. Бик фартовый кеше, сүзендә торта торган булырга тиеш, дип авыз суын корытып алды. Яка миннән булыр дигән сүз дә ычкындырып аткан. Менә нишлисең инде моның белән?

Мәгариф ана манный ярмасы хакында сүз катарга оялды. Бер баланны да туйдыра алырлык булмагач, ник чалбар киеп йөрисең, дияр. Фатыйх карт бик япьтәш кеше, теләсә нинди шартка җайлаша, яшәргә җай таба. Тәмам эт каешы булып беткән...

Шулай да каян табарга икән шул ярманы? Беркөн базарга чыгып караган иде, бик кыйбат сорыйлар, якын килерлек тә түгел. Ахырда бер вещмешок бәрәнге алып кайтты. Көздән запас әзерләп булмаган иде. Уңыш бик начар, диделәр. Шәһәр тирәләрендә авыллар ярлы. Чөнки җирләрнең бер дә рәте юк: сары ком да кызыл балчык. Бернинди тәрбиясез. Үсемлеккә дә ашлама кирәк бит. Тиресләрне ташу вакытында суга агызып бетерделәр...

Лена таба ала инде ул ярманы, ләкин ана ялынасы килми. Һаман да шул хәерче горурлык. Ул гына түгел, Лена да үз эше бәрабәренә нидер сорар. Хәзер бар нәрсә — баш на баш. Ә мин нәрсә табып бирә алам ана? Надия аша әллә бирәр дарумы? Әнә новокаин дигән дару бик модага кергән икән. Шунын уколын ясаткан кеше яшәреп китә, сырхауларыннан арына, имеш. Ленага новокаин кирәк түгелме икән? Моны ничек белергә? Манный ярмасын табарга шул дару ярдәм итмәсме?

Әллә ясле мөдире белән сөйләшеп караргамы? Баланы ашатмыйлар, ул көне буе ач ята. Шуна күрә үсеше дә юк, анын кебекләр тәпи йөри, ә бу үрмәләп тә китә алмый.

Малайны алырга кергәч, Мәгариф мөдир хатынны коридорда очратып сүз кушты. Юк, ул баланы ашатмыйлар дип авызыннан да чыгармады. Анын йомшаклыгы, ябыклыгы һәм һаман авырып кына торуы турында зарланды. Әмма әйтәсе килгәнне дә тел төбеннән сизәргә була иде. Мөдир хатын шомарган таш күренә, нәрсәдер чамалап алды һәм сүз белән адаштырырга кереште.

— Әнисе әллә врачмы?— диде бик тирән һәм сыналган фикер әйткән кебек йөзендә нурлар уйнатып.

— Әйе, сестра булып эшли,— диде Мәгариф, шунын белән мөдирне бераз өркетергә теләп. Чөнки врач халкы бала организмын яхшы белә, аларны коры кибәккә утыртып булмый дигән уй урнашсын мөдиргә, шул чагында ул икенче төрлерәк сайрар, балага игътибарны арттыра төшәр... Мәгариф шулай уйлаган иде, ләкин мөдир кайгылы йөз чыгарды:

— Врач-сестраларнын балалары шулай йомшак була шул. Никтер инде, үзебез дә гаҗәпләнәбез...

Мәгариф анын сүзләренә ышанмады, ялганлыйсын дип тә йөзенә бәреп әйтә алмады.

— Юк, сез дөрес уйламыйсыз,— диде Мәгариф кисәк кенә.

Мәгарифнен ышанмасын белеп, теге чәчрәп чыкты:

— Менә йомшак балаларны юри тикшереп кенә карагыз, барысы да врач-сестраларныкы!

Күз алдында кычкыртып алдый иде мөдир. Мәгариф ышанмаганын ныграк белгертеп, башын як-якка чайкап торды. Тегесе тагын күзләрен түгәрәкләндереп, үзенекен тукырга тотынды. Әмма Мәгариф анын белән мөнәсәбәтне бозмаска кирәклеген эчтән генә уйлап өлгерде һәм йөзенә килешкәнлек төсе чыгарды.

— Шулай инде, бик мөмкин,— диде тегенен күнелен үзенә авыштыру өчен генә.

Хәзер хатын-кыз сүзе өстен чыга... Әнә Лена да ир-атнын шул йомшаклыгыннан оста файдалана. Юньләп яза алмавын барысы да белә, ләкин беркем дә шуны әйтми, дәшми үткәрә. Лена эшләп түгел, кешнәп ярый. Буй-сыны ярыйсы гына, бит-йөзе дә күз төшәрлек, үзе телгә беткән. Сүзе һәм кыланышлары белән ир-атнын эченә үтеп керә белә. Лена Мәгарифне үзләренен тар даирәдә була торган аулак кичәләренә дә дәшеп караганы булды. Икесендә дә Надия төнге дежурда иде. Әллә шуны белеп юри чакырды микән? Күнсә, Надия берни дә белми калыр иде. Баланы әнисенә калдырып китә ул... Ленага болай нәфсе күзе төшеп йөрсә дә, Мәгарифнен йөгәнсезләнү хакында ишетәсе дә килмәде. Киресенчә, ул кыздан нигәдер курыкты. Анын сүзен уенга борган кебек итеп, шаяртып алды. Кыз көлде генә.

Тарикнын шушы сиртмә койрыкны житди сотрудникка санап йөрүе бер дә ошамый ана. Әмма Тарикнын да нәфсесе бар бит, дип аны аклагандай итә Мәгариф. Хатыны карт, үзе әле янып тора. Лена аны да үзенен тозагына

эләктергән кебек сизелә. Неужели шулай булыр икән, дип Мәгариф үз-үзенә ышанмаган сыман итенә. Бәлки бу минем нәфсемнән килеп туган шигемдер? Канәгатьләнмәгән нәфсе һәм башлыкның аны миннән өстен санавы әллә нинди начар уйларга этәрүе мөмкин бит.

Манный ярмасын беркайдан да юнәтергә мөмкинлек юк иде.

— Сезнең госпитальдә булмый калмас,— диде Мәгариф баласын яслегә киендергәндә. — Әллә сорап карыйсынмы?

— Продукт тирәсендә барысы да караклар,— дип кул селтәде Надия. — Мин дә шуларга кушылыйммы?

— Бала өчен бар нәрсәгә дә риза булырсың.

— Анда якын килерлек түгел, Мәгариф җаным, әле яңа гына ике каракны утырттылар. Хатыннары һаман елап госпиталь начальнигына йөриләр.

— Мин бу бала өчен урларга да курыкмас идем, валлаһи!— диде Мәгариф. Урлар идеме, юкмы, әмма шушы минутта туган чын фикерен әйтте ул.

Надия ана күз кырыен гына төшереп алды һәм эчке бер соклану тулы елмайды. Мәгарифнең баласын шул чаклы яратуы күнеленә май булып ята. Һәм хәтеренә күп үткәндәге хәлләр дулкын-дулкын кебек килеп, җанын тутыра башлый. Эчендәге дулкыннарын сиздермәс өчен ул баланы ашыктыра-ашыктыра киендерде һәм Мәгариф кочагына бирде. Аларны күз алдыннан тизрәк озатасы килгән шикелле иде.

Ире каршында Надия үзен һаман гаепле итеп сизә. Бу хис онытылыр, ярату аны оныттырыр һәм күмеп китәр дип көткән иде. Әмма көткән нәрсә никтер килми, кылган гөнаһ һич тә күмелми, онытылмый. Киресенчә, көчәя генә бара, куркынычы артканнан-арта гына. Әллә Мәгарифкә чынын сөйләп бирергәме? Минем ялганымны гафу итәрме икән?

Бу хакта икеләнмәскә мөмкин. Мәгариф аны шундый ярата. Ә ярату хисенә таянып була микән? Бүген бар ул ярату, ә иртәгә кинәт кенә бетеп куюы да мөмкин. Моторда бензин беткән кебек. Юк, аңа ышану бик беркатлылык булыр иде. Шуның аркасында мин Мәгарифне югалтып куюым бар бит. Юләр! Ихлас күңел белән мин ни ота алам? Берни дә! Киресенчә, бик күп нәрсәдән мәхрүм калам. Мәгариф әйбәт җанлы кеше, ләкин миннән чынын ишетсә, күңеленә бик зур яра булачак. Юк, аны яраларга ярамас. Яраланган җан үзенең ни эшләгәнен белештерми, кызулыктан берәр ахмаклык кылып ташламагае. Мәгариф тәэсирчән кеше, күбрәк йөрәгенә алып эш йөртүчән. Шуңа эшләре бик җиңелдән бармый... Ә нишләргә соң? Болай җанга гаять авыр. Һәрдаим йөрәкне чәнчеп, авырттырып тора. Әллә Мәгарифтән аерылып, бала белән үзем генә калыргамы? Ичмаса, үз-үзең каршында намуслы булыр идең. Юкса, упкын кырында яшәгән кебек. Менә-менә ялганың тотылыр да, бар тормышыңның асты-өскә килер. Һәр көнең ничектер тирән упкын ярыннан курка-курка барган кебек... Таеп китмим, тая күрмим дип һәр адымны саклап, бик күп көч түгеп атлыйсың. Бу авыр киеренкелек үзенең нечкә кынында гына сине тотып тора кебек.

*Ахыры киләсе санда*



Мөхәммәт
Мирза

# БЕРБӨТЕНЛЕК ХАКНЫҢ ТАЛӘБЕНДӘ

## Соң булмаса...

*...Җаныңның ваклыгын*
*Сылтама заманга...*

Р.Файзуллин

**1**

**Заман яраклаша белгән**
**бәндәсенә хәерхаһлы.**
**Йонлы куллы елгырлары**
**калмас ярык тагараклы...**

**Заман кемнең кулындадыр,**
**үзгәрде дә куйды барсы...**
**Тамгасы — куш бөркет башы,**
**кайсы бүре, кайсы аю,**
**Бар арслан, юлбарысы...**
**Елгырлар бүлде җир өстен,**
**бүленеп бетте җир асты...**

**...Заманнан артта калганга**
**Йөз мавродий сузды кулын...**
**Саламга ябышып күпләр**
**югалтты соңгы сыныгын...**

**Базар — сатудан, алудан**
**гайре һич ни дисәләр дә,**
**Асылында берсен-берсе**
**басып, таптап иңсәләрдә**

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; «Киек каз юлында», «Тере су», «Адәм баласы», «Елганың аргы ягында» h.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Мал талыйлар, мал бүләләр,
көчләренә ала мулын.
Мал! — дип чәйнәшеп үләләр —
кыргый базарның канунын
Үзгәртә алмаган кем дә
йөз гасырлар агышында,
Җаннары беткән вакланып,
алдау, талау табышында.

2

Дөнья малы мәңге бетмәс,
күчәр кулдан-кулга гына...
Күчемсез милек кулае
канун итеп кулланырга.

Һәр төбәкнең үз абрамы...
семиннары, ваминнары
Халык милкен көрәп алды —
Яклый, хаклый кануннары.

Күчемсезлеккә күчереп
бетерделәр дәүләт малын.
Патша, вәзир, морза, бәкләр
өр-яңадан калыкканын
Күреп гавам калды өнсез,
талау барды берөзлексез.
Кайчан, кайда, кемнең булган
бу кадәр милке күчемсез?

3

Халык вәкилләрен «сайлап»,
«Люпин» ясадылар хакта...
Канунчылар - халык милке
тамырына чапты балта:
Кануннарын күчемсезлек
мөлкәтенә яраштырып,
Үзләренә акмаса да,
тамачагын караштырып...

Милләт байрагы астына
өндәделәр тупланырга.
Мал, мөлкәтсез әләм-чүпрәк
нигә ярый кулланырга!

Нигезләмә, кулланмалар
күчемсез милек сагында...
Байрак, гим(ы)н — гавам өчен,
милке — байлар маясында...

4

Күчемсез мал иясенең
тәхете дә күчемсездер...
«Дәүләт - халык өчен!» дию —
берни түгел — төче сүздер...

...Тарих кабатлана диләр,
Әйләнеп басар куласа...
Дәүләт — сыер, гавам—сарык
Аттан яман бер дуласа...

Замананы хурлап кына
Хөрлек үзе килмәс ләса...
Тагын унҗиденче елны
Көтеп карыйк... соң... булмаса?!.

***

Дусларың бизмәсен, дисәң,
хәсрәткә тарма икән.
Урталыкның арбасыннан
егылып калма икән...

Туганың бизмәсен, дисәң,
әҗерең алма икән...
Искене ямап кисәң дә,
әҗәткә калма икән...

Дошманың бизмәсен, дисәң,
көн—төн чап, арма икән.
Арып аусаң, таптап узу
әхлакый норма икән...

Дустан — дошман, туганнан дус
бизендерер бер ара...
Дус—дошман бизәр, туганың
барыбер янда кала...

***

Бер күк астында яшәп тә,
күп төрле язмышлары.
Кемдер килә, кемнәрнеңдер
үтеп үк барышлары...

Язмышлар күктә языла —
Бер Хакның ихтыяры...
Язылганына разыйлар
Бәхетен тизрәк табыр.

Килү—китү арасында
бертуктаусыз юл икән.
Гомер итү чарасызлык,
урап үтү юк икән...

Үтелгән юл — күк күзендә
бер ачып йомган ара.
Сүтелгән йомгак шикелле
эзе сузылып бара...

Шул эзләргә шыплап тулып,
Яңа буыннар үтә...
Һәр мизгеле хәтер булып
Язылып бара күктә...

***

*(Х.Ә.Фәйсалга ияреп)*

**Табигый сайланыш — катгый канун,**
**Ташлама юк, юк бер искәрмә.**
**Тарихында килеп киткәннәр күп,**
**Тарихта урын юк хисләргә...**

**Килү–китүләрнең сәбәбендә**
**Гыйбрәтләнеп сабак алырлык.**
**Бербөтенлек Хакның таләбендә**
**Һәлакәттән саклап калырлык...**

**Һәлакәтен чигендерә алган**
**бөгелсә дә, сынмас, тураер.**
**Бүленсә дә — кабат якынаер,**
**Туганнарын җыеп зураер...**

**Рухи берлек аркадашлык итәр**
**Иңнәренә куеп иңнәрен.**
**Бердәм өммәт даны ерак китәр,**
**Сындырып җаһиллек җилләрен.**

**Тарихында килеп киткәннәр күп.**
**Гыйбрәтләнеп тагын ни әйтим?**
**Өммәтеннән көч–кодрәт алыр да,**
**Тураеп ук басар милләтем.**

***

**Борынгыдан килгән Идел–Йортта**
**Варислары булып чәчәннәрнең.**
**Бер Хак, шөкер, үзе тәкъдир итте**
**Монда туып, монда яшәүләрне...**

**Ана сөте белән Җанга иңгән**
**Илсү, җирсү хисе төкәнмәслек.**
**Гасырларның аръягыннан килгән**
**Илне өстен кую — төгәл мәсләк.**

**Иле булса гына кавем халык**
**Исеменә лаек сан алачак.**
**Мәңгелеккә барыр юлын табып,**
**Милләт булып җирдә саналачак.**

**Иле булса гына кара төннең**
**Күләгәсе аңар төшмәячәк,**
**Җаһиллекнең зәһәр җиле кубып,**
**Салкыннары җанын өтмәячәк.**

**Халкын илле итәр Ир лачыны,**
**Илен имин итәр Шаһ ирләре.**
**Рухи күге капусы ачылыр,**
**Сынлы, санлы булса шагыйрьләре...**

***

**Сорау арты сорау туып торыр,**
**Җавабы да бәлки табылмас.**
**Дәүләте булмаса, милләт корыр**
**Котылгысыз килер инкыйраз...**

**Дәүләте булмаса ябырылып**
**Ана телен таптап изәрләр...**
**Тәһарәтсез кавем ятагында**
**Иң ахырдан диннән бизәрләр...**

**Шул язмышка тарган күпме ыру**
**Безне дә бит шуңа өндиләр.**
**Бердәй бүленмәс ил бер буладыр...**
**Үз хәлеңә көн дә күн диләр...**

***

**Козгын кунды өйнең түбәсенә,**
**Хәбәре — хәтәрдер, сизенәм...**
**Утырды да бер тын, тын чыгармый**
**Кубарылып очты тиз генә...**

**Ни дип юрарга да шүрләп торам,**
**Ни юрасаң, беләм киләсен...**
**«Үз башыңа төшсен!» — дия күрмә,**
**Атканың үзеңә тимәсен...**

**Козгын хәбәрендә кисәтү бар,**
**Сынаганнар элек-электән...**
**Күрәчәген күрми,гүргә керми —**
**Бәндә тәкъдиренә береккән...**

**Үр менгәндә кемне гүре көтә,**
**Кем туенда кемнең матәме?**
**Мәңгелеккә килми бер кеме дә**
**Кемдер шуны, йә, үзгәртәме?**

**Утырды да бер тын, тын чыгармый,**
**Күтәрелде кинәт болытка.**
**Фанилыктан качып китеп булмый...**
**Килгәч, китү барын онытма.**

**Тын чыгармый очып китүен дә**
**Юрыйк әле, әйдә, уң кылсын...**
**«Үз башыңа төшсен», — дия күрмә,**
**Кош хәбәре — илаһи тылсым...**

## Көздә бер мәл...

**Колмак асылынган алмагачка,**
**салмак кына җилдә атына...**
**Каңгылдашып соңгы казлар оча**
**җитеп ак болытлар катына...**

Кәгазь көле кебек караланган
әрекмән беренче кыраудан...
Сүрән кояшының тансык нуры
көз пәрәвезенә уралган...

Бөтенесе көтеп тора кебек,
кемдер ни дә булса кыласын...
Шунда кинәт көчәеп нәзек җил
сызгыртты бакчамның курасын...

## Миндә көзләр салмаклыгы

Карар итәрлек чигенү
котылгысыз идеме?
Хәбәрсезлек хәбәреңнең
угы җанга тидеме?..

...Ташыганда ишелә яр,
йә качып китә инеш...
Миндә көзнең салмаклыгы
китмәскә килгән килеш...

Миндә көзнең салмаклыгы,
Синдә язның ташкыны...
Вакыт битараф хисләргә,
барысына баш кылыр...

Эзләп кайтыр инеш ярын,
Тал–курпы сарган булыр...
Дулкыны кагып тормагач,
шавы да ялган булыр...

Урап узган яңгырның ни
Сихәте бар гөлләргә?..
Чигенүең чарасызлык
булып басар көннәрдә.

Хәтереңнең чормасыннан
ургып торыр сагыш... моң...
Миндә көзләр салмаклыгы...
Син дә тынып калырсың...



Әсгать Салах

# АККАН СУЛАР...

ЯШЬЛЕГЕМ ХАТИРӘЛӘРЕ

## Тәүге яралар

Әй, гомер, гомер! Тынгысыз дәрья кебек агасың да агасың. Кеше дигән олуг затың бу дөньяда бәрәкәтле эш кылып, бәхет һәм шатлык, хөрлек вә хозурлыклар татып кына яшәргә хаклы булса да, шактый көне михнәт, моң-зар, кайгы-хәсрәт, әрнү һәм сыкраулар белән үтә.

Без — сугыш чоры балалары. Үземне белә башлаганнан бирле үткән гомерем турында уйланып утырам да, сагышланып, монсуланып куям.

Хәтердә калганнарның иң тәүгесе — дүрт почмаклы бәләкәй һәм иске өйнең ярым бозлы тәрәзәсеннән өй алдына карап торганым. Күрше йортның өй түбәсенә чаклы салган кар тавыннан балалар чана шуа. Алар арасында миннән биш яшькә олы Ризатдин абыем һәм өч яшькә олы Рәйсә апам да бар. Алтынчы яшендәге Рәйсә апаның өстендә жете кызыл бишмәт. Шул бишмәтендә ул әллә кайдан күренеп тора. Әни: «Рәйсә, мескенем, ул бишмәтне бик яратты. Ә син аны күрү белән: «Мики (минеке)! — дип тартыша башлый идең», — ди. Үз бишмәтем булмаганга тартышканмындыр инде.

Өстәл артында җиделе лампа яктысында Ризатдин абый дәрес хәзерләп утыра. Ул инде беренче сыйныфка укырга кергән булган. Түгәрәк хәрефләр чыгарып яза, китаптан иҗекләп укый. Авылыбызның мәшһүр укытучысы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденына ия, хәзер инде мәрхүмә Фатыйма апа Бәхтиярованың: «Ризатдин абыең бик зирәк малай, укырга теләге һәм сәләте белән башкалардан аерылып тора иде», — дип искә алып сөйләгәне хәтердә.

Мин Ризатдин абыйның китапларындагы рәсемнәрне караштырам, аның да миңа рәсем ясап бирүен сорыйм. Ул ат рәсеме ясап бирә. Атны бик оста, матур итеп ясый иде.

Әсгать САЛАХ (1935) – *язучы, публицист; «Каеннар юлы», «Сүнмәс моң», «Балыкчы малайлар» һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

Ике олы туганым турында хәтердә калганнар шуның белән тәгәлләнә дә бугай. Чөнки 1937 елның кышы алдыннан Елховой авылына балалар өчен үтә куркынычлы скарлатина (кызылча) дигән йогышлы авыру килеп керә. Һәм бер атна эчендә башта Ризатдин абый, аннан соң Рәйсә апа мәңгегә күзен йома.

Елховойда ул елны дистәләгән баланың гомере өзелә, чөнки Рәсәй җирендә медицина дигән фәннең ул вакытта скарлатинага да каршы торырлык көче булмаган.

— Ризатдин бик тиз авырып китте, тәне кызу булды балакаемның, сөйләшергә дә хәле калмады, — дип искә ала әни ул кайгылы көннәрне. — Төнлә үләр алдыннан аңына килеп: «Әни, мин... сезнең белән...» — диде дә, тынып калды. Нәрсә әйтергә теләгәндер, балакаем, бүгенге көнгә кадәр шул сорауга җавап таба алмыйм. «Әни, мин сезнең белән ятыйм әле», — диясе килдеме аның үлем куркынычы янаган вакытта ата-ана куенында үлем тырнагыннан котылуга өмет тотып, әллә терелә калган очракта алгы көннәрдә безнең белән берәр кая барырга теләвен белдерәсе килдеме?

Минем күз алдымда әле дә булса шундый күренеш тора: бер башын сәкегә, икенче башын идәнгә терәп куйган киң юкә кабыгында җиде яшьлек абыемның гәүдәсе ята. Аны юалар. Ә мин сәкедә утырам. Кинәт тәрәзә төбендә мин зур кыргаяк күреп алдым һәм куркып кычкырып җибәрдем. Өй эчендә ыгы-зыгы килгән туганнар, күршеләр: бала абыйсының үлгәненә тәмам инанып, куркып кычкырды, дип уйладылар булса кирәк, мине каядыр алып чыгып киттеләр.

Гүзәл Рәйсә апамның ничек үлгәнен, аны күмгәннәрен бөтенләй дә хәтерләмим. Өченче яшьтәге малайның тормышыннан алар икесе дә кинәт юкка чыктылар.

Бала үлү — канат сыну. Ике баласын бер атнада югалткан әни бу фаҗигане бик тирән кичерә, хәтта исәрләнеп тә ала. Мәрхүм балаларына багышлап бәетләр чыгара.

— Тавышлары гел колак төбендә торды. Җәй көне болытлар куера башласа, шашу хәленә җитәм, шул болытларда балаларым сурәтен күрә башлый идем. Ә кайчакта йә Ризатдин, йә Рәйсә мич артыннан килеп чыга — шулай күземә күренәләр иде, — дип сөйли ул.

Әллә кизү йогышы миңа да тәэсир иткән, әллә башка бер-бер хәл беләнме — ул көннәрдә сәламәтлегем начарланган булган: хәлсезләнгәнмен, ашамаганмын. Әти белән әни кабат пошаманга калганнар:

— Әллә бусы да китәргә җыена инде... — дип, әти ашый торган җиреннән кашыгын шык итеп өстәлгә куя торган булган миңа карап. Бәхеткә, мин каты авырып китмәгәнмен, хәтәр кизүдән исән калганмын.

Кызылча корбаннары — алар авылыбызда утызлап булган — күбесе Хәбибулла бай нәселе зиратына күмелгән. Әүвәл елларда хатын-кызны зиратка кертү тыелганга, әни балаларына үлгән туганнары җирләнгән урыннарны чама белән генә әйтеп калдырган иде. Үткән җәйдә гомерем буена йөрәгем түрендә сакланган туганнарым һәм башка сабыйларга атап, шул зиратка ак мәрмәрдән таш куйдым. Анда мондый сүзләр язылган:

*«Бу таш 1937 ел көзендә авылыбызда котырган кызылча (скарлатина) кизүе вакытында вафат булган сабыйлар:*

*Ризатдин Сәхап улы Салахов (1930)*

*Рәйсә Сәхап кызы Салахова (1932)*

*Минхәят Кәли кызы Шакирова (1932) һ..б. истәлегенә куелды.*

*Урыннарын җәннәттә әйлә, Ходаем!*

*Язучы Әсгать Салах*

*2012 ел, август.»*

***

Ул елны ярлы татар авылларының гөнаһсыз сабыйларын кырган скарлатина кизүе үзенә бер төрле котырынса, кара халык аңлап бетермәс сәяси тормышта җәллад Сталинның репрессия дигән кизүе икенче төрле котырынган. Тегесе дә, бусы да безнең нәселгә күз яше, хәсрәт, үлем алып килгән. Икенче улы Сәхабетдинның бер атнада ике йөрәк парәсе гүр иясе булган көннәрдә — 4 ноябрь таңы алдыннан Елховойга район үзәге Чирмешәннән «кара козгын» килеп төшкән һәм иртәнге намазыннан кайтып килүче алтмыш җиде яшьлек, бер күзенә ак салган, бер кулы гарип Салахетдин картны НКВД козгыннары алып китәләр һәм мал суештыргалап итен базарда сатып, алты баладан торган ишле гаиләнен авыр тормышын очын-очка ялгап алып баручы ярлы авыл крәстиәнен кулак дип атап, аны колхозлаштыруга каршы агитация алып баруда гаепләп, башбаштак «тройка» карары нигезендә үлем җәзасына хөкем итәләр һәм 1938 елның 7 гыйнварында Бөгелмә төрмәсендә атып та үтерәләр. Ләкин бу турыда авылда бу вакытта берни дә белмиләр әле.

Салах бабайны мин бер күренештә генә хәтерлим. Ишек алдында иске сары тун, төп салган кызыл бизәкле ак киез итекләр кигән урта буйлы бер карт басып тора. Аннары ул өйгә керде. Әнинең озак еллардан соң сөйләвенә караганда, бабай ул көнне «читтә» йөреп кайткан кече улы Әгъзаметдинне эзләп килгән булган. «Чит»тә аракы чөмерергә өйрәнгән Әгъзам абый авылда кунак булып, салгалап йөргән, ә бер көнне атасы йортына исерек килеш кайтырга базмыйча безгә килеп кергән һәм идәнгә ауган. Бабайның: «Ах, мәлгунь, ах, төртмеш», — дип орышынганын, идәндә яткан Әгъзам абыйның аякларына типкәләп чыгып киткәнен яхшы хәтерлим.

Озакламый Әгъзам абыйны армиягә озатканнар, ә тагын бераздан бабайны «халык дошманы» дип кулга алганнар. Шул китүдән бабай да, Әгъзам абый да туган авылларына әйләнеп кайта алмаганнар.

Озак еллар үткәч, минем Салах бабам язмышы турында белешеп язган хатыма каршы Татарстан АССР прокуратурасыннан җавап килде. Менә ул:

«Справка о реабилитации. Зарипов Салях Зарипович, 1875 года рождения (чынында 1870 елгы. Ә.С.), уроженец деревни Елхово Первомайского района ТАССР, из крестьян, беспартийный, по национальности татарин, арестован РОНКВД Первомайского района 4 ноября 1937 года.

По постановлению тройки НКВД ТАССР от 28 декабря 1937 года Зарипов С.З. расстрелян «За проведение антисоветской, антиколхозной агитации, за распространение клеветы по адресу советской власти и колхозного строя».

Указом Президиума Верховного Совета СССР от 16.01.89 года «О дополнительных мерах по восстановлению справедливости в отношении жертв репрессий, имевших место в период 30-40-х и начала 50-х годов, постановление отменено. Зарипов Салях Зарипович реабилитирован. Прокурор Татарской АССР, Государственный советник юстиции 3 класса О.М. Антонов. 16.06.1989».

Салкын, җансыз, артыгы белән рәсми җавап. Һичбернинди аклану, кылган гөнаһка үкенү яки гафу үтенү юк: расстрелян, реабилитирован... Ә сез теләсә нишләгез! Бердәнбер күңел юанычы — хакыйкать үзен-үзе яклый.

***

Әгъзам абый көнбатыш чигендә хезмәт иткән. Аның Силижар, Острогожск, Запорожьедан хатлары килгән. Хатны сирәк язган. Армия хезмәтен тутыруга да карамастан, аңа туган якларына кайтып китү бәхете тәтеми, кинәт башланып киткән сугышның дәһшәтле утында беренче

көннәрдән үк ялгыз күбәләк кебек көеп, югалып калган. Аның соңгы язмышы турында без бүген дә һичбер хәбәр белмибез.

Кызганыч, Әгъзам абый безнең нәсел өчен коточкыч сугышта югалткан беренче корбан булмады. Әле яңа гына Салах картның иң төпчек кызы гүзәл Нуриягә өйләнгән Кара Хәертдин улы Шәмсетдин Вилданов та сугышның башы белән фронтка озатыла һәм кыска вакыт эчендә ул да шулай ук хәбәрсез югала.

Озын, зифа буйлы, мәһабәт гәүдәле, шаян сүзле, акыллы һәм төпле егет буларак хәтердә калган Шәмсетдин җизни дә миңа бик якын иде. Апаның бертуганнары балалары арасында Шәмсетдин җизнинең иң яратканы мин иде дисәм — һич ялгышмам. Моның сәбәбе гади: ул безнең әтидә үзенең дустын һәм киңәшчесен тапкан, аны һәм әнине хөрмәт иткән. Яшь булса да, ул алты кырчылык бригадалы олы колхозның бер бригадасын җитәкли иде. Аның җиңел арбага җигелгән яхшы аты еш кына безнең капка төбенә килеп туктый. Йөзендә елмаю. Балалар белән шаярып ала да, олылар белән чәй эчә-эчә озаклап дөнья хәлләре, үз мәшәкатьләре турында гәпләшә. Аннан кабат басуга юнәлә, үзе белән мине дә ала. Юлда без үзебезчә сөйләшәбез, йә булмаса ул кычкырып җырлап җибәрә, мине дә җырларга кыстый. Аның белән кырда йөри-йөри мин тәмам алҗып, арбадагы хуш исле яңа чапкан үлән өстендә йоклап китәм.

Бу — балачакның иң бәхетле мизгелләре булгандыр!

Такташ әйтмешли, дөнья белән танышып йөрүне мин ярата идем. 1940 ел җәендә әти мине Шонталы тимер юлы станциясенә алып барды. Урып-җыю вакыты. Тракторларга һәм сугу машинасына ягулык алып кайтыр өчен колхоз станциягә берничә олау җибәрде. Һәрбер олауда бер тимер мичкә. Авылдан көндез чыгып киттек. Кичке якка Беренче Май районы үзәге Чирмешәнгә килеп төштек, «Елхово» колхозы фатиры булып саналган Питраучларга (Петровлар, әлбәттә) кереп кундык. Питраучларда мин тәүге тапкыр радио тавышын — диварга элгән кара тәлинкәдән Казаннан соңгы хәбәрләрне, татар концертын ишеттем. Таң атканчы ук торып без Шонталыга юл алдык. Йоклый-йоклый барсам да, күз ачылган минутларда шаулап торган урман арасыннан биек-биек агачларны күзәтеп баруым, әтинең ара-тирә атка: «На-а, әйдә, хайван!» — дип эндәшүе, аннан соң үзенең моңлы итеп җыр сузуы, Шонталыга җитәрәк урманны ярып яңгыраган поезд тавышы, безнең юлны аркылыга кисеп үткән тимер юлдан, әкияттәге дию пәрие кебек пошкырып, дистәләгән вагоннар таккан паровоз килеп чыгуы минем күңелдә бүген дә онытылмас хатирә булып саклана.

...Караңгы өй эче. Күрәмсең, кояшлы көн булмаган. Өстәл артында әти чит-ят бер кеше белән ашап-эчеп, сыйланып утыралар. Теге кеше түгәрәк матур йөзле, күпереп торган кара чәчле. Үзе бик пөхтә киенгән. Аягында затлы, күн белән каймалаган ап-ак фитр итек.

Әтинең яшьлек дусты, язучы Ләбиб Гыйльми булган икән ул. Балачаклары бер урамда уйнап, бер мәдрәсәдә, бар парта артында укып үткән икән аларның. Икесе дә ишле гаиләдән. Әти безнең бик зиһенле малай булып үскән, яхшы укыган. Элеккеге мөгаллимнәрнең бик акыллы гадәте булган: яхшы укыган балаларны укытуда үзләренең ярдәмчеләре итеп файдаланганнар. Сәхабетдин дә шундыйлардан булган. Бер вакыт ул авырып киткән, аяклары тыңламас булган. Мәдрәсәгә аны Ләбиб һәм башка шәкертләр күпмедер вакыт күтәреп йөрткәннәр.

Татарстан комсомолының икенче секретаре, ВЛКСМ киңәшчесе буларак Монголиядә комсомол эшен җайга салып кайтканнан соң республика язучылар оешмасы рәисе булып торган елларда Ләбиб Гыйльми сирәк-мирәк Елховойга, әнисе Камилә әби, башка туганнары янына кунакка

кайта һәм кайткан саен дусты Сәхап янына керә торган булган. Ул ана күргәннәре, эше, ижаты, киләчәккә планнары турында сөйли, уңышлары белән уртаклаша. Аннары малай чактагы кебек алар Шушма буена балыкка төшеп китәләр...

Ләбиб Гыйльминең бер хикәясе «Сәхап» дип атала. Анда ятим малай язмышы тасвирлана. Дусты Сәхап бу хикәя героеның прототибы ук булмаса да, әсәрне шулай дип атаганда автор дустын истә тотмый калмагандыр. Әни әти белән Ләбиб Гыйльминең «Чын мәхәббәт» романын, «Чемит Дурже», «Чалкаш», «Сәрән күпере» хикәяләрен (Урыс Сәрәне дигән авыл Елховойдан өч кенә чакрымда, ә Баграш дигән елга аркылы салынган күпер исә тагын да якынрак), «Совет әдәбияты» журналының 1933 һәм 1934 елгы саннарында монгол халкының батыр улы Сухэ-Батор турында яза башлаган зур әсәре — «Эмигрант» романыннан өзекләр укуларын сөйли иде без үскән чакта.

Кызганыч ки, 1937 ел ахырында Сәхап ике баласы белән атасын гына түгел, якын дустын да югалта, чөнки Ләбиб Гыйльми дә НКВД корбаны була.

Ләбиб белән генә түгел, Гыйльман картның Бәһман һәм Минәхмәтләре белән дә уртак тел табып яшәгән Сәхап. Хәтердә, 1940 елның кояшлы һәм жылы жәе. Бәһман абзый читән тота. Өч кырлап юнаган очлы казыкны жиргә бер утырта, як-якка селкетеп тартып чыгара да, чокырга су салып казыкны тагын ныклап утырта. Безнең әти аның янына чүгәләгән дә, тәмәке көйрәтә. Үзләре хәвефләнеп дөнья хәлләре турында сөйләшәләр. Шул вакыт аяз күктә бик өстә нindидер гүләү ишетелә.

— Тагын ярыплан, — ди Бәһман абзый. Ул да, әти дә, мин дә текәлеп күккә карыйбыз һәм озак эзләгәннән соң көнбатыштан көнчыгышка таба зәңгәр күктә кара тап булып очып баручы самолетны күреп алабыз.

— Бик өстән оча — немецныкы, — дип хәвеф сала күңелгә әти. Һәм ул хаклы булган. Сугыш алдыннан Германиянең югары очышлы самолетлары СССР күгендә иркенләп очканнар, «хужалык иткәннәр», разведка ясап, рәсемгә төшереп йөргәннәр. Ә безнең самолетларның аларга «буйлары» житмәгән.

Ир-ат еш кына, сугыш буласын сизенеп, уйга батып шул темага сөйләшеп утыра иде. Шушы атмосфера безгә — балаларга да тәэсир итми калмагандыр.

Әле искә алган ел — 1940 ел иде. Әтинең ашыгып-ашкынып яңа өй салган елы. Өйне Сәвәләй керәшеннәре эшләделәр. Алар икәү иде. Берсенең исеме Иван икәнен хәтерлим. Кичен эшләрен туктатып, ашап-эчеп, кояш баеп барган кичке вакытта балта осталары койма буендагы бүрәнәгә чыгып утыралар. Иван дигәне скрипкасын сызып жибәрә. Скрипка тавышын ишетеп аның тирәсенә күрше-күлән, бала-чага жыела. Иван еш-еш бию көе уйный, балаларны биергә кыстый. Мишәр балаларының музыка дигәненне әле рәтләп ишеткәннәре дә юк, биюме соң аларга? Иван үзе уйнаган скрипкага кушылып үзе үк жырлап жибәрә:

Әкрен кирәк, иплән кирәк
Ишетергә
Сандугач сайрауларын...

Тәүге тапкыр бу моңлы керәшен жырын мин әнә шул балта остасыннан ишеттем. Һәм соңыннан кайда да булса ул жыр яңгыраган вакытларда күз алдыма ерак кырыгынчы елның жылы, йомшак жәе, усак агачыннан бурап салынган, инде өлгереп килүче алты почмаклы ап-ак яңа өй, ялтырап торган үткен балталары белән ике керәшен абзыйның тырышып агач юнаулары, тирә-юньдә аунап яткан йомычкалар килә. Йомычка исен бүген дә тоям сыман.

«Аккан сулар»ның өзекләре газеталарда күренә башлагач, миңа шул мәгълүм булды: Сәвәләй керәшене, скрипкачы Иван агай — танылган җырчыбыз Виталий Агаповның әнисенең атасы, ягъни Виталийның бабасы булган икән. Бер очрашуда ул миңа бу турыда тәфсилләп сөйләде. Әнисе иреннән аерылып кайткач, Виталий бәләкәй чактан ук җырга-моңга оста, авыл халкын сокландырып скрипкада сыздыра торган бабасы хозурында үсә.

— Мин бабайны искиткеч ярата идем. Аның өчен исә мин дә бик кадерле булганмын. Җырга-моңга талпынуым да бабайдан килде, ул миңа оеткы салды. Мин аны бүген дә бик сагынып искә алам. Мировой карт иде, урыны оҗмахта булсын, — диде Агапов.

Дөрес, ул елны өебез тулысынча эшләнеп бетми калган. Алты почмаклы йортның дүрт почмагы гына өлгергән, чөнки хәл җитмәгән. Ә икенче елда инде... Өй кайгысы булганмыни, Елховойга гына түгел, бөтен ил халкына афәт алып килгән дәһшәтле 1941 елда...

Сугыш алдыннан, әллә инде май ахырларында, әллә июнь башында, читтән Кытай Шәйдук абзыйның бер туганы кайтып төште. Кулында кыңгыраулы гармун, сыздырып уйный, кычкырып җырлап җибәрә. Аның кайтуы безнең төбәк ир-аты өчен чын бәйрәм булды. Әле утызын гына тутырган Сәхаплар, Шәйдуклар, Сөнгатлар белән бергә кырыктан узган Кости, Әбелгата, Шәймәрдан, Әхмәтзыялар, барлык мәшәкатьләрен онытып, аш әзерләтеп, чәен-мәен куеп, кыңгыраулы гармунга җырлап, дөбер-дөбер биеп, йорттан йортка кунак булып, гомердә булмаганча күңел ачып йөрделәр ул көннәрдә. Гармун тавышы ишетелгән йортка хәтта җиденче дистәсен куган Насыртдин бабай да килеп керә иде. Аның артыннан картын эзләп Таифә әби килеп җитә. Бераз кызмача Насыртдин бабай чәркәсен тоткан килеш җырлап җибәрә:

Син дә кердең ишектән,<br>
Мин дә кердем ишектән;<br>
Безнең монда утырганны<br>
Таифә каян ишеткән?

Таифә әби «азгын» картын тирги-тирги, тарткалый-йолыккалый алып чыгып китә. Ә өйдә мәҗлес дәвам итә.

— Үз башларына котырынгандай котырындылар, — дип искә ала әни ул көннәрне. Ә мин аның белән һич килешә алмыйм. Тормыш йөгөн тарткан авыл ирләренең ул көннәрдәге күңел ачуы бәлки гомерләре буена беренче һәм соңгы тапкыр булгандыр. Дөрес эшләгәннәр! Сугыш газапларын кичергән, шунда мәңгегә башын салган мескеннәр өчен үкенечкә калмаган, һич югында бер шашып, «тугарылып», рәхәтләнеп күңел ачып калганнар.

Сугыш башлангач та ир-атны фронтка озату башланды. Күршеләребез Сөнгат абзый Кәшапов һәм Нурхәмәт абзый Нургатин тракторлары белән китеп бардылар. Көтү-көтү «РККА» категориясен алган атлар да озатылды. Янәсе, ул-бу була калса Рабоче-Крестьянская Красная Армиядә хезмәт итәргә тиешле, хәрби исәптә торган атлар. Шулар арасында әтинең колхозга кергәндә биргән яхшы аты «Сәхай» да бар иде.

Ә безнең әтиләр фронтка 14 июль иртәсендә чыгып киттеләр. Ул көнне безнең зур авылдан берьюлы 1907 елда туган унике кеше сугышка озатылган.

Иртәгә китәсе көннең кичендә безгә туганнар җыелды. Безнең нәсел һәрвакыт шат күңелле, шаян телле булуы белән аерылып тора. Тик бу кичне барыбыз да уйчан, сагышлы идек. Уен-көлкегә, үткер сүзгә оста әтидә дә шаяру кайгысы юк иде. Ул өч баласын, дүртенчесен көткән

хатынын калдырып сугышка китәргә тиеш. Зурысына нибары алты яшь. Берничә ел элек армиягә киткән энесе Әгъзамнан да хәбәр юк. Шулай ук көтмәгәндә бәреп кергән фашист илбасарлары белән бәрелештә һәлак булды микәнни?

Өстәл артында тынлык. Барысы да уйга чумган. Кинәт әти, авыр уйларны тарату теләге беләнме, башын чайкап җырлап җибәрде:

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кайталмам инде,
Бер китсәм кайталмам инде,
Сезне оныталмам инде...

Безнең әти җырларга ярата иде. Аның бер яраткан җыры мине гомерем буе озатып килә.

...Көз якынлашып килә иде бугай. Көн болытлы булса да, җылы, яңгырсыз иде. Әти иске коймабызны төзәтеп йөри. Мин аның тирәсендә бөтереләм. Бер атна эчендә ике сөйгән сабыен җирләгәннән соң мин аның олы баласы, «уң кулы» булып калдым ич. Эш арасында үзе минем белән сөйләшә, үзе көйли:

Өздереп гармун уйныйлар
Елховой авылында.
Йөрәгемә утлар яктың –
Янам мин ялкынында...

Гади генә итеп, ихлас күңелдән, табигать биргән тавышы һәм осталыгы белән җырлаган иде әти ул җырны.

Алтмышынчы елларда мин шул көйне радиодан ишетеп хәйран булдым:

Өздереп гармун уйныйлар
Наласа авылында...

«Наласа» җыры булган ич ул. Туган авылы аңа якынрак, кадерле булгангадыр, ул аңа «Елховой авылында» дип җырлаган. Радиодан җыр яңгырый, ә мин әтине искә төшерәм. Ак киез эшләпә, киндер алъяпкыч, тула оек белән резин калушлар кигән, кулына чүкеч тоткан, җырлый-җырлый эшләп йөргән әти бүгенгедәй күз алдымда тора. Юк, ни дисәң дә радиодан җырлаган җырчыга караганда әти «Наласа»ны җылырак, гадирәк һәм моңлырак җырлый иде кебек.

Әйе, матур гына җырлый иде ул. Авыл картлары әле хәзер дә искә алалар: «Әй, Сәхап абзый... Ничек шәп җырлый иде бит ул!» — диләр.

Әти утызынчы елларда ук Елховой авылының беренче үзешчән артистларының берсе була, спектакльләрдә катнаша, сузып-сузып моңлы җырлар башкара.

— Ул һәрвакыт берәр гарип-горабаны уйный иде, — дип искә төшерә бүген 90 яшен тутырган әни. Ә Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасындагы бөкре Мәхтүм — төп роль бит ул...

Тагын бер күренеш. Кич, кояш батып килә. Әни өйдә юк, ул бәлки кизләүгә суга, йә булмаса кер чайкарга киткәндер. Әти сәкегә аякларын бөкләп утырган да, безне — балаларын тезләренә яткырып башыбызны сыйпый, иркәли, ә үзе көйли.

Балаларын бик яраткан ул. Әмма киреләнгән чагыбызда коры куллы да була иде — анысы да яхшы хәтердә.

Соңгы кичтә дә балаларын сөеп-яратып китте ул. Олы малай дип тормады, мине дә кулына алып кысып кочаклады, ишекле-түрле йөри-йөри: «Әниенә булышчы бул, улым. Син бит зур инде», — диде. Туганнары, сөйгән хатыны, балалары арасында соңгы сәгатьләрен үткәргәнен, безне башкача беркайчан да күрә алмаячагын күңеле сизгән күрәсең...

***

Алар иртән-иртүк колхозның иң яхшы атларына утырып киткәннәр. Жырлый-жырлый, елый-елый, артка борылып карый-карый, кулъяулыкларын болгый-болгый киткәннәр...

Әтидән бары ике хат килде. Берсе Казаннан: «Вакыт бик тар. Атарга өйрәнәбез, сугышка әзерләнәбез. Синең берүзенә жинел түгеллеген беләм. Үзенне һәм балаларны сакла». Икенчесе инде фронттан, каяндыр Брянск тирәсеннән: «Сугыш якында гына бара. Озакламый без дә сугышка керәбез. Минем өчен борчылма, әниләре, исән-сау булсак кайтырбыз әле...» Шул ук хатта аның хатынына, балаларына атап язган жыр юллары:

Бәгырькәем, без киткәндә
Озата баруларың,
Әле дә күз алдымда тора
Арьякта калуларың.

Алма бакчасына кереп
Жый, бәгърем, алмаларын;
Сезнең тарафларга карап
Тала күз алмаларым.

Иртә торып тышка чыксам
Ай күренә күземә;
Яктылыгын сезгә охшатам,
Ялгызлыгын — үземә...

Бу инде аның соңгы хаты иде...

Халык өчен авыр тормыш башланды. Безнең йорт, өй, гаилә мәшәкатьләре тулысы белән кечкенә гәүдәле, дүртенче балага йөкле, кыюсыз, тыйнак әни жилкәсенә төште. Аның бер өстенлеге булгандыр — уңган, тырыш, көн буена тик тормый — эшли дә эшли. Унике яшеннән ятим калып, кырыс, ләкин кешелекле жиңгәсе тәрбиясендә үскәнгәдер, эшне жиренә житкереп башкара. Тик минә кул арасына керерлек бала гына юк, барысы да бәләкәйләр.

### Әни

Шушы урында нокта куеп, әни турында аерым сүз әйтергә хаклымын. Сугыш чоры һәр гаиләгә әйтеп бетермәслек кайгы-хәсрәт алып килде, аналар жилкәсенә дә, балалар өлешенә дә күп авырлыклар төште. Шул михнәтле елларны батырларча кичереп, балаларын саклап калган, аларны чын кешеләр итеп үстергән шанлы аналар аз булмады. Шулар арасында безнең тыйнак, ләкин гаять тырыш әниебез дә бар иде. Ул дәһшәтле, ачы михнәт елларының безнең кебек эбер-чебер вак һәм күп балалы гаиләләр өчен ничек авыр булулары турында күп язылды. Ачлыктан олылар һәм кечеләр арасында дөнья куйган авылдашларыбыз да шактый булды — алда мин аларның кайберләренә аерым тукталырмын. Әмма без ул афәттән исән-имин калдык. Һәм без моның белән әниебез Мөсәвәрә Гайнан кызына бурычлы. Аның тырышлыгы, тынычсызлыгы, балалар дип янып-көеп йөрүе, уңган-булганлыгы аркасында гына без ач үлем тырнагыннан котылып кала алдык.

Безнең әни үзе дә ачы язмышны балачактан татып үскән. Бу — үзе бер тарих. Әнинең атасы Гайнан Сабит улы Сабитов революциягә кадәр Елховойда таза тормышлы кешеләрнең берсе була. Күн әйберләр тегү остасы буларак, аның тирә-якларга даны таралган, байларга, сәүдәгәрләргә

көн пальтолар, курткалар, чемоданнар теккән. Тик совет хөкүмәте урнаштырылгач, ул елларның башбаштаклыгы төшемле һөнәр иясенә дә кагылмый калмаган. Гаделсезлек, төрле кыерсыту-кимсетелүләрдән котылу теләге белән, Гайнан хатыны Мәсрүрә Мөхәммәтҗан кызын һәм берсеннән икенчесе бәләкәй дүрт баласын алып, Урта Азия якларына бару теләге белән өеннән чыгып киткән. Ләкин алар Самарадан да ары уза алмаганнар. 1920 елда Идел буенда котырынган тимгелле тиф кизүе тимер юл вокзалында поезд көткән гаиләне өтереп алган. Башта йогышлы авыру Гайнанның унике яшьлек олы кызы Мөсәвәрә белән җиде яшьлек улы Габдрахманны бәреп ега. Аларны хастаханәгә салалар. Әтисе Мөсәвәрәне озата килә һәм, ул-бу була калса дип, кызының караваты янындагы диварга туган авыллары адресын язып калдыра: «Уфимская губерна, Мензелинский уезд, Ярсубайкинская волость, село Старый Багряж-Ялховой». Шул көннән Мөсәвәрә белән Габдрахман әти-әниләренең дә, тагын ике туганнары — Мөнәвәрә белән Фәйзрахманның да язмышын белмиләр.

Мөсәвәрә белән Габдрахман икесе дә тереләләр. Аларны балалар йортына озаталар. Әнинең Мәләкәс, Инза, хәтта Украина җирендәге балалар йортларында булуы турында сөйләгәне хәтердә. Елховойда калган Гайнанның Гыйммран исемле үпкә чирле энесе йортына Мөсәвәрә ике елдан соң гына кайтып төшә. Ләкин абзыйсы озак яши алмый, ярты елдан гүр иясе була. Мөсәвәрә җиңгәсе Хәтимә белән кала (балалары булмый).

Габдрахманны тагын ике елдан соң авыл кешеләре очраклы рәвештә беспризорниклыкта йөргән җиреннән Казаннан табып кайталар. Кеше өстендә, батраклыкта көн күрүләре ике ятимнән дә калмаган.

Егерме бер яшендә әниебез булдыклылыгы, гаделлекне һәм матурлыкны яратуы, уен-көлкеле, яхшы күңелле булуы белән авыл егетләре арасында аерылып торган егеткә — сукыр Салах Сәхабына кияүгә чыга. Алар бик яратышып өйләнешәләр. Һичшиксез, аларның бер-берсенә тартылуларына икесенең дә җырга-моңга һәвәслеге сәбәп булгандыр дип уйлыйм мин, чөнки әни дә, әти дә, әйткәнемчә, җыр осталары иделәр.

Безнең Елховой — базарлы авыл. Шунда бервакыт әни күрше Бәркәтә авылыннан бер хатын белән таныша. Сүз артыннан сүз китеп, ул хатын безнең әнигә 1920 елда тиф кизүе чорында Рузаевка станциясе хастаханәсендә Елховой авылыннан Мәсрүрә атлы хатын белән бергә ятканын исенә төшерә.

— Минем хәлем бик авыр түгел иде — озакламый чыгардылар. Ә Мәсрүрәнеке бик авыр иде. Авыр булса да, ул, мескенкәем, ире белән балалары турында кайгырып ятты, — дип әйткән. Күрәмсең, әнинең әнисе терелә алмаган. Әтисе Гайнан белән ике бәләкәй туганнары — Мөнәвәрә белән Фәйзрахман да хәтәр кизү корбаннары булганнар. Балалар бәлки исән дә калганнардыр. Ә менә әти-әнисе исән калган булсалар, Елховойга бер-бер хәбәр салмый яшәмәсләр иде...

***

Әти китеп озак та үтмәде, бер ак сарыгыбыз югалды. Бер көн, ике көн үтте, ә сарык юк. Көтүче Нуретдин абзый: «Күрмәдем бит, кая китте икән соң?» — диган әнигә. Кояшлы бер көнне төштән соң әни белән көтү йөрегән Чиялек әрәмәсенә киттек. Эзләдек-эзләдек, ләкин таба алмадык. Бик арып кайтып егылдык. Әни нәрсәдер сизенде булса кирәк, бу сарыклар берәм-берәм югалып бетәрләр, кышка азык та әзерләп булмый, сугыш та туктарга охшамаган, атагыз да тиз генә кайта алмас, иң яхшысы — тизрәк сарыклардан арынырга кирәк, дип сарыкларның берсен суйдырып, икесен сатып җибәрде.

Кырын эш кырык елдан соң да беленә, диләр бит. Гомерен авыл көтүен көтеп үткәргән Нуретдин картның илленче еллар ахырында көтүдәге бер бозауны суеп, итен идән астындагы базга яшерүен фаш итеп, шул итне бозауның үз тиресенә төреп, көтүченең муенына такканнар һәм аны ярты көн авыл урамнары буйлап йөрткәннәр. Совет законнары буенча хөкемгә тартырга кирәк булган да бит, ләкин озак еллар буе әле сарыгын, әле кәҗәсен, әле бозавын югалтып яшәгән авыл халкының ачуы бик кабарган булган — каракка борынгыча җәза бирергә карар кылынган. Шул җәзадан соң карак көтүче урын өстенәауган һәм башкача тормаган. Бу хәлне Елховойда әле бүген дә олы гыйбрәт итеп сөйлиләр: башка урлаучыларга сабак булды, диләр. Бәлки шуңадыр, авылда мал югалу очраклары бөтенләй булмый хәзер.

Көз үтте, салкын кыш килеп җитте. Икенче кышына кергән яна өйнең бүрәнә аралары рәтләп мүкләнмәгән, аннан җил өрә, өйдә җылы тормый. Миннән бәләкәй балалар караватта әни куенында йоклыйлар, ә миңа, олы малайга, анда урын җитми. Минем урын салкын идәндә. Өшүнең нәтиҗәсе озак көттерми — торган саен ас юеш була.

Колхоз китерткән чи усак утыны тиз генә кабынып, янып китми, пыскып тик ята. Төтене күп, кызуы юк. Иң уңайсызы — әнинең бер үзенә пычкы белән утын кисү.

Бер иртәдә әни мине уятты.

— Тор әле, Әсгать. Ягарга утын юк бит, кисәсе иде! Пила башыннан тотар идең ичмасам...

Безнең мишәрләр пычкыны русчалатып «пила» дип әйтәләр.

Минем әле пычкы тотып утын кисешкәнем юк. Йокы да туймаган, рәхәтләнеп йоклыйсы иде дә бит, әни киенгән килеш мине көтеп утыра. Аны да аңларга кирәк — мин булышмыйча кем булышсын? Әнә бит әти дә киткән чакта: «Син инде зур, әниеңә булыша торган бул», — диде. Теләр-теләмәс кенә торып, юеш ыштан өстеннән бишмәтне кидем. Киез итекләр дә мич башында җылынып торганнар.

Тик ишек алдына чыккач та җил бөтереп алды — декабрь иртәсе суык иде. Юеш ыштан аркылы ул бигрәк тә нык сизелә.

Пычкыны бит аны тарта да белергә кирәк. Башта ул минем өчен дә җиңел булмады. «Әйбәтләп тарт, аска басма, як-якка борма, туры тарт!»... Әнинең күрсәтмәләрен тыңлый-тыңлый җиде яшь тә тулмаган килеш анын кул арасына керә башлаганым әнә шулай башланды. Моннан соң инде әни белән утын кисү гадәти хәлгә әверелде.

Башкаларга караганда безнең өйнең бер өстенлеге бар иде. Бер катлы тәрәзәләрне кышкы ачы җилләрдән саклау өчендер инде, әти биш тәрәзәгә биш капкач ясатып калдырган. Берәр атнага сузылган бураннарның башында ук әни белән чыгып шул капкачларны ябып куябыз. Өйгә шунда ук ышык төшә, бозланып каткан тәрәзәләр эреп, тәрәзә төбенә су җыела. Без аны кашык белән савытка җыеп алабыз. Дүрт, биш, яки аннан да күбрәк көн дулаган буран бер иртәдә тынып кала. Ул авыл кырыена урнашкан безнең йортларны яртылаш кар белән күмеп киткән була. Без шул карны көри-көри тәмам хәлдән таябыз.

Сугыш еллары кышлары хәтердә бик суык, карлы һәм буранлы булып калган. Асты ачык, түбе тишек ызбаны җылытыр өчен мичкә гел ягып торырыга кирәк. Ә утын... Ул, һәрвакыттагыча, житми инде. Бер бик салкын айлы кичтә әни белән бәләкәй чана (безнең мишәрләр аны сәнәскә диләр) балта, пычкы алып күл буена төшеп киттек. Күлнең югары башында, Борһан тавы астында сугышка кадәр киндер сүсе эшкәртә торган бер җайланма бар иде. Көлтә-көлтә киндерләрне бергә җыеп агач бастырмалар

арасына кыстыралар да, күлгә суда жебетергә батырып куялар. Аннары аны киптереп талкыйлар. Авыл хатыннарының ул киндерне шул бурадан салган бина янында талкыганнарын әле дә хәтерлим, ләкин бина эчендә киндер сүсен нишләткәннәрен күргәнем булмады, бәлки анын анда җиһазлары да булмагандыр әле. Тик без барган төнгә анын бурасын яртылаш утынга сүткәннәр иде безнең оч кешеләре. «Барыбер сүтәләр, безгә дә ярап куяр», — дигәндер безнең әни дә. Минем өчен иң гаҗәбе шул булды, килүчеләр арасында үзебезнең башлангыч мәктәп директоры да бар иде. Ул апа безнең күрше Сәлимә абыстайларда фатирда тора. Үпкә чирле Сәлимә карчыкның, әлбәттә инде, утынга йөрерлек рәте булмагандыр. Чарасызлыктан ул укытучы апалар да «төнге ауга» чыгып киткәннәр. Ләкин мин ул укытучы апаларның авылда бик актив эш алып барганнарын да онытмыйм. Клубта спектакль, концерт кую, агитатор булып эшләү алар өлешендә иде.

***

Фронттан берсеннән икенчесе хәтәррәк хәбәрләр килә. Немецлар Мәскәү янына ук килеп җиткәннәр. Мәскәүне алсалар, тагын бер-ике атнадан Казанга да килеп җитүләре мөмкин. Безнең әтиләрдән күптән инде хәбәр юк.

Беркөнне авыл өстеннән түбән генә канатлары астына кызыл йолдыз ясалган берьюлы биш самолет лачындай очып үтте. «Эстребителләр», — диделәр бездән олырак малайлар. Каян очып килгәннәр, кая таба киткәннәр? Соңыннан гына сугыш вакытында Бөгелмә янында хәрби аэродром салынганы турында белдем — шундагы истребительләр булганнардыр инде.

Чатнама салкыннары, көчле бураннары белән сугышның беренче кышы үтте. Немец Мәскәүне ала алмады. Ләкин җәен Сталинград тирәсендә хәтәр сугышлар башланганын ишеттек. Ульян күперен немец самолетлары бомбага тоткан икән, дигән хәбәр дә килде Елховойга. Ләкин бомбалар күпергә туры килмәгән. Күперне зениткалар саклый икән, алар немецларның берничә самолетын бәреп төшергәннәр...

Сентябрьгә кердек. Бер көнне иртәнге якта мин гадәттәгечә урамда уйнап йөри торган күрше малайларын таба алмый аптырадым. Төштән соң гына килеп чыктылар. «Кайда булдыгыз?» — дигән сорауга: «Без хәзер мәктәпкә укырга йөрибез», — диләр болар. «Ә мин ни өчен укымыйм?» Мин бит инде болай да латин алфавиты белән басылган өебездәге бердәнбер җыр китабын укый алам.

Икенче көнне мин күрше Җәлилгә ияреп мәктәпкә киттем.

— Укытучы апа ничәнче елгы дип сораса, утыз дүрт, дип әйт, — диде Җәлил алдан ук кисәтеп. Елмаеп торган, матур йөзле яшь укытучы Закирә апа Шәйхетдиновага нәкъ Җәлил өйрәткәнчә җавап бирдем. Ул артык төпченеп тә тормады, фамилиямне язып куйды да, дәрес бирә башлады. Ул кичә өйрәткән «А» хәрефен мин инде күптән белә идем.

Минзәлә ягы кызы Закирә апа күңелдә йомшак күңелле, яхшы укытучы, оста тәрбияче буларак саклана минем хәтердә. Чын-чынлап беренче укытучым булды ул минем.

Беркөнне Киләк тавындагы көнбагыш басуына бер зур самолет килеп төште. Укуны ташлап барыбыз да шул самолетны карарга чаптык. Ике моторлы, карасу яшькелт төстә. Өстендә пыяла гөмбәз, ә гөмбәз эчендә пулемет көпшәсе тырпаеп тора. Андый көпшә әле тагын самолет астында да, койрык ягында да бар. «Штурмовик», — дип әйткән очучыларның берсе. Самолетның ягулыгы беткән булган һәм ул безнең Киләк тавы битенә төшәргә мәҗбүр булган. Әллә икенче, әллә өченче көнне генә аның

янына бер «кукурузник» (пар канатлы аэроплан) ягулык алып килде. Хәрби самолетның бик авырлык белән күтәрелеп киткәне бүген дә күз алдында.

Менә шушы хәл сугышның бездән ерак түгел генә баруы, хәвеф-хәтәрнең безнең өчен дә янәшәдә икәнлеген искәртеп китте. Ул гына да түгел, авыл халкына өстән әмер житкерелде: ул-бу була калса, һәрберсенең бакчасына окоп яки траншея казып куярга. Терәлеп торган күршебез ялгыз калган Сәлимә абыстай белән әни безнең бакчага уртак траншея казып куйдылар. Төнлә өй тәрәзәләреннән яктылык күренеп тормаска тиешлеген дә кисәттеләр.

Сугыштан кулы яраланып кайткан Фәхрислам абзый Гыйльманов Борһан тавында житкән авыл кызларына агач мылтык тоттырып, аларны сугышка әзерли, «айт-два»га өйрәтә башлады.

Авыл халкыннан сугышчылар өчен жылы оекбашлар, бияләйләр, азык-төлек, ә самолет һәм танклар төзү өчен акча жыю башланды. Безнең ишле гаиләдән акча да, оекбаш һәм бияләйләр дә артмагач, фронт өчен кайгыртучы әрсез апалар әнидән ике зур кабак алып киттеләр. Гөнаһыма каршы, үскәнче ул кабаклардан сугышчыларга бәлеш салып биргәннәрдер инде, дип уйладым мин һәм еш кына күз алдыма окоп кырыена кырын ятып пешә-пешә кайнар кабак бәлеше ашап утыручы солдатларны китерә идем.

Шөкер, безнекеләр фашистларны Сталинградтан уздырмадылар. Аннан соң инде сугыш әкренләп гел безнең файдага бара башлады.

Кырык өченче елның буранлы февралендә безнең бердәнбер әбиебез, әтинең әнисе Бибигайшә карчык вафат булды. 1937 елда НКВД явызлары алып киткән картын, сугышка озатылган өч улының, киявенең исән-имин кайтуларын зарыгып көтә-көтә, морадына ирешә алмый, кайгы-хәсрәт эчендә китеп барды әби бу дөньядан. Әллә ни карт та түгел, бары 63 яшьтә генә булган икән. Ул: «Догалар укыгыз, Ходайдан атагызның сугыштан исән-сау кайтуын теләгез, ул сезнең ялваруыгызны ишетми калмас», — дип безгә догалар өйрәткән иде.

Жиңү көне бигрәк тә хәтердә. Кояшлы май иртәсендә әни безне сугыш беткән дип уятты. Шатланышып урамга чыктык. Урамда тегендә дә, монда да халык жыелган, сугыш тәмамлану шатлыгын кичерә.

Халыкның төп ризыгы бәрәңге булганга, аны үстерүгә күбесенең үз бакчасы гына житми, колхоздан да жир алырга туры килә. Ул елны безгә дә өч сутый жир бирделәр. Жиңү көне дип тормадык, әни колхоз эшенә китте, ә без энем Тәлгать белән көрәкләр тотып әнә шул жирне казырга менеп киттек. Әй, эшләп тә куйдык соң жиңү шатлыгыннан! Жир йомшак, коры. Казыйбыз да казыйбыз. Һәм сугыш уены уйныйбыз. Казылган жир — дошманнардан азат ителгән илләр. Черек бәрәңге килеп чыкса — бу аларның яшереп куйган алтыннары. Әйе, черек бәрәңге безнең өчен алтынга тиң ризык иде шул...

Жирне казып та бетердек, коеп янгыр да ява башлады. Жылы, рәхәт янгыр. Бәйрәм янгыры!

Сугыштан авылга жиңүчеләр кайта башлады. Беренче булып күкрәкләренә орден-медальләр тагып Минхәеров Сабир, Низамов Самат һәм Вагыйз, мәрхүмә Бибигайшә әбиебезнең олы улы, әтинең бертуган абыйсы Хәертдин абзыйлар кайтып төштеләр. Торбы Хәлимә абыстай улы тупчы Мингата Зариповның күкрәгендәге ике Дан ордены безне тагын да горурландырып жибәрде. Минач абзый сугышта ике аягын калдырып кайтты...

Ә дүрт ел сугыш михнәтләрен татып, әле аннан соң да армиядә тоткарланып, фәкать 1946 елның март ахырында гына өенә кайтарып жибәрелгән Һади абзый, ничек кенә ишле гаиләсе янына ашыкмасын, кайтып житә алмады — төнге буранда юлдан язып, авылдан чакрым ярымда

Чиялек әрәмәсе белән Югары әрәмә арасында адашып үлде.

Ләкин авылга бик күп ир-атлар сугыштан кайта алмый калдылар. Безнең әтиләр дә, күпме көтсәк тә, олы юлда күренмәделәр.

Хәзер безгә барысы да, хәтта ил өчен һәлакәтле ул көннәрне үз башыннан кичергәннәр өчен билгеле булмаган нәрсәләр дә билгеле. Немец гаскәрләре һөҗүм итә. Яраланып кайткан авылдашыбыз Нургата абзый Нуруллинның болай сөйләгәне хәтердә: ул август азагында әтине һәм аның иптәшләрен очраклы рәвештә гаскәрләр бик күп тупланган Брянск тирәсендәге бер авылда очраткан. Алар элемтә ротасында булганнар. Шул ук иртәдә җилкәләренә тимер чыбык бәйләмнәре һәм телефоннар асып якындагы урманга кереп киткәннәр. Озакламый урманда атыш башланган. Урманның икенче ягыннан немец танклары килеп чыккан. Авылдагы гаскәрләр немецларны ут ачып каршы алганнар, ләкин дошман көчлерәк булып чыккан. Безнекеләр чигенә башлаган...

Билгесезлек интектерә: бәрелештә һәлак булганнармы, әсирлеккә төшкәннәрме, ни булган соң аларга? Башкайларын кайда салдылар икән — Брянск урманнарындамы, әллә фашист лагерьларындамы? Уникe яшь, таза Елховой ир-егетеннән бер генә хәбәр дә, сынар гына хат кисәге дә юк. Бар иделәр дә, юк булдылар...

***

Бөек Ватан сугышы инде биш дистә елдан артык ил тарихында тиңе булмаган бөек вакыйга буларак тасвирланып килә. Ярты гасыр аның тирәсендә шау-шу, ыгы-зыгы бара. Җиңүнең әһәмияте, совет сугышчыларының тиңдәшсез батырлыклары, совет халкының илгә җиңү китергән интернациональ дуслыгы, бердәмлеге, совет патриотизмы һәм «русский дух, русский характер» турында берсеннән-берсе купшырак язылган ярымялган сугыш тарихы, документаль һәм әдәби әсәрләр, төшерелгән кинофильмнар...

Баксаң, Бөек Ватан сугышы — Гитлер белән Сталин, Риббентроп белән Молотов арасында уйналган Европаны Германия һәм СССР арасында бүлешү уены белән башланып киткән бөек авантюра булган икән бит. Сугышның асылы бик тирән яшеренгән булганга, гади халык кына түгел, хәтта шактый өстәге катлау да аның серенә төшенә алмаган. Сталин һәм аның иң якын куштаннары йөзләрчә миллион совет халкын алдап сугыш утына тартып керткәннәр. Алданган, кол дәрәҗәсенә төшерелгән халык шушы бөек авантюра корбаны буларак сугыш кырында да, фашист концлагеренда да, совет ГУЛАГында да һәлак булган, тылдагы көч җитмәслек авыр хезмәт, ачлык-ялангачлык, НКВД урнаштырган коточкыч «тәртип»кә түзә алмый үлгән-кырылган. Сугыш китергән афәтне бүген дә халык төгәл генә белми. Шушы мәхшәр елларында һәлак булган халык санын да төгәл генә итеп санамаганнар — чама белән 20, 28, хәтта 50 миллион кеше харап булган диләр... «Чама белән» ... Һай, нинди әхлаксызлык!

Ярты гасыр вакыт үтүгә карамастан, Калинин урманнарында һәлак булган меңләгән сугышчыларның сөякләре һаман чытырманлыклар арасында, кабергә иңдерелмәгән килеш рәнҗеп ята...

«Бөек Җиңү» китергән «изге» сугышның чын йөзе әнә шундый. Ә без Туган ил, Ватан, Рәсәй дибез. Нигә кирәк Ватан, әгәр ул үз кызлары һәм уллары турында кайгырта, аларны яклый, саклый алмаса, ачлыкка, җәбер-золымга дучар итсә һәм син, табигатьнең олуг заты — Кеше буларак шушы Ватан өчен ике тиенгә дә тормасаң? «Иң олы закон — кешене рәхәттә яшәтү», — дигән Цицерон. Ә безнең халык бүген дә рәхәттә яшәүгә тиенмәгән әле.

Укучыларыбызны мин әнә шушы хәлләргә тарихи дөреслек күзлегеннән чыгып карарга, уйланырга, һәрвакыт уяу булырга киңәш итәр идем. Сабак булсын иде безнең үткәннәр һәркемгә!!!

## Ачлык

Сугыш елларында яшәгән, аның бөтен кайгы-хәсрәтен кичергән безнең буын кешеләренең бүген дә хәтерен биләп торган, озын кичләр утырып та сөйләп бетерә алмаслык ачы хатирәләре, исәпсез-хисапсыз тормыш гыйбрәтләре, йөрәгенә уелып калган моң-зары бар. Әйе, газап чиккән кеше барысын да хәтерли!

Белмим, кайсы тирәдә ничек булгандыр, безнең Елховой авылы халкы өчен ачлыкның иң котырган чагы инде сугыш тәмамланганнан соң, 1946 һәм 1947 еллар җәендә булгандыр. Гаҗәп хәл бит: тарихта тиңе булмаган зур, авыр сугыш туктатылган, илнең күге аязланган, барысы да әйбәт булырга тиеш сыман. Ә халыкка һич кенә дә җиңел түгел. Аның тормышы һаман начар, ул элеккечә чыгырдан чыккан ярлы, ач-ялангач. Һәм тормышының тиз генә уңай якка үзгәрүенә өмет тә юк.

Бигрәк тә авыл халкына авыр. Колхозда эшләүдән беркемгә дә файда юк. Иң уңган, иң булган колхозчы да ач яшәргә дучар ителгән. «Минимум» дигән чит ил сүзен әнә шул балачакта ишеттем: һәр колхозчы елына 300 хезмәт көне эшләргә тиеш. Ким эшләсәң сиңа өстәмә салым салачаклар, йә булмаса башка катгый чара күрәчәкләр — Алла сакласын!

Хәтеремдә, 1946 ел өчен безнең колхозда уңышны җыеп алып, күпмедер ашлыкны озатканнан соң, бер хезмәт көненә 75 грамм исәбеннән колхозчыларга икмәк бирделәр. Алны-ялны белми эшләгән (кайда инде ул елларда колхозда ял итү, бүген дә сирәк эләгә бит әле ул) иң уңган колхозчылар 500 хезмәт көне эшләсәләр дә, 37 килограммлап бөртек алганнар. Әгәр ул колхозчының өендә безнең кебек әле кул арасына да керерлек булмаган дүрт-биш тамаксау баласы булса? Нишли ала ул? Ата сугыш утында югалып калды. Аның өчен гаилә 72 сум пенсия ала. Базарда бер кило тоз 50 сум тора. Бер кап шырпының да бәясе 50 сум. Тоз алсаң — шырпыга җитми, шырпы алсаң — тозсыз каласың. Ә олы гаиләгә тегесе дә, бусы да бик кирәк. Әмма авыл Советында утыручы салым агентын ач гаиләнең мөшкел хәле мыскал да дулкынландырмый. «Салымыңны түлә! Бетте — китте»... Бердәнбер сыерыңа — салым, бәрәңге бакчаңа — салым, салам түбәле дүрт почмаклы шып-шыр ызбаңа (мишәрләр өйне шулай дип атыйлар. Мин дә аны «өй» дип атый алмыйм. Өй бит ул зур, матур була. — Ә.С.) — салым. Хәтта сарык сөтенә дә салым!

Салымны түләп бетерергә дә өлгермисең, заем белән кыса башлыйлар. Сугыш елларында җимерелгән халык хуҗалыгын торгызу өчен чыгарылган заем имеш. Гаҗәпкә калырсың: җимерек халык хуҗалыгын аның ач-ялангач халкы торгызырга тиеш...

***

...Урамда җылы май ае. Сугыш беткәнгә дә бер ел тулды. Авылда кызу эш вакыты: кырда язгы чәчү бара, авыл халкы бакча казый, бәрәңге утырта. Халык инде күнегеп килә — колхозга өмет аз, бөтен өмет үз бакчаңа — бәрәңгегә, кабакка, чөгендергә, шалканга.

Безнең бакча зур. Йортыбыз авылның өске урамында урнашкан булса да, бакчабыз юеш: кайдадыр аста чишмә чыгып ята булса кирәк, ул бөтен бакчаны юешләтә. Шуңа күрә аны авылда иң соңгылардан булып казыйбыз, тирес ташыйбыз, бәрәңге утыртабыз...

Жир, бакча казу олылар өчен дә авыр эш, ә безгә, 9-11 яшьлек балачагага, ул икеләтә авыр. Инкәеп-инкәеп эшлибез. Көрәккә балчык ябыша, аны әледән-әле кыра торырга кирәк. Берләнбер юаныч — былтыр жирдә калып черегән бәрәнге табу. Аны жыеп барабыз, ә кичкә әни аларны юыпчистартып, изеп-болгатып, тозлап табада кыздырып бирә. Сыек бәрәнге шулпасы түгел инде бу, ә чын деликатес!«Кәлжемә» дип искә алалар аны бүген бәдбәхет еллар «түмен» татыган татар балалары.

15-16 яшьлек Мөкатдисә, Мөхтәрәмә, Файзә, Мөсаллия апалар да безгә бакча казырга булышалар. Ул чагында үзебезгә дә эшләве күңелле булып китә. Житеп килүче кызларның сөйләшүләрен тыңлавы үзе бер кызык. Бакча да тиз казыла. Кичен исә әни казан тутырып бәрәңге пешерә — безгә бакча казышкан кызларны сыйлый.

Көннәр үтә тора. Бакчалар казылып беткән, кәлжемәләрнең исе дә килми башлаган июнь уртасы. Идән асты базында бәрәңгенең соңгы чиләкләре, ә янасы өлгерергә ерак әле. Ашау көннән-көн кысыла бара. Әле күптән түгел генә бәрәңгене иркен пешереп ашаган булсак, хәзер әнә әни ике-өч бәрәңге кырмалап сала да, казанда кайнаган суга бераз сөт өсти. Шулпа күп, ә туклыгы юк. Ашарга утырганда ничек ашыйсы килгән булса, ашап торгач та шулай ашыйсы килә. Ярый әле читән төбендә кычыткан бар — әни аны күпләп-күпләп сала шулпага. Аннан балтырганга, көпшәгә, какыга, кузгалакка чират житә. Алары картая башлагач бәрәңге, чөгендер яфраклары керә безнең «рацион»га.

Беркөнне күрше малайлары — Жәмил, Жәлил, Рәхимжан, Наил, Өлфәт белән Чиялек әрәмәсенә балтырганга киттек. Ул вакытта Чиялек әрәмәсе бик матур, бай иде. Таллыклар арасында күпереп үскән балтырганнар, сәрдәләр... Көпшәсен дә, бәбәген дә ашап жибәрәбез — барыбызның да утыз ике тегермәне эштә, сөйләшергә дә вакыт юк.

Капчык-янчекләрне тутырып кайтырга чыктык. Әллә бик күп жыйганбыз балтырган-сәрдәләрне, әллә инде хәл юк — аяклар тала, безне тыңламыйлар, алга бармыйлар. Ун-унбиш адым үтәбез дә, күпереп үлән үскән юл кырыена авып төшәбез. Күк йөзе зәп-зәңгәр, һичнинди болыт әсәре юк. Чәчкәдән-чәчкәгә күбәләкләр, умарта кортлары, башка бөжәкләр күчеп куна — табигатьнең илаһи бер вакыты. Ә бездә ул матурлыкка игътибар итү юк, сүрәнлек-сүлпәнлек. Тизрәк торып, кайтып китәр идек, хәл, аяк буыннарында егәр юк. Сөйләшәсе дә килми.

Ике чакрымдагы Чиялек әрәмәсеннән ярты көн кайтканбыздыр.

Балтырган, көпшәләргә энекәшләр һәм сеңелкәш ташланалар. Әни дә капчык янына килеп бәбкәләр барлый башлый — ана тизрәк балтырган ашы пешерергә, балаларын ашатырга кирәк. Тик ашыйсы килүне бернәрсә дә басмый. Иртән дә, көндез дә, кичен дә, төнлә дә ашыйсы килә. Бөтен уй ашау турында, бөтен теләк, хыял — ашау, ашарга табу. Сугыш башланган елны безне — аталары сугышка киткән балаларны хәзерге балалар бакчасы сыман жиргә йөрттеләр. Нигәдер аны безнең авылда «Площадка» дип атыйлар иде. Тәүге тапкыр манный боткасы тәмен мин әнә шул «площадка»да татыдым. Тәмле дә иде соң! Ә шунда эшләүче Минкәмәл апаның зур эмаль коштабактагы бодай әпәе кисәкләрен безгә таратып йөрүе әле дә күз алдыннан китми. Андый тәмле, андый туклыклы ипине башкача гомеремдә дә ашаганым булмады сыман.

Сугышка кадәр әти Казаннан нинди дер үзе озынча, үзе түгәрәк бер кызгылт ашамлык алып кайткан иде. Ах, аның тәме! Әнидән аның нәрсә булуы турында сорыйм — мин бит әле ул вакытта бәләкәй булганмын.

— Колбаса турында әйтә торгансыңдыр, улым. Атаң шулай кая да булса

барган жиреннән нинди дә булса ят, тәмле ризык алып кайтырга ярата иде, — ди әни.

— Нәрсә соң ул — кулбаса...

— Иттән ясыйлар инде аны, тоз, сарымсак, борыч кушалар...

Сүз колбаса (ә нишләп соң әле чыннан да кулбаса түгел!) турында барганын мин соңрак, инде үзем дә буровойда эшли башлагач кына белдем. Һәм бу очракта да шуны әйтә алам: андый тәмле колбасаны башкача ашаганым булмады бугай.

Ач булгангамы, әнә шундый тәмле ризыклар искә төшә.

Ашыйсы килү бер минутка да тынгылык бирми.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ташкүмер;
Ашак кели, кели, кели
Үтә безнең яшь гомер...

Көлсәң көл, еласаң ела, әмма без, мишәр малайлары, шулай җырлап йөри идек ул елларда.

Пенсияне алу көне килеп җитте. Әни кайгыда: шул аз-маз акчаны да заемга басып калачаклар.

— Тагын шырпысыз да тозсыз да калабыз инде...

— Мин барыйм әле, әни, бәлки алып кайта алырмын, — дим. Әни ризалаша, чөнки үзе барса, барыбер калдырып кайтырга мәҗбүр була: салым агенты шулкадәр имансыз бәндә — бугазынны буып алачак.

Җайлаганнар бит: почта бүлеге авыл Советы бинасында, ишеге исә салым агенты ишегенә каршы гына. Агент үз ишеген ачып куйган, пенсия алырга килгән һәркемне күзәтеп, кисәтеп тора. Почта бүлегендә эшләүче, сугыштан бер аягын өздереп кайткан Әхмәтзыя абзый Хәбибуллин исемлектән безнең фамилияне эзләгән арада агент абзый мине дә кисәтеп куйды: «Салахов, пенсиягезне алгач, минем янга кер!»

— Ярар, — дидем мин тыныч күренергә тырышып һәм, Әхмәтзыя абзый 72 тәнкәне санап биргәч тә, ишектән чыгып сыздым. Салым агенты арттан йөгереп чыкканда мин инде тыкрык башына җиткән идем. Анын:

— Салахов, Салахов дим, акчанны калдыр, — дип кычкыруына җавап итеп тар һәм кыска балаклы ыштанның төбен учлап күрсәттем дә, үзебезгә таба йөгердем.

Тормыш әнә шулай бөтенләй усал булмаганнарны да этлеккә өйрәтә ул.

Әй, халыкның ачка тилмерүе ул елларны! Ашамаган нәрсә калмады: алабута, черек бәрәңге, кычыткан, балтырган. Күл буенда яшәүче берничә гаиләнең бака пешереп ашаулары турында әле дә сөйлиләр. Бер апа казан астын ягып җибәрә дә, чиләк тотып күл буеннан бака җыеп кайта һәм инде суы кайнарлана башлаган казанга дүрт ботлыларны салып җибәрә. Теге бичаралар шырык-шырык килеп сикерешеп чыгалар икән. Шулай да ите тәмле икән бакаларның, балыктан да болайрак, дип сөйләгәннәр.

Әрлән, йомраннарны да ашаучылар булган. Аларның да ите тәмле икән. Булмыйни: бөртек тә, үлән белән генә тукланалар бит ул җәнлекләр.

Яна Чишмә авылы кешеләре юкә ботагын киптереп, шуны тарттырып он ясаштырдылар. Әтинең бертуган апасы Хәйрия абыстайларга баргач минем дә юкә пәрәмәче ашаганым булды. Каймак белән ашагач бик тәмле булган иде.

Бер көнне Түбән әрәмәгә балтырганга төшкән идем, кайтканда аскы урамда яшәүче әнинең балалар йортыннан кайтканнан соң яшәгән җингәсе Хәтимә әби белән Сөләйман бабайларга (ул читтән кайтып Хәтимәгә йортка

кергән) кагылдым. Хәтимә әби арыш һәм алабута онын кушып бәләкәй генә итеп салган ипинен яртысын мина кисеп бирде. Кош тоткан кебек кайтып кердем өйгә. Әни дә, туганнар да шатланыштылар. Шулчак күрше кызы Тәкан Асиясе килеп керде. Әле күптән түгел генә түгәрәк гәүдәле күренгән 17 яшьлек Асия апа ябыгып, хәлсезләнеп калган, ә йөзе табак чаклы булып җилсенгән. Бу ачлыктан шешенү галәмәте иде.

— И-и, Мөсәвәрә астай, үләм бит... — диде дә, акырып елап җибәрде Асия апа. Әни мин алып кайткан кара ипине алты тигез кисәккә бүлеп, Асия апага да өлеш чыгарды. Барыбыз да валчыгын да калдырмый ашап та бетердек. Бик тәмле булды ул кара ипи. Асия апа рәхмәтләр әйтеп чыгып китте.

Әни ашка бәрәнге әрчи. Ә без — мин, энеләрем Тәлгать, Әгъдәс һәм сенлем Мөзәянә чират торып бәрәнге кабыгын ала торабыз, учактагы күмер өстендә куырып авызга каба торабыз. Әнинен ашы кайчан пешә әле, ә безнен түзәрлегебез калмады — ашыйсы килә. Дүрт бала учак янында мәш киләбез. Куырган бәрәнге кабыгы тәмле...

Озак еллардан соң хатын ашка бәрәнге әрчеп утырганда куырган кабык искә төште дә, берне алып газ плитәсендә куырып авызга кабып карадым. Булса да булыр икән: авыздан үтмәде бит. Ничек ашалды икән теге елларда бу «затлы» ризык?

Кайсыбер күршеләр ат кузгалагы яфрагыннан пәрәмәч пешерәләр иде. Беркөнне мин дә Югары әрәмәдән ат кузгалагы җыеп кайттым. Чәчәгеннән өйрәсе тәмле була икән дигәнгә, әни сөт кушып өйрә пешерде. Мин ул өйрәне күбрәк ашап җибәрдем бугай — төнлә бик каты эчем һәм башым авыртып, күнелем болганып урынымнан тордым. Баш әйләнә, күз аллары карангы, хәл юк. Эчтә булган бар нәрсәне актарып чыгардым. Ике көн авырып яттым. Тамак диеп агуланып үлү дә аяк астында гына йөргән икән бит.

Болай да ярлы авыл кешесенен күпме генә артык әйбере булуы мөмкин? Әтинен бердәнбер кыска пальтосы, әнинен кадергә бәйли торган шәле, чиккән башлы сөлгеләр, тәрәзә кашагалары, хәтта керосин саклый торган 10 литр сыешлы зур шешә дә онга, бәрәнгегә алыштырылды. Вакыт-вакыт әни башка хатыннар белән, сандык төбен актарып алган кадерле әйберләрен кыстырып, Шөгер һәм Әлмәт якларына — Яна Елховой, Сембер, Сәмәрканд, Дәүләт, Чупай, Мәмәт авылларына чыгып китәләр, икешәр көн йөреп тегеннән-моннан ризык юнәтеп кайталар.

Атлар, тракторлар сугышка озатылганнан соң колхозда калган карт атлар белән генә кыр эшләрен башкарып чыга алмый башладылар. Чәчүлек басуларны 50 шәр сутый итеп һәрбер колхозчы хатынга бүлеп бирделәр. Башкалар белән беррәттән әни ач килеш иртәдән алып кичкә кадәр колхоз җирен казый. Әллә авыр эш көчкә килгән, әллә ачлыктан — беркөнне әни бик каты ашказаны авыртып кайтып керде. Ул авыру бик озак йончытты әнине. Түзә алмагач, күрше Кләмәнтәй авылы фельдшеры, әтинен дусты урыс Киселев абзыйга күренергә китте. Ул авыруның начар ашаудан булуын әйтеп, үзе ясап, үзе өчен генә саклаган даруын биреп җибәргән. Шуны эчкәч кенә әнинен сәламәтлеге рәтләнде.

Һәркем үзенчә ашарга ризык табу ягын карый. Бер төркем күрше малайлар белән күлгә төшеп китәбез. Камыш араларында үрдәк оялары күп, янәсе йомырка җыябыз. Йөрибез-йөрибез, әмма муеннан су уртасында үсеп утырган камыш арасына ничек керәсен?

Миннән бер яшькә олы Җәмил кармакка балык тотарга өйрәнгән. Әйдә, балык тотабыз Шушмадан, ди ул. Иртән иртүк елга буена төшәбез. Шушмага Бустрәй инеше кушылган җирдә подуст балыклары каба икән.

Тегәрҗепкә кармак тагып, аңа суалчан эләктереп суга салабыз. Ташлыкта су агымы көчле, подустның нәкъ урыны икән. Әһә, Җәмил әнә бер балыкны тартып та чыгарды. Оста шул! Минем кармакны да тартып куя балык, тик капмаган әле. Җәмил тагын берне эләктерә. Ниһаять, мин дә бер балык каптырам һәм шатлыгымнан аны тотып авылга чабам.

Тик икенче төшүдә көне буе утырып та икебезгә бер балык та тота алмый кайтабыз. Әни орышына, «Вакыт әрәм итеп йөрисез, кышын сыерга нәрсә ашатырбыз?» — ди ул. Дөрес сөйли. Миңа инде унбер яшь. Үземнең чалгым, бәләкәй арбам бар. «Темпы», — диләр аны безнең авылда. Темп — күмәк хуҗалык, социализм, коммунизм «җиңүләре»ннән ачы көлеп, сарказм белән аталган булгандыр инде ул арба. Темпы белән Кләмәнтәй урманыннан инкәеп-инкәеп утын ташыйбыз, шуның белән колхозның житеп килгән кызлары ач килеш елый-елый күрше районнан чәчәргә орлык өстериләр. Шул арба белән мин тау араларыннан, чокырлардан, чәчелми калган җирләрдән үлән чабып йөрим, бердәнбер өметебез, аклы-каралы сыерыбызга кышка азык әзерлим.

Гаиләбезнең олы бәхете иде ул бура кебек зур гәүдәле, тамаксау, әрсез аклы-каралы сыер — сугышның башы белән китеп югалган әтиебез төсе. Булдыклы кеше булган безнең әти! Авылга бер мәшһүр Холмогор токымлы сыер алып кайтып калдырган ул кайдандыр чит яктан. Үлән күпереп үскән җәйге айларда көтүдән кайткач әни бер чиләк, вакыт-вакыт чиләк ярым сөт савып ала иде. Иртән көтүгә озатыр алдыннан да чиләккә якын сөт биреп китә сөтбикәбез. Еш кына кичтән әни сыер сауганда аның янына савыт тотып күрше малайлары, кызлары керәләр. Хәттаерактанрак та сорап киләләр. Табигате белән гади, сораганны кире кага алмый торган кеше булганга, әни, үзенең дә дүрт баласы булуга карамастан, барысына да өлеш чыгарырга тырыша.

Шуның өстенә бит әле сөткә йөкләмә, «задание» дә бар. Бер тиенсезгә сөтеңнең шактый өлешен хөкүмәткә (хөкүмәткә булды микән әле?) тапшырдык.

Булган сөтне аертып әни каймак җыя. Аерган сөттән катык оета. Катык оерга да өлгерми, без аны ашап та бетерәбез. Атна ахырында әни май яза. Кило ярым май төшә. Әйрәнне үзебез эчәбез, ә майны иртән базарга чыгарып сатабыз да, акчасына он, яки бәрәңге алабыз. Майның килосы 350 сум, кило ярым сатсак 525 сум була. Ә он кыйбат. Бервакыт әни белән он сатучылар белән сатулашып йөргәнебезне хәтерлим. Кершән кебек ак бодай оны сатучы бер озын чуаш янына туктадык.

— Ни хак оның? — дип сорады әни.

— Вике пен тә вике сөс, — ди чуаш. Мин тиз генә аның нәрсә әйткәненә төшенә алмыйм. Безнең тирә чуашы булмады ахры, Кләмәнтәй чуашлары татарча бик яхшы сөйләшәләр. Ике мең дә ике йөз сум онның бер поты, дигән икән ул. Сатулаша-сатулаша булган акчага ун кадак (дүрт кило) он алдык. Аны күтәреп өйгә кайтып киләбез. Шулчак бәбкәләрен иярткән ана үрдәк кебек, бездән кыйгач кына яшәгән ут күршебез Чүлмәк Шәймәрдән абзый хатыны Гайшә абыстай биш баласын — Фаизә, Сажидә, Сәгыйдә, Зәмзәмия һәм Шамилнт ияртеп килеп керде.

— А-ач-ка бе-тә-без, Мөс-сә-вә-рә, кот-карр-саң син генә кот-кар-расың. А-а-ня, койманы а-ал, о-о-нынның яр-тысын безгә би-ир. А-ал-ла хакы ө-өчен! Шәм кебек Шә-ә-мәрдән кайтса, коймасы бу-у-лыр...

Гайшә абыстай, мәрхүмә, тотлыга иде. Әмма да батыр хатын булган икән. Карт белән карчык, биш бала, үзе — ничек яшәмәк кирәк ул заманда? Дөрес, Шәйхетдин бабай белән Шәмсенур әби сугыш ахырына кадәр яши алмадылар.

Иске койма бәрабәренә онны урталай бүлештек. Куе итеп пешергән умач күршеләр өчен дә, безнең өчен дә хан нигъмәтләренә тиң булгандыр.

Эбер-чебер Чүлмәкләр бәхетенә озын буйлы, таза гәүдәле, «шәм кебек Шәмәрдән» абзый, озак кына хәбәрсез югалып торганнан соң, исән-имин авылга кайтып төште — әсирлектә булган икән. Балаларның ачтан үлү куркынычы чигенде, чөнки нинди генә булмасын, ата кеше гаиләсен, сөйгән балаларын саклап калу өчен бөтен тырышлыгын куя ул.

Ачлык, даими ашыйсы килү кешене туктаусыз ризык турында кайгыртырга, ашарга табарга, эзләнергә мәҗбүр итә. Бәлки тагын балыкка төшеп караргадыр? Мин Җәмил янына кереп киттем — балыкка бит без һәрвакыт аның белән йөрибез. Тик Җәмил юк икән өйдә.

— Алар киттеләр бит, — ди унҗиде яшьләрендәге апасы Мөсаллия.

— Кая киттеләр?

Ачлыктан тәмам хәлсезләнгән Мөсаллия апа сәкедә яткан җиреннән торып утырды һәм елый-елый хәлне сөйләп бирде. Авыл Советы ике як авылдан — Елховой һәм Түбән Абдулдан бик ачка тилмергән дүрт гаиләдән сигез баланы район үзәге Чирмешәнгә озаткан. Җәмил белән сеңлесе Гасимә дә шул төркемгә эләккән. Аннан алар балалар йортына китәчәкләр икән. Миңа бу хәбәрне ишетү таяк белән башка суккан кебек булды — дустым белән аерылышуны белми дә калганмын бит! Шул ук вакытта аларның балалар йортына китүенә сөенеп тә куйдым, чөнки анда туйганчы ашатуларын, яхшы итеп киендерүләрен мин әнидән күп мәртәбәләр ишеткән идем инде.

Кызганыч ки, Чирмешәндә Елховой балаларына бәхет елмаймый. Ни сәбәптәндер, аларны балалар йортына алмыйлар. Миңгата абзый Хәсәншин ачка киселгән сигез баланы кабат арбасына утыртып, авылга кайтырга чыга. Тик бераз үтүгә, Гатаның арык аты тәмам хәлдән тая һәм ач балалар балтырган, сәрдә бәбәкләре, башка төрле үләннәрне ашый-ашый урманда кунарга мәҗбүр булалар.

— Үләнне никадәр ашасак та тамак һаман ач. Арбага барыбыз да сыймагач, үлән йолкып аска җәйдек тә, бер-беребезгә елышып җиргә ятып йокладык, черки талаганны да иртән торгач кына сиздек, — дип искә алган иде ул вакыйганы Җәмил дустым.

Икенче көнне кич белән генә кайтып төшәләр алар авылга.

Җәмилнең тәмам ачка киселгән сеңлесе Гасимә, балакай, озак яши алмады. Әгәр шул вакытта балалар йортына китә алган булсалар, Гасимә, сабый, бәлки исән калган, тагын озак еллар яши алган булыр иде әле.

***

Атмас таң, чыкмас көн... Ачлык өстенә баш күтәрә алмаслык мәшәкатьләргә тарыды халык ул елларны. Нинди генә мәсьәләгә юлыкма, нәрсә турында гына кайгыртма — шул юк. Соңгы ризыкларыңны пешереп ашар өчен утын гына да булмый иде көне-көне белән. Урман якын түгел, ул Кләмәнтәй авылы артында. Утынлыкның иң якыны да кимендә биш чакрымда. Колхоздан ат сорап алуга өмет юк, аның үзенең дә хәле мөшкел, сугышка алынмаган карт, арык атлары үлеп бетү чигендә, сабан сөрергә дә житмиләр. Үз сыерларыбызның бозаулаган чоры — җигәргә иртә әле. Утынга шул ук бәләкәй арба — «Темпы» белән генә барырга кала.

Бер көнне әниненң килендәше Гайшә абыстай, аның олы улы, ягъни минем ике туганнан туганым, миннән өч ярым яшькә олырак Рәшит абзый һәм әни белән мин бергә урманга, утынга киттек. Барган-барган күбрәк алып кайтасы килә бит ул утынны. Күбрәк булсын дип, коп-коры өрәңге һәм усак ботаклары җыйдык. Шактый җыелды алар — «Темпы»ларга тау чаклы ясап төядек. Кләмәнтәйгә чаклы җиңел генә төштек, чөнки юл аска таба, әллә ни көч түгәсе түгел. Ә менә Кләмәнтәй тавын менүләр... Тау

авылны чыкканчы ук башлана. Каян шундый озын булган ул тау? Сугыш елларындагы бәхетсез мишәр балаларын бимазалау өчен ясап куйганмы әллә аны Ходай? Балаларны гына түгел, олыларны да...

Иртән ашаган бәрәңгене ашказаны әллә кайчан эшкәрткән. Бәрәңге бит: «Мин сине алып барырмын-баруын, тик алып кайта алмам — миңа ышанма», — дип әйтә ди. Әпәй генә: «Мин алып та барырмын, алып та кайтырмын», — дия ди. Ә безнең ипине инде күптән күргән юк. Вакыт төшке якка әйләнеп килә — кояш аяусыз кыздыра. Берьюлы ашыйсы, эчәсе, утырып ял итәсе, тагын әллә нәрсәләр эшлисе килә, тик арбаны гына тартмыйсы иде — бигрәк авыр бит...

Гайшә абыстай эре сөякле, гәүдәгә дә олырак, ләкин сәламәтлеккә туймый, аңа озын таудан арба тартып менүләре тагын да газаплырак. Ундүрт яшьлек Рәшит абыйның үзенә генә туры килә тартырга. Без исә әни белән икәү өстерибез үз «Темпы»бызны. Әни дә бәләкәй — зур көч иясе түгел, миңа да унбер генә яшь — йөк атына тиңләшергә иртәрәк.

— Ашыкмыйк, утырып ял итик, — ди Гайшә абыстай. Аның тәкъдимен барыбыз да эчтән хуплап каршы алабыз һәм, арбаны ташлап, юл кырыендагы үләнгә авабыз. Сөйләшерлек тә хәл юк. Барыбызга да берәр телем ипи бирүче булсын иде дә, шуны ашап җибәрәсе иде. Аннан соң «Темпы»ны тартып менүе дә бик авыр булмас иде. Ә болай Кләмәнтәй тавын менеп җиткәнче дүрт-биш мәртәбә туктап ял итәргә туры килә. Менеп җитәбез дә, бераз аска — Биктуган чокырына таба төшәбез. Аннан соң, бик озын булмаса да, Кләмәнтәй тавыннан да текәрәк Биктуган тавын менәсе бар бит әле. Бу таудан без арбаларны берәм-берәм, дүртебез берьюлы тартып менәбез. Тәннән, маңгай, муеннардан тозлы тир ага, атлаганда егәрсез аяклар чалыш-полыш килә...

Бәләкәй арба белән утын, печән, салам, кыр бакчадан көзен бәрәңге ташулар, ул көннәрнең чиксез авырлыгы хәтердә шул хәтле тирән уелып калган ки, ярты гасырдан артык вакыт узса да төшкә керәләр: интегеп-интегеп, тиргә батып Кләмәнтәй тавыннан утын тартып менәсең имеш. Кинәт уянып китәсең дә, моның төш кенә булуына кинәнеп бетә алмыйсың. Тик тынычлану сиңа тиз генә килми әле: йөрәк ярсып дөпелди, сулыш кысылган, үзең шабыр тирдә...

Ул елларның газабын һәрберебез искә ала. Әни:

— Бер кичне озак вакыт йокыга китә алмый, уйланып яттым: өйдә иртән торып пешерергә һичбернәрсә калмады, хәтта бәрәңге дә юк, — дип сөйләгән иде. — Йоклап киткәнмен дә, төш күрә башлаганмын. Тавык төшенә тары керә инде. Ашарга бетү турында әбиегезгә (әнинең каенанасы, 1943 елда вафат булган Бибигайшә әби. — Ә.С.) зарланып утырам, имеш. Ул: «Әнә, төшеп Рәхимәдән ал, аның базында тагын унөч чиләк бәрәңге бар әле», — диде әбиегез. Иртә белән Рәхимә апаларыгызга төшеп, (әбинең кызы, әтинең сеңлесе. — Ә.С.) төшне сөйләдем.

— Әйе шул, нәкъ унөч чиләк бәрәңгебез бар, каян белгән аны мәрхүмә әни? — дип гаҗәпләнгән Рәхимә апа һәм әнигә бер чиләк бәрәңге тоттырып җибәргән, рәхмәт төшкере.

Ач булгач бит әле рәтле йокы да алмый. Беркөнне мин таң атып, кояш чыгуга хәлсез килеш иләс-миләс атлап урамга чыгып утырдым. Һәрвакыттагыча үлеп ашыйсы килә. Шулчак безнең турыдан Кизләү очына таба берничә хатын-кыз, бала-чага ашыгып китеп барды. «Кая баралар икән алар» — дип гаҗәпләнеп калдым. Бераздан беленде: төнлә шундый ук ачлыкка, авыр колхоз эшенә түзә алмыйча фермада колхозның карт бер аты үлгән икән — ачка тилмергән, үлем куркынычы янаган кешеләр шуны бүлгәләп алып кайтканнар, пешереп ашаганнар.

Ә безне ачка үлүдән әнә шул мул сөтле сыерыбыз коткарды. Җәй буе колхоз эшенә — утауга, уракка йөргән җиреннән әни көн саен берәр-икешәр көлтә үлән алып кайта да, аны киптереп пает башына менгереп салабыз. Мин дә аз-маз азык әзерлим. Ләкин азык җитми, кыш уртасына бетеп китә. Колхоздан салам сорап алабыз. Бәләкәй чана белән кырдан сорамыйча да алып кайткалыйбыз. Ә сыерыбыз сайланмый — арыш саламын «ура» гына. Вакыт-вакыт ул «браматка» чыгып китә, ферма тирәсендә коелып калган печән-саламнарны җыештыра, йә киртә аркылы сикереп берәрсенен бакчасындагы салам, яки печән өеменә керә. Мондый әрсезлеге өчен аның ике мөгезен сугып сындырдылар, янбашына балта чаптылар. Малкаем озак кына җәрәхәтеннән кан саркып, аксап йөрде.

Бер кичне әни сыер сауганда савыт тотып килгән балалар арасында урамның Борһан тавы очында яшәүче Зөһрә абыстай малае, минем яшьтәш һәм сыйныфташ Габдрахманны да күрдем. Тагын да бәләкәйрәк чагында мин алар очына барганда олырак малайлар мине шул Габдрахман, аның ике туганнан туганы Мохтар белән көрәштерәләр иде. Бик тыйнак, кыюсыз малай иде Габдрахман. Мин аны үз итә, якын күрә идем. Савытын алып әнигә суздым. Әни ана сөт савып бирде. Габдрахман сөт тулы бәләкәй савытын ике кулы белән тотып, әкрен атлап өенә кайтып китте.

Иртән без күрше Сажидә һәм Ясмык Минач абзый кызы Сания белән Елховой поселогы Яна Чишмә урманына җиләккә киттек. Аерма юлына чыккач Сания кинәт нәрсәдер исенә төшкәндәй: «Төнлә Габдрахман үлгән бит» — дип әйтеп куйды. Әйтерсең лә аяз көнне яшен сукты. Йа Хода, кичә кичтән генә минем кулдан бер савыт сөт алып киткән дустым Габдрахман ачка киселеп җан биргән бит!

Авыр иде шул аларның тормышлары. Әтиләре Харис абзый безнең әти кебек сугышта югалып калды. Гаиләдә әллә биш, әллә алты бала. Кәҗәләре генә дә юк. Авылда ярдәмгә иң мохтаҗ гаиләләрнең берсе булды бугай аларның гаиләсе.

Соңыннан мин шуны белдем: Габдрахман, бичара, бездән алып кайтып киткән сөттән авыз да итмәгән, әнисенә кайтарып биргән. Зөһрә абыстай иртәнге ашка дип калдырган. Ах, белсәм иде Габдрахманның үләсен, әнидән тагын бер савыт сөт алып, аның үзенә генә эчерткән булыр идем...

Юк, авылда ачлыктан киселеп үлүчеләр бер Габдрахман гына булмады шул. Озакламый йорттан-йортка ризык эзләп йөрүче яше җиткән дивана егет Фәхразыйның да ачка үлүе мәгълүм булды. Күпер янында яшәүче Галлә абзый төрмәдән кайтып кергән көнне үлде — аның да дистрофия (ачка киселү) булган. Күршебез Миңкәмәл абыстайның да ике баласы ачтан дөнья куйды. Каһәр суккан сугыш, шул сугышка китергән тәкәббер һәм булдыксыз ил башлыклары, башбаштак совет һәм партия системасы, шулар нәтиҗәсе буларак туган ачлык әнә шулай байтак ярдәмгә мохтаҗ кешеләрнең, шул исәптән гөнаһсыз сабыйларның гомерен өзде.

Мин сугыш еллары һәм сугыштан соңгы ачлык турында үзебезнең авыл мисалында гына хәтер яңарттым. Ә бит безнең Татарстанда гына да авылы-авылы белән ачлыктан кырылу вакыйгалары аз булмаган. Аксубай районының Яңа Үзи авылыннан чыккан, бүген Әлмәттә яшәп ятучы пенсиядәге укытучы абый мина авылларына Бөек Ватан сугышыннан 74 кеше әйләнеп кайтмавы, ә ачлыктан шул ук авылда 75 кеше үлүе турында сөйләде күптән түгел. Актаныш районының Әнәк авылында туып-үскән актив хәбәрчебез Мөслиха апа Нәгыймова күрше Зөбәер авылының һәр икенче йортында яшәүчеләрнең язгы ачлыкта җирдә кышлаган бодай ашап, агуланып үлүе турында бүген дә ачынып сөйли. Алтышар-җидешәр кешедән торган гаиләләр тулысы белән кырылып беткәннәр. Коточкыч

фаҗига бит бу! Һәм ул да әнә шул алда әйтеп кителгән ил буенча килгән башбаштаклык нәтиҗәсе булган.

Авыл кешеләре арасында да төрлесе булды, әлбәттә. Колхоз амбарчысы булып эшләгән абзый, сугыштан исән-имин кайтып идарә тирәсенә елышкан эреле-ваклы түрәләр, һич югында атлы эштә — олауда йөргән абзыйларның гаиләләре без ач утырган үтә кризис чагында да мич тутырып ипи салдылар, ачка тилмергән күршеләре генә түгел, хәтта якын туганнарының да хәлләрен белмәделәр.

Шулай да мин алар ризыгын уртаклашмавыбызга бүген бик канәгать. Чөнки без дә кеше хакына кергән, намусыбызга хилафлык китергән булыр идек. Ачтан үлгән дустым Габдрахман рухы алдында миңа гомер буе газап чигеп яшәргә туры килгән булыр иде.

Ачлык еллары безнең өчен олы сынау булды. Әйтерсең лә без сират күперен кичтек. Очраклымы, әллә очраксызмы, үлем тырнагыннан котылып калган балалар ул мәхшәрдән ныгып чыктылар. Гаделлек, намуслылык, татулык, тырышлык, шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек, ярдәмләшү, кеше хәленә керү, аның кайгысын уртаклаша, кызгана белү кебек асыл төшенчәләрне, аларның бер-береңбелән яшәү дәверендә үтә кирәкле күркәм сыйфатлар булуы турында аңладык без. Мин аны ачлык газапларын бергә татыган күршеләрем Файзә, Саҗидә һәм аларның сеңелләре, дустым Җәмил Гыйльманов һәм аның апасы Мөсаллия, сеңлесе Тәслия, Нурхая абыстай балалары Мөкатдисә, Наил, Мәгъсүмә һәм Әгъдәс, сугыш туктаганның икенче көнендә — 1945 елның 10 маенда Кенигсбергта һәлак булып калган Әбелгата абзый балалары Мөхтәрәмә һәм Җәлил, шулай ук бөтенләй ятим калган Хәдичә, Зәрига, Әгъзам, Әгъләметдин, Рәшит Бәдыйковлар һәм башка бик күпләр мисалында әйтә алам. Күрше кадерен, туганлык хисләрен, ризык кадерен аеруча сизгерлек белән тоялар алар. Кайсы турында сөйли башласам да, алар миңа якын туганнарым кебек. Авылга кайтканда алар белән очрашып сөйләшү үзе бер гомер. Һәрберсе рухи бөтен, саф алар. Яшәүнең кадерен, ямен табып, тырыш хезмәт, гадел, бәрәкәтле тормыш белән яшиләр. Урлашмыйлар, алдашмыйлар, кеше хакына кермиләр. Һәрберсенең әллә ничәшәр баласы, оныклары бар. Сәламәт кенә була күрсеннәр — миннән изге теләк шул аларга! Һәрвакытта шаулап торган самавыр, кайнар коймак белән чәй артында очрашырга насыйп булсын.

Һәм Ходай ачлык күрсәтмәсен иде халыкка...

## Алданиләр көтә?

Балачакның иң якты сәхифәсе — мәктәптә уку еллары. 1946 елда Елховойда башлангыч мәктәпне тәмамладык та, Түбән Абдул ягына җидееллык мәктәпнең бишенче сыйныфына киттек. Кызык хәл: Елховой авылында — Иске Багряҗ башлангыч мәктәбе (кайсыдыр бер чорда Елховойны Иске Багряҗ дип атый торган булганнар), ә Түбән Абдулда — Елховой җидееллык мәктәбе.

Агач мәктәп Шушма елгасы буена урнашкан иде. Түбән Абдул, Елховой, Кызыл көч һәм хәтта Елховой поселогы — Яңа Чишмә авылы малайлары-кызлары да шушы мәктәптә укыйлар. Шөкер, авыллар арасы ерак түгел. Елховой белән Түбән Абдулны биек итеп таштан күтәргән юл (гать) тоташтыра. Шул юлда Борһан күле, Тугай суы һәм Шушма аркылы салынган өч күпер. Кыска гына таш юлда өч күпер булу безнең ише хыялый малай-шалайда авылларыбыз өчен ниндидер горурлык хисе уята. Әйтерсең лә гади авыл күпере генә түгел, ә Идел аркылы салган күпер. Әнә күрше Кләмәнтәй авылында бер генә күпер. Анысы да бәләкәй. Андый күперләр безнең Кизләү инешендә дә биш-алты. Ә Шушма аркылы

салган күпер каршында өч-дүрт «үгез» дә бар. Алары инде күперне язгы бозлардан сакларга куйган «үгез»ләр. «Күперегезнең баганаларын аударып, үзен җимереп китәм», — дип ярларга кагыла-сугыла агып килгән ястык калынлыгындагы зур боз әнә шул «үгез»ләргә килеп төртелә. Елга суына субай кагып утырткан «үгез»ләр көчле бәрелүдән селкенеп, ыңгырашып куялар. Боз өстенә башка бозлар шуышып меңәләр. «Үгез»ләргә тагын да авыррак сыман, тик алар бирешмиләр. Бозлар «үгез» сыртында ярылып, ваклаңып, күпер баганаларына бәрелә-сугыла аска таба агып китәләр.

Язгы ташкыннарның да төрлесе була. Кинәт төшкән бик ярсулы ташкыннарда күперләрне «үгез»ләр дә саклый алмыйлар. Ә безнең күл аркылы салган күпернең «үгез»ләре бөтенләй булмаганга, аны ел саен диярлек боз алып китә иде. Аннары авыл ир-атлары җәй буе яңа күпер салалар. Юан имән агачыннан ясаган «бабка» белән өч-дүрт таза ир-ат көннәр буе субай кагалар. Аларның: «Әйдә тагын, әйдә тагын» дигән авазлары тын авылның иң аргы урамнарына чаклы ишетелеп тора.

Бишенче сыйныфка барган елның беренче сентябре якты кояшлы, җылы көне белән истә калган. Мәктәпнең иң аргы, кояш нурлары төшеп торган классның бер алгы партасына Тугай малае Ләбиб Ибраһимов белән утырттылар мине. Кара тутлы, чандыр һәм миннән калку Ләбиб яшькә дә олырак иде: әтисе сугышка киткәч әниләре вафат булган һәм ул апасы белән ятим калып, мәктәп яшенә җитсә дә, укырга керми торган. Ләбибләр бәхетенә әтиләре сугыштан исән-имин кайткан иде.

Ләбиб белән бик тиз дуслашып киттек. Бәлки безне күңел биреп, тырышып, һәрнәрсә белән кызыксынып уку дуслаштыргандыр. Бигрәк тә арифметика, тарих һәм тел фәннәре дәресләре безнең өчен кызыклы иде.

Арифметикадан безне мәктәп директоры Әхәт абый Гыйләҗев укыта иде. Озын буйлы, таза, үз-үзенә нык ышанып эш итүчән Әхәт абыйның бер кимчелеге бар — ул тиз кызып китүчән һәм андый минутларда сүзен әйтә алмый, «ныпь-ныпь» дип тотлыга башлый. Кара тактага борылып мисаллар, мәсьәләләр язганда төрле сыйныфларда берничәшәр ел утырып калган Саим, Хәмматгата кебек «башкисәрләр» иң арттагы партадан пышылдап Әхәт абыйны «мукшы», «ныпь-ныпь» дип үртәргә дә батырчылык итәләр. Әхәт абый шулчак яшен тизлеге белән борыла да, кулындагы йодрык чаклы акбурны тегеләр ягына тондыра. Теге малайлар баш иеп калалар, ә акбур бүрәнәгә бәрелеп челпәрәмә килә. Аннары Әхәт абый аларны берәм-берәм тактага чакырып, мәсьәлә чиштерә башлый. Кая инде аларга мәсьәлә чишү! Әхәт абый аларга олы канәгатьләнү белән «берле» чәпи. Тактага Ләбиб чакырыла. Аның да, минем дә дәфтәрләрдә бу мәсьәлә күптән чишелгән: Ләбибнең мыш-мыш килеп тактага тиз-тиз язуы гына ишетелеп тора.

— Абый, булды, — ди ул эше беткәч. Әхәт абый дикъкать белән мәсьәләне карап чыга да:

— Утыр — «бишле», — ди.

Сентябрь булса да, көн кызу. Тәнәфес вакытында Ләбиб белән Шушмага йөгереп чыгабыз һәм күпер алдындагы «үгез» өстеннән сикерә-сикерә, чума-чума су керәбез. Шушма суы ул елларда Кизләү суы кебек саф, төбендә яткан ак ташларга чаклы күренә иде.

Татар теле һәм әдәбиятыннан безне Халидә апа Касыймова укытты. Алтынчы сыйныфта аны Мөнфика апа алыштырды. Бу ике укытучы да минем күңелдә туган телгә һәм әдәбиятка мәхәббәт уяткан кешеләр буларак сакланалар. Мөнфика апа әдәбият дәресләрендә кызыклы укуны оештыра иде. Укытучылар авырып дәрескә килмәгән буш сәгатьләрдә дә татар язучыларының повесть һәм хикәяләрен чиратлашып укыйбыз. Әллә минем әдәбиятны бик яратканны белепме, Мөнфика апа олы-олы

әсәрләрне миннән укыта. Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» повестен бик озак вакыт гел миннән генә укытканы хәтердә. Укый-укый остарып, аннан бераз артистларча уйнап, персонажларны үзләренчә «сөйләтеп», кыланып укуны сыйныфташларым да ярата һәм Мөнфика апаның дәрескә кергәч: «Бүген кемнән укытабыз?» дигән соравына: «Апа, Әсгать укысын, Әсгать», — диләр. Мөнфика апа үзе дә моңа каршы түгел.

Алтынчы сыйныфта укыганда мин шул ук Мөнфика апа тәкъдим иткәч, аның белән бергә укытучы Зәйтүнә, Нурия һәм башка апалар куйган бер спектакльдә ниндидер малай ролен дә башкардым, «артист» булып киттем. Мөнфика апа ул вакытта мәктәп белән янәшәдә өлкән яшьтәге укытучы Камилә апа Вәлиеваларда фатирда тора иде. Спектакль куйган көнне (ул 1 Май бәйрәме уңае белән куелды) миңа Түбән Абдулда калырга, Мөнфика апа фатирында кунарга туры килде, чөнки язгы ташу вакытында безнең авыл күле аркылы салган күперне боз алып киткән иде.

Мәктәп — үзенә бер тормыш. Анда без фәннәр өйрәнәбез, башка акыл, гыйлем байлыгы, җанга исә рухи байлык туплыйбыз. Мисыр, Урарту дәүләтләре, коллар һәм гладиаторлар, фиргавеннәр һәм патшалар, таш сыннар һәм пирамидалар... Барысы да кызык һәм мавыктыргыч.

Тик мәктәп диварлары тышында безне һәркөн тормышның, дөресрәге, тартып-йолкып көн күрүнең кырыс чынбарлыгы каршы ала.

Әле бишенче сыйныфны тәмамлаган 1947 елда ук ачка тилмереп, ялангачлыктан гаҗиз булып, очны-очка ялгый алмый интеккән бер төркем авыл ирләре һәм хатыннары соңгы малларын куалап безнең авылдан 270 чакрым ераклыктагы Казанга, аның мәшһүр базарына чыгып киттеләр. Ул төркемдә безне үзенең мул сөте белән әлегә кадәр үлемнән саклап килгән аклы-каралы, үзе дә еш кына печән белән саламга туя алмый «бурлык»та йөреп, кылган гөнаһлары өчен янбашын җимертеп, ике мөгезсез, ярты койрыксыз калган сыерны алып әни дә китеп барды. Без, дүрт бала, әни сыерны алып чыгып киткәндә акырып елап калдык. Сөтбикәбез дә, әллә инде аерылышуны сизенеп, безгә таба борылып кызганыч бер мөгрәү авазы чыгарды. Карап торган бердәнбер ышанычыбыз да, тамак туйдыручыбыз да иде бит ул. Шуңа күрә без аны ярата идек, бәлки (сыер гына димәгез!) ул да безне ярата торган булгандыр.

Казаннан әни уникенче көннән соң гына әйләнеп кайтты. Сигез көн барганнар, ике көн анда булганнар, ике көн кайтканнар. Бәхет кошы тоткан кебек кайтып керде әни. Аркасында олы ак капчык. Үзебез дә бик сагынып, юксынып беткән идек — дүртәүләшеп аңа ташландык. Бигрәк тә эти югалгач, 1942 елның карлар эреп, шаулап ташулар аккан апрель көннәрендә дөньяга килгән биш яшьлек энебез Әгъдәс белән сигез яшьлек сеңлебез Мөзәянә нык сагындылар. Әни соңгы тапкыр язган майны сатып безгә он һәм бәрәңге алып калдырган иде. Аларны инде ашап бетергән, әни кайткач пешерергә бернәрсә дә калмаган, ач утыра идек. Мин, уникенче яшьлек малай, үземә күрә «хуҗа» булып, балаларга булган нәрсәне пешереп, аларны барлап торсам да, ризыкны дүрт балага уникенче көнгә җитәрлек ясап, тигез итеп бүлә алмаганмын, күрәсең. «Тормыш тәҗрибәсе» җитмәгән.

Әнинең ак капчыгыннан безгә күлмәкләр, ыштаннар, аяк киемнәре, яңа алюмин кашыклар, чүмеч һәм башка көнкүрештә бик кирәкле нәрсәләр килеп чыкты. Ләкин иң хәтердә калганы — яңа казан һәм бер зур савыт кершән кебек бодай оны иде. Иске казаныбызның төбе тишелеп, авыл тимерчесе Сәлман бабай иске көрәкләрдән төп ясап биргән иде. Калын итеп төп салган казанда аш пешерүләре бер газап иде безнең өчен, чөнки тиз генә кызулык үтми аңа, кочак-кочак утын ягарга кирәк. Ә утын кытлыгы һәрвакыт тенкәгә тия.

Иске казанны урыннан тартып чыгардык та, анын урынына янасын куйдык. Ярты сәгать үттеме икән, анда куе умач кабарып, пешеп чыкты. Туйганчы ашадык умачны.

Аннары әни ничек безнең яраткан сыерны сатып җибәрүе турында сөйләде. Базарда сыерлар күп булган, ә алырга атлыгып тормыйлар икән. Олы җиленле безнең сыер тирәсендә йөрүчеләр күп, тик малкайның «товарлыгы» юк: мөгезләр сугып төшерелгән, койрык кисек, янбаш янтайган...

Шулчак әни янына бер кеше килә һәм аны бер якка чакырып ала.

— Сеңлем, карап торам, сыерың шәп, әмма сатып җибәрүе җиңел булмас, — ди ул татарчалап. — Мин сиңа булыша алам, тик син буш итмәссең...

Бу кеше Казан базарында танылган димче-маклер икән. Ун минут эчендә бөтен базарга сыерны мактап иң кыйммәт бәягә — 12 мең сумга сатып та җибәрә. Хезмәте өчен дә күп алмый: «Үзеңнең дә хәлең начар икәнен күреп торам, кул ялына 150 сум бирсәң — шул җитә», — дигән ул.

Озакламый әни Бөгелмә ягыннан 7 мең сумга башка сыер алып кайтты. Калган акча тормышның очын-очка ялгарга ярап куйды. Сулыш алу бераз җиңеләйде.

Көзге салкыннар башланганчы берничә күрше хатын, аларның кул астына керерлек балалары белән кумәкләшеп Кләмәнтәй өстендәге урманга «сажин салырга», ягъни кышка утын әзерләргә киттек. Икеме, өчме көн бардык урманга. Шактый утын әзерләдек.

Аннары безнең яңа сыерны җигәргә өйрәттек. Урыс арасыннан кайткан яшь сыер мең мәшәкатьле татар тормышының нужа шулпасын татымаган — җигәргә өйрәтелмәгән булып чыкты. Көч-хәл белән камыт кидереп, тәртә арасына кертеп бастырып, җигеп бетерергә дә өлгермәдек, кайнар канлы, дәртле һәм көчле яшь сыерыбыз урам буйлап дулап китмәсенме. Безгә булышырга алынган әтинең бертуган абыйсы Хәертдин абзый белән мин көчкә куып җитеп, арбага сикереп менәргә өлгерә алдык. Хәертдин абзый дилбегәне тартып тотты, тик сыер башын бирми, күзләренә кан саугын, авызыннан күбек ага һәм шашып алга чабуын дәвам итә. Тыкрык башында Хәертдин абзый сыерны бер якка борырга маташкан иде, күчәр башы тыкрык баганасына эләгеп, арба кыйшаеп китте һәм Хәертдин абзый мәтәләп төшеп калды. Мин исә арбага нык тотынган идем. Хәертдин абзый егылып калгач, дилбегәне үз кулыма алдым. Дилбегәне тартып тормадым, ә кыр капкадан чыгып бөтен көченә Кләмәнтәй юлы белән элдерткән сыерга ирек бирдем: әйдә чап, берзаман туктарсың әле... Һәм шулай булып чыкты да. Көчле булса да, анын да шашынудан тыны кысылган, хәле тәмам беткән иде. Авылга ул кабаланмый гына, инде язмышына буйсынып кайтып керде.

Ә Хәертдин абзый шактый вакыт: «Билем», — дип зарланып йөрде.

Җеңле сыерны тәмам авызлыклагач, «сажинны» әни белән Кләмәнтәйнең мөселман чуашы Әхмәтгата абзый читәне буена төшереп куйдык. Ә бездән дүрт чакрымдагы Кләмәнтәйдән утын ташуны ул елны мин тулысынча үз өстемә алдым. Коры өреңге агачларын чанага иплэп кенә төйим дә, олыларча тартып бәйләп куям. Сыерыбыз көчле. Озын Биктуган тавыннан да «эһ» тә итми җилдереп менеп китә. Утын ташучылар ул тауны менгәндә чаналарына утырмыйлар, сыерларына җиңел булсын, янәсе. Ә безнең сыерның башы югары күтәрелгән, үз алдында олау күрсә, тагын да ашкына төшә — аны узып китмичә тынычлана алмый. Шулай берне, икенчене, өченчене уза. Утынчылар: «Вәт, малай, сыерың таза, күз тимәсен, ат та кирәкми», дип гаҗәпләнеп калалар.

Йортка кайткач та сыерны тугарып, алдына печән яки салам салам. Сыер ашкынып «кырт-кырт» китереп азык уртлый. Мин чанадан утыннарны

бушатам, агач келәт буена өеп куям. Энем Тәлгать белән бер агачны кисеп ташлыйбыз да, мин аны ярып та бирәм. Нишләптер, быел утын агачларын күтәреп йөрү, эш эшләү миңа әллә ни авыр түгел. Үземдә буыннар ныклыгы, көч сизәм. Үсәм, ныгыйм бугай. Миңа бит инде озакламый унөч тула...

## Бүреләр

Кыш уртасы. Чатнама салкыннар артыннан көннәр йомшарып китә дә, бураннар котырына. Салкын Урал якларыннан искән усал җилләр авызы ачык, төбе тишек безнең йортның алдына да, артына да кар ташып тутыра, көрт өя. Әти бар вакытта ып-ышык мал абзарының хәзер алды ачык. Арттагы читән дә утырып, сүтелеп беткән. Бердәнбер малыбыз булган сыерны хәзер агач келәткә ябабыз, чөнки йортыбыз авыл читендә, ә Юкәле тавы артында төнлә бүреләр улавы безгә аерым-ачык ишетелеп тора. Алла сакласын, соңгы ышанычыңны бугазлап китәрләр ул ерткычлар.

Сугыш елларында мәхшәрдән качып көнбатыштан безнең тыныч якларга килеп тулган бүре халкы сугыштан соң кабат үз ягына кайтып китәргә уйламады. Безнең якның симез сарыклары бик ошады булса кирәк чакырылмаган кунакларга: колхозныкы, шәхси хуҗалыкларныкы димәделәр — кыйдылар гына бичараларны. Бүсер Хатыйп бабайның абзарына кереп өч сарыгын бугазлап чыктылар, салам түбәне тишеп өстән төшкән явызлар. Иртән таң атмас борын абзардан чыгып ычкыну әмәлен табалмый аптыраган бүреләрне Хатыйп бабай, сарыкларны чыгарам дип, капкасын ачып үзе чыгарып җибәргән. Абзар капкасыннан чыккан «сарыклар» берәм-берәм койма аркылы сикереп шылгач кына Хатыйп карт эшне сизенә.

Сәндрәдә төш күреп ятам: ниндидер бер гаугалы җирдә йөрим имеш, кычкырыш-талаш, этләр ярсып өрә...

Әни тавышына уянып киттем:

— Әсгать, тор тизрәк, йортта бүреләр, Артисны алып китәләр...

Сәндрәдән атылып төшеп тәрәзәгә капландым. Тышта кышкы таң атып килә. Йорт уртасында бозау кадәр өч бүре, ә урталарында күршебез Өммиләрнең ике бүрек зурлыгындагы этләре Артис ачыргалана. Күптән түгел генә без бер олау салам алып кайтып абзарга керткән идек. Үзенең оясы да булмаган ярлы эт шул салам өеменә кереп йоклый иде. Бүреләрнең иң зурысе бер генә ыргылды Артиска — бичараның көчсезләнеп барган соңгы чинавы гына ишетелеп калды. Мин, батырланып, тиз-тиз өстемә киенә башлаган идем, әни чыгармады. Алай-болай иткәнче бүреләр маэмайның җаны чыгып барган гәүдәсен сөйрәп бакча артына таба китеп бардылар.

Үзебез белән уйнап йөргән Артисның шулай харап булуы күрше малайлары өчен олы вакыйгага әйләнде. Иртән җыелышып бүреләр эзеннән киттек, ак карга кадалган эт койрыгыннан башка берни дә тапмадык. Бүреләр маэмаебызны бакча башында ук ботарлап ашап бетергәннәр иде.

Иң гаҗәбе шул булды: бүреләр эт артыннан йортка өч яктан төшкәннәр — эзләре ярылып ята иде. Берсе урам ягыннан кергән, икенчесе бакча ягыннан, ә өченчесе җимерек читән өстеннән төшеп этне салам өемендәге урыныннан кузгаткан һәм йортка чыгарга мәҗбүр иткән. Мескен эткә бернинди котылу юлы калмаган. Кеше акыллары бар диярсең бу бүреләрдә!

Кышкы иртәнең иң четерекле мәшәкате — ут табу. Олы урамда бик сирәк кешенең генә шырпысы бар. Таң atканчы ук йә әни, йә мин соскы тотып утлы күмер артыннан берәр күршегә кереп китәбез. Урамга чыгу белән моржаларга күз төшерәсең: кайсыннан төтен чыга? Соскыңа утлы күмер салып кайту — ул инде тормыш дәвам итә, яшисең дигән сүз. Озакламый синең мичеңдә дә шатыр-шотыр килеп коры өрәңге утыны яна, чуенда бәрәңге пешә башлый.

Бер буранлы таңда Дөләфкәрь абыстайларга утка кергән әни кабаланып кайтып керде. Караңгыда ана бер бүре бәрелеп киткән. «Сускымны бәреп төшерә язды. Ничек миңа ташланмагандыр, утлы күмердән шикләнде бугай», — ди әни.

Бер кичне сукыр лампа яктысында дәрес хәзерләп утырабыз. Кинәт кемдер боз каткан тәрәзәне какты: «Хозяйка, пустите нас ночевать?» Өйгә өсләре бәс белән капланган, өшеп-күшегеп беткән ике марҗа килеп керде. Берсе олы яшьтә, икенчесе — калку, таза гәүдәле, яшь. Аналы-кызлы бу марҗаларның кая барулары хәзер хәтердә калмаган, тик аларның бүреләргә юлыгулары турында сөйләгәннәрен яхшы хәтерлим. Әлбәттә, әни тәрҗемәсендә. Ятим калып ике ел балалар йортында тәрбияләнгән әнинең урысчасы ярыйсы гына. Шуңа күрә фатир эзләп йөргән башка милләт юлаучыларын авыл халкы безгә җибәрә иде: «Әнә, Мөсәвәрә сезнең телне белә, шуңа кереп куныгыз»...

Кичке караңгы юлда бу марҗалар артына ике бүре төшә. Ә боларның кулларында таяк кына да юк. Бик куркыналар. Дөрес, бүреләр ташлану түгел, аларга бик үк якын да килмиләр, ләкин арттан да калмыйлар — ияргәннәр дә, киләләр дә киләләр. Марҗалар юлда ашарга җәймә пешереп чыккан булганнар — яшь марҗа, анасын алга җибәреп, шул җәймәне вак-вак өзеп бүреләргә ташлап бара башлый. Юк, тегеләр баш тартмыйлар җәймәдән, ашап баралар. Тик җәймә күп булмый, бетеп китә. Инде нишләргә? Шулчак яшь марҗаның исенә аның капчыгында кесә фонаре барлыгы исенә төшә. Шуны тартып чыгарып утын кабызгач кына бүреләр артта калалар.

Марҗалар бездә кунып киттеләр. Әни аларга бәрәңге пешереп ашатты, юлга да мичкә тәгәрәткән бәрәңге биреп җибәрде.

Ачмы, ялангачмы, малайлар — малайлар инде алар. Без дә уку, йорт эше, тормыш мәшәкате арасында чыр-чу килеп уйнарга да, шаярырга-шукланырга да вакыт табабыз. Сарайлар артына, тар тыкрыкларга, бакчаларга тау-тау булып өелгән кар көртләре өстеннән генә түгел, хәтта Борһан һәм Юкәле таулары өстеннән дә чана белән шуабыз, сугыш уены уйныйбыз. Әле һәрберебезнең бакыр яки җиз көпшәдән ясаган, дары белән ата торган «наганнарыбыз» да бар.

Март киче. Аяз. Күктә бөтен серлелеге, матурлыгы белән тулган ай балкый. Тирә-юнь су кебек якты. Бер төркем малайлар кырга юнәләбез. Болай гына, дөнья белән танышып кайту өчен. Һәрвакыт эзләнүчән, нәрсәгәдер омтылучан, хыялый малай күңеле тынгылык белми бит ул, җилкенә, каядыр ашкына.

Төн әкияттәй матур, салкын да түгел. Кар өсте каты — язгы якта җылы кояш нурлары астында кар аз-маз эри дә, кичен катып китә. Без кар өстеннән һич батмый, тротуардан барган кебек барабыз да барабыз. Инде Юкәле тавына да ерак калмады. Беләбез, Юкәле арты тыныч түгел, анда бүре базлары, бүреләр оясы. Ләкин без бүген барыбыз да батыр — бүреләрдән куркып торумы соң?

Шау-шу килеп сөйләшеп барган бер мәлне Борһан тавы артыннан кинәт бер кара шәүлә килеп чыкты. Кырыс тормыш сизгер булырга өйрәткән — без шып итеп туктап калдык. Барыбызның да башында бер сорау: бүреме? Беренче шәүлә артыннан икенчесе, өченчесе, дүртенчесе күренде. Малайларның теге карачкыларның ничә икәнен санап тору түземлекләре бетте — борылып, бар булган көчләренә авылга таба чаба башладылар. Батырлыкның әсәре дә калмады. Барысыннан да алда озын ботлы Җәлил эләртә, аның артыннан абыйсы, бездән өч-дүрт яшькә олы булса да гәүдәгә зур булмаган Рәхимҗан, аннары Өмми Җәүдәте, Наил, Минсәгыйрь, Өлфәт, башкалар чабалар. Мин дә алардан калышмыйм. Шулчак артта

кычкырган тавыш ишетәм. Минем бер энекәш артта калган икән. Мин аны алга уздырам һәм артка карый-карый иң соңгы булып чабам. Бүреләр исә безнең барлыкны да белмиләр...

Көч-хәл белән безнең келәт артына кайтып җитәбез һәм көрт өстеннән бүреләрне күзәтәбез. Алар ай яктысы астында бик ачык күренәләр. Әйтерсең лә бер бауга тезелгәннәр — берсе артыннан икенчесе тигез ара калдырып, салмак йөгереп сигез бүре безнең бакчалар башыннан ерак түгел җирдән Ярлар башына, колхозның сарык фермасы ягына үттеләр. Ул яктагы авыл этләре башта бик ярсып өрсәләр дә, бүреләр якынайган саен аларның тавышы берәм-берәм тынып калды. Койрыкларын кысып, ояларына кереп качтылар куркак маэмайлар.

Иртән кызыксынабыз: бүреләр колхоз сарыкларына тимәгәннәрме? Юк, тимәгәннәр. Бер аяныч вакыйгадан соң безнең сарык фермасын ныгытканнар иде шул.

Нәкъ шул көннәрдә бөтен авыл халкын бер яңа вакыйга таң калдырды: Нижгар бабай бүре үтергән...

Сугыш алдыннан гына Горький шәһәре тирәсендәге мишәр дөньясыннан Елховойга бер карт белән карчык килеп төпләнә. Ягъни, Нижний Новгород ягыннан. Шуңа күрә таза гәүдәле, торбадан чыккандай көр тавышлы ул бабайны барыбыз да Нижгар бабай дип атый идек. Таза тормышлы бу бабайларга без еш кына чана да, арба да, дирбияләр дә сорап төшә идек. Карт юмарт, беркемне дә буш кул белән кире борып җибәрми.

Аның бүре белән очрашу вакыйгасы болай була: беркөнне ул сыерын җигеп соң гына утынга китә. Утын төяп, кайтырга чыга. Биктуган тавын менгәндә инде караңгы төшә. Чокырга җиткәч, бабайның сыеры кинәт туктап кала, мөгери, пошкыра, башын чайкый башлый. Бабай алга караса, анда бозау чаклы бер бүре ыржаеп басып тора. Нижгар карт ике уйлап тормый, олаудагы сәнәген тартып ала да, бүрене чәнчеп үтерә.

Бу хәлдән соң озак та үтмәде, Татарстан җирендә, шулай ук безнең тирәдә дә бүре токымы белән аяусыз көрәш башланды. Аучылар төркеме дә, чаңгылы хәрби төркемнәр дә, аэропланнан да авыл хуҗалыгына, халыкка шактый зыян китерүче бу корткычларга каршы сугыш ачтылар һәм аларның күпчелеген атып алдылар. Артык азынганнар иде шул. Аннан соңгы елларда бүреләр инде бик сирәк очрый торган булды.

## Дәллә Шакир

Кыздырып торган кояшы, шаулап аккан гөрләвекләре һәм ташулары белән яз килде. Кардан беренче булып тау башлары ачылды. Малга азыгы беткән безнең ише ярлы-ябага сыерын шул тау башларына алып чыга башлады. Сыерлар әле генә башын калкыткан үләннәрне кыркып йөриләр, ә без, малайлар, учак ягып җибәрәбез дә, аның тирәсенә җыелып утырып, әкиятләр, төрле гыйбрәтләр сөйлибез. Кайсыберебез инде тәмәке тартырга да өйрәнгән — җиң очына яшереп кенә тәмәке көйрәтәбез, тәмәкесе булмаганнар бездән төпчек көтеп утыра.

Шулчак сыерын куалап безнең янга Кытай Әкрәме дә килеп җитә. Эте Альфа да ияргән. Әкрәм түгәрәкләнеп утырган малайлар янына килеп җитү белән:

— Йә, Альфа, кайсы боларның ялганлап утыра? — дип этенә эндәшә. Альфа исә, барыбызны да шаккаттырып, уң тәпиен күтәреп «сүз остасы» ягына күрсәтә. Рәхәтләнеп көлешәбез.... Менә сиңа маэмай!

Төштән соң авылга кайтабыз. Урамда аккан гөрләвекләрдән буа буабыз, кизләүдән су алып кайтучы кызлар юлына баткаклыклар ясап куябыз.

Әнә судан Минач абзый кызы Әминә апа белән күрше Файзә кайтып

киләләр. Чиләкләре мөлдерәмә тулы су, көянтәләре сыгыла. Аякларында ап-ак тула оек һәм чабата. Аякларын чылатмас өчен «корырак» жирне сайлап-сайлап атлап кайталар. Малайлар көрәкләр белән маташкан тирәгә килеп житкәч, алар сагаеп калалар. Ә монда аларны чыннан да безнең этлек сагалап тора — өстенә тизәкләр салып, яшереп ясаган баткаклыкларның исәбе юк.

— И, энекәйләрем, батырмагыз инде, аякларыбызны чылатмагыз, әле тагын суга барасыбыз бар бит, — ди Әминә апа ялынып.

— Ярар, ярар, батырмыйбыз, — ди баткаклыклар ясауда мәче йоткан Жәлил һәм житкән кызларга «юл күрсәтә» башлый.

— Менә монда бас, монда...

Берзаман Әминә апа гөбердәп тубыктан баткаклыкка чума. Ачуы килгән кыз чәчрәп чиләкләрен атып бәрә дә, көянтәсе белән Жәлилне алдыртып китә...

Безнең урам — өске урам, кардан тиз ачыла. Жир кипшенә башлау белән без ашык, туп, «чебен» уйный башлыйбыз. Ләкин озын-озак уен белән мавыгырга туры килми. Кипшенеп барган бакчаларда безне иксез-чиксез эш көтә. Язның бер көне ел туйдыра дип бер дә юкка әйтмәгәннәрдер. Бәрәңгене никадәр күп утыртсаң, шулкадәр тамагың тук булуга өмет бар.

Мен мәшәкать арасында чираттагы уку елы да тәмамланды. Бик үк яхшы булмаса да, имтиханнарны биреп алтынчы сыйныфны бетердем. Безнең чорның тормыш йөген тартышып баручы авыл балаларына бик яхшы уку мөмкин булмады. Мин, бәлки, табигать биргән сәләт, зирәклек белән укытучылар авызыннан ишеткән дәресләрне белеп, фәннәрне үзләштереп укучы балаларның берсе булганмындыр.

Инде үтә ачлык еллар артта калса да, әлеге 1948 елда да халыкның тормышы яхшы түгел иде. Бигрәк тә жәй башы нык сиздерә. Шул ук кычыткан, балтырган, черек бәрәңге, алабута... Он юк, бәрәңгенең соңгы чиләкләре.

Колхоз кырында башта арыш өлгерә, аннары борчак. Ашыйсы килү малай-шалайны арыш кырына берничә тапкыр алып барып кайтты инде. Юк, башаклар һаман өлгерми, бөртек булып туласы жисем урынында сөт кебек сыекча гына. Ниһаять, бер көнне ул сыекча бөртеккә әйләнә. Без ашкынып башак жыеп кайтабыз һәм кылчыкларын учактагы күмердә көйдереп, башакны учта уабыз да, бераз куырылган бөртекне авызга кабабыз. Әнә шулай тамак ялгый башлыйбыз.

Аннары чират борчакка житә. Ләкин борчакны кыр сакчылары нык саклыйлар. «Бардым борчакка, тутырдым корсакка. Каравылчы Якуп. Жибәрде атып. Калдым ятып. Калмасам ятып, үтерә иде атып...» Моны без яхшы беләбез. Безнең каравылчыларның мылтыклары юк-югын, ләкин атлары бик житез. Тансык Гомәр һәм Такуй Мингата абзыйлар Елховой өчен «тарихи» шәхесләр. Явызлар, кансызлар. Борчак кырында алар камчысына юлыккан малайларның аркалары бүген дә — бабай булгач та — сызлый торгандыр әле...

***

Сталинның авылларда күмәк хужалык төзү сәясәте баштан ук халыкка явызлык кылу ниятеннән булган икән. Барысын да саклап, бөртекләп, барлап яшәгән авыл кешесенең мал-туарын, эш коралларын тартып алып «күмәк хужалык»ка бир дә, аның үзен көн-төн эшләтеп, иккән игенен, сауган сөтен, суйган итен дәүләткә тапшыртып, ач-ялангач яшәт. Колхозга керергә теләми икән — аны кулак дип ата да, ата-бабасыннан калган жиреннән, туган төбәгеннән аерып Себергә озат, лагерьда, төрмәдә черет.

Колхоз дигән нәрсә ул башта ук урлашу, алдашу өчен корылган сыман. Көннәр буе арып-талып эшләп кайткан җир кешесенә «хезмәт көне» язалар. Ә ана бернәрсә дә бирелми, үзен исә ашап та, киеп тә булмый. Нишләсен колхозчы бу очракта? Ана бер юл — урлашырга кала. Юк, урлашырга да түгел, ә сорамыйча алырга кала. Үз колхозы бит: ана ул атын, сыерын, сарыгын-кәҗәсен биреп керде. Шуна карамастан, ул бүген ач утырырга мәҗбүр. Үзе инде ач та утырыр — балалар бар бит әле. Менә шуна сорамыйча алырга туры килә ана.

Ач булганга күрә, үскән чакта үз колхозыбыздан бераз гына безгә дә «сорамыйча» алырга туры килде. Мин бу эштә үземне дә, яшьтәшләремне дә, колхозның башка әгъзаларын да гөнаһлы санамыйм. Сталин, аның тарафдарлары гөнаһлы, әмма без түгел! Бөтен гаделсезлек алардан булды. Берәүләр колхоз игенен олау-олау урлап, ел әйләнәсенә мич тутырып ипи салды, ипи ашады. Икенчеләр өч-дүрт кадак бөртек белән тотылып төрмәгә олактырылды. Өченчеләргә урларга намуслары кушмады. Дүртенчеләр төрмәдән куркып урлашмадылар һәм ач утырдылар. Әнә шундый үтә гаделсезлекләр кылынды ул елларда.

Күпчелек кохозчы дер килеп, куркып яшәде. Кайсыдыр бер чорда (1947 елда бугай) «Елхово» колхозы рәисе булып Түбән Абдул кешесе Дәллә Шакир торды. Какча гәүдәле, ябык йөзле, иреннәре нечкә, күзләре очлы. Явыз кешеләрнең иреннәре нечкә-нәзек була, диләр.

Әниләр Киләк тавы артында урак белән арыш уралар. Бу вакытта инде бәрәнге өлгерә башлаган, без, бала-чага, мулрак яфраклы төпне капшап бармак башы чаклы бәрәңгеләрне өзәбез дә, пешереп, төшкә әниләргә илтеп ашатабыз. Кыюрак хатыннар куе булып үскән арыш арасында ут ягып, калайда арыш куыралар, шуның белән тамак ялгыйлар. Ә безнең әни кыюсыз. Дәллә Шакирның да елкылдап торган колхоз айгыры җиккән тарантаста минуты белән килеп җитүе бар, чөнки ындыр табагы бирedән ерак түгел, ә рәиснең күп вакыты шунда уза. Шулай да бу юлы безнең әни дә түзмәде: урган көлтәләрен бераз каккалап ике-өч уч арыш төшереп бирде һәм мин аны кипкә эченә салып куйдым. Кайтырга бөтен бригада хатын-кызлары, бала-чагалар бергә чыктык. Ындыр табагы юлдан 50-60 адым гына. Күзебез аңа төбәлгән: Дәллә Шакир андамы? Чөнки һәрберсендә азмы-күпме арыш бар, һәрберсе шикләнә. Алла сакласын...

Саклый ди ул сине! Кинәт салам эскерте артыннан колхоз рәисе килеп чыкты һәм безгә таба юнәлде. Аты-тарантасы белән эскерт артында яшеренеп, безне сагалап тора икән.

— Малайлар, качыгыз! — диде безгә Зәйтүнә апа һәм без, берничә малай, төрле якка таралып чабарга тотындык. Мин башта әкрен генә йөгерә башлаган идем. Бервакыт артыма борылып карасам, хром итекләр, галифе кигән колхоз рәисенең нәкъ мине куып килгәнен күреп алдым. «Бу бәләкәй малайны тизрәк тотармын». — дип уйлагандыр. Тотарсың менә! Монда инде ике уйлап торасы юк. Мин лобогрейка белән урган арыш кырына кереп, Ярлар башына таба бар көчемә йөгерә башладым. Артка карарга да вакыт юк — камыл өстеннән сыпыртам гына. Текә яр буена килеп чыккач кына тукталып артка карадым. Шакир абзый үпкә чирле иде, минем арттан озак йөгерә алмаган, борылып хатын-кызлар янына килгән. «Кем малае, әйтегез!» — ди икән. Кем әйтсен инде аңа? Әйтмәгәннәр. «Нииндидер чит малай иде ул», — дигәннәр.

Яр аркылы чыгып әкрен генә өйгә кайтып киттем, чөнки кинәт аякларым авыртканын сиздем. Үткен камыл башлары күп итеп аяк асларыма кадалган булып чыкты. Курку, кызулык белән сизмәгәнмен. Өй баскычына утырып кояш баеганчы әни минем аякларны болаука белән камыллардан тазартты, аннары үз бәвелем белән чылаткан чүпрәк урап куйды.

Бер-бер артлы дистәләрчә еллар үтеп, бик күп сулар аккач, минем бала чагыма куркыныч төш кебек кереп калган Дәллә Шакир абзыйның безнең гаиләазмышында әле 1937 елда ук коточкыч роль уйнавы мәгълүм булды. НКВД «өчлеге» карары белән «халык дошманы» дип 1938 елның 7 гыйнварында Бөгелмә төрмәсендә атылган Салах бабамның Казанда Черек күл янындагы КГБ бинасында бүген дә саклана торган 10125 санлы «дело»сында Түбән Абдул авылы кибете мөдире, 1905 елда туган Закиров Шакир Закир улының шаһит буларак бабам өстеннән НКВД ялчыларына биргән ялган шикаяте теркәлгән. Һәм бабам язмышын хәл итүче хәшәрәтләр бер Дәллә Шакир гына да булмаган икән бит. Бу турыда язасым алда әле...

Тик шуны гына җиткерәсем килә укучыларга. Кешеләрнең бер-берсенә кылган яхшылыклары да, начарлыклары да онытылмый. Аларның кайберләре тарихта да теркәлеп кала бит әле. КГБ архивы — тарих түгелмени? Дәллә Шакир, Әтәч Шәфыйк кебек әтрәк-әләмнәр үзләренең явыз донослары турында киләчәктә беркем дә белмәс, дип уйлаганнар иде микән әллә? НКВД (ул чакта), КГБ белән бәйләнешкә кереп, авылдашларына этлек кыл да, синең гөнаһыңны башка авылдашларың белми дә калсыннар, имеш... Ашыкма, бәдбәхет, кырын эш кырык елдан соң да беленә ул!

## Түбән Абдулда

1948 ел җәендә мине — унөч яшьлек малайны — яна бер хәл көткән булып чыкты. МТС мотористы булып эшләүче ерак кардәшебез Минхәеров Талип абзый белән яшь комбайнчы Исмәгыйль Гыйльмановны Түбән Абдул ягына, «Кызыл йолдыз» колхозына иген сугарга билгеләгәннәр икән, ә аларга үлчәүче кирәк. Үлчәүче булып анысы кем дә эшли ала — хатыннар да, кызлар да. Тик Талип абзыйга мотор яки комбайн төзәткәндә (ә техника ватылмый тормый) кул астына кирәргә малай кеше кирәк. Май салган савыт тотып күчәрләрне, чылбырларны майларга кирәк чакта да хатын-кызга эш кушалмыйсың. Әнә шулай мин тумыштан «р» авазын әйтә алмаганга Шый («шыр» сүзен «шый» дигән) кушаматы берегеп калган Талип абзый белән Исмайның ышанычлы ярдәмчеләренә әвereлдем.

Безне Түбән Абдулда фатирга Талип абзыйның бабасы (хәләл җефетенең атасы) — Мөәзин бабайларга урнаштырдылар. Фатир дигәч тә, өйдә Талип абзыйга гына урын булды бугай. Унҗиде яшьлек чатнап торган, үткен телле, шаян сүзле Исмай белән мина урын пает башында, печәнлектә генә тиде. Моңа безнең исебез дә китмәде, чөнки элек тә бер-беребезне яхшы белгәнгә, Исмәгыйль абзый белән без дуслашып киттек. Иртә таңнан алып кичке караңгыга чаклы сугуда булсак та, кайткач печәнлектә рәхәтләнеп сөйләшеп ятабыз, үзебезгә калса серләребезне уртаклашабыз. Сугуда, ындыр табагында күбесенчә җиткән, йә булмаса җитеп килүче кызлар эшли. Барысы да уңганнар, булганнар — бу безнең ул еллардагы татар-мишәр кызларына хас күркәм сыйфат иде. Үзләре дә чибәрләр. Ә Исмәгыйль абзыйның борынына инде кызлар исе керә башлаган вакыт. Аңа әнә барабанга көлтә биреп торучы Сания дә, җилгәргечтә эшләүче Вәсилә дә бик ошый. Тик Вәсилә бераз олырак бугай. Әмма аның җырлавы... Каян килгән авыл кызларына шундый моңлы тавыш? Мотор яки комбайн ватылып торган чакта, йә булмаса яңгыр явып көлтәләрне чылатып китсә, ындыр табагында эш тынып кала. Кызлар җыелып салам кибәне артында ял итәләр, сөйләшәләр, сузып җырлап җибәрәләр. Вәсилә апа исә җырчы кызлар арасында аерылып тора.

Каенлыкка кергән чакта
Уралдым каеннарга;
Уралмадым каеннарга,
Уралдым кайгыларга...

Эшебез тыгыз булмаса, мин дә, Исмәгыйль дә кызлар янына барып утырабыз, җыр тынлыйбыз. Кызларның әле берсе, әле икенчесе башлый җырны. Һәркем үзенең күптән ишеткән, белгән, аның рухи халәтенә туры килгән җырны күңеленнән барлап куя һәм чираттагы җыр тәмамлангач, кычкырып үзенең яраткан җырын башлап җибәрә. Күп очракта монсу, кайгылы җырлар яңгырый. Нишләсеннәр соң инде ул авыр елларның бичара кызлары? Тормышлары да шундый ук монсу, мәшәкатьле, кайгылы иде шул.

Җыр яратканга, үземнең дә моңланасым килеп китә һәм мин иң арттагы кибән артына ялгызым барып утырам да, җырлап җибәрәм:

Ага сулар, ага сулар,
Ага суның салкыны;
Дөньясына ут кабынды,
Безгә тиде ялкыны.

Бу безнең әнинең яраткан җыры, аның «репертуары»ннан. Мәгънәле җыр: дөньясына сугыш уты кабынды да, ялкыны безгә тиде, безне көйдереп алды, әнине — ирсез, без, дүрт баланы, — атасыз калдырды. Юк, безне генәме соң? Миллионнарга тиде ул аяусыз сугышның ялкыны...

Шулчак яныма Вәсилә апа, Вагыйзә һәм Лениза килеп утыралар. Мин, уңайсызланып, җырлавымнан кинәт туктап калам.

— Җырла, Әсгать, җырла, энем, бездән оялма. Син моңлы җырлыйсың, — ди Вәсилә апа. — Минә мин дә җырларга яратам. Җырлыйсың да, кайгылар таралып китә. Әйдә, бер яраткан җырыңны сузып җибәр әле!

Кызлар кыстыйлар, ә мин тарсынам. Җырлыйсы да килә...

Сандугачларның сайравы
Ник болай моңлы икән?
Моңлы бала түгел идем,
Миңа ниләр булды икән?

Җырның соңгы өлешенә Вәсилә апа да кушыла, Вәгыйзә дә җырлаган кебек итә. Ленизa гына, түгәрәк матур күзләре белән миңа текәлгән дә, нәрсәгәдер гаҗәпләнгән сыман карап утыра.

Моннан соң инде без Вәсилә апа белән тәмам дуслашып киттек. Самания апа белән дә. Самания апа безнең әни ягыннан чыбык очы кардәш. Кызлар кайдадыр, мин белмәгән яшерен җирдә, арыш куыралар. Самания апа кешегә күрсәтмичә генә миңа да бер-ике уч куырган арыш биреп китә. Вагыйзә дә мине игътибарыннан ташламый, чөнки безнең әниләр дускынайлар. Энесе Мөхәррәм белән бер сыйныфта укыйбыз. Бер-беребезгә йөрешәбез.

Дустымның дусты миңа дус, дигән кебек, Вагыйзәнең ахирәте, күп дигәндә унбиш яшьләр тирәсендәге, мишәр кызлары өчен гадәти булмаган ят — Ленизa исемле килеш-килбәтле, матур йөзле кыз да миңа карата күркәм мөнәсәбәттә. Колхоз рәисе ындыр табагында, сугуда эшләгәннәр өчен төшке аш пешерүне оештырып җибәрде. Ашау вакыты житкәч тә Вагыйзә белән әлеге кыз мине үзләре белән алып китәләр, яннарына утырталар, мине игътибар үзәгендә тоталар.

Ындыр табагына халык иртән иртүк җыела. Сәгать алтылардан да калмыйча, моторны кабызып, сугуга керешәбез. Көннәр матур тора. Андый алтын көннәрнең минутын югалтырга да намусы җитмичә эшли иде халык ул елларда. Аты, үгезе, сыеры — барысы да җиккән, барысы да комбайнга көлтә ташый. Төнге караңгы дип тә тору юк — көлтә өеме комбайн барабаны алдында тау чаклы өелә. Комбайнга җан керүгә, эш майланган кебек башланып китә һәм, техника ватылмаса, көлтә беткәнче сугу бара.

Бер көнне иртән эш башланганчы мин һәрвакыттагыча чылбырларны, күчәрләрне, комбайнның башка хәрәкәттәге механизмнарын майлап йөрим. Аска төшәм, өскә менәм. Шулчак комбайн белән биек көлтә өеме арасында Ленизa пәйда булды. Кыз мина кул изи: «Кил әле бирегә!» Манка гына малай булсам да, бу кызга карата минем хыялый күңелдә ниндидер бер ләззәтле, матур хис тәерләнеп килә. Аны күргән саен күрәсем, сөйләшәсем килә. Ә бүген ул үзе әнә мине эзләп килгән. Сикереп төштем янына. Ленизa мөлаем итеп елмайды да, кулдан суккан тастымалга төргән бер төен сузды һәм аралыктан чыгып та шылды. Тастымал эченнән әле җып-җылы берничә коймак килеп чыкты. Ачы коймак, майлы, тәмле коймак. Ул коймакларның тәме бүген дә авызымда тора кебек.

Ашлык суккан вакытта минем эшем авыр түгел. Кызлар сугылган бөртекне носилка белән өемгә ташыйлар, ә мин һәр носилканы санап, дәфтәргә теркәп барам. Носилкадагы бөртекнең авырлыгы үлчәнгән. Шуннан чыгып соныннан барлыгы күпме ашлык сугылганын чыгарам да, накладнойлар язып, берсен колхозга тапшырам, берсен МТСка биреп җибәрәм. Шулай һәркөн.

Мотор яки комбайн ватылса, мина инде кулга ачкычлар, чүкеч яки башка корал тотып, майга, пычракка батып эшләргә туры килә. Ләкин мин эштән баш тартмыйм, олылар нәрсә кушсалар шуны башкарам, көчемнән килгәнчә булышам аларга. Талип абзый сүзгә дә, мактауга да саран. Ә менә Исмәгыйль абзый белән без гел сөйләшеп, киңәшеп эшлибез һәм ул мине мактап, күңелемне күтәреп җибәрергә дә иренми: «Кая, карыйм әле? Әһә, молодец, дөрес эшләгәнсең. У-у, болай булсаң, син бик ерак китәрсең әле, үз вакытында туктамасаң...» Һәм рәхәтләнеп көлә Исмай. Мина да кызык булып китә. Шаян да сүзле инде!..

Минем МТС үлчәүчесе булып эшләвем гаилә өчен олы табыш. Теге як авылның Прогон тавы өстендәге ындыр табагыннан кайтып йөрергә ерак һәм арыган булсам да, көн аралаш мин өйгә кайтып кунам һәм кайткан саен шактый гына пешкән ипи калдырып китәм. Талип һәм Исмәгыйль абзыйлар да, мин дә МТС кешеләре булып саналабыз һәм безгә көн саен бер кило ипи бирәләр. Мин, әлбәттә, ипине саклап кына ашыйм, чөнки өйдә бит әле ашарга сораучы өч туганым һәм әни бар. Балалар мине ишектән керү белән: «Әпәй алып кайттыңмы?» — дип сорыйлар. Һәм мина аларның ипи ашауларын карап торуы күңелле булып китә. Үземнең аларга ипи алып кайтырлык кеше, эшче булып җитешүемнән ниндидер бер канәгатьләнү хисе тоям, горурланып куям. Ә әпәйне унган Түбән Абдул хатыннары тәмле салалар иде.

Арышны сугып бетердек. Прогон тавындагы ындыр табагыннан Каенсарга киттек һәм бодай суга башладык. Көннәр коры тора. Эш тә кызу. Август бетеп, мәктәптә укулар да башланды. Мәктәп директоры Әхәт абый Гыйләҗев ындыр табагына агитатор буларак килсә дә, мина да игътибарсыз калмый: «Әсгать, укырга кайтырга вакыт!»

— Тагын атна-ун көн эшләсен инде, — ди Талип абзый директорга. — Кышка бераз ашлык эшләр...

Әхәт абый ризалаша. Ләкин кабат килүендә тагын уку турында сүз

башлый. Инде сентябрьнең дә өч атнасы узган. Ниһаять, мин эштән китәргә булам.

Соңгы көн. Ындыр табагындагылар белән саубуллашып йөрим. Самания, Васила, Разыя апалар мине кочаклап алалар. Ындыр табагы мөдире бөкре Һади абзый минем белән саубуллашканда аркамнан сөя. Ә кибән артында Вагыйзә саламга капланып елаган Ленизаны юата: «Әллә кая китми бит ул, үзебезнең якта укырга гына китә. Безгә килгәндә күрми калмассың әле...»

«Кызыл Йолдыз»да эшләвем төшемле булды. Бер центнер бөртек һәм 251 сум акча бирделәр. Унөч яшьлек малайның беренче хезмәт хакы. Шытырдап торган ике йөзлек, бер иллелек һәм бер берлек. Тәүге тапкыр акча ведомстена кулымны куеп алдым һәм аларны олы кеше сыман горурланып әнигә кайтарып бирдем. Мондый байлык ул елларда, кызганычка, иң унган колхозчыларга да тәтеми иде бит әле...

## Лашманда

Жиденче сыйныфны тәмамлагач без, берничә малай һәм кыз, кая булса да укырга китәргә жыенып йөри башладык. «Китәбез!» Тик кая? Республика газеталарыннан «Укырга кая барырга?» дигән белдерүләрне кат-кат укыйбыз, уйланабыз, шөбһәләнәбез. Казан елга техникумы, мех техникумы, Лубян урман техникумы, Алабуга культпросвет училищесы... Дәрт бар, дәрман юк, дигән кебек, теләк зур, ләкин хыялланган беләнмени, әгәр хәерчелегең сине баудан ычкындырмаса. Шулай итеп, ерактагы калаларга чыгып китәргә насыйп булмады. Ахырда Беренче Май районында бердәнбер татар урта мәктәбе булган Олы Лашман авылына, сигезенче сыйныфка укырга киттек.

Лашман безнең авылдан егерме чакрымда. Атна саен бер көнгә авылга кайтып, бер чиләк бәрәңге, әгәр булса бераз он, туң май һәм әни пешереп биргән берничә бәрәңге күмәче салган капчыкны аркага асып китәм. Өч ел буе авылга барып укып йөрү беркем өчен дә жиңел булмагандыр анысы, миңа исә икеләтә авыр булды, чөнки анда гел аталы, таза тормышлы балалар гына укыды, атасыз, терәксез бала бер мин генә идем. Атасы сугышта югалып калган малайның бер өстенлеге бар — укыган өчен мәктәпкә елына 150 сум акчасын түләүдән азат, әгәр райсобеска төшеп мәктәпкә белешмә алып кайтып бирсә.

Лашманда укуның беренче көненнән үк көтмәгән хәлгә дучар булдык. Математика дәресенә безне Елховойда укыткан Мәрьям апа Галимова килеп керде. Исебез китте, шатлыгыбыз эчебезгә сыймады, чөнки Мәрьям апа безгә математикадан төпле белем биреп, безне кызыксындырып, ярыштырып, үзенә бер оста педагогик алымнар белән укыткан иде. Дәрескә кереп безне — Мөхәррәм, Әлфрит һәм мине күреп алу белән: «Үземнең укучыларым килгән бит!» — дип, эчендәге шатлыгын бөтен класска чыгарды.

Жәйге айларда Елховой мәктәбе военругы Әхмәт абый Мөхәммәтшин белән Мәрьям апа өйләнешкәннәр дә, Әхмәт абый Лашман МТСына килеп механик булып эшкә урнашкан икән.

Сигезенче сыйныфта да без Мәрьям апа йөзенә кызыллык китермәдек, тырышып укыдык.

Ләкин тугызынчы һәм унынчы сыйныфларда безне югары белемле булса да, математикадан үзе дә рәтләп белмәгән кеше укытты һәм без дә бу фәннән шактый саектык. Ә кесәсендә фәкать Бөгелмә ике еллык укытучылар институты дипломы гына булган Мәрьям апага, белеме искиткеч тирән булса да, югарырак сыйныфларда укытырга рөхсәт итмәделәр. Югары белеме юк, янәсе. Совет мәгариф системасының әнә шундый гажәп томаналыгы

бүгенгә мәктәпләрдә дә яшәп килә бит әле. Күрәмсең, тамырларын тирән җибәргән ул томаналык.

Беренче елны фатирда без — мин, Әхми Хәйруллин һәм Бәркәтәдән Әхсән Шәрәпов Фәхертдин абый Зөфәровларда тордык. Бәләкәй генә дүртпочмаклы өйдә Фәхертдин абый, хатыны (ул Мәгъзүмә исемле иде), әнисе Фәрхури әби һәм без өчәү. Фәхертдин абый әле үзе дә унтугыз гына яшьтә, сельпода йөк ташучы булып эшли. Чирмешәннән Лашман кибетләренә товар ташый. Фәрхури әби сукырайган булган. Шул вакытта уналты яшьлек егетне үзеннән өч яшькә олы Мәгъзүмәгә өйләндергәннәр, янәсе, килен өй эшен алып барыр. Ләкин без килгән вакытта Фәрхури әбигә операция ясаганнар, аның бер күзе янадан күрә башлаган иде һәм йортта элеккечә әби хуҗа иде.

Без Фәхертдин абый белән бик тиз дуслашып киттек. Озын буйлы, таза гәүдәле, иртә өйләнгән бу егеттән әле балалык та чыгып бетмәгән иде. Шаярабыз, урамда шар сугабыз. Бергә утын кисеп, салам өеп, бакчада эшләп керәбез. Бәлки минем шулай булышуымны истә тотып, әби дә үз күрә. Әбиләрнен яратканы — күнелле чыжлап утырган самавыр янында чәй эчү бит инде! Аз-маз шикәрне әби саклап, хәтта яшереп кенә тора. Башкаларга, еш кына улы Фәхертдингә дә эләкми торган бәләкәй генә шикәр кисәген мина да төртә.

Кызык кеше иде Фәхертдин абый. Чирмешәннән Лашманга күчмә кино килеп төшә. Әллә нигә бер килгән киногa халык күп җыела. Малай-шалайның акчасы юк. Киномеханик урыс малайлары алдында Фәхертдин абый телсез, чукрак булып кылана. Ә чукракка закон юк. Башта ул «у-у» диеп клуб ишегеннән мине кертеп җибәрә — янәсе, мин аның энесе. Аннан тагын биш-алты күрше малае билетсыз керү бәхетенә ирешә. Мәшһүр дүрт серияле Америка фильмы «Тарзан», «Мичурин», «Кубань казаклары» һәм башка кинофильмнарны әнә шулай «чукрак энесе» сыйфатында карарга насыйп булды мина.

Тугызынчы сыйныфка укырга килгән елны Фәхертдин абыйны армиягә алып киттеләр. Без аларның күршесе сиксән яшьлек Могыйз бабайларда тора башладык.

Бик күп елларга алга китеп, әле язганнарга нисбәтле бер гыйбрәт турында сөйләми булмас ахры.

Лашман урта мәктәбен тәмамлаганнан сон 25 ел гына узган булгандыр, бер җылы җәйге кичне Әлмәттән Лашман буасына балыкка барып чыктык. Төнне яр буенда уздырдык, балык тоттык. Иртән дә бераз эләкте, ләкин көндез чиртми башлады. Шунда мин иптәшләрдән аерылып күнелне җилкетеп торган Лашман урамына кереп, укытучым Мәрьям апалар йортын эзләп таптым. Яшь кырыктан узып, йөз сырланып бетсә дә, Мәрьям апа мине тиз таныды. Еллар түгәрәк матур йөзле Мәрьям апаның үзен дә үзгәрткәннәр. Өйгә чакырып керттеләр. Әхмәт абый, уллары, киленнәре, оныклары һәм тагын бер кеше ашап-эчеп утыралар. Мине дә өстәл артына утырттылар.

— Монда укыганда син кемнәрдә торган иден әле, Әсгать? — дип сорады шулчак Мәрьям апа.

— Беренче елны Фәхертдин абыйларда торган идек, — дидем мин.

— Сон, менә бу абыена кара әле, — дип Мәрьям апа теге кешегә таба ымлады. Ә ул абый елмаеп утыра: бәй, мин әйтәм, Фәхертдин абый бит бу. Кочаклашып күрештек. Аннан иркенләп сөйләшеп чәй эчтек. Мөхәммәтшиннар белән Зөфәровлар кода-кодагыйлар булып киткәннәр икән бит — Мәрьям апаның улы Фәхертдин абыйның бер кызына өйләнгән булып чыкты.

Ләкин минем өчен яналыкның иң көтмәгәне шул булды. Без Лашман

мәктәбен тәмамлап киткәндә Фәхертдин абый әле армиядә иде. Бу вакытта аның хатыны кыз тапкан иде. Фәхертдин абый армиядән кайткач аларның тагын бер кызлары туа. Ләкин озак та үтми, Мәгъзүмә ике нарасые белән ирен ташлап, нindидер бер азгын иргә тагылып, Урта Азиягә чыгып кача. Дөрес, Фәхертдин абый югалып калмый. Үзенә тугрылыклы хатын, кызларына кайгыртучан, мәрхәмәтле, киң күңелле ана булырлык кеше таба.

Фәрхури әбинең исән-сау икәнлеген әнидән ишетеп барган идем мин ул вакытта. Кайтып китәр алдыннан аның янына да кереп чыктым. Әбигә инде туксанның өсте иде. Ул кабат сукрайган булып чыкты. Шулай да без йорт янына килеп туктаганда әби капшанып тавыкларга жим биреп йөри иде. Мин ерактан ук:

— Әби, исәнме, мин килдем, — дидем. Ул башта сагайды, аннан күтәрелде, кулын сузып яныма килде, беләгемнән тотып алды һәм мине шаккатырды:

— Әсгать, улым, син бит бу! Нишләп озак килми тордың? — диде. Туксаннан артык яшьтәге карчыкның хәтере, зиһене яхшы булуга исем китте минем шул вакытта. Мин әнинең сәламен тапшырдым. Күчтәнәчләремне әби дога кылып кабул итте, рәхмәтләрен укыды. Озакламый тагын киләм, дидем. Һәм бер елдан үземнең шәхси машинамда тагын Лашманга юнәлдем. Ләкин ул җәйне бик яңгырлы булып, юллар изрәп, авылга керә алмый кайтып киттем. Башкача Фәрхури әбине күрә алмый калуыма бүген дә үкенәм.

Туксан тугызынчы елның август ахырында Лашман халкы авылның 150 еллык юбилеен билгеләп үтте. Кояшлы, матур, җылы көн иде ул. Тантанага авыл халкы гына түгел, аннан төрле калаларга китеп яшәп ятучы авылдашлар да кунакка кайтканнар, бәйрәмгә чыкканнар иде. Минем ике туганнан туганым Өлфәт Хәертдин улы Салахов җитәкләгән Ямаш технологик транспорт идарәсе коллективы Лашман уртасында агып яткан Калай чишмәне бик матур итеп, милли архитектура үрнәгендә төзекләндереп, җиһазландырып куйды бу бәйрәмгә. Өлфәт туганым да, мин дә Чирмешән хакимияте башлыгы, Лашманда туып-үскән, шунын урта мәктәбен тәмамлаган мөхтәрәм Минсәгыйть Закир улы Шакировның олы кунаклары булып бардык Лашманга, чөнки бу бәйрәмгә минем дә үземчә бүләгем булды — Минсәгыйть белән минем уртак укытучыбыз Мөслиха апа Нәгыймованың Лашман, аның кешеләре, мәктәп укытучылары тормышы турында язган «Күмелгән кыллар» повестен әзерләп, Чаллыда бастырып кайткан идем. Минсәгыйть Закировичка да зур рәхмәт — китапны бастыру чыгымнарын ул үз өстенә алды.

Кунакчыл Лашман тантанага килгән халыкны кайнар чәе, коймагы-бавырсагы, җиләк-җимеш кайнатмалары, балы белән сыйлады. Мәдәният йортында зур концерт-кичә уздырылды.

Әле Калай чишмәне ачу вакытында ук мин инде олыгаеп барган сыйныфташларым Вәли Закировны һәм Рафика Вәлиеваны очрату, күрешеп сөйләшү бәхетенә ирештем.

Тантана соң тәмамланса да, хәләл җефетем белән без Фәхертдин абыйларга да кереп чыгарга булдык. Безнең шулай кинәт кенә килеп керү житмешен тутырган Фәхертдин абыйда зур дулкынлану уятты. Бигрәк тә аны минем «Аккан сулар» да (беренче басма) алар турында язуым әсәрләндергән икән. Кысышып кочаклаштык.

— Әсгать, энем, чыннан да синме соң бу? Бик матур малай идең бит, инде картаеп та барасың түгелме соң? — дип яшьләнеп тә алды.

Минем язганнар тач дөрес икән. Беренче хатыны Мәгъзүмә Урта Азиягә качып киткән кешесе белән авылда чакта ук яшерен генә очрашып торганнар. Ул качып киткәндә олы кызына биш яшь, кечесенә исә жиде

генә ай булган. Нинди жан белән шушы нарасыйларны ташлап киткән ул хатын — һич акылга сыярлык хәл түгел. Шул китүдән аның Лашманда башкача эзе дә булмаган.

Ул вакытта Фәхертдин абый армия хезмәтен тутырып кайткан һәм колхозда бригадир, аннары озак еллар шул төбәктә район заготовщигы булып эшләгән. Икенче хатыны Фәхертдин абыйга ике ул алып кайткан. Балалар барысы да олы тормыш юлында үз бәхетләрен тапканнар. Дүрт балада дүрт оныклары бар.

Фәрхури әби беркайчан да авырмыйча 98 яшькәчә яшәп, берничә атна эчендә сырхаулап, тыныч кына гүр иясе булган.

— Абыең үзенне гел сагынып искә ала. Ярый әле килдегез, — диде чәй артында Фәхертдин абыйның ачык йөзле хатыны Миннури апа.

Мин аларга үземнең китапларны автограф белән бүләк итеп калдырдым.

— Инде калган гомер озын түгелдер, энем, килгәләп йөр әле, мин сине туганымнан да якын күрәм бит, — дип озатып калды Фәхертдин абый.

Хәзер инде Чирмешән якларына юлым төшкәндә Лашманга, Фәхертдин абыйларга керми калмыйм — бер күрешү үзе бер гомер.

## Мин — бригадир

Илленче ел. Әле сигезенче классны тәмамламаган. Авылга 1Май бәйрәменә кайттык. Кая инде ул бәйрәм итү? Авылда эш кызу — язгы чәчү бара. Без дә бакча казыйбыз, тирес ташыйбыз. Көн кояшлы, коры һәм бик жилле. Авыл кешесенең, жил күтәрелдеме, коты очып тора: ут-күз генә чыкмасын...

Һәм ул барыбер чыкты. Нәкъ бәйрәм көнне Түбән Абдул дөрләп янды. Салам түбәле ярлы өйләр генә түгел, хәтта бер бала, кош-корт, вак-төяк йорт хайваннары да янды ул көнне. Илле йортны ялмап кына алды ут. Илленче ел — илле йорт... Һич онытасы юк. Шушма аркылы салган зур күпергә дә капкан иде ул. Ярый әле өен елга буенда, биек-биек таллар артына салып утырган Әгъләм бабайның оныгы Шәһит саклады ул күперне. Күпернең ут капкан бер жиренә олы чүмеч, чиләк белән суны китереп кенә тондыра икән үсмер малай. Елга суы салкын, жылынырга өлгермәгән. Бер «үгез»дән икенчесенә күчеп ут сүндерүче малайның судагы өлеше өшеп бетә, ә өстән ут кыздыра. Үз йортлары дөрләп янганда да күпердән китмичә Шәһит аны саклый. Бөтен авыл халкы исе китеп сөйләде аның батырлыгы турында.

Ут елга аркылы Тугайга чыкса, аның Елховойга да ташлану куркынычы бар иде, чөнки көчле жил безгә таба исте ул көнне. Без бар булган әйберне өйдән бакчага ташып куйдык. Ходай саклады үзе.

Болай да ачка интеккән, хәерчелектән йончыган авыл халкы өчен тагын да тинсез сынау булды ул янгын. Ничек түзгәндер дә, каян гына табып йорт житештергәннәрдер ул авыр елларда Түбән Абдул халкы.

Имтиханнарны тәмамлап кайтып кына кердем, өйгә колхоз бригадиры Камил абзый Минабетдинов килеп житте. Хәл-әхвәл сорашты да, мина көзен уку башланганчы үзенең ярдәмчесе булып эшләргә тәкъдим итте.

— Быел игеннәр яхшы булырга күренә, энем. Көн саен ике хезмәт көне эченне тишмәс, — диде ул һәм мин ризалаштым. Үземә бер сажин, карандаш белән амбар кенәгәсе тоттырды. Шулай итеп мин бригадир ярдәмчесе булып киттем.

Безнең алтынчы бригадада 66 йорт. Иртән иртүк торам да, күпер төбеннән башлап эшкә кушарга тотынам.

— Миңнур апа, утаугa!

— Фәрхури астай, уракка!..

Миңнур апа да, сеңлесе чибәр Мәдинур да: «Ярар, ярар, барабыз»,

— дип калсалар, Лыбыр Фәрхури абыстай, авыр туфрагы җинел булсын, үзе эшкә бармый калмаса да (ул вакытта бармый кара!), җавапсыз калмый торган усал хатын иде:

— Йөрисең шунда, карсак тәре...

Урак өсте житте. Башта Бустрәй чишмәсе өстендәге арыш басуына төштек. Сажин белән санап һәр уракчыга аерым-аерым ал ярып бирдем. Урак уру җинел булмаса да, кыстатучы юк, чөнки халык ач, тамак туйдырырга чыга. Иртән иртүк килеп бераз уралар да, тиз генә бөртек кагып яр астында, чишмә буенда коры-сары белән ут ягып, калайда арыш куыра башлыйлар. Бераздан барысы да шытыр-шытыр итеп куырган арыш ашый башлый. Миңа да өлеш чыгаралар апалар.

Арышны олы-олы апалар да, яшьрәкләр дә, житкән һәм әле житеп тә бетмәгән кызлар да ура. Мин сажин белән кырны үлчәп йөрим: күпме урылган, тагын күпме урасы бар...

Кинәт шыр-р итеп кычкырган тавыш ишетәм. Басудан бар көченә йөгереп Сажидә килеп чыкты: «Елан, елан...»

— Кайда ул?

— Аркамда.

Кырда бердәнбер ир-ат кисәге мин генә. Елан кебек әйбердән үзем дә шикләнсәм дә, күршемне коткарсам мин генә коткара алам. Сажидәне туктатып, аркасын карый башлыйбыз... Елан кайдадыр шунда булырга тиеш. Ә анда... озын кылчыклары белән өскә үк үрмәләп менгән беләк буйлык арыш башагы. Безнең янга җыелышкан уракчылар рәхәтләнеп көләләр...

Уракчылар арасында иң олысы Мөжибә абыстай булгандыр. Эшкә уңган, тырыш бу карчык өстәвенә бик талантлы да иде. Мөнәҗәт, бәет, экспромт белән җыр-шигырьләр чыгаруы белән авыл халкын таң калдыра торган иде.

Бер көнне Мөжибә абыстай ура торган җиреннән кинәт кенә тукталып, иң арттагы зуратлары ягына йөгереп үтте. Бераздан аның үз алдына әкрен генә атлап кайтканын күреп алдым.

— Нәрсә булды, Мөжибә абыстай, нигә бик каты йөгердең ул якка? — дим. Мөжибә абыстай минем янга килеп туктады да, шигырь белән җавап бирде:

Алдымдагы зуратымны
Сугалар дип курыктым;
Барып житсәм — карга икән,
«Хөш-шә!» — диеп куркыттым.

Кыюрак уракчы апаларның үз алдындагы көлтәләргә тимичә, башка кеше көлтәләрен «тәпәләүләре» — була торган хәл иде. Күзләре күреп бетермәгән карчык зурат өстенә килеп кунган карганы көлтә сугучылар дип белгән икән.

Бүсер Хатыйп бабай Имае Илтән Бота авылыннан өйләнеп кайтты. Мөжибә абыстай ул елларның мишәр дөньясы өчен гадәттән тыш вакыйгасына мөнәсәбәтен үзенчә белдерми түзә алмады, әлбәттә, шигырь чыгарды:

Еракларда күренеп тора
Безнең мәчет калае;
Керәшен кызы алып кайтты
Бүсер Хатыйп малае.

Мин уракта, ә Камил абзый лобогрейка белән уручылар янында. Сирәк кенә безнең кырга да килеп чыга ул. Эш биредә әйбәт бара, шуңа күрә Камил

абзыйның мина дәгъвасы юк. Тик сәламәтлеге начар аның — ашказаны интектерә. Беркөнне иртән аларга барып кергән идем, Хәзинә апа:

— Энем, абзыеннын хәле авырайды, әти иртүк Чирмешәнгә алып китте, — диде. — Атны үзен барып ал фермадан һәм Камил абзыен кайтканчы син жик — ул сина рөхсәт итте.

Хәтерем ялгышмаса, Камил абзыйга әллә инде операция ясадылар ул елны, әллә ятып кына чыктымы. Колхоз рәисе Сафин Кыям абзый, нәрәткә төшкәч:

— Үзен генә эшләп тор, — диде мина. Шулай итеп, унбиш яшемдә мин колхоз бригадиры вазифасын үти башладым.

Беренче ашлыкны суктыргач та колхоз он тарттырды һәм сугыштан сон, ялгышмасам, тәүге тапкыр урактагылар өчен ипи сала башлады.

Ул көнне иртәнге якта мин кырга килеп, башта уракчылар өчен ал ярып бирдем. Аннары авылга ипи алырга кайтып киттем. Ипине һәр уракчыга ярты кило итеп кисеп, үлчәп, алдан ук әзерләп, аны арбага төяп кабат кырга килеп життем. Әпәй алып килүем турында ишеткәч, уракчылар башта ышанмый тордылар: гомердә булмаган хәл бит! И-и, аларнын кинәнүе! Барысына да яна уныштан салган, әле буы, хуш исе бөркеп торган арыш әпәен өләшеп чыктым. Барысы да өсте-өстенә рәхмәт яудыра мина. Хәтта һәрвакыт ачулы Лыбыр Фәрхури абыстай да аркамнан сөеп китте. Иртән эшкә кушканда да башкача мина теләсә нәрсә әйтеп кычкырмый башлады.

Ә үземнең яртылаш ач авылдашларыма ипи алып килеп өләшүемнән нинди олы канәгатьләнү, горурлык хисе тоюымны белсәгез! Әйтерсен лә колхоз рәисе түгел, ә үзем рөхсәт биргәнмен халыкка әпәй бирергә... Хәзер инде олы-олы абыстай, апалар да мине малайга гына санамыйлар, ә чын бригадир итеп таныйлар.

Шулай урак беткәнче көн саен ипи ашадык барыбыз да.

Гади, олыны-олы, кечене-кече итә белә торган, эшкә дә, яхшы сүзгә дә сәләтле Камил абзый белән авылда бер унган хатын Хәзинә апанын бишме-алтымы балалары үсте. Ләкин Камил абзыйның гомере озын булмады. Биш дистәсен дә тутыра алмый китте ул бу дөньядан әнә шул ашказаны авыртып. Мин аны һәрвакыт сагынып искә алам...

Камил абзыйның сенлесе Разыя апаны да бик хөрмәт итә идем. Унган-булган, тырыш, ачык йөзле, тәмле сүзле, акыллы кыз иде ул. Минем Ризатдин абыем белән бер сыйныфта укый башлаганнар алар. Ул еш кына Ризатдин абыйны мактап искә ала иде.

Разыя апа бүген дә авылда исән-имин яшәп ята. Анын да балалары да, онык-оныкалары да күп.

## Рәшәле иртәләр

Безнең Елховой, Түбән Абдул һәм Кызыл көч авыллары, аерым-аерым колхоз булып яшәсәләр дә, бер авыл Советына карагангамы, авыл үсешенә хас булган кайбер мәсьәләләрне уртак хәл итеп куялар иде. Әйтик, беркайда да электр энергиясе булмаган вакытта өч авыл бергәләшеп Шушма елгасының Борылыш дип аталган иллә дә жайлы урынына электр станциясе төзи башладылар. Әлеге дә баягы ачлыкка интеккән, үзе дә ярлы колхозның коллык богауларыннан ычкына алмаган гади халык — кызлар һәм егетләр төзеделәр аны. Ә элмәк сыман булып килгән Борылышның станция урнашасы «муены»н казып-ерып чыгасы иде. Ябь-яшь авыл кызларының авырлыктан инкәеп, носилка белән сулары агып торган балчык ташыганнары әле дә күз алдымнан китми.

Аннары бинасын төзеп, каяндыр турбинасын да алып кайтып, 1950 елның көзенә электр станциясен төзеп тә бетерделәр. Каяндыр, Әлмәт ягыннан

бугай, электромонтерлар килеп, авыл кешеләре казыган чокырларга төз һәм биек баганалар утыртып, чыбыклар сузып, өйләргә электр керттеләр. Шушы вакытта безнең мишәр малайлары теленә әлегә кадәр төшләренә дә кермәгән сүзләр килеп керде: «монтер», «турбин», «анкер», «изалэтор», «патрун», «разиткы», «эштипсель», «ылампочкы»...

Яңа ел тирәсенә станцияне эшләтә башладылар. Ул көнне бәйрәм көткән кебек көттек без. «Ылампочкы» дигән нәрсәдә ут кабынырга тиеш икән бит — шуны көттек. Һәм ул кабынды. Андагы шатлыклар!.. Өйләрдә генә түгел, урамнарда, багана башларында да кабынды утлар, гөлт итте. Урамнар гына түгел, тормышыбыз яктырып киткән кебек булды шул көннәрдә.

Монтерлар арасында Рәис исемле яшь, чибәр, бик тә эшлекле һәм шаянлыгы белән дә аерылып торган егет истә калган. Үзенең икенче бер иптәше белән безнең авыл укытучылары һәм яшьләре әзерләгән концертта да бик актив катнашканнар иде. Рәис төрле мәзәкләр сөйләп халыкның эчен катырды. Шуларның кайберләре бүген дә истә. «Майламаган, дегетләмәгән кучәрле арба авыр гына тауга үрмәли, тәгәрмәчләр ыңгырашып баралар: «Ма-е ка-я соң а-ның, ма-е ка-я соң а-ның...» Арба тауны менеп, икенче якка төшә башлый. Аска таба тәгәрмәчләр: «Мае-ние првались, мае-ние првались», — диеп текертәләр генә икән...»

Электр утлары кабынганнан соң озак та үтмәде, безнең авыллар радиолаштырылдылар, урамнардагы, өйләрдәге репродукторлардан Казанны да, Мәскәуне дә тыңлый башладык.

Дөрес, Мәскәүнең телен белмәгәч, аны озак сөйләтмиләр иде бездә, әмма Казанны иртән дә, кичен дә рәхәтләнеп тыңлый идек. Бигрәк тә Гөлсем Сөләйманова һәм Рәшит Ваһаповның җырлавы тансык иде безнең моңга талымлы татар кешесенә.

Кышкы кичтә Лашманнан кайтып барабыз. Менә Кара Чишмә авылы да артта калды. Бераздан тау өстеннән авылыбызның электр утлары җемелдәгәне күренә башлады. Арыган аякларга хәл, үзебезгә дәрт кереп китте. Электр! Ут бит әле безнең авылларда гына...

Күрер күрмәгән авыл балалары шуннан да чиксез сөенеч таба алмаганнар, күрәмсең.

Унынчы сыйныфта укый башлаган көзне татар әдәбияты укытучысы, мәктәп директоры Ибраһим абый Ярмиев безгә ирекле темага инша язарга кушты. Мин ул иншамда нәнә шул электростанцияне төзү, караңгы мишәр авылына «Ильич лампалары» килү һәм радио кертелү кебек вакыйгаларны бик әсәрләнеп бәян иттем. Ибраһим абый директор буларак та, укытучы буларак та бик кырыс иде. Әдәбиятны яратып, белеп укыганнарыбызны да «дүртле»дән ары узындырмады. Утыз баладан торган унынчы «б» сыйныфында әлеге иншадан берданбер «бишле»не алуым бөтен мәктәпне шаккатырды. Бәләкәй генә Минәсгать берьюлы ике башка үсеп киткәндер. Әлбәттә! Ярмиевнең үзеннән «бишле» ал әле син... Минем инде мәктәптә район газетасына мәкаләләр язып торуым билгеле. Шигырьләр язуымны да белә мәктәп. Шигырь генәме соң? Яраткан шагыйрем Такташка ияреп Америка капиталистларын сүгеп бер поэма да язган идем әле. Анда да, нәкъ Такташтагыча, җилләр улый, бураннар дулый, һәм әлбәттә инде, «парламентлар өстендә» дулый ул буран, у-у...

Ибраһим абый — шәхес иде. Мең мәшәкатьле директор вазифаларыннан тыш бит әле ул укытучы да, Лашмандагы ике колхозда агитатор һәм пропагандист та. Еллар авыр. Мәктәп иске, укучылар саны күп, чөнки районда берданбер татар урта мәктәбе, бүлмәләр җитешми. Ике бүлмәгә бер олы мич, аларны ягып мәктәпне җылыту өчен олау-олау утын кирәк. Моның өстенә укытучылар да җитешми.

Бер көнне мине директорга чакырттылар. Йөрәгем жу-у итеп китте, нинди гөнаһым бар икән дип, калтыранып кереп бастым. Ләкин ни гаҗәп, Ибраһим абый үз янына утыртып, минем ничек мәкаләләр язуым белән кызыксынды, нәрсәләр турында язарга кирәклеген әйтте, үзем һәм гаиләбезнең тормышы турында сорашты. Аннары: «Яхшы укы, бәлки сиңа да авылдашың, минем яшьлек дустым Ләбиб Гыйльми кебек язучы булып китү насыйп булыр», — диде. Коточкыч фаҗигале 1937 елда кулга алынып юк ителгән авылдашым, ә әтинең балачак дусты язучы Ләбиб Гыйльми белән Чистайда егерменче еллар башында бергә укып йөрүләре, озын юлдан бергә җәяү кайтулары турында ул элек тә кыска гына әйтеп куйган иде. «Халык дошманы» турында минем яшьлек дустым дип, Ибраһим абыйның курыкмыйча әйтә алуына гаҗәпләндем мин ул вакытта. Кыю кеше булган икән!

Алга китеп, Ярмиев абый турында шуны да әйтеп үтәсем килә. Урта мәктәпне тәмамлагач, без Чирмешәнгә паспорт алырга җыелышып бардык. Шунда кабат Ибраһим абыйны очраттык, укырга китәргә җыенып йөрүебезне әйттек.

— Югары уку йортларына керүләре җиңел булмас, балалар. Елап булса да керергә тырышыгыз, — диде ул.

«Елап булса да...» Аның шушы сүзләре әле дә истән чыкмый. Әлбәттә, авыр, озак көттереп булса да, институтына да, университетына да кердек, белемен дә алдык, кеше дә булдык. Иң мөһиме, олы мөгаллимебезнең әманәтен намус белән үтәдек.

Унынчы сыйныфта безнең класс җитәкчесе итеп шушы елны гына Сарытау педагогия институтын тәмамлап килгән Мария Никитична Земцова билгеләнгән иде. Озын буйлы, саргылт чәчен артка җыеп тараган, зәңгәр күзле, ап-ак йөзле, өч-дүрт урыс сүзен бергә китереп бер җөмлә дә төзи алмаган татар балаларын күреп хәйран калган аптырашлы карашлы яшь маржа иде бу. Рәсәй империясенең күп сандагы укытучылары кебек: «кече милләтләр барысы да «бөек» урыс телен белергә тиеш, ә үзебез, урыслар, белмәсәк тә ярый», — кагыйдәсеннән чыгып яшәүче яшь укытучы. Ул безгә күпмедер дәрәҗәдә урыс телен һәм әдәбиятын житкерде дә бугай, тик программада каралганча ук түгел. Аның каравы Мария Земцова безнең күңелләргә башка яклары белән кереп калды. Сугыш вакытында Сарытауны дошман самолетлары бомбага тоткан вакытта подвалларда укып урта белем, аннан соң авырлык белән югары белем алып чыккан бу кызда оста педагогик алымнар һәм оештыру сәләте бар иде. Көтмәгәндә класс комсомол төркеме оештыручысы итеп мине сайладылар. Аннары Мария Никитична тәкъдиме белән драма түгәрәге оештырдык. Дәресләр бетүгә репетиция башлыйбыз. Шулай тиз арада Мирсәй Әмирнең «Көнлекче Әхмәт» комедиясен әзерләп, Лашман клубы сәхнәсендә куеп, халыкны таң калдырдык. Көнлекче Әхмәтнең өендә ялгыз калган гүзәл хатыны янына килгән азгын мөәзин ролен башкару миңа тапшырылган иде. Чираттагы килүче ишек шакыгач, яшь хатын мөәзинне тавык йоны салынган әржәгә «яшерә». Бу көлкеле күренешләрне тагын да көлкелерәк итү өчен мин йонга батып әледән-әле әрҗәдән башымны калкытам, йон туздырам. Халык эче катып көлә. Иң гаҗәбе, ике авыз да татарча белмәгән Земцова апабыз котылгысыз шаркылдый...

Спектакльдән соң үткәрелгән комсомол җыелышында иң оста «артист» итеп мине таныйлар. Мария Никитична моңа чиксез шат.

Бераздан соң без шул ук Лашман клубында Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар»ын куйдык. Миңа бу юлы Тимай карт ролен башкару насыйп булды. Классыбызның гүзәле Әмир авылы кызы Гина Даутова Маһисәрвәрне,

авылдашым Мәхмүт Гыйззәтуллин — староста Дәүли картны уйнадылар. Башкаларның уйнавы истә калмаган.

Бер кичне Мария Никитична миннән үзен озаттырды. Минем белән аерым сөйләшәсе килгән икән. «Талантың бар синең, әллә актерлыкка укырга китәсеңме? Мин ГИТИСка (Мәскәү дәүләт театр сәнгате институты) хат язып җибәрдем. Их, шунда барып керә алсаң, актерлыкка укып чыксаң иде...»

Көннәрдән бер көнне шул институттан килгән хатны Мария Никитична миңа тапшырды. Анда керү шартлары, программа — барысы да бар иде.

Лашманда безнең тагын бер пар яраткан укытучыбыз бар. Болар — татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мөслиха апа Нәгыймова һәм безгә физика дәресләрен укыткан Әнәс абый Батыршин. Җирән чәчле, олы гәүдәле, ачык йөзле, һәр яклап укымышлы Әнәс абый сугыш утын кичкән, контузия һәм яралар алган, ачы язмышка дучар ителүгә карамастан, көр күңелле, искиткеч зыялы, шуның өстенә артык гади кеше иде. Үзен бик яраткангамы, дәресен дә белә идек. Дәрестә бер хәл, ә тәнәфес вакытында бөтен малай-шалай, егет-җилән Әнәс абый тирәсендә бөтерелә идек: ул күпне белә, мавыктыргыч итеп сөйли, акыллы киңәшләр бирә.

Искиткеч матур, гел елмаюлы, тирән белемле, дәрестән тыш татар әдәбиятыннан безгә яңа хәбәрләр җиткереп торучы Мөслиха апа белән Әнәс абыйның өйләнешүе безнең өчен чын бәйрәм булды. Ике яраткан укытучыбызга бәхетнең иң олысын теләдек.

Мөслиха апа бездә татар әдәбиятына чын-чынлап олы мәхәббәт тәрбияләгән укытучы. Аның тәэсире астында берничәбезгә шигырь җене кагылды. Аның җитәкчелегендә Лашман мәктәбендә әдәбият түгәрәге эшли башлады, әдәби альманахлар чыгарылды. Аларда Әнәс Борһанов һәм минем шигырьләр дә урын алдылар. Ул альманахлар әле дә саклана дип ишеттем.

Без Лашман урта мәктәбен тәмамлап киткәннән соң, Мария Земцова анда тагын бер ел эшли дә, үз якларына кайтып китә.

Төрле җирдә яшәп, шунда эшләп, инде шактый озын гомер юлы үтсәм дә, рус укытучысы Мария Земцованы, Әнәс абый Батыршинны һәм башка укытучыларны мин һәрвакыт искә алам. Димәк, искә алырлык, шуңа лаек, хөрмәткә ия, укыту осталыклары, күркәмлекләре, кайбер башка яхшы яклары белән хәтердә калырлык кеше булганнар. Мине бигрәк тә Земцованың соңгы язмышы кызыксындыра иде: исән-саумы, кайда һәм ничек яши?

Әле 1989 елның көзендә үк мин — «Знамя труда» газетасы редакторы урынбасары — Сарытауга партиянең югары мәктәбенә квалификацияне күтәрү курсларына барган идем. Икеме-өчме атна укыдык без анда. Сарытау булгач, Мария Никитична да шунда яшидер дип, паспорт өстәленнән эзләтеп тә карадым. Таба алмадылар. Өлкә газетасы «Коммунист»ка укытучымны искә алып, аны эзләвемне әйтеп мәкалә яздым. Мәкалә басылды, тик аңа җавап бирүче булмады.

Тагын еллар үтте. Ниһаять, һич көтмәгәндә 1999 елның март башында «Әлмәт таңнары» редакциясенә минем исемгә Волгоград өлкәсенең Калач на Дону каласыннан бер хат килеп төште. Хатны ниндидер М.Н.Черняева язган. Ачып карасам, исем-акылым китте: Мария Никитична язган бит. Ул үзе мине эзләп тапкан. Кырык җиде ел үткәч, яраткан укытучыңнан, син гаҗиз булып эзләп тә таба алмый аптыраган кешеңнән хат ал әле син! Һәм бу гаҗәп хәлнең сәбәпчесе минем китап булып чыкты.

Әле Лашманда чакта ук безнең укытучыбызның мәхәббәте Әнәс абыйның энесе Сабур Батыршинга төшкән булган. Сабур абый комсомолның райком

секретаре иде. Алар яратышалар, ләкин өйләнешә алмыйлар, чөнки шул ук Әнәс абый бу катнаш никахка каршы төшә. Менә сәбәбе дә була. Земцованың боларга бер килүендә Әнәс абый, хатыны Мөслиха апа, Сабур абый, сенелләре Фәридә рәхәтләнеп үз ана телләрендә сөйләшеп утыралар икән. Шулчак Мария, үпкәләп, почмакка керә һәм елый башлый: «Они не считаются со мной, не разговаривают на русском, все на свем болтают»... Әнәс абыйның менә тәмам сабырлыгы төкәнә:

— Өйләнмисең! — ди ул энесенә. — Мин ана татар телен өйрән дип күптән әйтеп киләм. Ә ул уйламый да, «на своем болтают» дип, безне мыскыл итә. Мондый хәлдә ничек яшәрбез без аның белән?

Болары турында миңа әле күптән түгел генә Мөслиха апа сөйләде.

Чирмешәндә яшәп яткан Сабур абый белән Мария Никитична әле дә сирәк кенә хәбәрләшеп торалар икән. Сабур абый аңа минем китап, анда Земцованың үзе турында язылуын хәбәр иткән, минем кем булып һәм кайда эшләвемне, ягъни адресны язып җибәргән. Хатта мондый юллар бар: «Здравствуй, Асхат! Пишет тебе Мария Никитична — я еще жива. Мне написали о твоей книге. Для меня эта весть через почти полвека стала большой радостью. Я узнала, что вошла в историю Лашманки хоть маленькой строчкой, значит не зря все-таки прожита жизнь. Для меня вы все, мои бывшие ученики, так и остались детьми со своими характерами: и озорные, и спокойные, и любознательные, но, главное, очень добрыми, именно добрыми, чего не хватало нам всем в те послевоенные годы. Часто смотрю на фотографии и всех представляю, кто где сидел за партой...

Асхат, очень хотела бы я иметь твою книгу, нельзя ли ее прислать?»...

Әлбәттә инде, сигезенче дистә белән барган укытучыма озын итеп сагынычлы хатымны да яздым, китабымны да, Мария Никитичнаның үзе турында «Знамя труда» газетасында басылган күләмле истәлегемне дә җибәрдем.

Бу хатка каршы Мария Никитична, рәхмәтләр әйтеп, тагын җавап язды. Анда ул Татарстан, Чирмешән якларын, Лашман авылын сагынуы, студентка оныкасы белән килеп күреп китү теләге барлыгы турында да язган иде. Мин аны чакырып тагын хат яздым. Бөгелмәгә поезд белән килгән очракта үз машинам белән каршы барып алырмын, миндә кунак булып, ял итеп алгач, Чирмешән якларына барып кайтырбыз, дидем. Ләкин бу хатка каршы җавап килмәде. Ул үзенең мәктәп директоры, роно инспекторы булып эшләгән елларда сәламәтлеген нык какшатуы турында яза иде. Әллә инде гомере өзелдеме, дип уйлыйм хәзер. Ничек кенә булмасын, Мария Никитична Земцова-Черняева турында якты истәлек — күңел түрендә... Бик әйбәт педагог, искиткеч күркәм кеше иде...

***

Илле икенче елның язы яңгырлы килде. Бер дүшәмбе иртәсендә тугызынчыда укучы авылдашларым Рәүф, Зәки һәм Җәмил белән күтәренеп авылдан чыгып киткәндә салкын яңгыр сибәли генә башлаган иде. Түбән Абдулны үткәч тә ул көчәйде. Кара Чишмәгә без инде шактый юешләнеп, ә Туймәткә суга манма булып кердек. Юл пычрак, аяк киемнәренә саз ябыша. Тәмам хәлдән тайдык, өшеп, күшегеп беттек. Балачактан аягы гарип Рәүфкә бару тагын да авыр иде.

— Юк, малайлар, барып җитә алмыйбыз, туңып үләбез. Әйдәгез, безнең Айсылу апаларга керәбез, — дип, Рәүф Туймәттәге апаларына алып китте. Барып кердек. Ачык кына кеше икән Айсылу апа. Өйләре чиста, җылы, ә безнең теш тешкә тими. Дүртме-бишме кыз бала чыр-чу килә. Берсе житкән, берсе житеп килә — безнең чамада. Айсылу апа кызларыннан урын

җәйдерде, безне чишендереп урынга яткырды. Минем урын бер кырга туры килгән иде, өскә одеял җитмәде. Шулчак Айсылу апаның минем яшьтәге кызы карават өстенә җыеп куйган ятак әйберләр арасыннан калын юрган тартып алды һәм, минем янга чүгәләп, мине төреп яткырды. Юрганны иплəп, аска кыстыра-кыстыра япканда аның җылы куллары минем боз кебек суынган аякларга, кулларга кагылып-кагылып китте, кайнар сулышы битемне иркәләде. Мондый назны гомеремдә дә күргәнем юк иде әле минем. Кызның күзләренә тутырып карадым һәм: «Рәхмәт!» — дидем. Ә ул шундый матур итеп елмайды — мин аз гына хуштан язмадым.

Җылыда изрәп йоклап алган ике-өч сәгать вакыт эчендә яшь болан кебек гүзәл, авыл кызларына гына хас унган-булган бу кыз берничә тапкыр минем янга килеп өстемдәге юрганны төзәтеп китте.

Без торганда җылы мич каршына элеп куйган киемнәребез кипкән, казанда бәрәңге дә пешкән иде инде. Ашап, кайнар чәй эчеп, Айсылу апага, аның матур, ягымлы кызларына рәхмәтләр әйтеп Лашманга юнәлдек. Чыгып киткәндә мин Саимәгә (ул кызның исеме шулай иде) тагын рәхмәт әйтеп, аңа бәхет теләдем. Ә ул миңа тагын да мөлаемрәк итеп елмаеп, карап калды...

Лашманга барганда мин юл буе әнә шул кыз турында уйладым.

Егерме (әллә күбрәкме?) чакрымдагы Лашманга өч ел рәттән җәяү йөреп уку чорында шактый михнәт кичердек без.

Бер чатнама суыкта авылга кайтып бару истән һич чыкмый. Суык утыз градустан да артык иде. Шуның өстенә без кайта торган төньяктан, каршыга үзәкләргә үтәрдәй җил исә. Ул безнең бер катлы чалбар-ыштаннардан үтеп тезләрне, ботларны өтеп-өтеп ала. Кайсыларының куллары бик өши, битләре агарып туңа — бер-беребезне тикшерә генә кайтабыз. Шулчак мин һәрберебезнең арка капчыгында бит яулыгы барлыгын искә төшердем — аны атна саен юарга алып кайта идек авылга. Шулар белән, юлны карап кайтыр өчен бер бәләкәй генә тишек калдырып, битләрне урадык һәм хәлебезне шактый җиңеләйттек. Бәхеткә, минем башта әтидән истәлек булып калган бөдрә бәрән тиресеннән теккән малахай, ә кулда шулай ук җылы бөркеп торган тире бияләйләр иде, гәрчә өстә иске, кечерәеп беткән куфайка булса да.

Икенче бер вакыт көчле буранда кайттык. Юлны кар каплап китә дә, без юлдан язабыз, аны эзләргә керешәбез. Шулай азапланып кайтканда кинәт минем бот төбем чатнап китте һәм мин көчкә-көчкә генә атлый башладым. Сәгадәт Минабетдинов, Әлфрит һәм Мәхмүт Гыйззәтуллиннар чиратлашып минем култык астымнан алып, миңа булышып кайттылар. Фәкать авылга кайтып җиткәч кенә аякның авыртуы бераз басыла төште.

Бу өч елны да язгы каникулга су төшкәч, урыны-урыны белән билдән язгы ташу ярып кайттык. Су салкынлыгы ул вакытларда яшьлек кайнарлыгы белән әлләни сизелмәгәндер дә, ләкин бүген аякларның сызлавы аларны еш искә төшерә.

Бик кайгырып һәм борчылып чыгарылыш имтиханнарын бирдек. Шул көннәрдә мин, унҗиде яшьлек егет, чигәмдә хәтта берничә бөртек ак чәч тә таптым. Уку — энә белән кое казу! Безнең Лашман урта мәктәбендә укулар, андагы таләпчәнлек, балаларның тырышулары, тырышмаганнарының, сәләтсезләрнең сыйныфтан-сыйныфка күчә алмыйча төшеп калулары, хәтта унынчыны да тәмамлый алмый имтиханнан елап кайтып китүләре — хак. Димәк, борчылырга нигез булган. Иң мөһиме — үзебез дә тирән җаваплылык тоеп укыганбыз бит. Һәм шушы еллардагы җаваплылык хисе безне гомер буена озатып килә.

Чыгарылыш кичәсе... Шатлык, бәйрәм югыйсә, ә ул фәкать моңсулыгы белән генә калган минем хәтердә. Урта мәктәп тәмамладым, кичәгә бераз

матуррак киенеп киләсе килә, ә өстә инде искереп, юа-юа унып беткән чаңгычылар костюмы гына. Шушы яшькә житеп ак күлмәк белән кара чалбар кию бәхетенә дә ирешкән юк бит әле. Аякта да кыш көне кирза итек, ә җәен Кәмәй башмаклары. Бәркәтәнең Хәмәтдин абзый иске камерадан ябыштырып башмаклар ясап сата иде. Кәмәй абзый үзе минем әтинең әнисе Бибигайшә әбинең бертуган энесе булган икән.

Шулай да иртәгә чыгарылыш кичәсе була дигән көнне әни, каяндыр акча табыштырып, мина тетер кебек ситсыдан ак күлмәк һәм шундый ук арзан тукымадан тегелгән кара чалбар алып кайтып бирде. Тик болар гына минем боек күңелне күтәрә алмаганнар ахры. Кичәнең ничек үткәне дә, анда нәрсә булганы да истә калмаган. Күңел түрендә туган хисләр сәбәпчесе сыйныфташ кыз белән дә ботка пешмәде, хәтта кичә сонында аның кая китеп югалганын да хәтерләмим. Күзләре бик елтыр, егетләрнең барысына да елмая торган кыз булгангадыр, минем тәүге хисләр сүрелеп киткән һәм ана багышлап шигырь язуыма да үкенә башлаган идем инде.

***

Театр турындагы хыяллар үтә ярлылык кыясына бәрелеп челпәрәмә килде. «Әнә, улым, соңгы кәҗәне сатсак кына инде, башка мөмкинлек юк», — диде әни. Укырга китәм дип, ничек инде соңгы кәҗәне саттырасың?

Сентябрь башында сельпо рәисе Фатих абзый Гарипов мине хисапчы итеп эшкә алды.

Бу — кеше булып житешүнең бик катлаулы һәм сикәлтәле юл башы гына иде әле. Алда безне ниләр көткәнен белсә бер Ходай гына белгәндер...

## Ашкынасың, яшьлек...

Хәтер капчыгымда 1952 ел ямьле мизгелләре белән калган. Хыяллар бөреләнгән, тойгылар сизгерләнгән, хисләр ташкан ел. Унжиде яшь... Урта белем алып чыккан ел... Олыдан торып хезмәт юлымны башлаган ел... Район һәм республика газеталарында, әлеге елны берничә ай гына яшәп калган Чистай өлкәсе басмасы «Сталин байрагы»нда шигырьләр, мәкаләләр бастырган ел...

«Кызыл Татарстан» газетасы редакциясеннән ул елны мина анкета да жибәргәннәр иде. Журналистларга, хәбәрчеләргә ул елларда бик кытлык булгангадыр, мине үзләренә эшкә алырга иде бугай исәпләре. Әле яңа гына урта белем алган, унсигез яшен дә тутырмаган егеткә кая инде ул республика газетасы редакциясендә эшләргә!? Югыйсә, өлгергәнлек аттестаты алып кайткач та кая булса да эшкә урнашырга атлыгып торган чак. Югары уку йортына китеп булмады — гаиләбез чыгырдан чыккан ярлы, иске куфайка кесәсендә җилләр уйный. Кая гына эшкә барып урнашырга да, тормышны аз-маз көйли, жайлый башларга соң? Колхозда эшләүгә өмет юк, анда элеккеге хәл — биленне бөгеп җәен-кышын җир сөрсән дә күп дигәндә егерме-утыз килограмм бөртек тияр сиңа.

Кемдер район культура бүлегенә барып карарга тәкъдим итте: бәлки район авылларының берсенә клуб мөдире итеп жибәрерләр? Жырга, биюгә, спектакльләрдә катнашырга, шуңа охшашлы эшләрне оештырырга сәләт юк түгел. Бардым. Бүлек мөдире — озын буйлы, какча гәүдәле, кара чәчле сүзчән генә яшь ир-егет мине тыныч кына тыңлады, тик эш тәкъдим итмәде. «Бәлки бераз соңрак булыр, тагын килеп чык», — дип калды ул арттан. Редакциягә кереп элек басылган шигырьләр, мәкаләләр өчен бераз гонорар алдым һәм Чирмешән ашханәсенә кереп тары боткасы алып ашадым да, ничек килгән шулай җәяүләп авылга кайтып киттем.

Икенче көнне үзем жиденче сыйныфны тәмамлап киткән мәктәпкә барып чыктым. Урта белемле егет лә мин! Ә мәктәпнен башлангыч сыйныфларында бүген дә жиде, сигез, тугыз сыйныф тәмамлап эшләүче укытучылар бар. Моннан тыш мәктәпнең киләчәге дә өметле. Былтыр без Лашманга унынчы сыйныфка укырга киткәндә Елховой жидееллык мәктәбендә сигезенче сыйныф ачылды, ә быел әлеге сыйныфны тәмамлаган малайлар һәм кызлар тугызынчы, киләсе елга исә унынчыда укыячаклар. Шулай итеп, Елховой мәктәбе дә урта мәктәп булачак...

Директор Рәвгать абый Таһировны мин эш урынында түгел, ә тора торган йортына барып таптым. Ләкин ул да мине кинәндермәде. «Мәктәп укытучылар белән тәэмин ителгән», — диде дә ул коры гына, мин башымны аска иеп кайтып киттем.

Тагын кайдан эш эзләргә була үземнең авылда? Әһә, сельпога төшим әле, бәлки берәр нәрсә елмаер. Сельпо рәисе — үзем белән Лашманда бергә укып йөргән, бер фатирда яшәгән дустым Жәмил Гариповның сугыштан бер аягын имгәтеп кайткан абыйсы — Фатих абзый. Бик гади, сөйләшергә ачык кеше — тартынып торасы юк.

— Ярар, алайса хисапчы итеп алырбыз. Тулькы бераз көт инде, райподан рөхсәт алып кайтканчы. Әлегә колхоздамы шунда, эшли тор, — диде ул һәм мин кош тоткан кебек өйгә кайтып кердем.

Иртә белән мине эзләп сугыштан ике аягын өздереп кайткан Минач абзый Гыйматдинов килеп житкән. Сугышта сапер булган икән, минага эләккән. Кайтканның беренче атналарында ул госпитальдән биреп жибәргән протезлар белән йөреп маташты урамга чыгып. Ләкин йөреп китә алмады, ташлады тимер аякларны. Тездән югары өзелгән бот башларына ипи калае кебек түгәрәк «башмаклар» ясап, кыска култык таяклар белән йөри торган булды ул соңыннан йорты, күрше-күлән тирәсендә, ә ераграк барганда инвалидлар коляскасына утыра иде.

Минажетдин абзый белән безнең уртак сүзебез дин турында иде. Сөйләшәбез, бәхәсләшәбез. Ул Ислам, Коръән яклы, мин исә ул елларның яшь комсомолы — каршы. Бәхәсләшсәк тә, бер-беребезне күрше буларак та, фикер алышырдай гәптәш буларак та хөрмәт итә идек.

— Мунча череде бит, Әсгать, яңаны бурап булмасмы дигән идем. Кәлимулла риза да, тагын бер булышчы булмасмы икән, ди ул.

Безнең үзебезнең мунча юк. Минач абзый мунчасын без дә еш кына ягып керәбез. Ул елларда шулай иде бит. «Юк, якмагыз, кермәгез», — дию юк. Киресенчә, берәрсе ягып кергәннән соң кызуы калса, сиңа, мунчасызга, килеп әйтеп тә китәләр әле: «Барып керегез!..»

— Мин булышырмын анысы, Минажетдин абзый, тик бурау ягы...

— Бүрәнә башыннан тотып торсаң ярый инде...

Без керә торган иске мунчаны инде сүтеп ташлаганнар. Авылыбызда бер унган балта остасы Кыргаяк Кәлимулла абзый мунчага имәннән нигез бүрәнәсе юнып ята. Мин дә тотындым эшкә: балта белән агачларны кайрыдан аралыйм, ботакларын юнам. Аннан Кәлимулла абзый өйрәтүе астында әкренләп бурарга да керештем. Әллә ике, әллә өч көн эшләдек, тәки икәү мунчаны бурап, эшен бетереп куйдык бит.

Менә ничек: минем кулдан балта эше дә килә икән бит әле. Дәрт керде. Бәләкәй чактан ук минем йоклау урыным идәндә булды. Тукта әле, нишләп мина, балта эшенә аз-маз булса да өйрәнгән егеткә, үземә агачтан карават ясамаска? Төрле жирдән эзләп агач һәм берничә такта таптым. Терәлеп торган оста күршем Кәлимулла абзыйдан коралларын сорап алып чыктым һәм бер көндә үземә — житкән егеткә йокларга карават ясап куйдым. Минем

янда хәтта яраткан кече энем Әгъдәскә дә урын булды — икәү йоклый торган булдык яна караватта.

Тик менә сельпо гына һаман суза эш белән. Хикмәт нәрсәдә, нигә сузалар?

Анда бәрелеп, монда сугылып көннәр бер-бер артлы үтә торды. Урак өсте житте. Иң җаваплы чор колхоз өчен. Ындыр табагында инде сугарга да хәзерләнәләр. Бригадир килгән:

— Сельпона урнашканчы сугу машинасы янында эшләп тор әле. Теләсәң көлтә бирерсең, теләсәң салам тарттырырсың, — ди бу.

Чыннан да, тик ятканчы эшли тору әйбәт анысы. Ындыр табагында яшьләр дә җитәрлек.

Иртән ындырга килдем. Сугуның беренче көне. Менә гөрләп трактор эшли башлады, аннан сугу машинасы да хәрәкәткә килде. Мин сугу машинасы астыннан суккан саламны ат белән кибәнгә тарттыра башладым. Тик бу эш белән мина озак маташырга туры килмәде. МК-1100 сугу машинасы машинисты Фәхрислам абзый Гыйльманов:

— Ташла әле ул эшенне, бир атынны берәр манка малайга. Барабанга көлтә бирүче кирәк монда. Давай, син мен әле, — дип, мине өскә, барабан өстәле янына алып менеп китте. Анда ул мина ничек бавы киселгән көлтәне таратып, барабанга бирергә кирәклеген күрсәтте. Мина бер күрсәтү дә җитә. Тузаннан саклау өчен һәр ягы ябык күзлек кидерделәр мина һәм юешләнгән яулык кисәге белән авызны-борынны бәйләп куйдылар. Янымда көлтә кисүче кыз сынган урак белән кышт-кышт көлтә бавын кисеп, көлтәне минем якка этеп җибәрә. Мин көлтәләрне берәм-берәм тигез таратып, тимер тешләре белән зыр-зыр әйләнеп торган барабанга озата торам. МК-1100 машинасы — көчле, көлтәләрне аждаһа сыман йотып кына тора. Вакыт-вакыт артык мавыгып, юанрак бәйләгән көлтәләрне ике кисәккә генә аерып, барабанга тыгып җибәрәм дә, машина «у-ух!» дип үкереп куя. Бу вакытта Фәхрислам абзыйның мина: «Малай!» — дип кычкырганын һәм йодрык күрсәткәнен күреп алам. Моннан соң мин көлтәләрне даими агымда биреп барырга тырышам.

Барабан янында коточкыч тузан, эш тә киеренке. Шуңа күрә барабанга көлтә бирүчеләр алышынып эшлиләр. Минем алмаш — башлангыч мәктәптә бер сыйныфта укыган Гөлсем иде. Яшькә миннән бераз олырак бу кыз гәүдәгә зифа, нык, эшкә унган, йөзгә дә сөйкемле. Өсте чиста, кырт итеп тора. Кеше белән һәрвакыт яхшы мөгамәләдә, киң күнелле, тыныч, шаярырга да һәвәс. Ул ял иткән минутларында авызга-борынга бәйли торган яулыкны юып килә һәм минем көлтә биреп торган җиргә менеп, авыз-борынымны шушы юеш яулык белән бәйләп куя. Әспәтләп[1], ышанычлы, тузан кермәслек ясап бәйли ул. Гөлсемнең әледән-әле шулай эшләвендә аның мина карата игътибарлылыгын, минем турыда кайгыртуын гына түгел, нindидер тагын да якынрак мөнәсәбәтен тоя идем мин. Тик ул мөнәсәбәт, ул хис безнең бер-беребезне хөрмәт итүдән ары узмады.

Гөлсемнең язмышы ничек булгандыр — мин аны, кызганычка каршы, белмим. Тик мин аның турында гомер буе бу унган, булдыклы, тирән акыллы, төпле кыз тормышка чыккач ирен дә, үзен дә, балаларын да бәхетле иткәндер дигән уйда яшим, ул бу олы һәм мактаулы эшкә сәләтле, әзерлекле иде. Һәм мин бу алдан күрүчәнлектә ялгышмаганмындыр кебек.

Көлтәне икебезгә дә бер үк кыз — минем әти кебек сугыш утында югалып калган, яшьлекләрендә аның белән бергә авыл сәхнәсендә спектакльләр куеп йөргән Әхтәм абзый кызы Рауза кисеп бирә иде. Шулай ук эшчән, унган-булган, чибәрлеге-көязлеге дә җитәрлек. Авылда аны ошатмаган егет

[1] Әспәтләп — җайлап, төзәтеп.

аз булгандыр, гәрчә Раузаның сайлап алганы бер генә булса да. Үз җаебыз белән, ритмны бозмыйча, Рауза белән гел сөйләшеп эшлибез. Яшь чак, гайрәтле чак, күңелләр кемгәдер тартылган, хыялланган, дәртләнгән чак. Кем ошый һәм нигә ошый?

Нигә, нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыннан тамалар?

Рауза эшлекле хәрәкәтләр белән тиз-тиз үткен уракчыгы белән көлтә бауларын кисеп-кисеп җибәрә дә, аларны миңа таба шудыра. Аның кайнар һәм йомшак беләге әледән-әле минем беләккә тиеп-тиеп китә. Үзебез һаман сөйләшәбез. Раузаның миңа үртәүле сораулары ява:

— Син — укыган кеше, безнең ишеләр белән генә бәйләнергә дә теләмисең инде...

— Лашманда яраткан кызың булган икән...

— Елховой кызлары гына ярамас дисең инде...

Кая инде ул яраткан кызлар? Өстеңә киеп йөрергә рәтле киемең дә булмаганда кайсы кызга эндәшә аласың, ди. Һи-и, булмаганны! Тик сер бирмим, хәйләкәр генә елмаям да, эндәшми калам Раузага. Ул өзгәләнә бугай минем эндәшмәвемнән...

Барабан өстәле янына Гөлсем менә һәм кайнар бармаклары белән миннән күзлекне алып үзенә кия. Аның да авызы-борыны чиста яулык белән бәйләнгән. Тар өстәл яныннан бер-беребезгә бик якын килеп, хәтта терәлеп урынны алышабыз.

— Чибәр кызлар бирдем мин сиңа, берсен каптырмый калма инде, — ди Фәхрислам абзый, елмаеп, трактор гөрелтәве, сугу машинасы гүләве астында. Ул, астына салам җәеп, тәгәрмәчле ХТЗ тракторы янына утырган. Ярдәмчесе — миннән бераз олы бертуган энесе Ибраһим тракторга ягулык салып йөри.

Төшке ашны колхоз әнә шул ике механизаторга да, ындыр табагы башлыгына гына китерә. Фәхрислам абзый мине дә исемлеккә кертте. Тозлаган сыер ите белән куе итеп пешерелгән аш, туклыклы авыл ипие — тагын ни кирәк әле һаман ашау ягы яхшырмаган авыл кешесенә?

Кичке караңгыга кадәр сугабыз ашлыкны. Ниһаять, Фәхрислам абзый тракторны туктата. Ашыгып өйгә кайтырга чыгабыз. Ындыр табагыннан өйгә кайтырга чакрым ярым бар. Шулчак лапас артыннан бөртек төяп колхозның «полуторка»сы килеп чыкты. Мин йөгереп барып машина әрҗәсенә менеп киттем. Аннан арттан йөгереп килгән берничә кызны тартып-тартып менгердем. Кинәт каяндыр Рауза да килеп чыкты һәм машина артыннан чаба башлады. Мин аңа кул сузам, ә ул куып җитәлми генә бит. «Тизрәк, тизрәк!» — дип көч бирәм көлтә кисүчемә. Ниһаять, көч-хәл белән мин аның кулыннан тотып алдым. Тик ул аягын машинаның арткы ягындагы басмасына куя алмый. Миңа аны тартып алу җиңел булмаса да, бар көчемне салдым һәм ул берзаман минем өскә килеп ауды да, хәле беткәнгәме, беравык кузгалмыйча, кайнар тәне белән миңа сыенып барды...

Икенче көнне ындыр табагына идарәдән район газетасын алып килделәр. «Сугу алдынгылары» дигән кыска гына мәкаләдә фронттан кулын имгәтеп кайтса да машинист булып эшләгән Фәхрислам абзый турында да, көлтә бирүчеләр Гөлсем, Рауза һәм минем турыда да язылган иде. Үзең турында газетада мактау сүзе ишетү күңелле була икән...

Сугуда эшләгән бер ай вакыт эчендә мин, инде ничәнче мәртәбә, авыл

хезмәткәрләре өлешенә авыр, җаваплы һәм шул ук вакытта кадерсез хезмәт төшкәненә инандым. Әллә өченче, әллә дүртенче сыйныфта укыган чакта тәүге тапкыр тары утарга чыкканнан бирле җәйге көннәрдә колхозда эшләргә туры килде. Балачакта утау-мутау, бәрәңге өю, алганда аны чүпләү, яшелчә алу кебек эшләрдә катнашсак, буыннар ныгый башлагач чалгы белән печән, боз суккан арыш яки солы кырын чаптык, кибән куйдык, сыер, үгез яки ат җигеп печән, көлтә ташыдык. Тик кайда гына эшләсәң дә, синең кадереңне белмәделәр колхозда. Тамагың ач, өстең ялангач булды. Ә эшкә исә мәҗбүри кудылар. Куркытып эшләтә торган заманнар иде шул...

Ындыр табагыннан караңгы төшкәч кенә кайтып китәсең, ә таң беленү белән үк, иртәнге сәгать дүрттә-биштә сина кабат торып китәргә кирәк. Ә торасы килми. Авыр эштән тән ватылган, арка, җилкәләр, бот башлары сызлый. Ләкин торып, булыр-булмас ризыгыңны капкалап, тагын эшкә чыгып китәсең...

Берничә көннән мине, ниһаять, сельпога чакыртып алдылар.

***

Елховой сельпосы урта урам белән Чәпешләр урамы почмагында, биек нигезгә салган алты почмаклы агач бинада иде. Олы, якты якта сельпо идарәсе. Шунда ук рәис Фатих абзый Гарипов өстәле, баш бухгалтер Салихҗан абзый Гыйззәтуллин, өлкән хисапчы Васыйл абзый Бәкеров һәм минем өстәлләр. Рәис урынбасары — Түбән Абдул авылы ягыннан бер күзе пыяла Мохит абзый Хәсәншин, ләкин аның утырып эшли торган урыны юк, чөнки эше дә даими тауар эзләп читкә, командировкаларга йөрүдән гыйбарәт. Отчет кәгазьләрен исә ул өендә ясап килә. Мохит абзый бик булдыклы, эшен яхшы, белеп башкара. Сельпо тауардан өзелми, ул аны әллә кайлардан кайтарып кына тора. Кибетләр сату планын даими үтәп килеләр. Моның өчен барлык сатучылар һәм сельпо хезмәткәрләре «прогрессивка» дигән өстәмә түләү алалар.

Бинаның икенче, бәләкәйрәк бүлмәсендә сельпо атларын караучы, йөк ташучы Әхмәт абзый белән хатыны яшиләр. Өйләнешүләренә шактый бар, ә балалары һаман юк.

Эшкә мин бик тиз өйрәндем. Иң мөһиме — арифметиканы яхшы белү, дөрес санау кирәк монда. Минем баш остазым — Түбән Абдул ягы кешесе, үз вакытында авыл активисты булып танылган, халык арасында абруй казанган Васыйл абзый Бәкеров. Тыныч холыклы, эшчән — ул көннәр буе счет төймәләрен шыкыл-шыкыл китереп санап утыра. Кәгазьләрне дә бик оста һәм пөхтә итеп тутыра. Язуы да матур. Эш кәгазьләрен тутырырга мин нигездә аңардан өйрәндем. Баш бухгалтер булып эшләүче Салихҗан абзыйдан шактый олы яшьтә булуга карамастан, Васыйл абзый икеләнгән вакытында аның белән киңәшә. Гомумән, коллективта бер-берсен хөрмәт итеп, олыны-олы, кечене-кече санап, игътибар белән эшләгәннәрен хәтерлим мин бу кешеләрнең.

Фатих абзый үзе бер һәрьяклап үрнәк кеше иде. Һичбер вакытта да тавышын күтәрмәс, сорашып, киңәшеп кенә эшләр, җайлы сөйләшер, синең эшеңне күрә белер, мактап куяр иде. Эш арасында көлкеле хәлләрне искә алып сөйләп җибәрә, күңелне күтәрә.

Салихҗан абзый Гыйззәтуллин исә, минемчә, бик талантлы хисапчы булгандыр. Үзе эшли, үзе сүзгә дә кушыла, кызык җирләрдә күңелле итеп, самими генә көлеп тә куя. Аны барысы да хөрмәт итәләр, чөнки сельпода күп нәрсә баш бухгалтердан тора, рәистән түгел. Хисап эшендә аның белмәгәне юк. Сельпо челтәренә унга якын кибет керә, моннан тыш вак тауар сатучылар да бар. Сатучыларның күбесе — авыл ирләре,

махсус белемнәре юк, кайберләре отчет та ясап китерә алмыйлар, сельпо хезмәткәрләренә — Салихҗан, Васыйл абзыйларга мөрәҗәгать итәләр. Мин килгәнче исәп-хисап кәгазьләрен алар төзеп биргән булсалар, соңыннан остазларым бу эшкә мине өйрәттеләр.

Күңелемдә бик уңай, яхшы кешеләр булып хәтердә калган Салихҗан һәм Васыйл абзыйларның бер йомшак яклары бар — эшләп арыганнан соң, «тамак чылатып» алырга яраталар иде. Юк, артыгы белән һич мавыкмадылар алар, шулай да...

Бераз күңел ачып алыйк дисәң, сельпо тирәсендә һәрвакыт мөмкинлек бар. Әйтик, шул ук отчет төзеп бирү.

— Салихҗан, энем, ясап бирегез инде, — дип ялына Бәркәтә кибетчесе Хәертдин абзый Шәрәпов.

— Вакыт юк бит әле, Хәертдин абзый. Әсгать, әллә син ясап бирәсеңме? Ясап бир, яме? — дип йомшак кына эндәшә Салихҗан абзый. — Тулькы, Хәертдин абзый, шарты белән...

— И-и, энеләрем, ясап кына бирегез, бөтен шартын китерермен...

«Шарты» аның шул инде: отчет төзелеп беткәч кибетче ике зур шешә «Портвейн» һәм капкаларга прәннек, конфетлар алып керә Әкрәм абзый Гыйльманов кибетеннән.

Түбән Абдул кибетчесе, яшь, чибәр Миңгата абзый Миңгалимов, Кызыл Көч авылы кибетчесе Нурхәммәт абзый Сафин, үзебезнең авылдан Әкрәм абзый Гыйльманов һәм башкалар да отчетны миннән ясаталар иде. Авылның иң олы кибете мөдире Шири абзый Галиәскәров кына һәрьяклап әзерлекле сәүдә остасы булгандыр. Гәүдәгә зур булмаса да, киң күкрәкле, таза бәдәнле Шири абзый аякларына нык басып йөри торган, сизгер, кыю, үз-үзенә нык ышанган кеше иде. Тормышын да ышанычлы, түгәрәк, матур алып бара иде ул. Нидәндер, без аның белән бик тиз дуслашып киттек. Яшь булуга карамастан, урта белем алып кайткан, катлаулы исәп-хисап эшенә тиз өйрәнгән, түгәрәк башлы, сүзен җиткереп сөйли белгән егеттә эшчәнлек, булдыклылык сыйфатларын таныпмы, ул мине үз итте.

Сельпога урнашу белән мин үземнең алга күптөрле максат куйдым. Шуларның берсе — сәләмә киемнәремне алмаштыру. Беренче хезмәт хакымнан мин кибеттән сары сатин сатып алдым да, сельподан кыйгачрак кына яшәүче тегүче, Җангир бабай кызы Сәҗидә апага күлмәк кисәргә кертеп бирдем. Ул вакытларда бит әле безнең кибетләрдә әзер күлмәкләр сату юк иде. Икеме-өчме көннән Сәҗидә апа миңа бик матур күлмәк тегеп бирде. Икенче хезмәт хакымнан мин өр-яңа, җылы һәм якалы итеп теккән зәңгәр төстәге куфайка алып кидем. Аннары кирза итекләремне яңарттым. Ә бер көнне мине Шири абзый үз кибетенә чакырып кертте.

— Менә, бик матур костюм бар, киеп кара әле, — дип, бу миңа төргәк сузды. Гади пинҗәк кенә түгел, йон тукымадан ясалган зәңгәрсу-кара төстә, миңа килешеп торган, өскә дә бик таман һәм матур костюм икән.

— Кыйммәтме соң? — дип сорыйм Шири абзыйдан.

— Ике йөз сиксән сум, — ди бу. Минем оклад та нәкъ 280 сум. Дөрес, «прогрессивка» белән мин 400-430 сумга чаклы алам. Ләкин ул акчаларның да урыны бик күп. Үземә дә, әнигә дә, туганнарыма да төрлесеннән киемнәр алырга кирәк. Мохит абзый үзебезгә генә дип каяндыр әлегә кадәр күренмәгән тары, бодай, дөге ярмалары да алып кайткалый. Алар әлләни кыйммәт түгел. Аларны да алмый булмый ишле гаиләгә.

— Акча юк бит әле, Шири абзый, — дим мин кесә ягын чамалап.

— Борчылма, алгач түләрсең. Мин монда булганда алып кал, сиңа бик килешә...

Костюмлы да булдым. Әнә шулай Шири абзый мине игътибарында тота иде.

Кибетләргә ревизия дә ясаштырырга кирәк. Мине ревизия комиссиясе рәисе итеп куя башладылар. Комиссия әгъзаларын үзем сайлыйм. Лашман мәктәбен тәмамлап кайткан дустым Әлфрит Гыйззәтуллин өендә эшсез ята. Авылда бер оста гармунчы яшьтәшләремнән берсе Наил Мостафин да эшсез. Ул да безнең белән Лашманга укырга барган иде, тик җиндерә генә алмады. Ревизия ясарга аларны чакырам. Кибетне эчтән бикләп куеп, ревизия ясарга керешәбез. Эш күп булса да, катлаулы түгел: бу яки теге тауар алып кайтканда күпме булган, күпмесе сатылган, күпмесе әле бар? Шуларны берәмтекләп санап чыгабыз, баланс ясыйбыз. Акча артык чыкса, акт төзибез. Ләкин үзем хөрмәт иткән Шири абзыйга ничек инде акт төзисең? Үзе юмарт та. Без ревизия ясап яткан арада ул балыкчы Нургали бабайдан зур бер табалык балык китертә, аны чистартып, йомырка да сытып, куырып куя. Ризык та, шәраб та мул була төшке аш вакытында. Егетләр канәгать, көн саен шулай ревизия ясарга риза алар, тик ревизия генә сирәк була...

Эшкә мин иртәнге җидедә төшеп утырам. Шул чамада Васыйл абзый да, башкалар да җыела. Эш күп булудан гына түгел, ә сельпода радио булудан да безнең иртә килүебез. Казаннан соңгы хәбәрләр, газеталарга күзәтүләр һәм иртәнге концерт... Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Салахова, Мәрьям Рахманкуловаларның җырлаулары тансык иде ул еллардагы җырга-моңга талымлы авыл кешеләренә.

Суда, суда, суда йөзәләсеңме?
Мин сине күрми түзәлмим,
Ә син түзәләсеңме?..

Нәкъ әнә шул 1952 елның ахырында иҗат ителеп, Гөлсем Сөләйманова җырлый башлаган «Суда, суда» исемле татар халык уен җыры бу. Аны безнең авыл яшьләре дә бик тиз отып, аулак өйләрдә түгәрәкләнеп уйнаганда да җырлый башладылар. Безнең яшьлек елларында мишәрякларында клубка җыелышып күңел ачу, түгәрәкләнеп уйнауларны мин хәтерләмим. Клубта җыелыш, сирәк-мирәк килгән күчмә кино, концерт, спектакльләр генә була иде. Концерт һәм спектакльләр куюда мин үзем дә еш катнаша, җырлый, бии, рольләр башкара идем. Тик сельпога эшкә килгәнче һәм килгәч тә берничә ай өскә киеп йөрергә рәтле кием булмады. Сәхнәдә җырласам да, биесәм дә, рольдә уйнасам да гел бер иске, инде юа-юа юкарып, көрән төсен югалтып бетергән чаңгычылар костюмы гына иде өстә. Авыл активисты Шәүкәт абзый Мостафинның миңа:

— Әй, энем! Матур җырлыйсың, оста биисең. Әгәр хәлем булса, мин сиңа яхшы кара костюм, ак күлмәк, өр-яңа туфлиләр алып бирер идем, сәхнәгә шуларны киеп чыгар идең, — дип әйткәне әле дә бик хәтердә. Ул заемга акча җыеп йөри иде. Безгә дә керә. Ләкин әнине акча сорап йөдәтми. Ул безнең хәлне яхшы белә. Минем белән сөйләшеп чыгар өчен генә керә ул.

— Әгәр заемга ун мең акча отсам, яртысын сиңа биреп, Казан консерваториясенә укырга илтеп урнаштырыр идем. Талантың юкка чыга инде... — дип уфтанып, минем йөрәкне яндырып чыгып китә иде мәрхүм.

Беркөнне мин иртән эшкә төшеп утырдым. Салихҗан абзый инде килгән, эшләп утыра. Бүлмә эче тып-тын. Бәй, радио нишләп сөйләми? Карыйм, кара тәлинкә юк урынында.

— Кара әле, Салихҗан абзый, кая киткән безнең радио? — дим. Ул:

«Белмим», — диде дә, кабат эшенә чумды. Мин торып барлык урынны актарып, репродукторны эзләп килдем. Нәкъ концерт вакыты, ә ул юк. Васыйл абзый да килде, аңа да әйттем. Ул да гажәпләнде. Эзлибез, эзлибез, ә таба алмыйбыз.

Кинәт Салихҗан абзый рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Үзе көлә, ә безгә бер сүз дә әйтми.

— Бар, төшеп ал, — ди бу миңа көлеп туйгач, идән астына күрсәтеп.

Кичтән Салихҗан абзый яхшы гына төшергән булган. Иртән башы авырта икән. Сельпога килеп кергән, ә монда бар куәтенә радио сөйләп утыра. Салихҗан абзыйның ачуы чыккан да, репродукторны йолкып алып өй базына ташлаган икән...

Әнә шундый сәер, кызык гадәте бар иде минем остазның.

Тагын бер мизгел. Салихҗан абзый күп сөйләшми. Бераз салгач аның теле ачыла. Тик бу озакка бармый, тагын ике-өч мәртәбә тотып куйса, теле тоткарлана башлый һәм аның, бик сөйләшергә теләсә дә, нәрсә әйтергә теләгәнен беркем дә аңламый иде.

Салихҗан абзый мине бишенче сыйныфта татар теле һәм әдәбиятыннан укыткан, минем яраткан укытучыларымнан булган Халидә апага өйләнгән иде. Лашман авылы кызы Халидә апа Касыймова — мәшһүр Гаяз Исхакыйның ике туганнан туганы, Лашман авылы мулласы, Һади Атласый «эше» буенча 1937 елда кулга алынып, Атласый үзе, Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар һәм башкалар белән бергә юк ителгән Касыйм Исхаковның икенче кызы. Гомумән, язмыш мине Касыйм Исхаков балалары белән шактый гына аралаштырып яшәтте. Аның иң олы кызы фельдшер-акушер Саибә апаның тормыш юлы безнең Елховой авылында бәрәкәтле хезмәт белән үтте. Ленин орденлы Саибә апа бүген дә сау-сәламәт, авылыбызда аның абруе тиңсез.

Касыйм мулла балалары белән рухи уртаклык табып яшәү бәлки язмыш уртаклыгыннан да килгәндер. Каһәрле 1937 елда аралары ерак булмаган ике авылдан ике кеше кулга алынып атылган. Берсе Лашманнан Касыйм мулла булса, икенчесе Елховойдан «чабаталы мулла» («Эш»тә нәкъ шулай язылган), минем бабам Салах карт булган.

Ул ел — минем газеталарга бик актив язышa башлаган ел да бит әле. Авыл яңалыклары, аның унган кешеләре турында язып кына җибәрәм. Һәм минем мәкаләләрнең басылмый калганын хәтерләмим. «Кызыл Татарстан» газетасында басылган мәкаләләрем турында радиодан иртәнге күзәтү вакытында ук ишетәм. Сельпода монда да игътибар итми калмыйлар. Салихҗан абзый зур ышаныч белән:

— Безнең Әсгать ул язучы була! — ди барыбыз алдында.

Мәкаләләр өчен гонорар да мул килә иде ул елларда, хәзерге кебек кенә түгел. Почтага минем исемгә гонорар килү белән, почта бүлеге мөдире, сугышта бер аягын өздереп кайткан Әхмәтзыя абзый Хәбибуллин, протез аягын сөйрәп, сельпога килеп җитә һәм кул таягы белән тәрәзәне кага. Сугышка кадәр ул Ленинградта яшәгән, теле яхшы гына урыслашкан, авылга кайткач та урыс акценты бетмәгән иде.

— Асхат, гонорар...

Әхмәтзыя абзыйның азапланып протез белән минем арттан килүенең сере бар. Ул да салгаларга ярата. Гонорар алгач та Әкрәм абзый кибетенә кереп бер стакан шәраб салдырам.

Ул сугыштан кайтып безнең авылда укытучы булып эшләүче, ирен сугышта югалткан яшь Кирлегәч авылы хатыны Карәбә апа Напаевага өйләнде. Карәбә апа безнең Нурия апаларда яши иде. Ә Әхмәтзыя абзый күршедә генә.

Мин әле тормыш юлына чыгып кына киләм. Әхмәтзыя абзый инде заводта да эшләгән, сугыш юлын үткән, шунда аягын да өздергән. Ләкин бу безгә дуслашып китәргә һич комачауламады. Ул бик яхшы шахмат уйный. Мин дә аңа ныклы каршылык күрсәтәм, вакыт-вакыт отып та куям. Кайбер кичләребез аларда әнә шулай шахмат тактасы янында, яки сөйләшеп уза. Карәбә апа безне чәй белән сыйлый. Ул да мине үз күрә, чыгып киткәндә: «Әсгать, син безгә гел килеп йөр, Әхмәтзыя абзыең сине бик ярата», — ди.

***

...Салкын яңгырларын, шул яңгырда изрәгән сукмакларын-юлларын, караңгы һәм шыксыз кичләрен ташлап көз китте. Аның урынына җир өстендәге бар гөнаһларны, бар җитешсезлекләрне каплап беренче кар яуды, кыш килде. Дөнья яктырып, сафланып киткән кебек булды, күңелләр тынычланып калды. Беравыкка авыл халкының мәшәкатьле, тынгысыз, көне-төне эш белән, тормыш михнәтләре белән мәшгуль вакыты артка чигенде. Колхоз авылы өчен кыш — ул авыр хезмәт җәennнән соң җиңел сулыш алу, бераз ял итү дә бит әле. Халыкның санаторие дә, ял йорты да, пансионатлары да — ап-ак карлы кышкы зәңгәр көннәр. Иң кадерлесе — иртән торгач синең тәрәзәң каршына килеп унтер офицер тавышы белән: «Сиңа фәлән җиргә эшкә!» — дип бригадир килеп кычкырмый. «Хәлең ничек, авырмыйсыңмы, иртән торгач ашарга әзерләрлек ризыгың бармы, нәрсә ашап торасың, мин дә, колхоз рәисе дә сиңа бернәрсә дә бирә алмадык бит, бар булган ашлыкны дәүләткә тапшырттылар, халыкка хезмәт көненә бүләргә бик аз калдырдылар», — дими ул сиңа. Очлы, нурсыз күзләрен тасрайткан да: «Эшкә!» — дип кабатлый һәм иске итеген лыш-лыш сөйрәп башкаларны эшкә куаларга китеп бара...

Яшьләрнең кышкы озын кичләре күбрәк аулак өйләргә, кызлар янына йөреп үтә. Миңа хәзер кызлар янына барырга оят түгел: өстемдәге киемнәрем яхшырды. Уенда егетләр арасында иң дәртлеләреннәндер: җырга да, биюгә дә, уен оештырырга да һәвәс. Үзеннән-үзе кичәләргә өч егет — оста гармунчы Наил, теге оч егете Кукы Зәкие һәм мин бергә йөри башладык. Наил гармунында шулкадәр оста уйный, кулына иске итек кунычы китереп тоттырсаң да көй, моң чыгарыр иде сыман. Зәки белән мин исә — кичә тоткалары. Аулак өйдәге уен кичәсе күңелле булсын дип кайгырткан кызлар, ул еллардагы мишәр дөньясындагы тыйнаклыкны онытып, колактан-колакка безгә китереп җиткерәләр: «Бүген фәләннәрдә җыелышып утырабыз, Әсгатьләр килми калмасыннар...» Башка егетләрнең әллә ни хаҗәте дә юк, әгәр дә берәр кызның күзләгәне булмаса. Ләкин без үзебез дә сайланабыз: кайда якты, иркен, җылы, рәхәт һәм кайда кызларның артык чибәрләре, күңелләләре, җаңга ошаганнары. Олы авылда кышкы кичләрдә өч-дүрт җирдә җыелган була кызлар. Без башта бер җиргә кагылабыз, аннан икенче җиргә... Карыйбыз, сыныйбыз, үзебез дә кызлар күзлибез. Бу җирдә ошамаса, бераз уйныйбыз да, чыгып китәбез. Бирсдә җыелган кызлар исә без киткәнгә елый язып, тилмереп калалар. Ә ошаган җирдә рәхәтләнеп сиптерәбез. Кайбер аулак өйләрдә исә без уен белән мавыккан арада казанда бәрәңге, хәтта итле аш та пешеп өлгерә. Шау-гөр килеп идәнгә табын җәеп, сыйланып алабыз да, тагын кичәне дәвам итәбез. Кулга-кул тотынып, түгәрәккә тезелеп җырлап җибәрәбез:

Әй, сибәләр, сибәләр лә,
Сибә белми сибәләр шул...

Жырның әлеге яртысы башкарылган вакытта уртада басып торган кыз кемне уртага чакырыйм икән дип карана, уйлана. Якын кешесен, биредә булса күзләгәнен чакыра инде ул. Тик кем аның күнеленә хуш? Кабартма Моктәеме, Кукы Зәкиеме, Пыльдыр Мәжитеме, әллә Сарык Әхәтеме? Уртада Гөлсем булса — Моктәйне чакыра, әлбәттә. Тансык Фатыймасының күзләре гел Кукы Зәкиендә. Тик җилбәзәк Зәкинең күзләре генә әллә кемнәрдә...

Егет белән кыз култыклашып түгәрәк уртасында әйләнгәндә жырның икенче яртысы яңгырый. Ул яртысының темпы тизләнә, бию темпына әйләнә:

Сикереп суга төшәр идем
Сине суда дисәләр...

Ярлылыкның иге-чиге юк. Шулай да, кичке уенга кызлар бар булган, матур, затлы дип санаган киемнәрен киеп киләләр. Тик андыйлар да күп түгел. Фатыйманың өстендә яшькелт-зәңгәр төстәге, киң бала итәкле күлмәк, тамбурлап чиккән, киң эшләпурлы ак алъяпкыч. Башына туздырып бәйләгән, алгы ягын чукландырып сүткән зәңгәрсу яулыгы да килешеп тора үзенә. Алъяпкыч изүе астында унган күмәч чаклы калку күкрәкләр. Битенең шактый өлешенә мул итеп иннек яккан, күзенә сөрмә тарткан. Бер караганда чибәр кызлардан һич калырлыгы юк. Уенда да кыю, сөйләшкәндә дә сүз артыннан күршегә керми.

Рауза да чиккән ак алъяпкычтан, ул да битенә иннек сөрткән. Ләкин Рауза болай да чибәр. Гөлсем исә кызларның күбесеннән мөлаемлеге, сөйкемлелеге белән өстен, гәрчә киемнәре бик гади булса да. Гомерлек ярым булсын дип йөргән егетләр урынында мин, әлбәттә, Гөлсемне сайлар идем...

Бии-бии арыганнан соң кызлар-егетләр утырып, ял итә-итә йөзек салыш уйныйлар. Ләкин иң кызыгы — йолдыз санау. Бу уен кичәгә әле тәүге тапкыр килгән, уен белән таныш булмаган кешеләр, бигрәк тә читтән кайткан кунаклар өчен исәпләнгән. Аны уртага чыгарып бастыралар да, бер өс киеменең җиңен өскә күтәреп, «йолдыз санарга» кушалар. Теге тырышып-тырышып җиңнән яктылык эзләгән вакытта берәү чүмеч белән өстән су сала...

Инде соң, төн уртасы җиткән. Кичке уенга җыелган кызларга, егетләргә таралышырга да вакыт.

Күк күгәрчен күкләрдә,
Җиргә төшә чүпләргә;
Инде ни хәлләр итәргә,
Вакыт җиткән китәргә...

Без өчәү — Наил, Зәки һәм мин гармунга кушылып җырлап кайтып китәбез:

Әйдә, дуслар, җырлыйк әле
Уйнаган гармуннарга;
Яшьлектә яшьнәп калыйк бер,
Бирешмик кайгыларга...

Төнге авылның саф һавасында безнең җыр тавышы иң тын почмакларга барып ирешә. Салкын кышның аяз күгендә яктырткан ялгыз ай безне монсу гына озатып кала...

***

Илле өченче елга кердек. Гыйнвар башында мина 18 яшь тулды.

Февраль аенда жирле Советларга сайлаулар булды. Район газетасыннан үземнең Елховой сайлау округы сайлау комиссиясенең секретаре итеп билгеләнгәнемне белдем: «...секретаре — Әсгать Сәхап улы Салахов...» Кем шулай хәл иткән? Миннән сораган, минем белән сөйләшкән кеше дә булмады, югыйсә. Шулай да сайлау эшендә бик нәшат катнашып йөрдем. Комсомол бит! Сайлау көнне өстәл артында утыручылар күп иде, комиссия секретаре дип тормадылар, атка утырттылар да, әрҗәне тоттырып карт-корыдан сайлатырга чыгарып жибәрделәр. Ә минем бер хәлнең шаһиты буласым килгән иде.

Җәен, иген урып-җыю вакытында, ындыр табагына райком вәкиле Фәттахов килеп төшә. Хәтерем ялгышмаса, НКВД да ниндидер житәкче булып эшләгән әлеге бәндәдән бөтен халык өркеп яши иде ул елларда. Куркытып яшәүдән тәм тапкангадыр, гадәтләре дә котырынкы иде аның. Жир кендеге диярсең!

Ул килеп кенә житкән, салам кибәне өстеннән сыерын жигеп сугу машинасына көлтә ташучы Хатыйп бабай Миндаров төшеп килә икән.

— Син нишләп салам кибәне өстендә йөрисең, картлач?

— Өйлә намазымны укыдым, — ди бабай тыныч кына.

— Ә какое имеешь право общественный урында намаз укырга? — дип жикеренә Фәттахов.

— Анысын инде синнән сорап тормадым, балакаем. Ходай ризалыгы өчен укыйм мин намазларымны.

— Бирермен мин сиңа Ходай ризалыгы өчен, — ди дә вәкил, картка чыбыркысы белән кизәнә. Зур гәүдәле, таза, үзенең дәрәҗәсен белгән намуслы һәм абруйлы авыл карты әдәпсез вәкилнең кыланмышына түзеп тора алмый, очраклы рәвештә аяк астында аунап яткан күсәкне кулына ала.

— Сугып кара, оятсыз, муен тамырыңны өзәрмен, — ди ул.

Шушы хәлдән соң Хатыйп бабайга карата жинаять эше кузгатыла. Ул елларның башбаштаклыгы, законсызлыгы белән гаделлеккә ирешү мөмкин идеме соң? Бүген дә гаделлек юк бит әле ул. Ходай бәндәнне ул КГБ, милиция, прокуратура, суд дигән нәрсәләр каршына китермәсен...

Хатыйп бабай жинаять эше кузгатылганы турында ишеткәч, авылдан шылды. Ул бик озак качып йөрде — әллә башка жирләрдә, әллә өендә генәме? Әйдә, йөрсен, әллә кая китә алмас, сайлау көнне участокка килми калмас, килмәсә сайлауда катнашмаган, совет властен инкарь иткән өчен аңа тагын да зуррак срок чәпәячәкләр, диделәр булса кирәк хокук саклау органнарында. Һәм көттеләр.

Мескен картның сайларга килми мөмкинлеге калмаган иде. Килгән, сайлаган һәм... кулларын артка каерып, богау салып алып киткәннәр район үзәге Чирмешәнгә. Картлык көнендә ике ел төрмәдә утырып кайтты бабай...

Әйе, Сталин заманы иде шул ул! Ләкин ул коточкыч заманнарның да үтәр вакыты житеп килгән икән бит. Март башында бөтен ил радиосыннан хәтәр хәбәр — Сталинның бик каты авырып китүе турында житкерделәр халыкка. Ул көннәрдә сельпога халык күп жыела башлады. Барысының да колагы кара тәлинкәдә: «бөек юлбашчыбыз»ның хәле ничек? Үлеп китмәсен тагын... Безнең ише кара халык белми бит әле аның дөньяда тиңе булмаган коточкыч явызлыклар кылган палач икәнлеген. Сельпо диварлары Политбюро әгъзалары рәсемнәре белән тулган. Менә Ул — мөлаем йөзле, мыек астыннан гына ягымлы елмаеп тора. Әнә Молотов, Маленков, Каганович,

Ворошиловлар... Барысының да күзләре сиңа төбәлгән, ышанычлы караш үзләрендә. Ә менә Бериянең карашы бер якка төбәлгән. Нишләп ул якка карый? Минем аңа һич ышанычым юк... Салихҗан, Васыйл абзыйлар үзләре генә калган вакытта мин бу турыдагы фикерем белән алар белән дә уртаклашам. Һәм алар да бу турыда уйланалар, шөбһәләрен белдерәләр. Һәм кисәтеп тә куялар: «Башка кешеләргә сөйләмә тагын»...

Сталин үлгәннән соң халыкка авырга туры килер дигәннәр иде, ләкин алай булмады. Тауарларга бәяләр төшә, халык мәнфәгатен кайгыртып ниндидер карарлар чыга башлады. Убыр китте, урыны калды... һәм ул урынга азмы-күпме кешелек сыйфатлары булган яңа убыр утырды булса кирәк...

***

Көләч кояшы белән яз, апрель килде. Квартал, ай ахырыннан соң отчетларны ясап, балансны чыгарып куйдык та, аларны район үзәгенә озатырга җыендык. Балансны чыгару — иң җаваплы эш. Бер тиен килмәсә дә, балансың чыкты дия алмыйсың. Бер үк саннарны өчәүләп саныйбыз, счет төймәләре җырлап тора. Мин дә бу эшкә шактый остардым. Санап чыгарам да, саннарны Салихҗан һәм Васыйл абзыйларга әйтәм.

— Әсгатьнеке дөрес булуы ихтимал, ул яшь, башы әйбәт эшли, — ди алдан ук Салихҗан абзый миңа ышаныч белдереп. Һәм ул, чыннан да, еш кына хаклы була иде.

Исәп-хисап кәгазьләрен, ай буе җыелган акчаларны районга алып китәргә кирәк. Ләкин ничек? Ат юлы өзелгән чак. Иртәнге салкында җәяү генә үтәргә мөмкин. Чирмешәнгә ерак. Ике араны колхоз «полуторка»сы шоферы Мәсгут абзый Гобәев күптән үлчәгән инде. Елховой мәчетеннән Чирмешән чиркәвенә чаклы нәкъ 33 чакрым.

— Әсгать, энем, сиңа барырга туры килер инде, — диләр миңа сельпода. Эш кәгазьләрен илтү берни түгел. Җәяүлегә тулы бер сумка акча алып баруы куркыныч. Чирмешәнгә утыз өч чакрым... Шыплап тутырылган «полевая сумка»да 33 мең сум акча! Күпме бу? Бер елдан соң, инде мин Баулыда буровойда эшли һәм хезмәт хакын да меңәрләп ала башлагач, ул елларда әле күренә генә башлаган «Победа» автомашинасы 16 мең сум торганын белдем. Димәк, минем сумкада ике «Победа» автомашинасы алырлык акча булган бит!

Иртән-иртүк чыктым юлга. Аякта кирза итекләр. Сумканы бавыннан җилкәгә аркылыга салып барам. Бераздан аның авырлыгы да сиздерә башлады — җилкәгә баса. Кара Чишмә, Туймәт авылларын төнге салкында каткан юлда җиңел үттем. Инде кояш кыздыра, кар йомшара, юл да изри башлады. Үземә яхшы таныш Әмир авылы турысына җитеп киләм. Кинәт артымда атка атланган ике кешене күрдем. Каян килеп чыктылар? Туймәтнекеләрме, әллә башка авылданмы? Минем янга килеп җитәргә ерак әле. Аларның да атлары изрәп килгән карлы юлда батып-батып китәләр. Кемнәр алар? Каяндыр минем акча илтүче икәнемне белеп артымнан чыкмаганнардыр бит? Күңелгә шик төште. Ашыкмыйлар, акрын гына атлыйлар. Әнә Подлесный авылына җитәрәк урман башлана. Бәлки миңа һөҗүм итәр өчен урманга барып җитүне кулайрак саныйлардыр? Кесәдә бернинди корал, пәке генә дә юк. Болай гына бәйләнгән очракта каршылык күрсәтермен анысы, икәү генә бит алар. Әгәр инде кораллары булса...

Урманга җитәрәк сулга юл кереп китә. Бәлки алар шул юлга борылырлар? Минем арттан инде атларының авыр мышнап килүен ишетеп барам. Гел якынаялар. Кайчан һөҗүм итәрләр? Мин теге юлны артта калдырып, Чирмешәнгә таба юнәләм, ә атлылар әкрен генә русча сөйләшеп, сул якка

китә торган юлга борылалар. Аларның миндә гамьнәре дә юк. Булса да, юлаучы бер егет, сумкасында юлга алган ашамлыклары дип уйлаганнардыр. Анда ике автомашина алырлык акча барлыгын белгән булсалар, белмим, ничек тотарлар иде икән үзләрен?

Өстән тау төшкән кебек булды минем ул кешеләрнең борылып китүләрен күргәч...

Бу вакыйганы күпләргә сөйләргә туры килгәне бар. Араларыннан: «Шул кадәр акчаны үзең генә алып сыпыртырга иде», — диючеләр дә булды. Тик андый ахмаклыкны эшләү түгел, ул кара уйның башыма да килгәне булмады минем.

Сельпоның акчасын, исәп-хисап кәгазьләрен яхшылап тапшырып, икенче көнне күтәренке кәеф белән авылга кайтып киттем. Кәеф күтәренкелегенең сере дә бар иде, чөнки районда мин искиткеч матур бер кызны очраттым. Андый гүзәл затны минем әле Елховойда да, Лашманда да күргәнем юк иде. Туймәтнең Айсылу апа кызы Саимә генә аңа тиң булгандыр. Бу — мукшы авылы Кутәмә сельпосында минем кебек үк хисапчы булып эшләүче Надя иде. Урыс сүзләрен ватып-җимереп сөйләшә торгач белдем мин аның турында. Тик бу минем аны беренче һәм соңгы күрүем булды...

Дөньясында синең күз явыңны алган, җилкенләндергән-дулкынландырган, хисләндергән-уйландырган, төшләрдә күргән гүзәл кызлар аз очрамый. Яшьлектә сине аның кайсы милләттән булуы да уйландырмый. Тиле яшьлек, сукыр мәхәббәт барысын да оныттыра. Азмыни шул сукыр мәхәббәт аркасында яшьлегендә урыс яки мукшы марҗасына, хохлушкага яки чуваш кызына өйләнгән татар егетләре, мәхәббәт дип ата-бабаларының борынгыдан килгән гореф-гадәтләренә, күркәм йолаларына, үз милләте язмышына төкереп, туган телен, газиз иманын сатып гомер кичерүчеләр? Һәм андый тормышның күп вакыт фаҗигале тәмамлануы, картлык көнендә ике милләт кешесенең, ике дин, ике тел, ике төрле йоланың уртаксызлыгыннан гаҗиз булып, аңлашу, гармония таба алмый, кимсенеп, җан әрнешләре кичереп аерылу-каерылулар, нигә соң мин яшьлегемдә үз милләтем, үз динемдәге кеше белән кавышмадым икән дип үкенүләр? Бәхетемә, ул фаҗига мине читләп үтте. Әллә бу минем иманымның ныклыгыннан, милли тамырларым тирәнлектән, төрки-татарлыгым көчлелектән булдымы?

***

...Карлар эреп, сулар акты. Инде җир өсте дә кипшенә башлады. Озакламый колхоз игенчесе басуларга чыгар, язгы кыр эшләренә тотыныр. Ләкин аңа чаклы әле берничә көн бар. Бу вакытны авыл яшьләре бушка үткәрмиләр, сөлге җыеп алалар. Башка җирләрдә ничек булгандыр, язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң үткәрелә торган Сабан туе өчен безнең авыл яшьләре әнә шул кыска гына мөмкинлектән файдаланалар, кыр эшләренә чыкканчы сөлге җыеп алалар иде. Унтугыз-егерме яшьтән дә узмаган өйләнмәгән авыл яшьләре үзләре кебек үк яшь колхоз атларына, тайларына атланып, күмәкләшеп, гармунга җырлый-җырлый, бер йорттан икенче йортка йөри-йөри сөлге җыялар. Ат тисә, ундүрт-унбиш яшьлек малайлар да чыга.

Юк, һәр йорттан да түгел, әле быел гына өйләнешкән, әр-яна йорт өлгерткән, баласы туган, заемга акча откан, башка зур шатлык кичергән гаиләләрдән генә сөлге тиеш. Алары да кешенең хәленә карап. Әлбәттә, өйләнешкән яки яңа йортка кергәннәрдән озын, баш-башлары милли нәкыш белән чиккән сөлге генә кабул итәләр яшьләр. Әгәр сөлге бәләкәй булса, сатулашу китә — өстәп нәрсә бирәсез? Өстәп бер-ике дистә йомырка алалар. Инде тавыклар йомырка сала башлаган вакыт. Шөкер, анысы бар.

Атка атланган егетләрнең берсендә йомырка чиләге. Ул йомырканы кайбер егетләр сытып-сытып эчеп тә җибәрәләр.

Ул ел минем сөлге җыярга чыгуымның тәүгесе дә, соңгысы да булды. Ат караучы якын күршем Шәймәрдан абзый миңа яхшы гына тай калдырган иде. Атланып ашыга-ашыга кайтып киләм. Шулчак кизләү тыкрыгыннан минем кебек үк атларга атланган өч егет килеп чыкты. Теге оч егетләре. Алда Сәхай. Ул миннән өч яшьләргә олы.

— Тукта әле, — ди бу миңа. Сүзе бардыр ахры, дип уйладым. Ә ул якын килде дә, камчы белән миңа ике тапкыр сугып алды. Ә минем кулымда бернәрсә дә юк, җавап бирә алмыйм. Җен ачуларым чыкты. «Ярар, мин әйтәм, болай гына калмас әле бу эшең», һәм атны чаптыра-чаптыра кайтып киттем.

Сәхайның миңа карата кылган бу эшенең сәбәбе бар иде — мин аны шунда ук аңладым. Аның әтисе әле сугышка кадәр үк безнең авыл базарына килеп сыер саткан урысны талауда катнашкан да, төрмәгә эләккән. Әнисе, авыл чибәре Газзәбану (Газизәбану, әлбәттә) апа, иреннән мәхрүм калганнан соң ир назын тансыклаган яшь хатын, минем әтигә күзе төшеп, аңа хисләрен җиткергән. Белмим, безнең әти, шулай ук берничә бала атасы, хатын ире, якын барганмы Газзәбану апа янына, әллә юкмы, әмма авылга даннары чыккан.

Минем башта бу хәлгә карата бер гөнаһсыз фараз да яши әле. Газзәбану апа кыз чагында чибәрлеге белән генә түгел, хислелеге, дәртлелеге белән дә авыл кызлары арасында аерылып торган. Минем әтигә карата аның хисләре шул чакта ук бөреләнгән. Дөрес, җырга-моңга һәвәс, сүзгә оста, эшкә уңган, төскә-биткә дә камил Сукыр Салах Сәхабына күзе төшкән кызлар бер Газзәбану гына булмаган. Тик егетнең сайлаганы бер — шулай ук җыр-моң иясе, кулларыннан гөлләр түгелеп торган ятимә кыз Мөсәвәрә генә булган. Газзәбану да башкага кияүгә чыккан, малай тапкан һәм... аңа Сәхап дип исем кушкан. Бу бер дә юкка гына шулай эшләнмәгәндер. Сөеп-сөеп тә кавыша алмый калган яшьләрнең икенче берәүләр белән кушылып яши башлагач тапкан балаларына кайчандыр өзелеп сөйгән ярларының исемен кушу — борынгы бабалардан килгән гадәт. Һәм ул гадәт бүген дә яши, дәвам итә.

Сәхай, минем уемча, үз анасы белән минем әти арасындагы четерекле мөнәсәбәт турында белми һәм үртәлми яшәмәгәндер. Миңа, бер гаепсезгә, тиктомалдан китереп сугуның да сәбәбе үч алудан булгандыр.

Сөлге җыярга чыккач, бу турыда мин Моктәйгә әйттем. Сәхай кебек үк миннән өч яшькә олы зират очы Кабартма Хәлимә абыстайның икенче улы Моктәсим белән дус идек без. Олы авылның ике очында яшәсәк тә, үтә ярлылык, тормыш мәшәкатьләре дуслаштырган иде безнең әниләрне дә, үзебезне дә. Сугыштан соңгы елларда очны-очка ялгау теләге белән Хәлимә астай, минем әни һәм авылның башка терәксезләре соңгы сыерларын, сарыкларын алып Казанга сатарга китеп бардылар. Җәйнең сусыл үләнгә иң бай, матур көннәрендә, төнге һаваның җиләс вакытында чыгып киттеләр алар юлга. Моктәй белән мин әниләрне Мукшы әрәмәсенә чаклы озата бардык.

Без кайтканда инде таң атып килә иде. Әрәмәдәге таллыкларда — кошлар оркестры. Өздереп сандугачлар, башка кошлар сайрый, Баграж суында, үзе тар гына булса да, балыклар уйный. Түбән әрәмәдә чабышкан атларның тояк тавышлары, кешнәве ишетелеп, ат көтүче малайларның сызгыруы, кычкырып сөйләшүләре безгә килеп ирешә. Без ашыкмый гына, үз җаебыз белән сөйләшә-сөйләшә кайтабыз. Сүзебез шул ук әниләр хакында. Бүген киттеләр, тиз генә кайтмаслар шул, ике атналап кына йөрерләр әле...

— Син безгә килгәләп йөр, бергә-бергә сагынырбыз әниләрне, — ди Моктәй.

— Син дә безгә кил, — дим мин дә.
— Әйдә жырлыйбыз, — ди Моктәй.
— Әйдә...

Моктәй мине урамда жырлап йөргән авыл егетләре сыман кочаклап алды һәм жырлап жибәрде.

Әй, дусларым, без бергә лә,
Аерылмас идек бер дә шул;
Тар гүрләргә сыяр идек,
Куймаслар инде бергә...

Бу безнең авыл яшьләренең урамда жырлап йөри торган жырлары. Кем нәрсә белә инде, жырның ертыгы юк...

Моннан соң инде без бер-беребезне бик якын, дус күреп яши башладык.

...Сәхайның мина кул күтәргәнен ишеткәч, Моктәй бер көтү яшьләр арасында ваемсыз гына сөйләшеп торган Сәхайны эләктереп алды да:

— Син нәрсә дип минем дуска кагыласың? — диде ул килә-килешкә һәм чашт-чошт китереп аркылыга да буйга камчылый да башлады. Сәхай кул да күтәрмәде, чөнки Моктәй авыл яшьләренең кендеге, иң чаясы һәм шул ук вакытта гаделе дә. Ул үзе беркемне дә хаксызга рәнжетмәде, ә тәрәксезләрне яклый алырлык кыю егет иде.

Кызганыч ки, мин армиядә хезмәт иткән елларның берсендә Моктәй дустым Чистайда эшләгән жирендә очраклы рәвештә вафат булган.

***

Кабартма Моктәе дигәннән, безнең авыл халкы бер-берсенә кушамат кушарга хирыс. Ялгыш авызың кыйшайса да сиңа кушамат чәпәп куялар. Камка Минач абзыйның кушаматы бер генә дә түгел, берничә иде. Сугыштан яраланып аксак аяк белән кайткан бу абзый: «Мин бик зур елга — Кунай елгасын кичкәндә ранный булдым», — дип сөйләп йөргән икән авылда, Дунай елгасының исемен буташтырып. Һәм ана яңа кушамат бирү өчен безнең мишәрләргә шул житкән. Ләкин алдан бирелеп, дистәләрчә еллар буе үзен «аклап» килгән «Камка» кушаматы үз позициясен, күрәмсең, тиз генә бирмәгән: Минач абзый элеккечә «Камка» булып калган, ә үсеп килгән улы Салихка «Кунай» кушаматы тагылып киткән.

Камка Минач абзый турында төрле сүзләр йөри иде авылда. Сугыштан партиягә кереп кайтканга, аңа колхозның дуңгыз фермасын «ышанып» тапшырдылар, озак еллар шуның мөдире булып эшләде. «Дуңгызның иң тәмле жире колак кимерчәге, ашаганда кытыр-кытыр итә», — дигән сүзләр дә Минач абзыйныкы.

Ул елларда татар, мөселман авылларында да дуңгыз асраталар иде бит колхоз фермасында. Әле андый мәсхәрәне дә күрдек бит! Шөкер, соныннан елховойлылар дуңгыз асраудан ваз кичтеләр...

Уйлап карыйм да, кушаматсыз кеше дә юк бугай безнең авылда, дигән фикергә киләм. Мишәр дөньясының үзенчәлеге инде бу. Минем әни «Керән» төбеннән. Димәк, әни ягыннан без Керәннәр. Әнинең бер бабасы урыс ягыннан керән алып кайтып утырткан икән бакчасына һәм ул котырып үсеп киткән. Ләкин үскәндә без һәрвакыт «Сукыр» булдык. Салах бабабызның бер күзенә ак салган булган. Көлке хәлләргә, мәзәккә оста Сәхап абзый Мостафинга «Гульдыр Сәхап» диләр иде. Балачакта: «Күгәрченнәр гульдыр-гульдыр итәләр», — дигән икән. Күршебез Шакиржан абзыйны Тәкан диләр иде. Ул да балачакта исемен ничек дип сорагач: «Тәкан», — дигән булган, Шакиржан янәсе. Тәмтук

Мингата абзыйга да кушаматы балачактан тагылып калган: «Ашының да тәме тук, чәенең дә тәме тук, әпәйнең дә тәме тук», — дигән бер авырып ятканда. Әхмәдулла абзый кыргыз далаларыннан кыргыз кызына өйләнеп кайткан, һәм шул хәлдән соң инде ул «Кыргыз» булып киткән. Әле Кытай, Япун, Урыс, Мукшы, Чуашлар да бар бездә. Инде йорт хайваннарына килсәк: Үгез, Бозау, Сарык, Кәҗә, Әтәч, Тавык, Чебеш, Ата каз, Мәче... Санап бетергесез. Ул анда төрле-төрле киек хайваннар, җанварлар, кошлар: Аю, Бүре, Төлке, Куян, Ләтчә, Керпе, Көзән, Ябалак, Карчыга, Үрдәк, Карга, Саескан, Чәүкә, Чыпчык, Аккош, Челән, Сандугач, Күгәрчен, Ярканат...

Шул кушаматлар аркасында төрле-төрле кызык хәлләр дә булгалый әле. Авыл самавырларын торбасыз куеп булмый бит инде. Ә безнең торба искереп беткәч, әни торба сатып алырга базарга төшеп киткән, тик ул аны базарда тапмаган. Кайтканда әнигә аз-маз тимер-томыр һөнәренә һәвәс Илалетдин абзый очраган.

— Синдә самавыр торбасы юкмы? — дип сораган әни.

— Миндә юк, Мөсәвәрә, әнә күпер төбе Кыям абзыйда бик күп, — дигән шаянлыгы-шуклыгы белән дә мәшһүр Илалетдин абзый җитди төс белән. Әни Кыям абзыйларга килеп кергән һәм гозерен әйткән.

— И-и, Мөсәвәрә, Илякка ышансаң... Беләсең бит инде безнең кушаматның Торбы икәнлеген, — дигән Кыям абзый. Әни бик уңайсызланып кайтып киткән. Ә чынында исә Кыям абзыйның ишле гаиләсендә «Торбы»лар шактый икән...

Физик җитешсезлеге, гариплеге белән кушамат алганнар була да була инде авылда: Бөкре, Кырын, Кылый, Шадра, Аксак, Чатан, Биләнке, Бүсер, Таз...

Таракан, Кыргаяк, Борча, Чебен, Черки кебек бөҗәкләргә нисбәтле кушаматлар да аз түгел.

Ләкин килеп чыгышы бүген дә билгесез һәм мәгънәсе белән дә аңлашылып бетмәгән кушаматлар турында да әйтим әле мин. Мәсәлән, нилектән Кырняк, Чәпеш, Чәйка, Лепи, Кытыр, Чытыр, Сорка, Ялпәк, Чәтек һәм башкалар?

Телгә зәһәр мишәрләр кушаматны теге яки бу кешегә кимсетү йөзеннән дә кушалардыр. Тик мин шәхсән авылдашларым турында искә алганда кушаматлары белән атыйм икән, бу фәкать минем кем турында сөйләвем тизрәк аңлашылсын өчен генә эшләнә. Кабартма Моктәенә дә, Гульдыр Сәхап һәм күршем Чүлмәк Шәймәрдан абзыйларга да кушаматларын атап язуымнан хөрмәтем дә, җылы хисләрем дә кимеми. Аларны мин һәрвакыт сагынып искә алам. Урыннары оҗмахта булсын...

***

...Май уртасында дусларым Әлфрит, Наил, Түбән Абдул ягыннан сыйныфташым Мөхәррәм Фәйрушин мине үзләре белән бергә Әлмәткә бораулау эшчеләре хәзерләү мәктәбенә китәргә үгетләп килделәр. Ай ахырында чираттагы курслар башлана икән. Ничек инде дуслардан каласың? Ни булса — шул булыр дип, җыенып чыгып киттек Әлмәткә.

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт
Таң җилләре искәндә,
Мин җырлармын сине сагынып
Өзелеп искә төшкәндә...

Марат
Кәримов



# КАЙЛАРГА ЧАБАСЫҢ, ГОМЕРЕМ...

## Ватан

**Җир шарында ике полюс, дибез,
Рәсәйдә дә шулай — сер түгел.
Мин Ватан, дим, син дә Ватан, дисең,
Тик ватаннар безнең бер түгел.**

**Синең Ватан — патша сарайлары,
Таш коймалар аны ураткан.
Минем Ватан — җиргә сеңгән өйләр,
Күренеп тә бармый ерактан.**

**Синең Ватан — алдау офислары,
Банклар һәм биржа заллары.
Минем Ватан — минем кебекләрнең
Фәкыйрьлектән туган зарлары.**

**Синең Ватан — тамыры юк Ватан,
Дер калтырар давыл-җилләрдән.
Минем Ватан — мәңге шушы җирдә,
Тамырларын тирән җибәргән.**

**Кара һәм ак... Ялган белән хаклык...
Бер-берсенә алар иш булмас.
Ике полюс кушылмаган кебек
Ватаннар да безнең кушылмас!**

## Рәшәткәләр

**Балконнары тимер рәшәткәле,
Тәрәзләре тимер рәшәткәле.
Ишеге дә тимер. Чак ачтылар,
Монсына да бик зур рәхмәт әле!**

Марат КӘРИМОВ (1930) — *Башкортстанның халык шагыйре; өч томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Уфада яши.*

Бакчаларга чыгам — рәшәткәләр,
Кибетләргә керәм — рәшәткәләр.
Өндә генә түгел, хәзер хәтта
Төшләремдә күрәм рәшәткәләр.

Яңгырдан соң шыткан гөмбәмени —
Ярыша-ярыша үсә рәшәткәләр.
Үсә-үсә адәм баласының
Күңеленә күчә рәшәткәләр.

Онытыла йөрәкләрне ачып,
Нурлар чәчеп, яшен яшьнәткәннәр.
Күңел белән күңел арасына
Сакчы булып баскан рәшәткәләр.

Рәшәткәләр аша карый-карый
Без тиңләштек бугай тоткыннарга.
Рәшәткәле язмышыбыз безне
Сөйри тагын нинди упкыннарга?

Бер нәрсәсез урында да хәзер
Бар шикелле тоела рәшәткәләр.
Үлгәч тә бит аннан котылу юк —
Каберләргә куела рәшәткәләр...

## Җизни пәкесе

Берәр җирдә бу йоланың бармы ише?
Кайнешенә пәке бирә җизни кеше.

Малайларга шатлык юктыр шуннан артык,
Пәке белән мактана ул, танау тартып.

Ә мин йөрдем мактаналмый байтак заман.
Апаларым нигә кияү тапмый һаман?

Һәм, ниһаять, тапты алар эзләгәнен —
Чит милләттән булып чыкты җизнәләрем.

Иосиф җизни, Войтек җизни, Коля җизни,
Семен җизни — минем өчен олы җизни.

Әй йөрдем мин күкрәк киереп, танау чөеп:
Нинди генә милләттән юк туган! — диеп. —

Урысы бар, яһүде бар, полягы бар.
Әле әйтми калганнары тагын да бар!

Төрле-төрле булды биргән бүләкләре,
Берсеннән дә әмма пәке эләкмәде.

Моның өчен бәрәсеңме башны ташка,
Һәр милләттә гадәт башка, йола башка.

Төкереп бир, әйдә, җизни пәкесенә,
Сүзем күчә апамнарның бәхетенә.

Яшәделәр тормышыбыз уңмасмы, дип,
Ике ярны тоташтырып булмасмы, дип.

Моның өчен төрле-төрле юллар табып,
Чит милләткә кызлар табып, уллар табып.

Безгә генә килде мәллә бу буталыш?
Алай дисәң, күпмеләрдә шул ук язмыш!

Булыр кайнешләрдә әле минем уем.
Бәйрәм иткән чакта апалары туен,

Күзләрендә шатлык уты кабыныр микән?
Пәке бирер җизниләре табылыр микән?

## Кайларга чабасың, гомерем...

— Талларга тотынып, бөгелгән талларга,
Кайларга агасың, Иделем, кайларга?

— Төягем тау түгел, астагы үзәндә.
Түбәнгә ашыгам, урыным түбәндә.

— Кайларга чабасың, гомерем, кайларга?
— Тауларга, офыкта күренгән тауларга.

Түбәндә яшәүнең мәгънәсе нилектә?!
Биектә кешенең урыны, биектә!

## Үпкә

Баш заманы булган элек,
Булган да беткән инде.
Хәзер аның урынына
Аяк заманы килде.

Туп тибүче егетләрне
Күкләргә күтәрәләр,
«Алар илнең герое!» дип
Исләрне китәрәләр.

Сәхнәләрдә сикеренгән
«Йолдызлар»га бак кына:
Адәм рәтле моңнары юк,
Бар шәрә аяк кына.

Шушыларны карыйбыз да
Кәеф-сафа корабыз.
Үзебезне шуның белән
Бәхетле дип тоябыз.

Кешечә дә сөйләшү юк,
Ул чаклар узды, дибез,
«Вафат булды» дип әйтмибез,
«Ул аяк сузды» дибез.

**Җәмгыятькә уйландырыр**
**Әдәби сүз нәрсәгә?**
**Фикерләүләр, баш ватулар**
**Кирәк түгел кемсәгә.**

**Үпкәсе бар шуны күреп**
**Шигырь язган Маратның:**
**Ходай, нигә мине**
**аяк**
**Заманында яраттың?**

## Болгарга бару

*Марат Шәриповка*

**Үзем белән алып бабалардан**
**Мирас калган хәтер янчыгын,**
**Бөек Болгар, сиңа килдем әле**
**Мин, синең бер тере ярчыгың.**

**Чишелде дә янчык сихри мираж**
**Пәйда булды тарих чүлендә.**
**Таш пулатлар... Әнә хан сарае...**
**Алмуш ханмы тәхет түрендә?**

**Кем соң анда Багдад хәлифенең**
**Хатын укый? Ибн Фадландыр.**
**Сихри мираж, берүк югалмый тор,**
**Үткәннәрне шулай җанландыр.**

**Алып ташла әле күз алдыннан**
**Дәверләрнең кара япмасын.**
**Әнә күрәм сансыз кәрваннарга**
**Шәһәр ачып куйган капкасын.**

**Даны чыккан Ефәк юлының да**
**Монда мәллә соңгы ноктасы?**
**Алыш-биреш, чыңлый алтын-көмеш,**
**Шул бит инде базар токкасы.**

**Нинди генә телләр яңгырамый!**
**Көнләшерлек хәтта Вавилон.**
**Кинәт кенә мираж юкка чыкты,**
**Алда күрәм урыс авылын.**

**Кайда, кайда югалдың соң әле**
**Бабамнарның данлы каласы?**
**Ятып елар өчен ничек кенә**
**Нигез ташларыңны табасы?**

**Әмма барыбер синең рухың монда,**
**Монда килгән татар баласын**
**Колач җәеп каршы аласың да,**
**Моңсуланып озатып каласың.**

Озатасың мена мине дә син,
Янчыгымда изге балчыгың.
Самогонмы–нидер куып калды
Чит милләтнең сәрхуш карчыгы...

## Мин — оҗмахка кандидат

Әбиемнең әйткәннәре
Хәтергә нык уелган:
«Кемнең нәрсә күрәчәге
Алдан язып куелган».

Күкнең шул картотекасын
Күрәсе иде, дидем,
Минениләр көткәнлекне
Беләсе иде, дидем.

Әмма тормышка ашмады
Шушы уем — хәстәрем.
Фәрештәләр югалтканнар
Минем язмыш дәфтәрен.

Шуңа минем ул дәфтәргә
Булмады һич катышым.
Әле үзем теләгәнчә
Гомер итеп ятышым.

Көнем булды, төнем булды —
Төрле–төрле чак булды.
Ни булса да мир алдында
Минем йөзем ак булды.

Булды бугай гөнаһы да
Эзләүчегә табарлык.
Әмма берсе дә булмады
Тәмугларда янарлык.

Еллар килде, еллар китте,
Чал өстәп чәчләремә.
Һәр адымны язып бардым
Язмышым дәфтәренә.

Шул дәфтәрне тәмамлагач
Иң соңгы сүзем белән,
Бакыйлыкка күчкән чакта
Алам дим үзем белән.

Язганнарымны дөресләп
Кул куеп ахырына,
Аны тапшырырга исәп
Ходайның архивына.

Аптыраган фәрештәләр
Әйтерләр бер авыздан:
— Теге югалган дәфтәргә
Шул ук язмыш язылган!

**Димәк, ул тик без кушканча**
**Яшәгән. Шаккатырлык!**
**Шуңа үзен бүгеннән үк**
**Оҗмахка озатырлык!**

## Түрә буласым килә

**Ачынулар житкән чакта**
**Иң соңгы ноктасына,**
**Ирексездән колак салам**
**Шайтанның коткысына.**

**Пышылдый ул: «Төкереп бир**
**Җәмгыять чирләренә!**
**Әнә түрәләрдән өйрән**
**Шәп яшәү серләренә».**

**Шулай дигәч, җылы гына**
**Урын билисе килә,**
**«Җитәкчеләргә дан!» диеп**
**Нотык сөйлисе килә.**

**Моның өчен буш итмәсләр,**
**Мактау көтәсе килә,**
**Шулар ышыгында гына**
**Гомер итәсе килә.**

**Начар яткан дәүләт милкен**
**Күзләштерәсе килә,**
**Әмәлләрен табып, аны**
**Үзләштерәсе килә.**

**Күзләремне йомган булып**
**Ришвәт аласым килә,**
**Җылы диңгез ярларында**
**Сарай саласым килә.**

**Балаларны Лондоннарда**
**Гына күрәсе килә,**
**Аксөякләр кастасына**
**Мотлак керәсе килә.**

**Белеп булмый, безгә нинди**
**Еллар боласы килә.**
**Шуңа кадәр тизрәк–тизрәк**
**Түрә буласы килә.**



Сирень Якупова

# ХИКӘЯЛӘР

### Җанның ялангач чагы

Җәй көне бөтен агачлар да бертөсле, яшел була. Һәрхәлдә, беренче карашка шулай тоела. Ә кышын, яфраксыз чакта күрегез: каеннар ап-ак, кайбер агачларның кәүсәләре соры йә яшькелт, ә кайберләре бөтенләй кап-кара булып тырпаеп утыра. Яфраксыз чакта... Без кешеләр дә шулай түгелмени? Адәм баласының чын йөзен, асылын, үзәген танып белер өчен аның җанының, күнеленең шәрә калган мәлен күрергә кирәктер. Җанның ялангач чагын...

***

— На-а-а, малкай! Аллага тапшырдык...

Курчак өе кебек матур, яңа авыл өенең ишегалдыннан жигүле ат кузгалып китте. Аны озатып калган аксыл чәчле үсмер малайның сагышлы карашы арба артыннан бик озак ияреп барды. Юлаучылар бөтенләй күздән югалгач, яшь белән мөлдерәп тулган зәңгәр күзләр, түгелер өчен ышык урын эзләгәндәй, ашыга-ашыга койма буенда үскән кычыткан өсләреннән, сары вак чәчәкләр белән чигелгән яшел чирәм эченнән йөгереп уздылар да, ахыр чиктә, нәни сәдәфләр булып сибелгән песи борчаклары арасына кереп чумдылар... Дөньяда бу минутларда сипкелле түгәрәк йөзне көйдереп аккан пар чишмәне туктатыр көч табылмас кебек иде. Кинәт янбакча ишегеннән, яше өч яшьләр чамасы булыр, малай шикелле үк сипкелле кызчык атылып чыкты.

— Абый, абый, капканы яп инде! Күбәләк чыгып китә бит!

Сеңлесенең куркынган әче тавышына койрыгын чәнчеп чапкан бозауның аяк тавышы да килеп кушылды. Малай күлмәк җиңе белән җәлт кенә яшьләрен сөртте дә, почык борынын тарта-тарта, өйләре шикелле үк яңа, челтәрләп ясалган урыс капкага барып ябышты. Гадәттә жырлап кына ачылып ябыла торган капка бүген әллә нинди моңсу тавышлар чыгаргандай тоелса да, «абый кеше», ни генә булмасын, ничек кенә булмасын, капканың эчке ягында да, тышында да тормыш дәвам итәчәген аңлап өлгергән иде инде...

---

Сирень ЯКУПОВА — *язучы; «Йолдызлы уйлар», «Яшәү сере», «Өстәгеләрдән дә өстә» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

***

Жигүле ат урман авызына якынлашты. Арбада ир белән хатын. Хатын алда, дилбегә тотып утырган, ә ир кеше, зур мамык мендәргә терәлеп, чәчәкле юрганга төренеп, ярым яткан хәлдә бара. Берсе икенчесенең йөзен күрми. Шуңа да битлекләр салынган — йөзләрдә сүз белән аңлатып булмаслык чарасызлык, моңсулык, күзләрдә газап, сагыш, тагын әллә ниләр...

Өйдән чыкканнан бирле ләм-мим бер сүз дәшмичә барган юлчылар, ниһаять, икесе бертыннан: «Урманга җитәбез», — дип пышылдадылар. Тик шунда ук янә һавада, һавада гына түгел, җаннарда да авыр тынлык, бушлык урнашты. Әлеге, җанны сытып сыгарлык тынлыктан котылу өчендер, мөгаен, кинәт хатын болай да ярыйсы гына тизлектә юртучы атның сыртын талчыбык белән «сыйпап» үтте. Аннары кирәкмәгән, гаепле эш кылганын аңлагандай, ак яулыклы башын түбән иде. Моны күреп торган ир, тирән итеп сулыш алды да, тынлыкны үзенчә җиңәргә омтылып, арба дыңгырдаган җайга үзәк өзгеч моңлы тавыш белән җыр башлады:

Кар-ра гына ур-р-ман, караңгы төн-н,
Яхшы атлар кирәк лә-ә үтәргә-ә-ә...

Җырны шул урында бума ютәл өзде.

— Т-р-рр!

Хатын күз ачып йомганчы арбадан сикереп төште. Ашыга-кабалана, суынмасынга дип мендәр астына тыгып куелган шешәдән чынаякка үлән төнәтмәсе агызып, иргә эчерде. Ир бераз тынычлангач, алъяпкыч кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, иплэп кенә аның ирен читләреннән агып чыккан алсу канны сөртеп алды.

— Нишләвең инде бу? Терелгәч җырларсың әле, Алла теләсә. Ярамый бит сиңа, духтырлар кушмый.

— Духтырларыңны әйтер идем. Башта алар минем зарымны тыңламадылар, дәваламадылар. Инде мин аларны тыңламыйм. Тыңлаудан узган инде монда.

— Алай димә әле син. Әйдә, төренебрәк ят. Һәм, гупчим, оста барда телең тый дия иде минем әби. Ишетәсеңме, кошлар ничек матур сайрый. Урман шавында да әллә нинди серле моң бар. Авылыбызга бер оста җырчы булсаң да, син аларны «едыва» уздырырсың, әтисе.

Бу сүзләрне әйткәндә, хатынның йөзенә, соңгы ярты елда беренче тапкырдыр, саран гына елмаю ятты. Ни хикмәттер, шул елмаю ирнең дә күңеленә шифалы тамчы булып тамды, сызлаган йөрәгенең иң түренә үтеп керде...

Жигүле ат инде урман юлыннан атлый. Арбадагылар бертуктамый сөйләшә, көлешә. Иргә аркасы белән утырган хатынның биленә төшеп торган пар толымы, ул борылып сүз әйткән саен, әле уңга, әле сулга чайкалып, хәтер инешләрен айкый.

— Сал әле шул яулыгыңны, йөз ел сине яланбаш, чәчең тузгыган килеш күргән юк.

— Минем синең алда чәч тузгытып кайчан йөргәнем бар?

— Кияүгә чыкканчы инде.

— Ә?!

— Нурислам абзыйның бөтен урам малайларын шүрләтеп торган «атаман» кызын беренче тапкыр кич тәрәзә пәрдәсе читеннән күрдек лә без. И йөрисең, мин сиңа әйтим, яланаяк идәнгә дөп-дөп басып, сачларыңны иңнәреңә таратып. Ялгышмасам, күлмәкнең дә бик үк озыны түгел иде өстеңдә.

— Аһ, оятсыз! Ордин-медальләреңне елтыратып мине сорарга килгәндә әүвәл бисмилла күргән кебек кыландың бит әле. Белгән булсаммы!

Тагын көлештеләр.

Чыннан да, язмыш сукмакларының кай тарафка борыласын, алда нинди авыр сынаулар көтәсен белгән булса, авылда «урман җене кагылган» дигән аты чыккан ятим егеткә кияүгә барырга ризалык бирер иде микән иркә, төпчек кыз? Юктыр, билләһи, юктыр...

Ә бүген... Бүген анын унөч ел гомер иткән ирен урманы белән хушлашырга алып килүе. Соңгы тапкыр ауга барам дип мылтыгына кадәр янына куйдырды бит. Куян-мазар очрамый калмас дип ике патрон да корды. Күр, арбага утырганнан бирле уң кулын мылтыктан алмый. Песи баласын иркәләгән кебек сыйпаштырып та куя бугай.

— Йә, туктап бераз ял итикме? Аланы да җиләкле күренә, җиләк булмаса, әнә мәтрүшкәсен җыярмын.

— Туктыйк. Мин яраткан алан бу. Чирләгәнче гел шушында утырып тамак ялгый торган идем. Кечкенә кызыма куян күчтәнәчләрен дә нәкъ менә биредә төреп кесәмә сала иеем бит. И-и-и-х!

— Бүген дә күчтәнәч көтеп калды кызыбыз. Куяннары гына күренми. Хәтерендәме, көне буе йөреп тә буш кул белән кайткан чакларында, күрше бабай: «Нәрсә, аучы егет, бу юлы куяннарны агачка бәйләп куймаганнармы әллә?» — дип көлә иде үзеннән. Син шул сүзләргә үпкәли дә иден әле, сакаллы сабый.

Хатын, чыннан да, бүген бик нык ябыгып, гәүдәсе сабый баланыкы кебек җыеләеп калган ирен сак кына арбадан күтәреп диярлек төшерде дә, алдан әзерләп куйган урынга утыртты. Иңнәренә мамык шәл япты. Анын: «Мылтыкны, мылтыкны бир!» — дип өзгәләнүенә бераз аптыраса да, каршы килмәде, кабат арбага үрелде. Тик куллары тимергә тиюгә тәне буйлап нинди дер бер шомлы дерелдәү узуын тоеп гаҗәпләнде...

— Юк, юк! Ашыйсым да, эчәсем дә килми. Бар, син җиләк җый, ә мин урман һавасын сулап утырам. Атны читкәрәк бәйлә, бу килбәтсез арба миңа, кем әйтмешли, бөтен манзараны каплый. Шундый матур хатынны күз уңыннан җибәрәсем килми. Йә урман пәрие урлап китәр үзенне.

Үлемнен җан өшеткеч салкын сулышын якында, инде бик якында тойган ир, балалары «әти битуны» дип йөрткән кып-кызыл мәк чәчкәләре төшерелгән ак эмаль савытны селки-селки, житез адымнар белән алан уртасына атлаучы хатынын сокланып бераз күзәтте дә, күзен йомды.

Йә, Аллам! Мең үлемнән калдырдың бит, мен үлемнән. Сугышның беренче көннәреннән алып соңгы минутларына кадәр мине пуля-снарядлардан саклап, исән-имин туган авылыма кайтардың. Бердәнбер абыйсын да яу кырында югалткан ятимеңне башлы-күзле иттең. Тупырдап торган ике ул, фәрештәдәй кыз бала биреп сөендердең. Бер ел элек һәрбер бүрәнәсен менә шушы кулларым белән юнып, һәр тактасын сыйпап, шомартап, бизәкләп яңа өй җиткездем. Яшәргә дә яшәргә иде бит исәп. Ник мине үтерәсен, Ходаем? Ник бүген? Ник бер утыз-кырык елдан сон түгел? - Ирнең бите буйлап яшь тамчылары тәгәрәде. Аннары ул авырлык белән генә күзен ачты һәм жылы кояш нурларында иркәләнә-иркәләнә мәтрүшкә өзүче хатынын күзәтә башлады. Әйе, хатынның асылын насыйп итте ана язмыш. Чибәр, уңган, булган, сабыр... Ниндидер могҗиза булып терелсәме? Юк инде, юк! Могҗиза булмаячак. Әнә, чарасызлыктан тәмам гаҗиз булган хәләленен Мәскәүгә, Кремльгә хат язып салуына ун көн дигәндә өйдән пырылдатып машина белән килеп алып киткәннәр иде үзен Казан больницасына. Тик бер атнадан ничек алып киткән булсалар, шулай кайтарып та куйдылар. «Соң инде...» дигән сүзләрен үз колаклары белән ишетте ул. Ишетмәскә тиеш булса да, ишетте.

Кинәт ир, сул кулы белән кискен хәрәкәт ясап, күз яшьләрен сыпырып төшерде. Ә уң кулы мылтыкка үрелде. Анын йөзенә усал тәвәккәллек

билгеләре чыккан иде. Мишәр башы белән нишләп җебеп утыра соң әле ул бүген? Өч көн элек барысын да хәл итте бит инде. Мылтыгында ике патрон. Хатыны һәм үзе өчен. Ә балалар? Балаларны ил ташламас, үсәрләр. Ә хатынын ул читләргә ташлап китә алмый, теләми дә. Бергә үләчәкләр, нәкъ менә шушы аланда... Ир корылган мылтыкны күкрәгенә кысты, көпшәсен аланга таба юнәлтте. Шул чакны, нидер сизенгәндәй, яшь хатын бар гәүдәсе белән ире утырган якка борылды һәм елмаеп аңа карап тора башлады. Бил тиңентен үскән чәчәк-үләннәр арасыннан ул мылтык көпшәсен күрмәде. Шартлап кан чыкканчы иреннәрен тешләгән ирнең шашынган күзләре: «Карама, зинһар, миңа, артың белән борыл, борыл!» — дип кычкырдылар. Ул саташыр дәрәҗәгә җитте...

Нәрсә, иптәш сержант, кыенмы газиз кешеңнең йөзенә туп-туры карап йөрәгенә атулары, ә? Аркасы белән борылганын көтәсеңме? Хәтерлисеңме икән сугышның беренче елында немец разведчикларына әсирлеккә төшүеңне. Озак кына сорау алгач, бер олырак солдатның сине атарга алып баруын оныттадыңмы? «Йөгер! Йөгер!» — дип ымлагач, йөгереп китүең исеңдәме? Һәр адымың соңгысы булып тоелган иде бит. Һәр мизгел мәңгелек булып тоелган иде. Тик ул чакта фашист булып фашист син малакасуснының аркасына түгел, читкә, куаклыкка атып калды. Язмыш үзеңне кызганды. Кайтып бәхет тәмен татысын, оя корсын, балалар тудырсын диде. Ә син?! Ә син бүген Ходай бүләге өч баланың анасын вәхшиләрчә атып үтерергә җыенасыңмы? Яңа гына дөньяга аяк баскан газизләреңне тома ятим калдырырга телисеңме?

Ир, үзен-үзе белештерми, терәлеп утырган агачка башын бәрә-бәрә, ярсып кабатларга тотынды:

— Юк! Юк! Юк! Бу мөмкин түгел! Кичер, Аллам! Кичер мин диванаңны. Кичерә күр!

Ире белән нидер булганын аңлаган хатын кулыннан җиләкле савытын төшереп җибәрде. Шул арада, урман һавасын ярып, бер-бер артлы ике ату тавышы яңгырады...

— Ходаем, нәрсә булды? Хәлең начарайдымы әллә? Кай җирең авырта?

Дары төтене эчендә утырган ир:

— Нәрсә булсын, куяннарны бәйләмәгәнсең бит. Качтылар әнә, — диде дә, хәлсез генә елмаеп куйды.

## Мичче кызы

Сәвиянең әнисе мичче. Җәйгә керүгә, дөресрәге, май аеннан ук, иртәдән кичкә кадәр өй борынча йөреп мич чыгару, морҗалар төзәтү белән мәшгуль ул. Билгеле инде, куелган чират, сөйләшенгән бәя буенча. Сәвия белә, бер мич чыгару унбиш тәңкә тора, ә абыйсына былтыр җәй сатып алынган лисәпид өчен әнисе нәп-нәкъ дүрт мич бәясе, ягъни алтмыш сум түләгән. Әлеге лисәйнең күпме торганлыгын йоклаганда да аякларын пидәл әйләндергән кебек селкетеп ятучы абыйсы Шамил, Сәвия һәм аларның энекәшләре Фәнис кенә түгел, ә абыйсының иптәш малайлары да, күрше-күлән дә көненә берничә тапкыр ишетә булыр. Әниләре Мәрьям кычкырыбрак сөйләшә шул. «Ир дә, хатын да — үзем. Кычкырсам да, сүгенсәм дә гөнаһ түгел», — дип кенә aклана ул бөтенләй үк кызып киткән чакларында. Ни генә булмасын, Сәвия өчен әнисеннән дә матур, әнисеннән дә яхшы кеше юк бу дөньяда. Шуна да кичтән анын «струментлар» салынган иске кара күн сумкасын барлавын күрсә, йөрәге өзелеп төшәрдәй була кызның. Иртәгәсен тагын адашкан бәбкә төсле ялгызлары ишек алдында, капка төпләрендә, йә булмаса янбакчада каңгырып йөриселәре бар икән. Абыйлары болында, йә кырда чакта өй ишеге дә йозакка бикләнә бит әле. Игезәкләрдәй охшаш, борын аслары каралып беткән сипкелле йөзле

балаларының мунча идәненә аякларын бөкләп утырып бакалар сайрашкан көйгә көненә ике мәртәбә ипи белән сөт кенә ашап торуларын белә дә соң әниләре. Барыбер сары балчыгы мәңге юылып бетмәс «мастирогын», кечкенә балтасын, шомарткыч тактасын алып, чакырган җиргә китеп бара шул. Җәй тиз үтә, кыш чыгарлык акча юнәтәсе бар, ди. Их, әтиләре исән булсамы!

Хәер, күрше Әсма, Сажидә апаларның да көндез өйдә торганнары юк. Ярый әле әниләрнең кайсын кырдан, кайсын урманнан, ә Сәвиянең әнисен һаман да шул балчык-кирпеч арасыннан өйгә ашыктыручы «көтү кайта» дигән тылсымлы сүз бар. Манькаларны, Зурькаларны савасы булмаса, яз туган Күбәләк, Йолдызлар су кушылган җылы сөт сорамаса, билләһи, җәй буе балалар аналарын бер күрергә тилмерер иде...

Куе кара чәчле түм-түгәрәк нәни башына төшкән менә шундый уйлардан оеп утырган кызчык кинәт дерт итеп китте:

— Сәвия-ү-ү! Ач капканы!

Мал-туарларының авылга кергәч тә исән-имин абзарга ябылуы өчен җаваплы абыйсы Шамил тавышы бу. Хәзер ана сыерлары да кушылачак:

— Му-у-у-у!

Сәвия абына-сөртенә йөгереп урыс капкага барып ябышты. Капканы ачып җибәрүе булды, әнисе мичтән чуенлы бәрәңге ала торган «ухбат»тан да зуррак мөгезле сыерлары килеп керде. Аның артыннан тузанлы мамык кисәкләрен хәтерләтеп сарык-бәрәннәр атылды. Иң соныннан инде авызы ерылган, әнисе әйтмешли, «Берлинны алган кыяфәттә» Шамил абыйсы күренде. Ул Берлинны алуы ни буладыр, күрше Сәлим абый да хатыны Сания апаны капка төпләрендә шулай җырлап каршы алганын еш ишетә кыз:

Саниякәй эштән кайта
Берлинны алган кебек.
Сәлим мескен каршы ала
Плинга калган кебек...

Тик Сәвиянең бер дә «плинга калып» өйдә утырасы килми әле монда. Аның үзе генә белгән сере, үз «эше» бар җәйге кояш баешының бу сихри мәлендә. Кызый еш кына, әнисе болыннан ияреп кайткан кигәвеннәрне куа-каргый сыер саварга керешкәч тә, аягына иске чүеген элэктерә дә, чиләккә чаж да чож төшкән сөт тавышын тыңлый-тыңлый, тыкрыктан ындыр артына йөгерә. Бүген дә нәкъ шулай булды. Сөт тавышы ишетелми башлагач, Сәвия кулындагы кыска таяк белән коймага сугып үзе көй чыгарып барырга тотынды. Кызык бит... Тык-тек, тык-тек, тек-тек-тек... Койма ярыгыннан үрелеп аны гаҗәпләнеп күзәткән кояш нурлары белән качышлы да уйнап маташты әле ул. Тик алардан качып буламы соң! Тыкрык бетеп ачык урынга килеп чыгуы булды, алсу нурлар аны: «Элэктеңме, шук кызый!» — дип кочып ук алдылар. Сәвия нур яңгыры астында чирәм уртлаган, бөтен ындыр артын тутырып таралган сарыклар янына килде. Аннан: «Ник өйләрегезгә кайтмыйсыз, хужаларыгыз көтәдер сезне, вәчкәйләр» — дип әбиләрчә такмаклый-такмаклый көтү арасыннан яшь бәрәннәрне эзләргә керешге. Кыз белә, гадәттә алар адашып, әниләреннән аеры елап, бәэлдәп йөриләр, башсызлар. Менә, әйтте бит, күр инде: берсе ап-ак, икенчесе аклы-каралы, шундый матурлар, бөдрәләр үзләре! Кычкыра-кычкыра тавышлары карлыгып беткән мескенкәйләрне Сәвия кулы белән этә-төртә көтү таралган ындыр буйлап куалап китте. Ә очлы күзләре чирәм ашау кайгысы булмаган ялгыз әни сарыкны эзләде. Ул каядыр шунда гына булырга тиеш, шунда гына. Нинди әни, балаларын ташлап, тыныч кына абзарга кайтып печән күшәсен ди. Менә хәзер килеп чыгачак сарык, менә хәзер... Кыз ялгышмады. Кинәт бер «вәчкәй» бәрәннәргә таба ыргылды. Ул да булмады, бәләкәчләр дә әниләрен танып алдылар. Һәм икесе ике яктан

йөгереп килеп койрыкларын пропеллер кебек зыр-зыр әйләндерә-әйләндерә сарыкны имә башладылар. Сәвиянең йөзен елмаю балкытты. Булды бүгенгә! Ул олыларча шалт-шолт кулын кулга суккалап куйды. Әни белән бала аерылмаска тиеш, шулай гына рәхәт. Әтиләре булса, Сәвиянең әнисе дә гел өйдә торыр: көненә әллә ничә тапкыр тәмле аш пешерер, янбакчада матур чәчәкләр үстерер иде. Акча дигәнен әтисе апкайтыр иде әле... Һич югы, бер генә тапкыр әниләре энекәше белән икесен үзе белән алып барсын икән дә бит. Юк шу-у-л... Сәвия башын иеп монсу гына тыкрыктан өйләренә таба атлады. Кулындагы таякчыгы кайдадыр төшеп калган, коймага сугып көй чыгару уе да эреп дигәндәй юкка чыккан иде кызның.

Могҗиза димә, шул кичне йокларга ятканда әниләре иртәгәсен Түбән урамда яшәүче Рәсыйх абзыйларга Сәвия белән Фәнисне дә ияртеп төшәргә вәгъдә бирде. Үзе:

— Иртәгә безнең урам буйлап чегәннәр жырлап-биеп, канцирт куеп йөриячәкләр икән. Бәлки, абыегыз белән өйдә генә калырсыз? Күрше Рәшидә әбиегез дә хәл белергә керермен дигән иде, — дип сөйләнде. Тик кая ул әнисенең хәйләкәр карашын күрү дә, соңгы әйтелгән сүзләрне ишетү! Бу минутта балаларны тәмам бәхет баскан иде.

Сәвия ничек елмаеп йоклап киткән булса, иртән шулай елмаеп уянды да шикелле... Ә инде менә төш житкәндә кызның йөзенә «ник тудым?» кыяфәте чыккан иде. И-и-и, бер генә дә күнелле түгел икән бит әнисенең эшендә. Сәвия белән Фәнис күргән бөтен игътибар — иртән Рәсыйх абзый хатыны Рәсимә апаның ашыгып алар учына салган икешәр эшләпә кәнфит белән берәр прәннек булды. Аннан китте ыгы-зыгы: кирпеч ташу, измә изү, ком иләү. Юлда тормагыз, имгәнерсез, әниегезне аптыратмагыз — балаларның олылардан ишеткән сүзләре әнә шуннан артмады.

— Мәрьям апа, авырдыр инде сиңа бу балалар белән, авырдыр, — дип башын чайкады арадан берсе.

Әнисе дә, Сәвияне гажәпкә калдырып:

— Сөйләмә дә генә инде, күршекәем, бик авыр. Үзем генә беләм, — дип куйгач, кыз түзмәде:

— Әни, ник авыр дип торасың, син бит безне күтәрмисең, яныңнан үзебез йөрибез! — дип әйтеп салды. Китте көлеш... Берни аңламаган кыз үпкәләп читкәрәк китеп утын түмәркәсенә барып утырды. Ул чын-чынлап капка төпләрен, өйләрен сагынды. Югыйсә әнә йортлары матур булып әллә каян күренеп тора, тыкрыктан гына менәсе дә унга борылып керәсе. Ялгызларына гына кайтырга әниләренең рөхсәте юк шул. Чү! Жыр-гармун тавышлары да ишетелә түгелме? Әллә чыннан да чегәннәр килгән инде? Их, ник кенә әнисенә иярделәр алар? Алтынсу комнан гараж ясап, трактор тимерен машина итеп тыныч кына уйнап утырган Фәнискә дә ачуы гына чыкты кызның. Ул сикереп торды да рәшәткәле капкасы ярым ачык калган бакчага кереп китте.

У-у-у, монда матур икән! Кыз түтәлдә тирбәлгән чәчәкләргә аһ итте. Эскәмиягә чыгарып тезелгән чүлмәкләрдәге купшы яраннар да искитмәле иде. Сәвия шулчак сулы зур тагарак янындагы яшел «ләйкә»не күреп алды. Әһә, кызга да эш булырга тора әле бирелә. Тагарак кояшта көмешләнеп ялтырап яткан жылымса су белән туп-тулы. Кырында чүмеч тә бар. Менә шулай... Кызның батырып су алырга жыенган чүмечле кулы һавада эленеп калды. Күр, су өстендә берничә бөҗәк тыпырчынып ята түгелме? И бичаралар! Әчәселәре килеп батканнар инде болар. Сәвия тиз генә үлән кыягы өзеп алды да бөҗәкләрне коткару «операция» сенә керешә. Менә берсе корыга чыгарылды, аннан икенчесе, өченчесе. Беренчесе шундук очып та китте! Кызның күнелен шатлык биләп алды. Ул үзен бик тә кирәкле, яхшы эш эшләгән кебек хис итте. Инде «ләйкә»гә су тутырырга да була. Кинәт койма буендагы зур булмаган агач ко-

рылмаданниндидер тавыш ишетелгәндәй булды. Сәвия сак кына атлап шунда юнәлде. Бу корылма-читлекнең кояшка карап торган ягында әлүмин рәшәткә генә икән. Кыз якынрак килде һәм эчтә ап-ак куян күреп өнсез калды. Аның тере куянны беренче күрүе иде. Озын колакларын артка салып кызыл күзләре белән Сәвиягә карап утыручы бу җәнлек китап битеннән сикереп төшкәндер кебек тоелды. Кичә абыйсы укыган китаптан инде.

Куян, син кайда?

Яшел тугайда...

Түгел шул, тугайда түгел, Рәсыйх абзыйларның бакчасында булып чыкты куянкай. Сәвияне тәмам бәхет басты. Ул ак йомгактан күзен ала алмады. Аның һәр хәрәкәтен: оясының бер почмагыннан икенче почмагына күчеп йөрүен, әле кәбестә яфрагын, әле кишер сабагын иснәп карауларын рәхәтләнеп, дөньясын онытып күзәтте...

— Хайт, кызыйны!

Сәвия көтелмәгән тавыштан сикереп куйды.

— Курыкма, әнә куян курыксын. Син бит куян түгел, аучы кызы.

Кып-кызыл йөзенә елмайган кыяфәт чыгарырга тырышкан бу абзыйны Сәвиянең кайдадыр күргәне булса да, аның кем икәнен тәгаен исенә төшерә алмады.

— Аучы кызы түгел мин, мичче Мәрьям кызы!

Күзләре төсен кояш алгандай тоныкланып калган абзый сүзен дәвам итте.

— Әйе, әниең мичче, ә менә әтиең тирә-якка бер аучы иде. И-и аның атып алган үрдәкләренең, мин сиңа әйтим, санын бер Ходай үзе генә беләдер. Яхшы кеше иде атаң. Моңлы итеп җырлый иде, патамушты ятим бала булып үскән. Ә әниең усал, командир!

— Усал түгел минем әни!

Сәвия нишләргә белмәде. Каян килеп чыкты соң әле бу абзый? Әллә ниләр сөйләнә, кырынмаган, ямьсез.

— Яңа гына мине бөтен күршеләр алдында рисвай итте анаң. Ялкау имгәк, исерек түмгәк, имеш. Кыска буйлы булуыма мин гаепләме? Төтен юлын дөрес калдырмыйсың, астарак булган, кеше биеклегендә кирәк иде дигән идем, менә шулай изүемнән эләктереп алды да мич янына китереп тә бастырды. Син үзеңне кешегә чутламыйсыңмы әллә, синең буе бит, күр дип миннән кычкырып көлә дә башлады. Кинәш итәргә дә ярамаган. Бөтен күршеләр алдында рисвай итте. Сез ятимнәрне дә кагып-сугып үстерәдер әле. Кыйныймы әниегез дим?

Кыз абзый сөйләгәннәрдән соңгы ике сүзне генә аңлады.

— Кыйнамый! Ул усал түгел, матур күлмәкләр тегә, тәмле бавырсак пешерә!

— Ник балага бәйләнәсең, Гали?

Ашка турар өчен суган кыягы өзәргә дип бакчага чыгып килүче хуҗа хатын Рәсимәнең тавышы кырыс яңгырады.

— Нинди бәйләнү ди, күрше. Гәпләшәбез әле менә сенелкәш белән. Күз карашлары да сурьезный, сөйләшүләре дә гел олыларча бу баланың.

— Синдә генә ул бала акылы да юк. Бераз гына Рәсыйхка булышыр идең, ичмасам, измә изеп куллары талды әнә.

— Юк инде. Беренчедән, миңа авыр эш эшләргә ярамый, духтыр кушмый, икенчедән, телчән Мәрьямегезне киламитрдан әйләнеп узачакмын дип яңа гына үземә сүз бирдем.

Рәсимә апа куян читлеге янына килде дә кинәт Галигә борылып:

— Куян бәлеше ашамыйм дип тә сүз бирмәгәнсеңдер бит?

Гали сап-сары тешләрен күрсәтеп ыржайды.

— Шту син? Ахмак мәллә мин!

— Алайса, хәзер үк менә бу куянны суеп туна. Кичке ашка бәлеш булыр, Алла боерса.

Рәсимә Сәвиянең зур итеп ачылган күзләренә карап, аклангандай:

— Ялгызы гына бит. Балаларның да исләре китми хәзер, ашатырга-эчертергә дә оныталар. Баштагы мәлне генә көне буе янында бөтерелделәр, — дип өстәде дә, Сәвияне чәйгә чакырып, ашыгып бакчадан чыгып китте.

Гали канәгатьлек белән кулларын уды.

— Бер тавык та бер савыт дигәндәй, бәлеш янына ак башы да булыр кебек әле монда, мичче кызы! Хәзер үткен пычагымны гына алып киләм дә, кых-х-х куянны, — дип муенына сызып күрсәтте дә юк булды.

Сәвиянең йөзе коймa буенда үскән ромашка тажыдай агарып чыкты. Нишләргә? Куянны ничек коткарырга?! Ул озак уйлап тормый агач боргычны борып читлек ишеген ачты да:

— Кил тизрәк. Тырмашма, — дип, куянны колакларыннан эләктереп алды. Ни гаҗәп, куян бераз тыпырчынгач, кызның кочагында тынычлангандай булды. Сәвия аркылы-торкылы киртәләр белән генә бүленгән бәрәңге бакчасына таба китте. Җайлы гына итеп ике киртә арасыннан шуып чыккан кыз, шау чәчәк атып утырган бәрәңге сабакларын ерып, йөгерергә үк тотынды. Бакча уртасына җиткәчрәк, буразнага сузылып ятты, үзе бертуктамый куянны сыйпады. Дөп-дөп-дөп... типте куянкайның йөрәге. Кызның йөрәге дә аныкыннан калышмады. Шулчак Сәвия борын төбендә генә селкенгән яфракта ял итеп утыручы камканы күреп алды: «Камка тутай, ирең килә камчы белән кыйнарга. Оч та кит!» Шул сүзләрне генә көткән кебек, кызыллы-каралы япма ябынган бөҗәк очып та китте. Их, минем дә канатларым булса, дип уйлады кыз. Минут эчендә үзебезнең ишек алдына очып төшәр идем. Куян белән өйгә кереп бикләнер идек. Әни кайтканчы ишекне беркемгә дә ачмас идек...

Калганы куркыныч төштәге кебек кенә булды. Олы йонлач куллар Сәвиядән куянны тартып алдылар. Кәкре симез аяклар бәрәңге чәчәкләрен таптый-таптый алпан-тилпән абзарга таба атлады. Буразнага ятып үксегән, аклы күлмәге кара балчыкка буялып беткән кызның кайнар чишмә булып аккан күз яшьләрен күрмәс өчен кояш болыт артына йөзен яшерде дә әкрен генә офыкка таба тәгәрәде. Сабыйны әле чәчләреннән сыйпап, әле кулларыннан үбеп юатырга теләгән җәйге йомшак җил дә арып-талып янәшә ятып йоклап китте...

— Кызым, син кайда-а-у?..

— Сәвия-ү-ү!

— Син кайда-а-а?

— Яшел тугайда, — дип елмайды Сәвия йокы аралаш, әнисенең җылы кочагында тирбәлә-тирбәлә.

— Куянкаем, йомшак күңелкәем, — дип уфтанды ана. — Бу каты бәгырьле дөньяда ничекләр яшәрсең икән син?!

## Өстәгеләрдән дә өстә

— Бахх! Ба-бах! Тук-тук!

— Йә, Ходаем, йоклап кына китәм дигәндә! Нишләтергә инде бу өстәгеләрне?

Зөләйха күзен ачты. Өстәлдәге сәгатьнең янып торган саннары: «Әһә, сиңа да йокы юкмени?» — дигәндәй, хатынны үртәп биешеп алдылар да төнге берне күрсәтеп, тынып калдылар.

Икенче катка яна күршеләр килеп урнашканнан бирле Зөләйхалар фатирында тынычлык бетте. Көндез дә тавыш, төнлә дә. Ә ял көннәрендә әйтерсең лә шайтан туе котыра. Өч баласы булган әлеге урыс гаиләсе белән ире дә сөйләшеп карады, Зөләйха үзе дә берничә кат оялтып төште, барыбер файдасы тимәде. Валлаһи, тормыш түгел бу, тәмуг! Утыр инде менә хәзер

төн убыры булып, ни йокы, ни ял күрми, чирек гасыр тир түгеп алган таш читлектә. Их, авыл өендә яшәсән икән лә ул! Шушы теләк-хыялы хатынның йокысызлыктан кызарган күзләрен мөлдерәмә яшь белән тутырды...

Авыл өе дигәндә, Зөләйха, билгеле инде, иң әүвәл Дим авылындагы газиз әбисенең йортын күз алдына китерде. Нарат бүрәнәләрдән генә өелгән, шуна да хуш исле һавасын сулап туймаслык өйдә үтте энесе Фәнис белән Зөләйханың балачак, үсмер еллары. Ул өйнен буяу ише әйбер белән бөтенләй таныш булмаган киң идән такталарына һәрвакыт куллан тукылган буй-буй җаймәләр җәелгән булыр иде. Ишекләренә, мич аралыкларына аллы-гөлле чаршау-кашагалар эленгән, тәрәзләрен, җәен-кышын шау чәчәктә утыручы яраннарны күз тимәслек кенә итеп бераз каплап торучы ап-ак челтәр-пәрдәләр бизәр. Ә инде өйнен иң асыл, иң затлы бизәге булып, әле түр якта, әле олы мич тирәсендә мәш килеп, бәләкәй генә гәүдәле, йомшак күңелле, эшсез торуның ни икәнен дә белмәс Рәйсә әбиләре йөрер. Күршеләре әйтмешли, Рәйсәттәй.

Бирсә дә бирер икән Ходай адәм баласына сабырлыкны! Авылда әбиләренең фәрештәдәй холкына сокланмаган, аны ихтирам итмәгән кеше булмагандыр, мөгаен. Менә шушы һичбервакыт гайбәт сөйләмәс, сүз белән түгел, карашы белән дә кеше рәнҗетмәс әбиләре көтмәгәндә нык кына авырып китте. Аллаһының рәхмәте белән, терелеп, аякка басты-басуын, тик ялгызы гына булганда, кемнәрнедер бик каты ачуланып сүгә торганга әйләнде.

— Әшәке җаннар! Кайчан безне тынычлыкта калдырырсыз икән? Яшәргә ирек бирмисез!

Бу әле әбисенең билгесез затларга яудырган каһәрләүләренең йөздән бер өлеше генә иде.

Кайчагында әбисе сизмәгәндә мәктәптән кайтып кергән Зөләйханың, аптырап:

— Әй, әби, кемнәрне генә шулай ачуланасың соң син? — дигән соравына Рәйсәттәй, тыныч кына:

— Кемнәрне булсын, өстәгеләрне инде, — дип җаваплый килде. Ул чакта кыз: «Самолетта очучыларны әйтәсеңме, әллә вертолеттагыларынмы? Бәлки әле чит планетадан килүчеләрнедер? — дип көлгән булса, бүген ул, күпме гомер узгач, гади авыл карчыгының әлеге сүзләрендә тирән мәгънә ятуына төшенгәндәй булды...

Өстәгеләр, өстәгеләр... Уйлары Зөләйхага һич тынгылык бирмәде. Алар аны тагы да ераккка, сабый чагына ук алып киттеләр. Хатын аларга иярмәскә теләп ничек кенә карышса да, барып чыкмады. Зөләйха аңлады: иртән эшкә керфек тә какмаган килеш барачак...

Аның күз алдына ерак Урал таулары, ел әйләнәсенә сөрем эчендә утыручы туган шәһәре Түбән Тагил килеп басты.

Түбән Тагилда да алар үз өйләре белән яшәделәр. И-и ул яна өйнең биеклеге, иркенлеге! Әллә биш яшьлек Зөләйхага гына шулай тоелды микән? Сары чәчәкле аланны хәтерләткән идәндә энесе Фәнис белән колыннар кебек уйнаклап, кояш куяннары белән куышып йөгергәннәре әле дә исендә. Бигрәкләр дә нурлы иде, якты иде ул чакта дөнья! Балачак күгендә әниләре кояш, әтиләре ай булып балкыгангадыр. Шулайдыр. Зөләйха ирексездән:

Кояш, кояш, мәңге балкый,
Мәңге нур сибә... –

дип көйләде. Аннан, кычкырып елап җибәрмәс өчен, юрган почмагын тешләде дә күзен йомды...

***

— Иртәгә тимер юл вокзалына төшеп, Мәскәү поездына билет алып кайтасы булыр. Тәвәккәлләп, атна көн юлга чыгарбыз дип торам. Тирекүн эше әйберләр дә берничә тун тегәрлек кенә калып бара, башкала татарларының ушын ала торган казылыкның да самый өлгергән чагы. Күрше хаклы, безнең чормадан килгән тәмле ит исе бөтен Тагил мәчесенең йокысын качырды инде. Шулаймы, кызым? Кем әйтмешли, сатасын сатарбыз, аласын алырбыз, исән булсак.

Бу — әтисенең тавышы. Кулындагы ялык-йолык килеп торган зур кайчы тирегә акбур белән сызылган эзләр буйлап йөгерә. Өлгергән арыш төсендәге чәч-кашлары арасыннан күк чәчәк төсендәге шаян күзләр елмая.

— Ярый соң, мин риза. Ходайга тапшырырбыз. Балаларны, гелдәгечә, Сания апа карап торыр.

Тавышның монысы, бәрхеттәй йомшак, ягымлы-назлысы, тегү машинасы артында утыручы әнисенеке. Келтер-келтер, келтер-келтер...

— Бүген мунча ягып кертәсе иттем әле үзегезне. Суын ташып, кабызып та жибәрдем инде!

Әлеге чатнап торган тавыш иясе — ишектән суык һава белән житәкләшеп килеп кергән, алардан берничә йорт аша гына яшәүче Сания апалары бугай. Әйе, нәкъ үзе. Чү! Иреннәре бертуктаусыз елмая, ә күзләре никтер усал карый. Карашы гел тычкан аулаган мәченеке шикелле, өйнең бер почмагыннан икенчесенә йөгерә.

— Әй, апа, нишләвең инде бу? Иске авыздан яңа сүз дигәндәй. Өченче көн генә мунча юындык түгелме? Көннәр бик салкын тора бит, балаларны чирләтербез йә. Иркенләп, тәмләп җизни белән икәү парланырсыз инде бүген. Мәтрүшкәле себерке — бездән. Хәзер чормадан алып төшәм.

— Ә мин коймак пешереп торырмын. Мунчадан туры монда кайтырсыз, баллап чәй эчәрбез.

— Юк, юк! Сезнең өчен генә дип яктым. Үпкәлим, мәгәр, бармасагыз! Туган итмисез, димәк...

Йөрәген тырмый-тырмый сүтелгән хәтер йомгагының җебе шул турыга житкәч, Зөләйха, кисәк кенә, үзен-үзе белештерми, өстеннән мамык юрганын алып атты һәм караватына торып утырды. Әйтерсең лә, моннан кырык биш ел элек түгел, ә нәкъ менә бүген, хәзер аларның язмышлары, киләчәге хәл ителәчәк иде. Ул мизгел эчендә, теге ерак кыштагы шикелле, әнисенә елышып еламсыраган кызчыкка әйләнде дә:

— Әнием, бармыйк мунчага, минем инде йокым килә. Әнә Фәнис тә күзен уып утыра. Бармыйк, әнием, яме? — дип такмакларга тотынды.

— Бармыйк мунчага, бармыйк, әнием! Тыңлама Сания апаны. Тыңлама әтине...

Шулчак чиксез дулкынланган хатынның колагына әтисенең ягымлы тавышы ишетелеп киткәндәй булды:

— Апаның хәтерен калдырмыйк инде, кызым. Әниең белән тиз генә юынып кайтыйк. Ә сез энекәшең белән икәүләп тәрәзәдән карап безне көтеп торыгыз, яме?

Зөләйха шул тавышка буйсынып, ни сәбәпледер кечтән бүлмә уртасында торып калган урындыкка абына-сөртенә, тәрәзә каршысына ашыкты. Урамда бүген дә, ул чактагыдай, ап-ак кыш, күбәләктәй кар бөтерелә иде...

Балалар елый-елый шешенеп беткән йөзләрен бозлы тәрәзәгә терәп, мунча сукмагыннан күзләрен алмыйча, әтисе белән әнисенең кайтуын озак көтте. Тик ул төнне өйнең бусагасын күрше әбине иярткән Сания апалары гына атлап керде. Һәм нәкъ менә шушы әбекәйдән сабыйлар иң беренче тапкыр, моңарчы ишетмәгән, ул минутта аңламаган да, ләкин инде моннан

соң аларны гомер буе озата барачак «ятимнәр» сүзен ишеттеләр... Өстенә бик тә авыр йөк алган бичара карчык, яшьле күзләрен Зөләйха белән Фәнистән яшерергә тырышып, башларыннан сыйпый-сыйпый аларны юатканда, йокларга үгетләгәндә Сания апалары, әтисенең бертуган апасы, ни гаҗәп, өйнең астын-өскә китереп нидер эзләвен генә белде. Тапты да бугай, анын куенына төенчекләр кыстырып, әледән-әле урам якка чыгып йөгергәне шәйләнде. Зәңгәр ишек, сулкылдаган тавыш чыгарып, һәр ачылып ябылган саен ике пар нәни күздә дә өмет чаткысы кабынып сүнгәнен күрдеме икән соң ул? Юк, күрмәгәндер. Аның-җанын томалаган комсызлык, чит байлыктан көнләшү аны дөм сукыр иткән, тәмам таш бәгырьгә әйләндергән төн иде бу...

— Бах! Ба-бахх!

— Йә, Ходаем! Йоклап кына киткәннәр иде, бәгырькәйләр.

Чормадан килгән тавышка сискәнеп уянган Фәнис, аннан инде Зөләйха да, кычкырып елап, кабат әниләрен чакыра башладылар. Бу хәлләргә йөрәге әрнүдән гаҗиз булган күрше әби, өзгәләнеп, яшь катыш нәфрәт тулы күзләрен түшәмгә төбәде:

— Имансызлар! Гөнаһысын кая куярсыз икән?

Өстәге дөбердәү таңга кадәр тынмады...

Зөләйха, ул кара төнне энесе белән икесенең котын алган, куркудан куырылырга мәҗбүр иткән әлеге тавышларның, мунчада ис тиюдән үлеп яткан әти-әнисенең хәләл малын бүлешүче, дөресрәге, урлап ташучы ерткыч туганнарының аяк тавышлары булуын еллар узгач кына белде. Белде һәм мәңге кичермәячәген аңлады. Аның йөрәгендә, канлы таш-төер булып, чиксез рәнҗү, аяусыз язмышка үпкә торып калды. Әлеге төерне, меңнәрчә чакрым юл үтеп, үксез онықларын татар иленә алып кайткан һәм хәленнән килгәнчә тәрбияләгән Рәйсә әбисенең йомшак сүз-гамәлләре дә, газиз әнисенең сеңлесе, ана ике тамчы судай охшаш Мәүлия апасының якты йөзе, назы да, башка туганнарының, күршеләр, авылдашларының искиткеч яхшы мөнәсәбәте дә эретә алмады...

— Зен-н-н!

Зөләйха дерт итеп китте. Кыңгырау шалтырый! Аның башыннан яшен тизлегендә: «Кем булыр бу? Ире төнге сменада, кызы Гүзәл күптән үз бүлмәсендә йоклап ята», — дигән уй үтте. Ул сак кына басып ишеккә якынайды һәм шалтырауның кабатланганын көтеп, тынып калды. Тик тавыш башка кабатланмады. «Әллә саташам инде? Шайтан эшедер бу. Тьфу, тьфу, тьфу!« Шулчак Зөләйха мәрхүмә әбисенең дога китабын байтактан кулына алмавын искәрде. Хәер, ул андагы догаларның күбесен яттан белә бит.

Хатын иплән кенә, инде сап-салкын булып беткән, урын-җиргә барып ятты. Күзен йомды. Керфек очларына эленеп калган, шулай ук суынырга өлгергән яшь тамчылары йөзе буйлап тәгәрәде: «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әлхәмдү лилләһи раббил гәләмин. Әррахмәнир-рахим...» Зөләйханың моңлы, аһәңле тавышы фатир эчендә генә сыешмыйча, бөтен урамга, алай гына да түгел, бөтен җиһанга таралды, күкләргә ашты. Шуның белән бергә яралы, таш-төерле күңеле, барча галәмне тәрбия кылучы, яшәтүче, бөтен өстәгеләрдән дә өстә һәм өстен булган, рәхимле вә изгелекле Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән, бушый, иркенәя, сафлана барды... Озакламый ул тирән йокыга талды. Эшкә уяныгра нәкъ бер сәгать вакыт бар иде.



Илдус
Гыйләҗев

# ҖАНЫМ ИРЕК, ХӨРЛЕК ТЕЛИ

## Калмам хурлыкка!

**Милләтчеме, чи татармы,**
**Киребеткән мокытмы? —**
**Чәйнәсеннәр... үз телемдә**
**Сөйләшәм мин тотлыкмый!**
**Сүз белән сүз арасында**
**Тукталыш юк диярлек.**
**Бай безнең тел, еллар буе**
**Берөзлексез сөйләрлек!**
**Фикер йөртәм, яза алам**
**Ят сүзләрне кыстырмый.**
**Телем бетә, югала дип**
**Каравыл да кычкырмыйм.**
**Яшәсен ул! Тел билгеле**
**һәр милләтнең зурлыгын.**
**Ил югалту — коллык булса,**
**Тел югалту — хурлыгың!**

## Укый гына күрсеннәр...

**«Тәнкыйть кәнфит түгел», — диеп**
**Йөргән чаклар бар иде.**
**Ярты гәҗит-журнал тулы**
**Әйткәләшү, зар иде.**
**Социалистик реализм**
**Иң алдынгы фән, имеш.**
**Язганнарың шул таләпкә**
**Тәңгәл килергә тиеш.**
**Буйсынмасаң, әсәреңә**
**Сугылды кара мөһер.**
**Бүген андый этлек белән**
**Шөгыльләнмиләр, шөкер.**

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) — *шагыйрь; «Җир китабы», «Мәгарә», «Кадерле китап» һ.б. шигырь китаплары авторы. ТР Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Азнакай районында яши.*

Күпме «даһи» эшсез калды,
Булмагач үрнәк–калып.
Дөрес мактый, дөрес сүгә,
Иң шәп хөкемдар — халык!

## Кыйбласын табалмагач

Аркылыга такта салып,
Урал тавы сыртына.
Атынасы килеп китә
Охшап Рәсәй холкына.
Аның да бит сәясәте,
Таган төсле, чайкалыш.
Йә көнбатыш, йә көнчыгыш,
Тудым–судым чайпалыш.

## Кояшлар хакында

Синсез язлар миңа нигә кирәк?
Үлән шыта, ә мин корышам.
Никләр мәшәкатьләнә бу Кояш,
Җылытырга нигә тырыша?
Җан өшеткеч котып салкыннары
Йөри ала икән күченеп.
Бөтен вөҗүдемне боз ясады,
Җылым качты, яшим күшегеп.
Тышкы кояшсыз да яшәп булмый,
Аңлыйм ла мин аның кадерен.
...Бергә чакта белеп яшә икән,
Эчке кояшыңның кадерен...

## Язмышыбыз чагылышы

*Муса Җәлил шигырьләре алтмыш*
*җиде телгә тәрҗемә ителгән.*
Матбугат хәбәрләреннән.

Алтмыш җиде күпмени ул?
Тынычландырмый бу сан.
Меңнән артып китәр иде
Бүтән милләттән булса.
Без дөньяга чыгабыз шул
Ике тәрҗемә аша.
Турыдын–туры булмагач,
Телнең бит тәме кача.
Андый шагыйрь табалмассың,
Тарихны сүтеп җыйсаң.
Татарның йөз аклыгы ул,
Үрнәк ал, укы, җиһан!

## Үскәндә табалмасаң...

Рөхсәт бирче әле миңа,
Күкрәгеңә башым салыйм.
Бер мизгелдә онытылып
Сабый бала булып алыйм.

**Мөмкинлек бир әле миңа,**
**Йөрәк тибешеңне тойыйм.**
**Җылы куен уртасында**
**Нәни песи кебек ойыйм.**
**Аңлатып бир әле миңа,**
**Нигә бәхет тора әздән?**
**Нинди була икән соң ул**
**Ана назы дигән бәлзәм?!**
**Гомерем буе эзләсәм дә,**
**Табалмыйча әллә китәм?**
**Юат мине, күтәреп ал,**
**Мин бит синнән шуны көтәм...**

## Үзебездән тора

**Гарәпчә дә яздык, латинча да,**
**Бүген сызгалыйбыз кириллица.**
**Кытайларныкын да өйрәнербез**
**Исән калыр өчен кирәк булса.**
**Рухыбыз бит яши, үзгәрмәде!**
**Барып чыкмый әле аларчарак.**
**...Язу–сызу гына тезләндермәс,**
**Фикер йөртә белсәк — татарчалап...**

## Беләсеңме?

**Кирәк булса, минем өчен**
**Бар мөлкәтең бирәсеңне**
**Мин аңладым. Ул чыгымның**
**Бәяләрен беләсеңме?**
**Хәлсезләнсәм, үз җаныңның**
**Бер өлешен бүләсеңне**
**Мин төшендем. Ул адымның**
**Хәтәрлеген беләсеңме?**
**Минем арттан җиденче кат**
**Күк түренә менәсеңне**
**Белеп яшим. Ихлас сөю**
**Шундый була, беләсеңме?**

## Яңгыр исе

**Яңгырның бит алдан исе килә**
**Җиле, тузанына ияреп.**
**Көткән чакта, авыл кешесенә**
**Бәхетнең ул үзе диярлек.**
**Шатлык өстәп, тере тамчылары**
**Өмет булып җанга бәрәләр.**
**...Яңгыр исе мичтән яңа чыккан**
**Икмәк исләренә бәрабәр...**

## Хуҗа булырга телим!

**Җөмһүрият көне дисәм,**
**«Шәһәр көнен» тагалар.**
**Үз бәйрәмем булдырмаска**
**Туксан хәйлә табалар.**

**Хәтта Сабантуйның хәзер**
**Тик исеме татарча.**
**Кыланмышлар...сыланмышлар...**
**Ярты сөйләм аларча.**
**Җаным Ирек, Хөрлек тели,**
**Миңа кирәк — минемчә!**
**Безнең хәл бит үз өендә**
**Бием булган киленчә...**

## Әлегә шулай

**Сәясәтче дә җырлый,**
**Сәяхәтче дә җырлый.**
**Чибәркәйләр дә җырлый,**
**Сөяркәләр дә җырлый.**
**Тыңкышлары да җырлый,**
**Зыңкышлары да җырлый.**
**Зарлылары да җырлый,**
**Зомбилары да җырлый.**
**Чын җырчы кайда җырлый?**
**Әлегә акча җырлый...**

## Ярату

**Мин күргәнне син күрмисең,**
**Син күргәнне мин күрмим.**
**Икебез дә күзле дә бит,**
**Карашлар ике төрле.**
**Мин йөгерәм, син каласың,**
**Син кузгалсаң, мин туктыйм.**
**Ә тормыш бит дүрт аякның**
**Тигез атлавын хуплый.**
**Мин сүз башлыйм, син битараф,**
**Син дәшкәндә мин чукрак.**
**Бер ешлыкка сыешмыйбыз**
**Икебез ике тукран.**
**Мин кул сузам, син селкисең,**
**Син йодрыкмы? Мин – култык...**
**Нигә болай җәфалана**
**Бу ике сантый — кылтык?**
**...Дүрт сан төгәл булу гына**
**Җитми шул мәхәббәткә...**

## Турыдан–туры баш иям

**«Ник мәчеткә йөрмисең?»–дип,**
**Миңа да еш әйтәләр.**
**Барганым бар, күргәннәрдән**
**Корып кайта теңкәләр.**

**Андыйлар бик сирәктер шул,**
**Бармак бөгеп санарлык.**
**Иң чистасы, иң пөхтәсе —**
**Алдындагы намазлык.**

**Мөнбәрдә кем вәгазь сөйли?**
**Азгын затмы, сәрхушме?**
**Каян табыйм пәйгамбәрнең**
**Дәвамчысы — дәрвишне?!**

**Аллаһыга сәҗдә кылу**
**Арадашсыз төшенчә**
**Иман шул ук мәхәббәт ул,**
**Анда артык өченче...**

# БУЫННАР ЯЗМЫШЫ

«Бала үз язмышы белән туа», диләр. Шулайдыр, чөнки Илаһи көч барысын да сокланырлык камил итеп яраткан. Язмышның да бик мөһим өлеше — әти-әниләрдән, бабай-әбиләрдән яшь буынга биреп калдырылган генетик мирастыр. Аның үзенчәлеге күп еллардан соң гына беленер. Әмма һич кенә дә шикләнмәскә кирәк: ул барыбер үзен сиздерер. Югыйсә, әтисен бөтенләй күрмәгән, өч яшендә әнисез дә, бөтенләй караучы туганнарсыз да калып, үз гомерендә җиде ят хатын-кызга «әни» дип эндәшергә мәҗбүр булган Тукаебыз, татар халкының өмете, сөекле улы булып танылыр өчен, үзенә гаҗәеп зур яшәү энергиясе өстәрлек көчне кайдан алыр иде? Әлбәттә, илаһи генетик мирастандыр. М.Горькийның «Рожденный ползать — летать не может» дигән мәгълүм гыйбарәсе дә шуңа ишарәдер. Күрәсең, ул очар өчен туган.

Әлбәттә, һәр баланың яшәгән мохите, уку, эшләү шартлары, аның тырышлыгы, ниятләренең изгелеге, хыялларының матурлыгы, омтылышларының бөеклеге, һичшиксез, язмышына да зур йогынты ясыйдыр. Илаһи зат анысын да исәпкә алмый калмагандыр. Әйтик, Габдуллабыз Кырлайда, гомерендә беренче мәртәбә гаилә җылысы күргән Сәгъди абзыйларда калган булса.., яки менә яшь егет Михаил Ломоносов туган авылы, диңгезче поморлар яшәгән Денисовкада төпләнсә... Фаразлау — кыен гамәл, күпләр аны «файдасыз» дип тә әйтәләр. Әмма аның «файдасы», әлбәттә, китерелгән мисалларда түгел, ә бәлки шундый мисаллардан алган гыйбрәттәдер: авыр хәлдә калган кешегә, бигрәк тә балага яки сәләтле яшүсмергә ярдәм итү һәрберебезнең кешелек бурычы, бәлки әле иң саваплысыдыр да. Шундый изге күңелле ярдәмчеләр булу тормышыбызны бизи.

Нинди куаныч, янәшәсендәге шәфкатьле, кайгыртучан кешеләр Габдуллабызны да Җаек (Уральск) шәһәренә алдырып, язмышында бөтенләй башка мөмкинлекләр ачалар: танылган «Мотыйгыя» мәдрәсәсе һәм аның киң карашлы мөдире, урысча да укып алу, типографиядә эшләү, редакцияләр белән хезмәттәшлек... Инде ул «өметле» шагыйрь булып танылып Казаныбызга кайта һәм... халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайга әверелә. Ә Казанга кайтмаган булса?..

Ә бит кемнәрдер кызыксынучан үсмер егет Михаилның күңелендә мәгариф чаткылары кабызалар һәм инде 19 яшьлек егет ерак Төньяк диңгез ярларыннан Мәскәүгә юл ала (нинди матур тәвәккәллек!). Анда бу зур гәүдәле авыл егетенең сәләтен тоеп, көчле теләген исәпкә алып, аны славян-грек-латин гимназиясенә укырга алырлык кайгыртучан мәгариф хезмәткәрләре табыла. Михаил үзеннән 8-10 яшькә кечерәк балалар белән сабак ала һәм аның белем эстәүдәге үҗәтлеге, сәләте ихтирам яулый. Егетне Петербург университетына кабул итәләр һәм, бер ел укыгач, кайгыртучан мөгаллимнәр ярдәме белән Германиягә җибәрелә. Заманының иң мәшһүр профессорларыннан лекцияләр тыңлап, алар белән якыннан аралашып, заманча җиһазландырылган лабораторияләрдә, танылган галимнәр җитәкчелегендә тәҗрибәләр үткәреп, нәтиҗәләрен анализлап, Михаил үзе дә фән дөньясына керә. Зур сәләте, тырышлыгы аша дөньякүләм танылган галимгә, Россиянең горурлыгы — Михаил Ломоносовка әверелә. Ә Германиягә җибәрелмәгән булса?..

Димәк, һәр кеше үз язмышын булдыруда үзе төп рольне башкара. Аның сыйфаты

тормыш юлында кемнәр очраудан һәм аларның карашларыннан, ярдәм күрсәтә алырлык теләк-гамәлләреннән тора. Ә инде илдәге сәясәт, вазгыять, рухи халәт, әлбәттә, шул ил кешеләре язмышында үз тәэсирен дә калдыра. Моны күзаллау өчен дөньяның кайсы кыйтгаларында, кайсы илләрендә яшәү рәвешенең, сәнгатьнең, фәннең, мәдәниятнең, әхлакның ни хәлдә булуына күз салу да житә. Аерма — хәйран калырлык.

Әлеге язма Татарстан Фәннәр академиясенең икенче президенты, якташым, зур ихтирамга лаеклы замандашым Әхмәт Мазһар улы Мазһаров турында булып, югарыда китерелгән уй-фикерләремә нигезләнә. Әхмәт Мазһар улының шәхес буларак формалашуында дәүләтен югалткан халыкның гасырлар дәвамында күргән авыр кичерешләре, дәһшәтле егерменче гасыр фажигаләре, дингә һәм диндарларыбызга каршы коммунистлар оештырган дәһрилек газаплары, үкенечләре, якты өметләре чагылыш тапкандыр. Әйе, күнелләге өмет иң авыр елларда да бәндәгә яшәү көче өсти, гомерен озайта. Нәтижәдә буыннар чылбырының бербөтенлеге тәэмин ителә. Кайбылев-Мазһаровлар нәселен дә шул яшәү көче саклагандыр.

Чыгышлары белән Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылыннан булган Кайбелевларның нәсел агачы түбәндәгечә: Сөләйман →Габделмәжит (1786) + Гайшә (1789-1856) →Жамалетдин (1808) + Зөләйха (1818) →Мирхафиз (1851-1934) + Хәнифә →Мазһар (1889-1961) + Рәкыйга (1908-1995) →Әхмәт Мазһаров (1943) + Әлфия (1950). Истәлекләргә караганда, Мирхафиз бабай — муллалар нәселенең дәвамчысы. Шулайдыр, югыйсә рухи һәм матди яктан хәлсез гаиләдә үскән бала Казан артының данлыклы «Кышкар» мәдрәсәсенә килеп, танылган мөгаллимнәрдә уку бәхетенә ирешә алмас иде. Гомумән, бу як татарлары укымышлы һәм диндар булулары белән аерылып тора. Дөньякүләм танылган Терегулов, Сөнәев, Нигъмәтуллин кебек галимнәрнең чыгышлары белән Пенза якларыннан булуы юкка гына түгелдер.

Ул төбәк авылларын бүген дә ислам нуры ямьләндерә. Әнә Качкару авылында да соңгы елларда зур, заманча зәвыклы итеп тагы ике — өченче һәм дүртенче мәхәллә мәчетләре төзелгән. Мәктәпләрдә туган тел укытыла. Халык телен, динен, гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен саклауга беренчел бурыч итеп карый, тырышып эшли, мул тормышта яши. Киләчәкләре дә бәхетле булса иде.

Тырыш, максатчан Мирхафиз да Кышкар мәдрәсәсенең көчле шәкерте булып таныла һәм бу мәгълүмат Вятка губернасындагы Малмыж өязенең Арбор волосте (бүгенге Татарстан республикасы, Балтач районы) Сасна авылыннан чыккан Гомәр бай Якуповка барып ирешә. Кодрәтле бай Сасна авылы мәхәллә чыгымнарының күп өлешен, әйтик, мәчет, мәдрәсә салуны, имамнарга матди ярдәмне үзе күтәрә торган була. Гомумән, Октябрь революциясенә кадәр халкыбызның мәгарифен, нәшриятын булдыру, аны үстерү фәкать имамнарның, заман зыялыларының фидакарь тырышлыгына һәм татар байларының матди ярдәменә генә нигезләнә. Казаннан ерак Кышкар, Түнтәр, Курса кебек авылларда көчле мәдрәсәләр оешу, әлбәттә, уртак тырышлыкның куанычлы нәтижәләре. Шушы изге эшнең мөһимлеген бүгенге татар байлары да төшенсә иде!

Сасна авылында да өч мәхәллә, өч мәдрәсә һәм биш мәчет (икесе биш вакыт намаз мәчетләре) була, чөнки авыл биш чакрымга сузылган бер урам булып урнашкан. Сасна байлары бу мәдрәсәләрдә көчле мөдирләр һәм мөгаллимнәр булдыруны үз игътибарларында тоткан, лаеклы табылганнарын, шартлар тудырып, еракларднан китергән. Әйтик, Чистай өязеннән Сәфәр Талкышыйны, Бөгелмә өязеннән Тажетдин Иштирәкине шулай чакыралар һәм алар бу якларда мәгарифне үстерүдә якты эз калдыра. Мирхафиз Кайбелевны да 1882 елда Саснаның икенче мәхәлләсенә имам булып килергә күндерәләр. Икенче мәдрәсәгә мөдәррис (мөдир) итеп билгелиләр, шәп йорт салып бирәләр һәм, теләсә, хаж кылуда ярдәм вәгъдә итәләр. Ул дәвердә Россиядә капиталистик мөнәсәбәтләр зур үсеш ала һәм татар байлары да үзләренең уңышлары белән таныла. Алар арасында беренче, икенче... гильдия сәүдәгәрләр үсеп чыга. Балтач төбәгеннән Якупов, Хәкимов, Ишморатов кебек зур капиталга ия булган күренекле байлар шундыйлардан. Тормыштагы бу унай үзгәрешләр, үз чиратында, мөселманның иң чыгымлы йоласын үтәү — хажга

бару мөмкинлекләрен дә арттыра. Бу мәсьәләдә шул ук төбәкнең Түнтәр авылы, чын мәгънәсендә хаҗилар авылы, аерым игътибарга лаек.

Мирхафиз Кайбелев та сасналылар ышанычын аклый, мәхәллә халкы белән уртак телне тиз таба. Тирән белемле булуы һәм үз вазыйфаларына җаваплы каравы белән зур ихтирам казана. Әлбәттә, Якуповлар да үз вәгъдәләрен истә тоталар һәм инде Сасна кешесе булып танылган Мирхафиз хәзрәт 1913 елда хаҗ сәфәренә тәвәккәлли. Мөгаен, аның бу фикергә килүенә Кышкар мәдрәсәсен үзе кебек үк уңышлы тәмамлаган, эшен дәвам итә алырлык ышанычлы улы Мазһарның төп йортта, Саснада булуы да зур йогынты ясагандыр. Улына инде 24 яшь һәм ул мәчеттә, мәдрәсәдә, төп йортта аны алыштырырлык!

Мирхафиз хәзрәтнең сәфәре сигез айга сузыла... Шунысын да истә тоту зарур, ул елларда хаҗ кылу дәвамлы гына түгел, куркыныч сынау да була. Әнә, киң танылу алган Габденнасыйр Курсави хаҗ сәфәре вакытында 36 яшендә вафат була, Истамбулда җирләнә. Нәкъ шундый ук фаҗигагә хаҗи, Гали ишанның кияве, кырык биш яшьлек Шәмсетдин Түнтәри дә юлыга. Ә Мирхафиз Кайбелевка хаҗ сәфәре вакытында инде 62 яшь! Шөкер, ул исән-имин Саснага әйләнеп кайта. Үзе һәм гаиләсе өчен генә түгел, барлык таныш-белешләре өчен дә гыйбрәтле вә кызыклы вакыйга була бу. Чөнки дөнья сәясәтенең үтә катлаулы, шөбһәле заманы, ә Мирхафиз хәзрәт күп илләр күреп, күп авырлыклар кичеп максатына - хаҗ кылуга ирешә. Нинди тәвәккәллек!

Тик, ни кызганыч, хаҗ сәфәренең куанычларына язмыш үтә дә кыска гомер калдырган була. Илдә тетрәндергеч вакыйгалар, һәр гаиләгә бәла-казалар китерәчәк, Россия империясенең үзен дә юкка чыгарачак фаҗигаләр чоры башлана: Беренче Бөтендөнья сугышы, Россиянең ул сугышны оттыруы, илдә гражданнар сугышы башлану, армиянең акларга-кызылларга бүленүе, үзара үтерешү, күпме корбан, ачлык, хәерчелек, халыкны «Яңа икътисади сәясәт» белән алдау һәм «кулак» дип газаплаулар; иң аянычы — дәһриләрнең динебезгә һәм диндарларыбызга каршы оештырылган көферлек кыланмышлары.

Кайбелевлар гаиләсенә дә тулысы белән эләгә бу газаплар. Мөгаен, иң авыры Мазһар Кайбелев өлешенә төшкәндер. Беренчедән ул, бәбәй чакта ук бер җилкәсе имгәтелеп, инвалид булып кала. Икенчедән, әти-әнисе бу зиһенле егетнең киләчәген имамлыкта, мөгаллимлектә күрә. Уллары Мазһар әлеге өметләрне аклый: Кышкар мәдрәсәсен уңышлы тәмамлый һәм укуын дәвам итү өчен ана Каһирәдәге әл-Әзһәр (Мисыр) мәдрәсәсенә барырга тәкъдим итәләр... Тик Рәсәйдәге тормышның фаҗигале юнәлеш алуы бу кызыктыргыч тәкъдимне тормышка ашырырга мөмкинлек калдырмый. Илдә кулакларга, гомумән байларга, буржуазиягә һәм дингә, дин әһелләренә каршы вәхшиләрчә һөҗүм башлана. Идарәче даирәләрнең эш ысуллары акылга һәм гаделлеккә түгел, ә нәфрәткә һәм вәхшилеккә нигезләнә. Большевикларның бу кыргый, дәһшәтле кыланышына Кайбылевлар гаиләсе дә дучар була. Сиксәнен тутырып килүче Мирхафиз хәзрәтне бөтен гаиләсе белән өйләреннән куып чыгаралар, бар мал-мөлкәтен талап алалар һәм гаилә фәкать күршеләр йортында гына сыену таба.

«Бәла ялгыз йөрмәс», дигән гыйбарә бар. Аягында йөри алмаган Мирхафиз хәзрәт урынына аның инвалид улы Мазһарны репрессия корбаны ясыйлар. Ә сиксән яшьлек авыру хәзрәт, аның яңа гына Кайбелевларга беренче нәсел дәвамчысын — Мөхәммәтне — алып кайткан Рәкыйга килене терәксез, йортсыз, малсыз ничек яшәргә тиеш? «Яңа тормыш» коручыларны мондый сораулар бөтенләй кызыксындырмый. Аларның максаты — «искене» җимерү.

Гаиләләре өчен иң авыр шушы чорда Кайбелевлар яшь буынның фамилиясен Мазһаровка алыштыралар. Мөгаен, бу адым да күрәчәк михнәтләрне чикләү теләгеннән чыгып эшләнгәндер. Бу котылгысыз сәяси афәткә күпчелек имамнар дучар ителә. Сирәк-мирәк кенә Урта Азия яисә Себер якларына качып китә алганнары да ни кичергәннәрен үзләре генә белгәндер. Инде Сасна, Шода мәктәпләрендә эшләп, сәләтле укытучы булып танылган Мазһар мөгаллимгә дә, гәрчә ул заманда укытучыларга гаять зур кытлык булса да, фәкать Вологда лагерьлары гына лаеклы дип табыла.

Совет лагерьлары... «Үзгәртеп кору» елларыннан башлап андагы җәлладларының тоткыннарга карата коточкыч кыланмышлары турында байтак мәгълүматлар дөнья күрде. «Соловки» лагеренда алты ел утырып, гарип калып, бертуган энесен шунда җирләсә дә, үзе исән кала алган бөек рәссамыбыз, сынчыбыз Бакый ага Урманче фикерләре бик гыйбрәтле. Ул үзе, бертуган энесе — алфавитыбызны алыштыруга каршы язылган һәм 82 кеше кул куеп Сталинга җибәрелгән хатның авторлары — «Соловки» лагерьларына «милләтче» мөһере алган «җинаятьчеләр» буларак эләгәләр. Шулардан берничә кеше генә исән кала. Совет власте хөкемдарларының миһербансызлыгы турында сүз чыкканда: «Аягымны бераз кыскартсалар да, «Соловки»да, соңыннан җәнлек фермасында төлкеләр үстереп, «минус 39» дигән статьяга эләгеп, мина исән калу насыйп булды. Ә менә Буа районы Кул-Черкен авылында яшәгән имам, мәдрәсә мөдире әтием Идрис хәзрәтне бөтен гаиләсе белән йортыннан куып чыгаралар, барлык мал-мөлкәтен талап алалар... һәм әниебезнең юлда вафат булуы, әтиебезнең Казанда, ят кешеләр ишек алдында җан тәслим кылуы, әлбәттә, ин аяныч», — дигән иде. Шундый ук вәхшилекне Сасна авылында Кайбелевлар гаиләсенә карата да Мәскәүдән килеп кылмаганнар бит.

Җәлладлар булган кебек, һәр урында миһербанлы кешеләр дә табыладыр, күрәсен. Һәркем сынау алдында каладыр һәм гамәленә карап йә гөнаһка, йә савапка лаек буладыр. Бакый Урманчены да бер рәхимле бәндәсе төлке фермасына эшкә куя һәм гомерен саклый, сәнгатебез өчен игелекле гамәл кыла. Нәкъ шундый ук икенче бер игелекле кеше Вологда лагеренда Мазһар хәзрәтне урман кисү отрядына язудан, димәк, үлемнән саклап кала, сәламәтлеге начар булуны сәбәп итеп, хәтта лагерьдан ереккә чыгарып җибәрә. Ә шундый гадел кеше очрамаган булса?

Мирхафиз хаҗи 1934 елда вафат булып, 83 яшендә бу фани дөнья газапларыннан котыла. Ә менә исәннәр өчен ул сынаулар дәвам итә. Йортсыз да, мал-мөлкәтсез дә, эшсез дә калган Мазһарны «налогын түләмәгән өчен» кабат төрмәгә утырталар. Моны да әллә кайдан килгән ятлар түгел, ә җирле, «яна тормыш» коручы түрәләр башкара. Түзә Мазһар Кайбелев, бусыннан да исән-имин котыла. Бу чор тормышының авыр чынбарлыгы Мөхәммәт ага Мазһаровның бай эчтәлекле, «Укытучы уйланулары» исеме белән нәшер ителгән китабының аерым бүлекләрендә бик үтемле тасвирланган. Болар — Сасна авылындагы хәлләр, әмма илебезнең бик күп авылларына хас үткән тормышның ачы чынбарлыгы.

Ничек кенә авыр булмасын, тормыш дәвам итә, кешене киләчәккә булган матур уйлары яшәтә. Инде лагерь, төрмә газапларын узып, гаилә бергә җыелгач, Мазһар хәзрәт белән Рәкыйга абыстай да 1937 елда кыз бала — Сәлманы, 1943 елда ир бала — Әхмәтне алып кайталар. Шулай итеп, Кайбелевлар гаиләсендә төп куанычлары, өметләре булып өч бала — Мазһаровлар үсеп килә.

Язып узылган буыннар язмышында Әхмәт Мазһаров, мөгаен, иң бәхетлеседер. Чөнки ул сугыш чорында туса да, аның төп газапларын күрмичә, әти-әни мәхәббәтен тоеп, төпчек бала булып, абыйсы, апасы ышыгында үсә. Шуңа күрәдер, аның күңелендә нинди дә үпкә, рәнҗү кебек тойгылар бөтенләй сизелми. Күрәсең, төпле тәрбия һәм мәдрәсә белеме алган, тормышның авыр сынауларын узган ата төпчек баласына бөтен күңел җылысын, изге теләкләрен ирештерә алган. Ул ана назында, туганлык җылысы тоеп, тату гаиләдә үскәндә генә шулай була. Абыйсы үз энесенә булган матур хисләрен, аның белән горурлануын югарыда аталган китапта ачык чагылдыра, Әхмәтнең яшьтән үк мөстәкыйль, максатчан һәм тырыш булуын ассызыклый. Укытучы дөрес фаразлый: нәкъ шушы сыйфатлар Әхмәт Мазһаровны бүген дә күпләрдән аерып тора. Үземнән өстисем килә: Әхмәт — рухи сәламәт кеше, югары әхлак тәрбиясе аның яшәү рәвешенә әйләнгән. Андагы бу асыл сыйфатны замана сынаулары да, дәрәҗә таләпләре дә үзгәртә алмый: ул элеккечә саф күңелле, ярдәмчел һәм игътибарлы, чын кеше булып кала. Әхлак кыйммәтләре бизмәнсез калган заманда — үзе бер уникаль күренеш. Күрәсең, ана илаһи генетик мирасның да затлысы насыйп булгандыр.

Әхмәт Мазһаровның үзен тотышында үк зыялыларга гына хас сабырлык, уйлап кына гамәл кылу кебек асыл сыйфатлар бар. Ул ашыгыр, әмма кабаланмас, юк-бар сораулар белән үзен дә, башкаларны да бимазаламас, ә эшендәге яки

тормыштагы катлаулы мәсьәләләрнең унай чишелешен эзләр. Төз гәүдә, акыл, житди караш һәм йөрешендәге тәвәккәллек анын өлгергән шәхес, эшлекле кеше булуын ассызыклыйлар.

Балачак дөньясы, балачак мавыгулары... Аларда никадәр илаһилык, сөю хисләре, яки күпме нәфрәт, әрну, үч. Беренчеләре — зурая төшкәч, кеше күнеленә матурлык, ә икенчеләре — ачулы тойгылар, тискәре омтылышлар булып күчә. Әхмәттә беренчеләре үсеш алган. Кечкенә чагында Муса бабай ясап биргән чаңгыда Сасна болыннарын гизеп, туган авылы тауларында җилдертергә өйрәнеп, ул мәктәп, район ярышларында җиңү яулый башлый. Студент булгач, институт җыелма командасында да бу уңышларын дәвам итә. Шул вакыттан бирле чаңгыда шуу Мазһаровнын, аннары гаиләсенең дә иң яраткан ял итү шөгыле булып кала.

Студент егет Әхмәтнең Казанда, Кабан күлендә яратып өлгергән байдарканы авылдашларына күрсәтәсе килү теләге дә — авыл баласы өчен табигый хәл. Һәммәбезнең барлык шатлыкларыбызны да авылдашларыбыз белән уртаклашасы килә. Әхмәт тә мең мәшәкатьләр белән Саснага байдарка алып кайта һәм анын белән Шушма елгасы киңлекләрен инли. Спортның бу ике төре әле дә Ә.Мазһаров өчен яшьлек истәлеге, җан азыгы, сәламәтлек чыганагы булып кала.

Әхмәт өчен балачак хатирәләре, әлбәттә, ямьле Шушма тугайлары, анын күнелгә якын әрәмәле ярлары, су буйларында балык тоту белән бәйләнгән. Сугыш артының ачлы-туклы елларында балык тоту — ризык юнәтүнең бер чарасы була. Юк, һич кенә дә су буенда хозурланып йөрү түгел! Аның шулай икәнлеген без балык алып кайтканда, өлкәннәрнең куанычлы йөзләреннән үк сизә идек. Бүген инде бу шөгыль ял итү формасына әверелде. Әхмәт тә, илнең кайсы өлкәсен, дөньяның кайсы илләрен гизмәсен, хезмәттәшләре арасында су буенда ял итәргә, балык шулпасы белән сыйланырга ярата. Хыялында гына булса да, Шушма буйларына кайтып килә булыр.

Шушы урында бүгенге көндә халкыбыз алдында торган иң җитди ике проблемага тукталып, аларга Әхмәт Мазһаровның мөнәсәбәтен белдереп узмасак, бу язма тулы ук булмас иде. Анын беренчесе — туган телебезнең бүгенгесе һәм киләчәге. Дөресен әйтергә кирәк: анын хәле бик мөшкел, бу бигрәк тә соңгы елларда күнелгә бәрелә башлады. Беләбез: куллану даирәләре гел кими бара, хәтта дәүләт статусы бирү дә уңай нәтиҗәгә китерммәде.... Шулай булгач, татар теленең язмышы бик аяныч булырга мөмкин. Хакыйкать шул: тел югалса — халык юк, халык югалса — дәүләт юк!

Әхмәт Мазһар улының туган теле — татар теле, гаилә теле дә — татар теле. Гаиләләрендә һәрберсе өч-дүрт телне камил белсәләр дә, туган телебезгә, әдәбиятыбыз-мәдәниятебезгә, тарихка олы ихтирам саклана. Әхмәт Мазһаровның татарча чыгышлары да әдәби телебездә сокланырлык матур яңгырый.

Икенчесе — динебезнең бүгенге хәле һәм киләчәге. Ул авыр һәм катлаулы тоела. Күпләребез, мәчетләр төзелгәч, дин кайтыр, анын белән иман һәм әхлак ныгыр дип уйлаган идек. Ялгышканбыз. Шөкер, инде мәчетләребез байтак, әмма куанычы аз. Коммунистлар үткәргән «чистарту» сәясәтенең иң аяныч нәтиҗәләре мәчетләр җимерүдә түгел, ә руханиларны юк итүдә булган икән. Иң үкенечле мирас - шушысы. Без бүген, мөфтигә димим, гади имамнарга да нинди таләпләр куелырга тиешлеген һәм аларны кайда, ничек тәрбияләргә, укытырга, хәтта хезмәтләренә күпме түләргә икәнен дә белмибез. Шуна динебез тирәсендә очраклы кешеләр күбәйде. Нәтиҗәдә күнелсез вакыйгалар артканнан арта. Ни кызганыч...

Мирхафиз хәзрәтнең оныгы, Мазһар хәзрәтнең улы Әхмәт - академик, үзенең уйлап табулары, аларны гамәлгә кертү буенча дөньякүләм танылган галим — намаз укый, дин кануннарын ихтирам итеп яши! Бу нәсел халкыбызда иман саклауга хезмәт итүе өчен олы фаҗигаләр кичерүгә карамастан, бүген дә динле, укымышлы, тәрбияле.

Әхмәт балачагының иң матур истәлекләре итеп әтисе белән бергә вакытларын, бигрәк тә анын дусларына кунакка барган мизгелләрне, юлдагы «табигать дәресләрен» сагына. Нормабаш авылыннан данлыклы умартачы Вәлиулла картның ярдәмчел һәм кешелекле булуын сөйли, әтисе васыятен искә ала. Ул, «үзем белән

бергә каберем янына куммәрсез» дип, ике ящик гарәп әлифбасында язылган китаплар әзерләп куйган була. Күрәсен, бу адым каһәрләнгән гомере өчен рәнжегән имам күнеленең явыз Сталин режимына, халкыбызның рухи дөньясына ясалган гаять зур җинаятенә протест йөзеннән эшләнгәндер. Чөнки ул елларда бу җинаятькә каршы килгән зыялыларыбыз юк ителгән, китаплар да, кирәксезгә әйләнеп, теләсә кайда ята торган була.

Әхмәт институтка әтисе тәкъдиме белән бара һәм укуы да нефтехимия буенча түгел. Нефтехимиягә аны язмыш китерә. Шул ук язмыш Д.И.Менделеев исемендәге Мәскәү химия-технология институтының кафедра мөдире, профессор Н.Н.Лебедев белән очраштыра һәм ул аспирантын нефтехимия фәненә алып керә. Галим укучысының — инде фәннәр кандидаты Әхмәт Мазһаровның углеводородларны күкерттән чистарту юнәлешен сайлавын хуплый, һәм яшь галим Казанга, фәнни институтка (ВНИИУС) лаборатория мөдире сыйфатында кайта. Эш башлар өчен профессор Н.Н.Лебедев ана яна катализатор да биреп җибәрә. Бу хезмәттәшлек гомерлек булып чыга. Рәхмәтле укучысы, инде Николай Николаевич күптән вафат булса да, остазының истәлеген кадерләп саклый. Бүген дә Әхмәт Мазһаровның институттагы кабинетын Лебедев портреты бизи.

1974 елда институтка директор итеп тәҗрибәле практик, Түбән Кама «Нефтехим» заводында директор булып эшләгән В.Венюков җибәрелә һәм ул, ВНИИУС эшчәнлеге белән танышкач, углеводородларны күкерттән чистарту тематикасының үтә перспективалы булуына төшенә, үзенең фән буенча урынбасары итеп Ә.Мазһаровны билгели. Институт эшчәнлеге күпкә көчәя. Сонрак Ә.М.Мазһаров директор итеп сайлана.

Институтның моннан соңгы фәнни уңышлары, гамәли казанышлары, бигрәк тә халыкара аренага чыгып киң танылу алуы, шиксез, аның директоры Мазһаров Әхмәт Мазһар улы эшчәнлеге белән бәйле. Ул чын мәгънәсендә фән өлкәсендә нәтиҗәле эшләүнең матур бер үрнәген күрсәтеп яши.

Углеводородларны халык хуҗалыгында куллану мөмкинлеге XX гасырның икенче яртысыннан башлап дөньяда елдан ел арта бара. Инде нефтехимия дә барлык сәнәгать төрләре арасында әйдәп баручы тармакка әверелә. Бу хәл, үз чиратында, углеводородларның чисталыгына таләпләрне бик югары күтәрә. Чөнки полимерлаштыру процессларында файдаланыла торган углеводородлар бөтенләй күкертсез булырга тиеш. Ягулык материалларының чисталыгына (бензин, дизель ягулыгы) куелган таләпләр дә елдан-ел катгыйлана: анда да сыйфатны билгеләгәндә ppm-нар белән эш итәләр. Шуның өчен углеводородларны күкерттән чистарту фән һәм җитештерү тармагы (производство) алдында торган иң көнүзәк мәсьәләгә әйләнә. Ә. Мазһаров җитәкчелегендә эшләүче Углеводород чималы фәнни-тикшеренү институтының (ВНИИУС) галимнәре, фәннең чын мәгънәсендә алгарышка хезмәт итүен раслап, бик күп нефть эшкәртү, нефтехимия заводларының уңышлы эшләвен тәэмин итәләр.

Институтның бердәм һәм интеллектуаль көчле коллективы хезмәте белән Россиядә һәм чит илләрдә барысы илледән артык күкерттән чистарту җайланмасы гамәлгә куелган. Россиядән тыш Казакъстанда — 6, Иранда — 5, Болгариядә — 2, Литвада — 1, Беларусьта — 2, Сириядә — 1 завод эшли. Болар белән янәшә, нефтьне җыю, эшкәртү, газлардан арындыру җайланмалары өчен тагын ун технология тәкъдим ителгән һәм эшләтеп җибәрелгән. Мазһаров җитәкләгән коллективның танылган «Шеврон» фирмасы белән Тингез чыганагында, Иран нефть чыгару компанияләрендә уңышлы эшләве Татарстаныбыз абруен ныгытуга һәм үстерүгә хезмәт итә.

Фәнни эшчәнлекнең иң җитди күрсәткече булып уйлап табулар — патентлар, аларны «эшләтеп җибәрү» — җитештерү әйләнешенә кертү һәм басылып чыккан хезмәтләр санала. «Эшләтеп җибәрү»нең масштаблары хакында югарыда әйтеп үтелде. Чыннан да, бу өлкәдә максатчан, үрнәк итеп куярлык киң колачлы эш җәелдерелгән. Әхмәт Мазһар улы — 134 авторлык таныклыгы һәм патентларның авторы, соңгыларының бишесе АКШта һәм берсе Алманиядә теркәлгән. Шулай ук Ә.Мазһаров — төрле фәнни җыентыкларда, журналларда, конференцияләр

материаллары буларак басылып чыккан 207 мәкалә авторы. Аның фәнни-гамәли конференцияләрдәге чыгышлары теманы әйбәт белүе, куелган мәсьәләнең чишелү ысулларын ачык күрсәтүе, тәкъдимнәренең төгәл булулары белән башкалардан аерылып тора һәм тыңлаучыларда, белгечләрдә һәрвакыт зур кызыксыну уята.

Ә «үзгәртеп кору» башланмаган булса?.. Дәүләт бәйсезлеге турында декларация кабул итү Татарстан республикасына үз Фәннәр академиясен булдыру мөмкинлеге бирде. Бу тарихи эшне әдәбият галиме, зур оештыру сәләтенә ия, абруйлы житәкчебез Мансур Хәсәнов житәкчелегендә, фәнни эшчәнлекләре Казаныбыз һәм республикабыз белән бәйләнгән олуг галимнәрдән торган, югары дәрәҗәле комиссия бик күркәм башкарып та чыкты. 1992 елны Әхмәт Мазһаров исә академик итеп сайланды.

Беренче президент буларак Мансур ага Хәсәновның оештыру эшчәнлеге зур ихтирамга лаек. Фәнни җәмәгатьчелек тә, хөкүмәтебез дә моны әйбәт белә һәм югары бәяли. Әмма, ни хәл итәсең, еллар тормышка үз төзәтмәләрен кертә. Академик Мансур Хәсәнов та пенсиягә чыкты, яңа президент сайлау ихтыяҗы туды. Әлбәттә, республиканың, төп үсеш юнәлешләреннән чыгып, академия президентына куелган таләпләр дә үзгәрде. Ул фәнни эшчәнлеге производство үсеше, икътисад, рухи дөньябызның киләчәге белән бәйләнгән, республикада, Россиядә һәм чит илләрдә дә танылу алган, фәнни җәмәгатьчелектә абруй казанган, оештыру сәләтенә ия галим булырга тиеш. Бу югары таләпләргә академик Мазһаровның күрсәткечләре тәңгәл килүе ачыкланып, аның кандидатурасы президентлыкка тәкъдим ителә. Һәм ул бертавыштан сайлана да. Әхмәт Мазһар улы Мазһаров — Татарстан Фәннәр академиясенең икенче президенты.

Ә дәүләт бәйсезлеге турында декларация кабул ителмәгән булса?... Сасна егете Әхмәт Мазһар улының фәндә, сәнгатьтә зур уңышларга ирешеп, җәмгыятьтә күркәм танылу алуына иң күп куанучылар, мөгаен, якташлары булгандыр. Балтачның үзендә академик Мазһаров урамы барлыкка килде, туган авылы Саснада да төп урам Әхмәт Мазһаров исемен йөртә. Бу мисаллар аңа туган ягында ихтирамлы караш булуын күрсәтә. Ә ул бер яклы гына булмый, Әхмәт үзе дә туган авылы, укыган мәктәпләре белән даими элемтәдә тора. 2000 елдан бирле Сасна мәктәбе укучылары арасында конкурс үткәрелеп, Әхмәт Мазһаров исеменнән өч премия бирелә. Берсе физика-математика буенча, икенчесе химия-биология предметларыннан иң сәләтле укучыга, ә өченчесе — иң көчле чаңгычыга. Балтачта исә ел саен «Академик Мазһаров укулары» исеме белән өлкән класс балалары өчен республика конференциясе үткәрелә. Укучылар өчен 8 юнәлештә: математика, химия, физика-астрономия, география-экономика, биология, техник иҗат, мәгълүмати технологияләр, туган як тарихы буенча — өчәр диплом каралган һәм үз төрендә беренче урынны алганнарга Мазһаровтан истәлек бүләге тапшырыла. Шулай ук Әхмәт туган авылында мәчет салуга да нык ярдәм иткән. Рәхмәтле Сасна халкы мәчетне Әхмәтнең әтисе исеме белән «Мазһар мулла мәчете» дип атаган.

Әхмәт Мазһар улы Мазһаров эшчәнлегенең иң көчле чорын кичерә. Ул эше, гаиләсе, замандашларының җылы мөнәсәбәте белән бәхетле. Аңа киләчәккә дә зур уңышлар, бәхетле гаилә тормышы телик, Әлфия ханым белән балаларының бәхетле тормышын күреп, куанып яшәсеннәр. Киләсе буыннарның язмышы матур язылса иде!

**Азат ЗЫЯТДИНОВ,**
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы,*
*Татарстан Дәүләт Советы депутаты*

***Редакциядән:***

*Татарстан Фәннәр Академиясе президенты Әхмәт Мазһар улы Мазһаров 2013 елның гыйнварында 70 яшьлеген билгеләп үтә. Олы юбилее белән ихластан котлыйбыз, нык сәламәтлек, иҗат уңышлары теләп калабыз.*

# «МИН ГАДЕЛЛЕК ҖИЛЕ...»

## ШАГЫЙРЬ ФӘРИТ ГАБДЕРӘХИМГӘ 80 ЯШЬ

Мин татар шагыйре һәм татар тудырган шигърият турында язарга телим. Әмма дөнья әдәбиятында ин яраткан «шигырем» — чәчмә әсәр, уналтынчы гасырда язылган «Дон Кихот» романы. Монардан да рыясыз, эчкерсез шигырьне белмим. Яраткан «шагыйрем» дә шул роман авторы — Мигель де Сааведра Сервантес, яраткан героем да шул әсәрдән — Хәйләкәр идальго Дон Кихот Ламанчлы. Нәрсә, үзем сурәтләячәк шагыйрьне яратмыйммени? Яратмагач, язып буламы? Яратам, ничек кенә яратам әле! Ул да, нәкъ Сервантес шикелле, килеш-килбәте белән калтырча арбадай җинел сөякле, озын кипкән буйлы, сыны белән нәкъ шул Дон Кихот шикелле, җил тегермәненә охшаган. Ятратканга гына язам да!.. Ярату ул салават күпере сымак күп төсле. Шулаен шулай да, әмма татар шагыйре турында язганда бу кадәр сәер шартлылыкларны ничек бер төенгә бәйләп бетерергә? Кайчандыр, утызынчы елларда, бәрәнге ашап утырганда язылган «Гренада»ның авторы шундый ук «хәйләкәр идальго» Михаил Светлов әйткәнчә, «каян килгән безгә мондый гишпан монсулыгы»?! Бәй, үзен шул тәмуглар аша үткәч, мон ничек килмәсен, ди? Әле советлар исән чакта ук шагыйрь үзенен «Иң сыйфатлысы» дигән шигырендә илдәге ялганны себереп аткан булган икән:

*Төзләребез иң шәп төзләр иде,*
*Бөкеребез — иң шәп бөкере.*
*Киләчәккә илткән юллар иде*
*«Иң сыйфатлы» дигән мөһерле...*
*Әллә инде тимер пәрдә белән*
*Дөньябызны кабат каплыйсы?*
*Чәнечкеле тимерчыбык кына*
*Икән бездә — иң сыйфатлысы...*

Шагыйрь Фәрит Габдерәхим иҗаты хакындагы язмаларымны шушындый көтелмәгән кереш һәм түбәндәге коргаксыган сан-цифрлардан башланыр дип һич уйламаган идем. Бәлки аларны озак башлый алмый җәфаланганымнандыр? Нишләмәк кирәк, башкача чара булмады: анын «Кичер мине!» (1995), «Синең белән мин» (2000), «Соңгы шигырьләр» (2011) дигән китапларыннан һәм башка чыганаклардан менгә якын шигырен укырга насыйп булды. Алар барысы да милләткә, анын ачы һәм чарасызлыктан «төчеләнә төшкән» язмышына багышланган. Аларны укыганда ике йөз кырык кына түгел, өч йөз алтмыш вольт көчәнешле трансформаторлар да тиз янып чыга. «Җирне йөз кат үтерергә мөмкин, без сәләтле булу сәбәпле. Бик үкенеп әйтмәбезме бер чак: «Нигә соң без артык сәләтле?!» Бүгенге татар шигъриятендә яхшы, хәтта ки бик шәп шагыйрьләр байтак, әмма Фәрит Габдерәхим алардан аерылып тора. Мин мондый бүтәнне хәтерләмим. Тематика ягыннан алар бәлки ниндидер күләмдә Илдус Гыйләҗев белән охшашлардыр. Ләкин бирелә поэтик камиллекне истән чыгарып, иҗат миллилеге белән милли темада урчегән иҗатны бутарга ярамый. Монардан бер генә социаль нәтиҗә килеп чыга: Фәрит Габдерәхим, югарыда телгә алынган шигырендәге «ин сыйфатлы тимерчыбык» кебек, үзе дә бүгенге татар шигъриятенен «иң сыйфатлы» Сервантесы да, шул исәптән Сервантесның җил тегермәннәре белән сугышып йөргән «ин сыйфатлы» инсаны — Дон Кихоты да икән. Әйе, без, татар шагыйрьләре, үз иҗатыбызда кемнәр белән генә ярышмадык: Гомәр Хәйям, Гете, Пушкин, Гарсиа Лорка, Есенин, Маяковский, Назыйм Хикмәт, Пабло Неруда да булдык, инде Тукай, Дәрдемәнд,

Сәгыйть Рәмиевләр турында әйтәсе дә юк, аларны еш кына «үтелгән этап» күреп, чүп урынына да санамадык. Имеш, алар — татар башындагы милли тимрәвебез кебек үзебезнеке, безгә читләр һәм читләргә хезмәт иткән «перебежчик» Нуриевлар, Гобәйдуллиналар кадерлерәк!.. Ә менә Фәрит Габдерәхим абзабыз, әллә нинди чит-ят «модный кумирлар» белән мавыкмыйча, Тукай-Дәрдемәнд әвәрәсеннән чыкмыйча, ачып-өлгереп, без күреп өлгермәгән илле-алтмыш еллык иҗат гомерендә бик табигый рәвештә татар шигриятенең Сервантесы һәм Дон Кихоты булып калган да куйган! Әнә ни дигән ул әллә кайчангы заманнарда: «демократик сырмабызның җиң очыннан большевистик камчы күренә». Югыйсә, нинди генә җәмгыятьтә яшәмә, иҗтимагый сыйфат өчен көрәш уртасында инсан-кеше сыйфаты өчен көрәш торырга тиеш! Ә без ул инсанны күрмәскә, тапмаска, табылганын танымаска тырыштык. Алар күләгәдә калды. Шагыйрь раславынча, «Күләгәле урыннарның хәлләрен беләсе бар. Әнә шул тарафларга да Кояшны борасы бар». Шулай да бит, әмма тиз генә борып булмый шул. Аны бер шәһәрдә яшәгән, еллар буе бер бинада, янәшә катларда эшләгән, бер җырлар җырлап, бер кайгылар белән сызланган мин-колыгыз да күрмәгән-бормаганмын!.. Ә бит бер юллар-сукмаклардан йөргәнбез. Икебезнең дә борын тишекләребезне нефть-мазут исе кытыклаган, күрәсең: ул Октябрьский нефть техникумын тәмамлауга, аның аудиториясенә имтихан бирергә дип мин кергәнмен, әмма, математикадан икеле алып, керә алмау бәхетенә ирешкәнмен. Ул тәзелештә, мин нефтеразведкада эшләгәнбез, соңрак ул Уфа, мин Казан университетында шигырьдә каешланганбыз...

*Туган җирдә шатлык тора көтеп:*
*Шытып чыга чәчкән һәрбер бөртек.*
*Халкым тарихыннан агу ясап,*
*Безне чаккан кортлар качты өркеп, —*
*Мине беркем ега алмый төртеп...*

Расларга җөрьәт итәм: бүген татар шигъриятендә гомере буе беркайчан да вакытлы шау-шуларга кысылмыйча, исем-җисемнәргә исе китмичә, хәтта бер генә тапкыр да туган көннәрен, юбилей кичәләрен билгеләмичә, милләткә хәйран калырлык тугрылык, гигант (башкача сүз табалмыйм!) тыйнаклык аша татар сагышының гамен, серен саклап, татар шигъриятенең сыйфаты — татарда шәхеслек сыйфаты өчен армый-талмый, үкенми-икеләнми, зарланмый, командировочный вә премиальный чыгымнар таләп итмичә системалы көрәш алып барган бердәнбер шагыйрь ул Фәрит Габдерәхим дисәм, башка бик тә талантлы каләмдәшләрем авыр кабул итмәсеннәр иде. Язма барышында барысы да үз урынына утырачак һәм алар минем белән килешәчәк, Алла боерса!.. Рөхсәт итегез!..

*Овидийлар һәм Җәлилләр шаһит,*
*Саный китсәң, алар азмы соң!*
*Аерым башлар нәрсә! — Хөкемдарлар*
*Таптый хәтта халык язмышын...*
*И горур зат — Кешем!*
*Синең алда*
*Ул тәхетләр — бары чүп кенә.*
*Синнән югарырак беркем дә юк,*
*Синнән югарырак — күк кенә!..*

Серле зат ул Фәрит Габдерәхим атлы инсан!.. Үзе турында тәмам да онытып, Идел-Уралыбызның халык җырлары сакчысы булып калган ул. Чөнки үзе җырчы һәм белемле җырчы. Васыятенә игътибар итегез: «Ул җырларны ертма, туган, — калкуы бар яна туфан». Башкортстанның атаклы «Кызыл Тан» газетасында утыз еллап әдәбият бүлеге мөдире булып, Сәйфи Кудаш, Мостай Кәрим, Нажар Нәҗми, Әнгам Атнабаев кебек талантларның, дистәләгән язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең хезмәтләрен басмага әзерләп, еш кына төзәтеп, «классик» булсалар да, «кондициягә

житкереп», әвәләп, башкалар турында йөзләгән тәнкыйть (еш кына юбилей мактаулары!) мәкаләләре яздырып, бастырып, үз иҗаты турында сиксән яшенә җиткәнче (!) бер генә дә мәкалә яздыртмаган һәм чыгартмаган тыйнаклардан тыйнак бер пәрвәр бит ул Фәрит абзый. Ышануы да кыен! Аның турында, ялгышмасам, берике «очраклы очракны» исәпләмәгәндә, тәнкыйть мәкаләләре дә юк бугай. Күптән түгел «Мәдәни җомга»да минем тарафтан чыгарылганы беренчеләрдән түгелме? Шул мәкаләгә җавап рәвешендә килгән хатында, ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк, ул «Минем хакта язу җинел түгел, әйе, — дип тәкрарлый. — Мине, минем иҗатымның нечкәлекләрен шактый беләсең. Мин бит кәбестә кебек беркатлы, тоткасыз ишек кебек горур-гасаби. Тоткасын тапмасаң, ишек катында көнә буе басып торуың мөмкин» дип бик дөрес язасың... Ә минем хакта язмау хәерлерәк».

*Гел ышыкта яту җитәр,*
*Керәм давыл уртасына.*
*Кемнең кемлеге күренә*
*Калган чакта ут астында.*
*Яшәвемнең мәгънәләре*
*Чын тормышның үрендәдер.*
*Хәтта күләгә, яктыга*
*Чыксаң гына күренәдер...*

Шаярта Габдерәхим ага. Аһ, катлаулы, аһ, каршылыклы шәхес ул, мин сезгә әйтим. Андыйлар турында «каты күңелле», кайберләренә «кирегә беткән» дә диләр. Ул салкын кайнар һәм кайнар салкын. Хурласалар — мыегы, мактасалар керфеге селкенмәс. Бу хактыр. Әгәр дә аны кемдер рәнҗетсә, нәтиҗәдә фикере кирегә үзгәрсә, ул тоткасыз ишеккә әйләнә дә куя, андыйлар белән аның егерме тугыз ел сәламләшмәве — кул бирмәве мөмкин. Әгәр берәр кеше алдында үзен гаепле тойса, киресенчә, йөрәге өзгәләнеп, гафу үтенү өчен ишек катында инде үзенең егерме тугыз ел басып торуы мөмкин — аның кебек миһербанлы, йомшак күңелле инсан бар микән?.. Бер караганда, аның шигырьләре ачуны китерер дәрәҗәдә бертөрле, тапталган кебек, әмма укып чыгу белән алар һәрвакыт «бертөрлене» яңача ачу белән куандырачаклар. Алар, эчке энергия белән яшәгәч, өстәмә биотуклану чараларын таләп итмиләр, тышкы эффектның нәрсә икәнен дә белмиләр. Кызык килеп чыга: шигырьне кабул итми зарланып өлгермисең, мизгел-ачыштан елмаеп куеп, ялгышканыңа куанасың. Менә шундый диаметраль каршылыклар кушылмасын тәшкил итә аның кешелек фигыле. Ул яраткан әсәрен еламыйча укый алмаган кадерле җанбикәсе — Гамбәриясе белән кышларын Уфада кышлый, җәйләрен Бүздәк төбәгендәге туган авылы Арысланда җәйли. Анда, туган нигез ихатасында, әнисеннән калган керпесе бар. Фәрит үзен дә «керпе малае» дип атый. Хакы да бар. Шактый чәнечкеле, каршыга сыпыручан. Аны кирегә беткән, чәнечкеле кеше дип йөрүчеләр бу атаманы бик тә туры килә дип уйлыйлар. Чынлыкта алай түгел. Түбәндәге шигырьне нәкъ үзе турында язылган диярсең:

*Туры сүзгә каш җыерма. Әйе,*
*Син түгелсең саран, —*
*Юмартсың.*
*Үз кесәсен генә кайгыртучы*
*Мал колыннан бик-бик ераксың...*
*Сорасыннар гына, өстеңдәге*
*Күлмәгеңне салып бирәсең.*
*«Ыштанын да салып бирәчәк бу...» —*
*Бичә бит ул, әйдә, тиргәсен...*

Аның шигърияте дә, үзе кебек, бизәкләүне җене сөйми. Бирелә дә каршылыклар гармониясе. Табигатьнең барча төсләре аның шигъри тукымасында күренмәс халәткә кереп эрегәнгә шулайдыр ул. Шагыйрь төсләрне гүя салават күпере итеп туйганчы

изгән дә, бизәкләрдән мәңгелеккә бизгән. Ул нечкә лирик, әмма тирән хис көн кызуында политологик «уннар-суллар», «сез-без»ләр белән чуарлана башлый. Сорау туа: шигыреңдә Фәрит Габдерәхим кем — сәясәтчеме, лирикмы? Җырчыга тын җитмәү, ирек җитмәүдән зарлану гына сәясәтче ясый аны. Әгәр иле, халкы ирекле булган булса, ул империягә каршы шигъри антибиотиклар җитештермәс, ә бәлки мич башында гүзәл татар кызлары, татар шәрабының шигърияткә булган шифасы турында сокланып язган татар Сәгъдие, татар Гомәр Хәйямы булган булыр иде. Югыйсә, лепкәсеннән аякларындагы тырнак очларына кадәр гражданлык белән сугарылган, хәтта ки авырган, шул гражданлык канәгатьсезлегеннән контузия алган шагыйрь татар лиро-эпик шигъриятенең иң югары өлгеләрен биргән остабыз ләбаса!.. «Башкалар чәчкәнне урырга, Мәҗлесләр корырга сез кирәк. Теш кысып, шәрепләр борырга, Пушкалар корырга без кирәк», ди ул яшь аша елмаеп. Аның иҗаты бәрәкәтле, таратканнан кимеми, такыраймый, киресенчә, арта гына. «Күп медальләр инде чынламыйлар, Чын йөзләре мәгълүм, ниһаять: Күп медальләр медаль түгел икән, Металлары икән — җинаять». Никадәр җинел әйтелгән, әйеме? Бар, әйтеп кара. Габдерәхим иҗаты, әгәр шулай әйтергә яраса, татар шигъриятенең социологиясен, политологиясен һәм политэкономиясен берләштергән этик-эстетик һәм имани-әхлакый фән ул. Мин башка шагыйрьләребездә шигырьдән шигырьгә килгән мондый сәяси тәфсирне хәтерләмим.Сораулар дар агачы кебек конкрет: алгамы-арткамы? дененме-малынмы? җанынмы-тәненме? Мондый үҗәт, баш миен вата торган сораулар вакыт-вакыт укучыны арыткан да кебек: әмма спорт та арыта бит, арыта дип спортны ташлаучы осталар күренми әлегә. Без Фәрит Габдерәхим белән Горбачевның җанатар дәрәҗәсендәге тарафдарлары, моны гына төшенәбез. Әйтик, аның «пәһлевәндәй көчле, әкиятләрне чынга ашырган ил»турында «Артка» дигән тетрәткеч шигыре бар:

*Ул — беренче! Богауларны өзеп,*
*Гаделлеккә таба атлады.*
*Чамалардан чыгып киткән чакта*
*«Мин — беренче!» диеп акланды.*
*Җимешләре озак көттермәде*
*Ашыгуның-кабалануның:*
*Алга чыкты! Башта авыл тойды*
*Ни икәнен җирсез калуның...*

Әйе, бу ил, кулына балта тоткан сукбай-держава, шагыйрь сурәтләвендә хөкемсезнисез кеше ату, асу-кисү буенча, чиркәү-мәчетләр вату буенча беренче урынга чыга. Шулай итеп, бу ил башта табигатьне, аннан халыкның үзен дә буйсындыра. Буйсындырмаган бер нәрсәсе калмый: беренче бит. Елгаларны буып ясаган «электр сазлыклары» арта, Арал, Каспий диңгезләре кибә-корый. Ахырда лагерьлардагы ата-ана назыннан мәхрүм калган милли шагыйрь-җырчыларыбыз да «паспортсыз сукбай»га әйләнә һәм идеал буларак мактала. Шулай итеп, «бездетность» өчен дә салым салган һәм:

*Шикаятьчеләре бик күп булган*
*Мондый илдәй тагын ил кайда?*
*Ата-ана назы ни хәлдәдер,*
*Аборт буенча ул — иң алда.*
*«Мин — беренче!» Күкрәк кага-кага,*
*Син, ахрысы, юкка ашыктың.*
*Алда — упкын! Артка җан-фәрманга!*
*Кату алса алсын касыкны...*

Упкын алдында торган татар шагыйренең күп һәм буш сүз сөйләргә мөмкинлеге юк. Аның фикер хрестоматиясе һәр искәне яңача ача. Сүзләр шомарып беткәнче искергән, ә фикер исә әле генә туган бала кебек янарган. Мондый могҗиза зур,

сирәк шагыйрьләргә генә бирелә. Мондый кыскалык үзеннән-үзе логик тәгәллеккә алып килә. Мондый логик тәгәллеккә, үз чиратында, күпне аңлатырга теләп күп сөйләү түгел, ә аз сөйләп, күпне аңлату аша ирешелә. Сәер күренеш: сатира, сарказм гражданлык лирикасының төп фигурасына әверелә. Укучының авызы чалшаеп катып кала, еларгамы, әллә көләргәме — ул аптырашта сискәнә. Фәрит Габдерәхим нинди дер шаккатырырлык образлар, чагыштырулар, очып барган паласлар эзләп җәфаланмый һәм укучыны да оригинальлек белән җәфаламый. Һәм шигъриятне эчпошыргыч бер «робагый эзләү» җәфасына әйләндерүдән коткара. Ул, югарыда әйтеп киткәнемчә, бар төр ясалмалык, бизәкләрнең дошманы, аның шигыре дә, үзе кебек, бизәк түгел — антибизәк, образ түгел — антиобраз, чагыштыру, метафора түгел, бәлки — античагыштыру, антиметафора. Ул, табиб кебек, һәр күренешкә диагноз куйган булып чыга, гәрчә аңа омтылмаса да, ни өчен дигәндә, ата-анасы, туган җире, кыйналган Ватаны, каны-кардәшләре, укытучылары Тукайлар, Дәрдемәндләр, Сәгыйть Рәми, Салих Баттал һәм Гамил Афзаллар аны шулай тәрбияләгән. Башкача була алмый. Ул яшерен мәгънә, Эзоп теле эзләп вакланмый, турыдан яра һәм мондый турылык бердәнбер дөрес поэтик чара булып чыга. Шуңа күрә дә Габдерәхимдә сүз иң мөһим, иң реаль, бердәнбер чынбарлыкка, санаулы мәртәбәгә әйләнә. Шуның нәтиҗәсендә аның шигырендә исем өчен генә эскәк белән элэктереп күрсәтерлек бер генә буш, урынсыз кулланылган сүз, гыйбарә тапмассың. Ул бирелә аеруча хәстәрле «экономист». «Алла колы» булырга теләмәгән, без Алласыз да яши алабыз, Алла бездсез яшәп карасын, дип мәчет манараларын кискән икенче бер «пролетар экономистлар»дан әче көлеп, ул нибары уналты сүздә менә нинди искиткеч нәтиҗә китереп чыгара:

*«Кешеләрсез торып калды!» диеп*
*И шатланды шайтан, шашкандай.*
*Бездсез Алла — һаман Алла!*
*Ә без?*
*Ә без әйләнгәнбез шайтанга...*

Әйдәгез, шушы күзлектән чыгып, аның уникe генә юллы «Алдану» шигырен шәрехлик. Анда, бер караганда, сүз атлар турында бара сыман:

*«Җитте!» — диде атлар. — Күпме мөмкин*
*Чиләнергә кысан аранда?!»*
*Тышауларын өзеп, кушаяклап*
*Чыгып чапты иркен яланга...*

Яланда иркен, бияләр дә, айгыр затлар да, колыннар да бер гаилә булып тын алалар. Умырып өзәргә сусыл үләннәр, бик теләсәң, татлы чәчкәлекләр тулып ята. Дүрт як кыйбла. Ат көтүчеләр дә күзгә чалынмый:

*Ишетелә: «Ирек! Ирек!» — диеп*
*Йөрәкләрнең бердәм типкәне.*
*Каян белсен атлар бу яланның*
*Бары зуррак утар икәнен...*

Бәй-бәй, бик кызык килеп чыга түгелме соң әле бу? Бая гына иркен ялан иде, хәзер инде иркен ялан дигәнебез нибары мулрак утлар өчен «зуррак утар» гына икән ләбаса! Азакта кызык тагын да үсеп, утта көйдерелгән «сызык»ка әверелә дә куя:

*Атлар хуҗасының йөзе көләч,*
*Ниятләре мәкер-тозаклы.*
*Бер кулында — корык, ә берсендә*
*Яңа тышау — богау йозаклы...*

Туган теленең нечкәлекләреннән киткән кайбер укучыларыбызга «корык»ның ат өстеннән атлар аулый торган җайланма икәнен аңлатканнан соң, сорау куйыйк: нәрсә булып чыга соң бу, ягъни мәсәлән? Бик гади нәрсә: атлар хуҗасы Борис падишаһ Ельцинның Рәсәйнең басып алынган һәм биш гасыр изелгән милләтләренә бирелгән суверенитеты, соныннан энәсеннән-җебенә кадәр тартып алынган һәм таланган милләтләрдән көлеп, «суверенитетлар парады» дип аталган мөстәкыйльлек кәмите хакында булып чыга инде бу нибары уникe юллык шедевр.

Авторның мәҗмугаларында мин укыган мең шигырьнең күбесе менә шундый көчәнешкә ия. Аларның барысын да беррәттән милләт турында язылган бер шигырь итеп кабул итәргә мөмкин. Мин бу мәкаләмне кайсы гына шигырьдән башласам һәм дәвам итсәм дә, анда уннан да артык шигырьгә туктала алмам һәм язмам барыбер шушы калыпта туган булыр иде. Шунысы гына кызганыч, шагыйрьнең китапларында урын алган әсәрләрнең язылмыш еллары күрсәтелмәгән. Авторның иҗат трансформациясен билгеләү авыр. Бер уңайдан шунысын да әйтим: милли нәшриятлар шигъри җыентыкларны басарга әзерләгәндә әсәрләрнең язылу елларын сызып ташлап, авторлар шуңа юл куеп, укучы һәм әдәбият фәне алдында зур җинаять кылалар. Биредә авторның таланты гына коткара: шигырьләрнең кайсысына гына тотынма, һәркайсында казылмыйча табыла торган байлыкларга ия буласың. Аларда ниндидер Майков, Фетларга хас булган «аһ-уһ»лар, чишмә агышыннан туган импульсив кабынуларның эзе дә юк, үзебезчә әйткәндә, «мөхәммәтсадриларча бәйрәмчелек» тә, «әхмәтерикәйләрчә канәгатьчелек» тә тапмассың. Аларда автор бернинди гүзәл чәчкәләр, очраклы пальмалар каршында әсәрләнеп туктап калмый, пенсиягә чыкмый; ул «теге» югары максатка таба хәрәкәттә. Бары тик күнел «фасылына» гына статус бирә. Шуңа да сурәтләп азапланмый, бары тик төшендерә генә. Күпнокталар, өндәүләр бөтенләй юк диярлек. Нокта гына. Анарда нокта да категория белән эш итә. Һәр әсәрне ал да, милләт кадәр милләтнең кардиологик халәте турында фәнни дисссертация яз. Миллионлаган татар Уфасы, югарыдан төшкән ике дәүләти шовинизм шартларында, милли радио-телевидениесез, сәяси-иҗтимагый матбугатсыз, башлангыч, урта һәм югары мәктәпсез гомер кичерергә мәҗбүр булганда бу йөрәк ничек түзә?! Яшерен-батырын түгел, безнең кайбер танылган «лирикларыбыз» гомерләрен язын яшәргән, көзен саргайган яфраклар турында җырлап үткәреп, милләт исе-косы аңкыштырган бер-ике корама корыштыралар да, шуларны гражданлык шигърияте өлгесе итеп ел саен Тукай бәйрәмнәрендә укып куаналар. Әйе, болай да мөмкин, һәркемнең шәхси демократиясе йөрәктәге халәт белән билгеләнә. Моның өчен беркемне дә гаепләп булмый һәм кирәкми дә. Әмма йөрәк бар. Ул 1552 елда чатнаган. Һәм ул чатнаган килеш әле дә тибә! Куанычмы? Куаныч. Үкенечме? Үкенеч. Зармы бу? Зар. Гарьме бу? Гарь. «Ялганчының иле ялган була, Шуннан эзли акыл, тапкырлык. Ачтан үлүчеләр бетү белән «Без — бәхетле!» диеп акырды, — дип икърар итә шагыйрь. — Шаклар каттык, беткәч төрмә Диварлары өелеп... Көенәбез микән, элек Яшәгәнгә сөенеп?»

Фәрит Габдерәхим кебек моңлы-зарлы җырчы өчен Тукайның «бәйрәмнәре» булалмый. Аның өчен Тукайның мәтамнары гына була ала. Әмма мондый шартлылык шагыйрь куанасы урында куана белми торган бер таш бәгырь икән дип уйларга форсат бирми. Киресенчә, куанасы урында ул башка беркемгә дә охшамаганча, балаларча сафлык-садәлек белән сөенә. Хәтта шикләнеп тә куясың: без үзебез Фәрит Габдерәхим шикелле эчкерсез, рыясыз итеп шатлана алабыз микән әле? Аның «Тукай җиле» дигән шигыре бар икән. Минем исә быел яз гына «Тукай җебе» дигән шигырь язганым хәтергә төште. Охшашлыгын кара!.. Махсус эшләсән дә булмас! Ул, сизелүенчә, Горбачев үзгәртеп корулары, Уфада татар милли хәрәкәте оешып киту уңаеннан язылгандыр.

*Төрле җилләр була: җитезләре,*
*Суыклары исә, җылысы.*

*Дөнья башка хәзер,*
*Замананың*
*Кояшлысы килде, җырлысы.*
*Берүк җилләр инде исә булыр*
*Барлык тарафында илемнең.*
*Чү! Ни икән — үксез бөерелә?*
*Өн сибелде: «Тукай җилемен!»*

Бу шигырь унаеннан тагын да искә шул төшә: соң Башкортстанның татар милли хәрәкәтен кичектергесез оештыру буенча минем беренче гамәлем әле ерак 1988 елның август айларында нәкъ шул «Кызыл таң» газетасының Фәрит абзый җитәкләгән әдәбият-сәнгать бүлеге бүлмәсендә булды бит инде! Конспирация саклаган булып күрәсең, редакциягә килгән берничә милләтпәрвәр — Мәсгуть Салихов, Сәид Еникеев, Марат Фәтхерахмановларны икенче күрше бүлмәгә алып кереп, оешма оештыру турында килешкән идек. «Тукай җилен» шунда тойган идек. Ул социаль тигезлекнең кайта башлау җиле иде. Милли мөлкәтебез кая? Саттыкмы? Утка яктыкмы? Әйе, «Мин гаделлек җиле — Тукай җиле!» Шагыйрь бу җилгә шулкадәр куана ки, соңгы утыз елдагы шигъриятебездә Горбачев алып килгән яңарышка бу кадәр куану мисалларын таба да алмыйм кебек. Юк, бездә бу яңарыш турында кычкыру һәм, ул җимерелеп төшкәч, ачыну очраклары булды. Ләкин Фәрит Габдерәхимдәге шикелле чын куану һәм чын гарьләнү очраклары күренмәде кебек. Карагыз, Мәҗит Мөдәрисовлар гасыр башында оешып таралган Уфа «Нур»театрын кабат оештырып җибәрәләр. Куаныч. Фәриттән — шигырь. «Өмет» дигән татар яшьләре газетасы ачыла. Куаныч. Фәриттән — шигырь. «Тулпар» дигән татар әдәби журналы чыга башлый. Фәриттән янә дә шигырь:

*Чая энеләрем тышау*
*Салдыртмаслар сиңа, Тулпар!*
*Үткән, бүген вә киләчәк —*
*Синең мәйдан түгел — утар.*
*Синең йөктә булмас чүп-чар.*
*Җан азыгы булыр Тулпар!*
*Җилдән җитез җилдерәсең,*
*Камчы сөймәс горур Тулпар!*
*Ефәк ялларыңны тарап,*
*Кызларыбыз тагар чуклар...*

Әмма без тагын да алданмабызмы? Сәяси олигархлар безне, изелеп беркатлыга әверелгән автономистларны, бу юлы да читкә тайпылдырмасмы? — дип борчыла автор һәм ул, ирекле Тукай җиленнән исәңгерәгән пәрвәр, шагыйрь, киләчәк һәлакәтебезне алдан сизенеп, дөрес сискәнә:

*Башка бер җил әллә кыланамы*
*Сиңа охшатып, сине кабатлап?*
*Әллә яшьләр,*
*Әллә инде яңгыр*
*Тамчылары ага яңактан...*

Юк, бу җил гадел җил, дөрес җил иде. Ул башка булып кыланмады, үзебез генә кыландык. Булдыра алмадык. Булдыра алмаган бурычлар киләчәккә калды. Бу бурычлар турындагы борчылулар шагыйрьнең «Синең белән мин» дигән китабының азагындагы «Ике Мохтар» һәм «Бөек Иванга ачык хат» дигән поэмаларында ачыла. Соңгысына Салих Батталның «Батый-ханга ачык хат»дигән кин билгеле әсәреннән «Мин ачык хат язам, Батый, сиңа» дигән эпиграф куелган. Әйе, шагыйрь әйтмешли, «һәркемнең үз Иваны булган» кебек, татарда «батыр үлеменен маржадан булуы» да мәгълүм. Мин китапның менә шушы төшенә җиткәч кенә үземне төзәтергә

тиеш таптым: бәй, җил тегермәннәре белән көрәшкән Дон Кихот һәм аның атасы Сервантес дәдәй бурычларын татар шигъриятe язмышында Фәриттән күпкә алдарак Салих абзый Баттал үтәп килгән булган бит. Шигъриятебезнен Равил Фәйзуллиннарын, Мөдәррис Әгъләмнәрен, Зөлфәтләрен, Фәрит Габдерәхимнәрен тәрбияләгән өчен мәңгелек рәхмәт аңа, Остазга.

«Ике Мохтар» — бөек Такташның «Киләчәккә хатлар»поэмасындагы бер «мин»ендә ике «мин» булган Мохтар картның дәвамы. Автор безнең заман Мохтарының бик тә үзенчәлекле образын тудыруга ирешкән. Проблема уртасында татар, татар фигыле, татар әдәбе, татар шәхесе һәм татар инсанияте, аның сыйфат күрсәткечләре ята. Кем идек? Кем булдык? Безгә кая барырга? Алгамы, арткамы? Укучының хәтерендәдер, бәлки, мин «Аргамак» журналының 1991 елның октябрендә чыккан беренче санын «Уфа-Казан поезды: алгамы? арткамы?» дигән публицистик язма белән ачкан идем. Хәзер егерме бер елдан соң укучыга хисап бирәм: халыкка бик кирәк булган бу тәрәккый бәйләнеш чарасы йөрүдән туктатылды. Туганнар туганнары белән күрешә алмый иза чигә. Димәк, Мохтарларның тормыш тәгәрмәчләре артка таба тәгәри. Туктатырга вакыт!.. Соңлап куймыйк!.. Бәлки миңа Фәрит Габдерәхим иҗаты турындагы бу язманы шушы ике кечкенә поэмадан башларга, бар шигъриятен шушы әсәрләр кысасы эченә кертергә кирәк булгандыр. Чөнки «Ике Мохтар» һәм «Бөек Иванга ачык хат» шагыйрьнең иҗат үзенчәлекләрен ачып салган асыл мисаллар. Ярар инде, дим, ничек язылган, шулай калсын.

Татар кешесе, татар инсанының сыйфаты өчен көрәш соңгы елларда, сизгәнсездер, яна баскычка күчте. Моны җанын-тәнең белән кичерергә, икенче Мохтар әйтмешли, «Шайтан коткысына каршы Торучы сирәк икән. Башта мәчетне җанында Төзергә кирәк икән». Күп кенә кәрваннарыбыз мәңгелеккә китеп югалса да, инсан сыйфаты өчен көрәштә шагыйрь күңелен төшерми, барыбызга да ишетелерлек итеп оран сала:

*Тамырлары җитсә күңелләргә,*
*Кырып бетерсәң дә таллыкны,*
*Кабат күтәрелә...*
*Җиңеп була,*
*Буйсындырып булмый халыкны.*

Рәхмәт сиңа, Шагыйрь.

**Айдар ХӘЛИМ**

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез Фәрит Габдерәхимгә 2013 елның 8 гыйнварында 80 яшь тулды. Аны олы юбилее белән тәбрик итәбез, сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.*

# РУХИ–ӘХЛАКЫЙ ЯҢАРЫШКА ТАБА

Гасырлар алмашканда Россия дигән уртак Ватаныбызның сәяси-икътисади, мәдәни-әдәби барышында кискен үзгәрешләр килеп чыкты. Ничәмә-ничә гасырлар дәүләтчелеген югалту ачысын йота-йота толерантлык күрсәтеп яшәгән татар халкының да үзаны уянып китте. Узган тарихта ике мәртәбә — Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверләрендә һәм XX гасыр башында иҗтимагый-мәдәни күтәрелеш кичергән милләтебез кабат талпынып, тернәкләнү, алгарыш өчен көрәш-тартышлар мәйданына аяк басты.

Милләтпәрвәрләребезнең тырышлыгы белән бу уяну, кузгалышның нигез ташлары салынды, совет чорында югалта язган, кыерсытылган телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне, тарихи хәтеребезне, Гаяз Исхакый мирасын халкыбызга кайтару бәхетенә ирешелде. Беренче Президентыбызның фатихасы белән үзебезнең дәүләтле, мәдәниятле халык икәнлегебезне искә төшереп, азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылышыбызны символлаштырып, Кол Шәриф хәзрәтләре хөрмәтенә мәһабәт мәчет бастырып куюу үзенә күрә бер рухи җыну иде. Әмма XX гасырның азагында үзгәртеп кору җилләре белән башланып киткән бу яңарыш хәрәкәтенең гомере, умырзая чәчәгенеке кебек, бик тә кыска булды. Ул яшәешебезнең һәр өлкәсендә, аеруча милли дәүләтчелек атрибутларын сакларга омтылышыбызны, мәгарифне ээзәрлекләгән түнтәрелеш белән алмашынды. «Мәскәү кулында алтатар — татарга!» (М.Мирза) дигән шик-шөбһәле шигарь хакимлек итә башлады. Тарих кабатланып килә, еш кына андагы вакыйгалар, мәдәни-әдәби күренешләр кире әйләнеп кайта диләр. Түнтәрелеш дигән кара заман да үтәр дигән өмет белән яшәп, Тукайча: «Кисмәк өстендә каракош иттифакый (очраклы — Р.К.) кунган ул», диясе килә. Чөнки илдәге вәзгыять никадәр генә җайсыз, каршылыклы булмасын, халкыбызның гасырлар дәвамында тупланган мәдәни-әдәби байлыгы зур, салынган нигез ташлары нык. Әдәби барышның һәр өлкәсендә җигелеп эшләүче талантлы каләм әһелләре дә җитәрлек. Канатлы җайдакларын иярләп, милли мәнфәгатьләрне күздә тотып, Гаяз Исхакыйча, көрәш-тартышларга чакыручы шагыйрь һәм шагыйрәләребез иҗаты аеруча игътибарга лаек. Әдәби иҗат — милли алгарышның беренче шарты дип ихлас инанган күренекле шагыйрьләребезнең берсе — Мөхәммәт Мирза (Ибраһимов Илфак Мирза улы).

Шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе, җөмһүриятебезнең Габдулла Тукай исемендәге бүләк иясе Мөхәммәт Мирза 1953 елның 3 гыйнварында Сталин тоталитаризмы тарих сәхнәсеннән төшкән елда Актаныш районының Чалманарат авылында дөньяга килә. Совет режимының кешелексез юлдашы булган репрессияләр, сугышлар аларның да нәсел-нәсәбен, ата-бабаларын читләтеп үтми. Ике аты һәм дин әһеле (мөәзин) булган бабасы, бай дип тамгаланып, җиде баласын ятим калдырып, атып үтерелә. Оста биюе белән дан тоткан әтисе дә унҗиде яше тулуга фронтка озатыла, Киев өчен барган сугышларда Днепрны кичкәндә унсигез яше тулган көнне ике аягын өзләрә; туган туфракка кайтып егылгач та, 41 ел дәвамында тимер протезларда йөри; мәктәптә тарих укыта, шактый еллар директор, беркадәр вакыт авыл советы секретаре вазифасын да башкара. Бала арбасы тартып колхоз эшенә йөргән, искиткеч булганлыгы, уңганлыгы белән авылда дан тоткан хатыны Мөсәвәрә белән алар унбер бала тәрбияләп үстерәләр, аларның барысына да югары белем бирәләр. Ата-аналарының бу фидакарьлеге, оста рәссам ясаган картиналардагы кебек, Мөхәммәт Мирзаның шигырьләрендә дә чагылыш тапкан. Балачакта әнисенең «итәгенә ябышып», ни рәвешле кырдан кайтып килүләрен ул болай тасвирлый: *«Күз алдында җуелмаслык сурәт: / Бер менеп, бер төшеп буразнасын, / Басу буйлап әни кайтып килә, / Индә чалгы, кулда — кул арбасы».* «Әнкәй» дигән Бөек Йолдыз» образы шагыйрьнең гомер һәм иҗат юлын бүген дә яктыртып тора. Сынмас рухлы, көчле шәхес итеп сурәтләнгән, аякларын югалткан әтисе образы да җанны тетрәтә: «Протезларын салып куйган әти... / Тубыкланып атлап килде дә, / Алмаш-тилмәш безне күккә чөйде: / Бөркетләрем минем! — диде дә». Бу шигырь юлларын укыгач та, ихтыярсыз Нәҗип Думавиның «Ватан каһарманы, яки Агач аяк» хикәясендәге Шакир солдат образы искә төшә. Беренче бөтендөнья сугышыннан каты яраланып, авылга кайткан, улларын-кызларын ач үлемнән саклый алмаган, актык урагын

да закладка салган Шакир — бик тә кызганыч агач аяклы солдат. Икенче бөтендөнья сугышыннан тимер аяклар белән кайткан Мирзамөхәммәт исә соңгы көннәренә кадәр хатыны, балалары өчен абруйлы Ата, зур гаиләнең матди һәм рухи терәге булып кала. Әтисенең рухи биеклеге алдында баш игән шагыйрь Илфак Ибраһимов үзенең көньясен — тәхәллүсен дә Шәрекъ мәдәни дөньясында кабул ителгән этикет (әдәб) кагыйдәсе буенча «Мөхәммәт Мирза» дип кабул итә. Әтисе тәэсирендә яшь Илфак әдәбиятка тартыла, Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим шигырьләрен күңеленә сеңдерә; каләм тибрәтә башлый; армиядә хезмәт иткәндә дә шигърият белән кызыксынуын дәвам итә. Мәдәният институтының театр сәнгате-режиссура бүлеген тәмамлагач та (1975), Актанышта җирле радио-тапшырулар редакциясе мөхәррире, комсомол оешмасының беренче секретаре, эчке эшләр бүлегендә урынбасар, мәдәният бүлеге мөдире булып эшли, «Агыйдел дулкыннары» исемле әдәби иҗат оешмасын да әйдәп бара. Җитәкчелек эшендә шактый тәҗрибә туплаган белгеч буларак, Мөхәммәт Мирза Казанга күчерелә, дүрт ел Мәдәният министрлыгында урынбасар, җиде ел дәвамында Татарстан язучылар берлеге идарәсенең рәисе вазифасын башкара. Бүгенге көндә ул — кабат торгызылган, әмма кыска гына вакыт аралыгында тарихыбыз, мәдәни-әдәби хәрәкәтебез турында эчтәлекле материаллар белән укучыларның игътибарын җәлеп иткән «Чын мирас» журналы мөхәррире.

Мөхәммәт Мирза шигърияткә өлкәнәйгәч, зур тормыш тәҗрибәсе туплап килде. Шуңа күрә еш кына үзенең язмаларында ул «мин — көзге шигырь», «Шагыйрьгә: сонардын» димәгез» дип, укучыны кисәтеп куя. Анынча, «көз ул — дөньяны танып белү, күз утыру, кирәкмәгән әйберләрне читкә кую». Аның бу фикеренә каршы чыгып, Ркаил Зәйдулла «шигърияттә биологик яшьнең әһәмияте юк. Туксанда да тупсада ятарга, алтыда алтын тәхеткә менәргә мөмкин», — дип яза. Әйе, моның шулай икәнлегенә дөнья һәм татар әдәбияты тарихыннан күп мисаллар китерергә мөмкин. Мәсәлән, Тукай бик тә иртә, гомеренең язында ук кулына каләм ала, язларда ук китеп бара. Сибгат Хәким гомер кояшы язлардан җәйләргә күчкәндә, Нури Арсланов җәйләрдән көзләргә аяк басканда шагыйрьлек таҗын кияләр. Фарсы-таҗик Ренессанс әдәбиятының бөек шагыйре Сәгъди «Бостан», «Гөлстан» кебек мәшһүр әсәрләрен гомеренең көзендә генә — ничәмә-ничә дистә еллар сәфәрләрдә үткәреп, Ватаны Ширазга кайтып егылгач кына тәмамлый. Аурупаның даһи шагыйре Гёте үзенең атаклы Көнбатыш-Көнчыгыш диванын бик тә яшь Марианна исемле артисткага гашыйк булып, 70 яшендә генә иҗат итә. Таланты белән Гётены әсир иткән Габдрахман Җами үзенә дөньякүләм танылу алып килгән, җиде поэманы берләштергән «Җидегән йолдыз»ын гомеренең «алтын көзендә» 60-80 яшьләр арасында язган. Шагыйребез Мөхәммәт Мирзаның алтын көзләре әле алда; әлегә ул, шәрекъчә әйтсәк, «гомер муенса»сының уртасында гына.

Узган гасырның сиксәненче елларында Мөхәммәт Мирза шактый уңышлы каләм тибрәтә. Туксанынчы еллар — шагыйрьнең жанрлар, сәнгатьчә фикерләү, дөньяга карашлар өлкәсендә үз алым-ысулларын, үз кыйбласын эзләгән чор. Аның хыял-максаты — «канатлы ат»та җилдереп, шигърият биеклекләренә күтәрелү: *«Толпарымны табасы бар. / Күтәрелеп Парнасыма, / Ир-ат исемен аласым бар»*. СССР таркалган, иҗтимагый формацияләр, идеологияләр алмашкан һәм дә сүз ирегенә күк капуслары ачылып киткән бу чорда аның «Кәккүк тавышын санадым» (1994), «Турайгыр» (1998) кебек шигъри җыентыклары дөнья күрә. Россия империясенең рус булмаган халыкларны изү, юк итү сәясәте төрле жанр, тема, мотивларны берләштергән «Турайгыр» китабында постмодернистларча ачыктан-ачык, үтә кискен бәяләмәләр белән кире кагыла. Автор үткән тарихта шәһри Казанны яндырган, «биш гасыр кызыл кар яудырган», татар халкына вәхшидән-вәхши яу оештырган Явыз Иванны да, яңа заманда Чечня халкын канга батырган, үз илендә гражданнар сугышы башлап җибәргән, «дөньякүләм палачка» әйләнгән Борис патшаны да борынгы грекларга хас булган чәнечкеле бик тә усал, ачулы сардоник һөҗү белән тәнкыйтьли итә. Татар тарихының, Идел йортның авыр сәхифәләре миниатюр сюжетларга, рецептив эстетика канунnarына корылган поэмаларда тәэсирле итеп укучы аңына җиткерелә; сталинизм дәверендәге рәхимсез сыйнфый көрәшнең ничек итеп якташларына, авылдашларына, туган-тумачаларына, хәтта хуҗаларыннан тартып алынган атларга — Турайгырларга фаҗигаләр алып килүе нарратив (хикәяләү)

поэтика һәм тирән психологик кичерешләр ярдәмендә ачып бирелә. Сиксәненче еллар азагыннан милли яшәешебездә башланган унай үзгәрешләр дә автор игътибарыннан читтә калмаган. Ул ихлас күнелдән мәдәни-әдәби кыйммәтләрнен — Идегәй дастанынын, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Гаяз Исхакый кебек каһарман затларнын исемнәре һәм иҗатлары халкыбызга әйләнеп кайтуга куана, остазы Рөстәм Мингалим, зыялы замандашлары, сәнгать әһелләре, якыннары турында язылган шигырьләрен милли сагыш һәм гамьнәр белән үрелгән якты лирик буяуларда сурәтли.

XXI гасырнын беренче ун елы — Мөхәммәт Мирза иҗатынын яна шигъри жанрлар үзләштерү һәм фәлсәфилеккә таба юл алу чоры. Ул бер-бер артлы «Киек каз юлында» (2003), «Тере су» (2007), «Адәм баласы», «Агыйделдә ак пароход» (2009), «Гыйбарәләр» (2010), «За той рекой» — «Елганын аргы ягында» (2011, рус һәм татар телләрендә) исемле китапларын бастырып чыгарды. Шигырьләренен байтагы башкорт, төрек, рус, инглиз телләренә тәржемә ителде.

Мөхәммәт Мирза шигъриятенен кителмәгәнчә өр-яна сыйфатлар белән баюында заманаларнын үзгәрүе, дәһри совет режимынын сәхнәдән төшеп, тыелган ислам мәдәнияте кыйммәтләренен, Коръән тәгълиматынын реабилитацияләнүе зур әһәмияткә ия булды. Аксиома рәвешен алган бер кагыйдә бар: кайда гына булмасын, Шәрекъ һәм Гареб халыкларынын дөньяви алгарышы кайчандыр ниндидер сәбәпләр белән юкка чыккан традицияләрне кире кайтарудан һәм дини Яңарыштан башлана. Монын шулай икәнлегенә төшенгән шагыйрь әле гасырлар чигендә «Мәнгелек сорау» исемле дүртьюллыгында болай дип язган иде: *«Гел яңаны эзләп табабызмы, / Табып югалтканны күптәннән? / Киләчәккә таба барабызмы, / Кайтып киләбезме үткәннән?»*

Тирән эчтәлекле, универсаль яңгырашлы, вакыт агышын өч яссылыкта (үткән, бүген, киләчәк) постмодернистларча үреп биргән бу шигъри юллар Мөхәммәт Мирза иҗатынын асыл мәгънәсен аңлауга ярдәм итүче ачкыч вазифасын үти. Юкка гына ул аны «Тере су» китабынын тышлыгында үзенен төп иҗат шигаре рәвешендә кабат урнаштырмаган. Дөрестән дә, халкыбыз кайчандыр бабаларыбыз Шәрекътәге ерак тарихтан, мөселман мәдәнияте жирлегеннән тапкан, «яңа» дип «кабул иткән», аннары «югалткан» кыйблабызга кайтып килә; Коръәни Кәрим белән ингән рухи кыйммәтләрне һәм ислам әдәбиятларынын (гарәп, фарсы, төрки) һәр өч юнәлеше — дини-әхлакый, суфичылык, дөньяви Яңарыш әдәбиятларына хас казанышларны яңабаштан иҗади үзләштерергә омтыла.

«Тере су» шигъри җыентыгынын исеме символик яңгырашлы. Геологларнын гыйльми язмаларына таянып, автор гасырлар дәвамында мәнгелек бозлавыкны ашап, тишеп, боз катламнары карнында күлләр ясап, вулканнардай ярсып, дингез-океаннарга ыргылучы тере су образында тарихи барышта мәнгелек хәрәкәттә булган, авырлыкларны җиңеп алга баручы Кеше образын символлаштыра, анын җирдәге миссиясенә мәдхия укый. Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтәргә кирәк: Шәрекъ классик әдәбиятында, мәсәлән, Низами Ганҗәви иҗатында анын икенче мәгънәсе дә очрый: «Тере су» иҗат кешесе каләменнән тамган, хәрефләр дулкыны сыман агып барган уй-фикерләр һәм хис-кичерешләр.

Жанрлар төзелеше ягыннан китап үзенчәлекле: анда берьюллыклардан башлап, сигезьюллык шигырьләргә кадәр бирелгән. Кош теледәй кыска мәкаль-әйтемгә тартым берәмлекме ул, фәрдләр — икеюллык бәйтләрме, өчьюллыклармы, дүртьюллыклармы, робагыйларммы — аларнын үз эчендә дә төрле бүленешләр һәм төсмерләр яши. Шагыйрьнен дүртьюллыклары Рудакинын миниатюр драмаларына, Хәйямнын кителмәгән чишелеш тәкъдим иткән новелла-робагыйларына охшаганнар да, охшамаганнар да. Аларда Урта гасыр Шәрекъ әдәбиятларында бик популяр булган әдәб жанрлары традицияләренә таянып, үзебезнен милли мәнфәгатьләрне искә алып, рухи яңарышка чакыру, фәлсәфи-этик фикер әйтү көчле.

Әдәби традицияләр күзлегеннән караганда да, «Тере су» китабы күп тармаклы: ул төрки-татарларнын сүз сәнгате хәзинәсенә, Коръән тәгълиматына, Шәрекъ Ренессанс әдәбиятына, акыллы, хикмәтле сүз әйтүгә, фәнни-фәлсәфи фикерләргә, әдәб жанрындагыча үгет-нәсыйхәт белән үрелгән рухи кыйммәтләргә нигезләнгән. Шуна күрә автор үзе дә: «...Мин барлык кыйммәтләрне / Шигырь бизмәненә / Салып үлчим хәзер...», — ди.

Ислам мәдәниятенең үзеген тәшкил иткән төп кыйммәт — Акыл. Мөселман фәлсәфәсе буенча да Аллаһы Тәгалә иң элек Акылны яраткан, диелә: «Әүвәлү ма халәкә Аллаһу әл-Акла». Акылның даими юлдашы итеп гыйлем, белем күрсәтелә. Акыл белән гыйлем үзенең тышчасы сүзләр ярдәмендә генә яши ала дип аңлатыла. Сүз сәнгате дигәндә ислам дөньясында иң элек Коръән өйрәтмәләре күздә тотыла.

Шагыйрьнең газәл, робагый һәм гыйбарәләрендә Коръәннең асылын тәшкил иткән әт-Тәүхид (монотеизм) фәлсәфәсенә ихлас ышануны белдергән юллар байтак очрый. «Бар халыклар, илләр, галәмнәр өчен, — ди ул, — бергә генә бердәнбер — Бер Хак Тәгалә — Аллаһы үзе генә. Шагыйрьнең «Тере су» китабындагы газәл лирикасы да, андагы гыйшык җырлары да, гарәпләрнең касыйдә жанрындагыча, Аллаһы Тәгаләгә мәдех укудан башланып китә: *«Фатихасыз бер көнем дә торалмам, / Ил көнемә иминлек бир, Бер Аллам. / Ун кыл юлын бөтен нәсел-ыруның, / Кодрәтең киң, рәхмәтең зур, Бер Аллам»*.

Дөньяны акыл һәм хисләр белән хаклыкны танып белергә юллар ачкан, рухи камиллек баскычларына күтәргән, бәхетле иҗат мизгелләре бүләк иткән Аллаһыга лирик герой бик тә рәхмәтле. Икенче бер газәлендә ул Бөек Кодрәт иясенең Коръәни Кәрим ярдәмендә гөнаһлы җир кешеләренең тәүбә итеп Хак юлына аяк басуларыннан хозурлык кичерә: *«Коръән — бел, хаклык үрнәге бердәнбер, / Раббым мәңгелек нурына төргәндер»*.

Изге Китап күрсәтмәләренең кеше табигатен уңай якка үзгәртү һәм Илаһият капкаларын ачудагы әһәмияте күкләрдәге нәкышле яктылык балкышын хәтерләткән гарәп хәрефләре ярдәмендә хикмәтле сүз әйтүгә корылган гыйбарәләрдә ассызыклана:«Коръән кяферлеккә киртә куеп, тәүбә иттереп, оҗмахка илтә...»

Иҗат психологиясен дә автор шагыйрьгә күкләрдән ингән илһам — нур рәвешендә аңлата: «Шагыйрьнең китабы бергә генә була. Бөтен гомере буе язган барлык шигырьләренең иң асыллары, илаһының нурына манып язылганнары, тупланганы...» Илаһиятнең мәңгелек бер кыйммәте булган сүз сәнгате турындагы карашлар сигезъюллыкларда Низами һәм Котб поэмаларындагыча чагылыш таба: *«Шигырь, дустым, Илаһының / Җанга биргән сулышы!»* Бакыйлыкка күчкәндә дә ул илаһият нурларының үзенә юлдаш булуын тели: *«Балкыт илаһыдан килгән нурыңны, / Яктырт мәңгелеккә күчәр юлымны!»*

Дини кыйммәтләр белән бәйле тагын бер мотив — шагыйрь иҗатының буеннан-буена төрле мәгънәви төсмерләрдә кабатланып килүче иман сафлыгы мәсьәләсе. Иман Аллаһы күрсәтмәләренә, пәйгамбәребез сөннәтенә турылыклы лирик геройның җир йөзендәге имин яшәешен тәэмин итә: *«Ил-йортым киң, ризыгым мул, рухым шат, / Юлым ачык — хилафсыз иманыма»*.

Милли-рухи янарыш мәсьәләләрен хәл итү өчен дә һәрдаим Иман кирәк: Коръәндә кырыктан артык искә алынган «иман» төшенчәсе, анынча, төрле бәла-казалардан — «шайтаннар, сихерчеләр, имчеләр хәйләсеннән саклану өчен иң үтемле чара». Дөньядагы матди байлыклар бүген бар булып, иртәгә юкка чыгарга мөмкиннәр. Ә дингә ышану, иманлы булу — мәңгелек хәзинә: *«Байлык — бер айлыктыр, / Ярлылык — гомерлек... / Адәм баласына / Бетмәс байлык — Иман, / Оҗмахка керерлек»*. Шуңа күрә ул замандашларына да: *«Каршылыйк / Киләчәкне якты өмет / Иман белән»* дип мөрәҗәгать итә.

Яшәү фәлсәфәсен бу рәвешчә Алла, Коръән тәгълиматы, иман төшенчәсе, шагыйрьгә илаһияттән ингән илһам кебек тема-мотивлар тирәсенә туплап, милләттәшләребезгә дә дини-әхлакый, мәдәни таяныч һәм яшәү үрнәге итеп тәкъдим итү — Мөхәммәт Мирза шигъриятe өчен дә, бүгенге татар әдәбияты өчен яңа күренеш иде. Чынбарлыкта исә, бу — урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларының төрле жанрларында киң таралыш тапкан, матур әдәбият белән фәлсәфә арасында торган куәтле һәм нәзакәтле әдәб жанрының яңа тарихи шартларда калкып чыгуы.

Мөхәммәт Мирзаның газәлләрендә дә полифоник яңгырашлы яшәү фәлсәфәсе өстенлек итә. Бер төркем газәлләрдә Алла, Иман, күкләр һәм җир, кешенең җирдәге миссиясе, ахырзаман кебек эсхатологик темаларга бәйле кичерешләре чагылдырылса, икенчеләрендә Коръәндәгечә Илаһияттән ерагайта торган бозык гамәлләр — антикыйммәтләр турында сүз алып барыла; өченчеләре исә дөньяны ыгы-зыгылы, алыш-бирешле базар, бертуктамый әйләнеп торучы сәхнә-тамаша итеп күз алдына

китереп бастыра; дүртенчеләрендә вакыт төшенчәсе һәм кеше гомере, ел фасыллары турындагы уй-кичерешләр бирелә; бишенчеләрендә дәүләте булмаган «качып китмәс, баш күтәрмәс» эш аты булган кардәшнен туземлеге калмыйча, «Бәйнәлмилал» жырына ишарә-аллюзия ясап: «Тор, күтәрел, милләт!» «бусагада яна гасыр», «мен дә бер богауны өзеп орыйкмы» икән әллә дип, «төштән сон» гына акылга килгән татар кешесенен уйланулары бирелә. «Хәтердән чыкмас кара кан исе» һәм йөрәктә «йөз яра» калдырган Октябрь түнтәрелешенә дә ижтимагый-сәяси эчтәлекле махсус газәл багышланган.

Саф мәхәббәт темасын яктырткан газәлләр Мөхәммәт Мирза лирикасында әлләни күп түгел. Аларнын булганнары да фарсы һәм төркиләрнен Ренессанс дәвере газәлләреннән нык аерыла. Анда суфичылык шигърияте́ндә кин кулланылышта булган, Алла белән берләшүне, кушылуны символлаштырган, йә булмаса, дөньяви эчтәлекле Хәйәм, Хафиз робагый һәм газәлләрендәгечә матур табигать кочагында сөйгән ярлар белән шәраб эчеп утыру кебек гедонистларча бирелгән һәм битарафлык, ваемсызлыкка өндәгән, ләззәтле жан тынычлыгына чакырган эпикурчылык мотивлары очрамый. Гашыйклыктан авыруга сабышу, ә аннан мәжнүнгә әйләнү халәтен гәүдәләндерү дә күзәтелми. Шагыйрьнен Аллаһынын барлыгына һәм Берлегенә мәдех укыган, Коръән өйрәтмәләренә таянып, замандашларын рухи янарырга чакырган газәлләре, әйткәнебезчә, XXI гасыр башы татар шигърияте өчен үзенә күрә бер ачыш булды. Дөньяви мәхәббәт темасына, мәсәлән, гомер юлдашына багышланган газәлләрдә дә интим хисләр «әдәп-сафлык», итагатьлелек кысаларында садә, серле, нәфис, «ап-ак жилкәнле кораб» образында чагылыш таба: *«Татлыдан да татлырак ни жиһанда — / Учларыннан чишмә суын эчкән дә!..»* Сәнгатьчә фикерләүнең матур үрнәге булган мондый тыйнак сурәтлелеккә корылган бәйтләрне шагыйрь газәлләреннән күпләп китереп булыр иде.

XX һәм XXI гасырлар аралыгында марксистик идеология белән бәйле карашларнын әһәмияте юкка чыгу, Коръән тәгълиматы әйләнеп кайту аксиологик кыйммәтләргә игътибарны бермә-бер көчәйтеп жибәрде. Философлар гына түгел, башка гуманитар фәннәр белгечләре дә, дәррәү кузгалып, рухи-әхлакый кыйммәтләрне өйрәнү эшенә керештеләр. Ижтимагый-мәдәни яшәешебезнен көзгесе булган аксиологик кыйммәтләргә татар әдәбиятында да игътибар артты. Милли ихтыяжларга жавап бирү максатын күздә тотып, татар һәм шәрекъ халыкларынын акыл жәүһәрләрен ижади эшкәртү нигезендә Мөхәммәт Мирзанын «Мен дә бер гыйбарә» исемле китабы дөнья күрде. 5 бүлектән, 31 бүлекчәдән торган, тематик принцип буенча оя-оя итеп тезелгән бу гыйбарәләр китабын аксиологик сүзлек дип кабул итәргә мөмкин. Алла — Кеше — Жәмгыять триадасын, дөньяви һәм дини этика, әдәби ижат психологиясе кебек бик күп мәсьәләләрне эченә алган бу чәчмә, ярым шигъри афоризм, хикмәтле сүз, мәкаль-әйтемнәрне парлы аксиологик кыйммәтләр күзлегеннән өйрәнү, безнеңчә аеруча отышлы (мәсәлән, Аллага ышану — имансызлык, ата-ананы, туганнарны, кешеләрне хөрмәт итү — мин-минлек, тәкәбберлек, нарциссизм; яшәү — үлем; елау — көлү, бәхет — мескенлек, дуслык — дошманлык, тугрылык — хыянәт, миллилек — манкортлык, байлык — мохтажлык, юмартлык — саранлык һ.б.). Шул ук вакытта бу гыйбарәләрне Коръән өйрәтмәләренә туры килмәгән, Аллаһы Тәгалә кабул итмәгән антикыйммәтләр күзлегеннән дә барлап була (миһербансызлык, кяферлек, иблислек, усаллык, гайбәт сөйләү, хәйләкәрлек, комсызлык, куркаклык, ахмаклык, исереклек, ялкаулык, әрсезлек, хөсетлек, мәнсезлек, мактанчыклык, булдыксызлык, караклык һ.б.).

Гыйбарәләр жанры турында әдәбият белемендә төрле фикерләр әйтелгән. Берәүләрчә, чәчмә сүз белән язылып та, теге яки бу гыйбарә укучыда тирән уй-фикер һәм хис-кичереш уята икән, аны тулы хокуклы шигырь дип атарга кирәк. Икенче берәүләр дөньяны танып белүнен бер төре булган мондый гыйбарәләр анлатмалы сүзлек алымына карый диделәр. Габдулла Тукай ижатында, аеруча анын сатирасында, күләм ягыннан шактый зур урын алып торган бу жанр галимнәребез тарафыннан шул күзлектән чыгып өйрәнелде, дөнья әдәбияты тарихында бик күп язучыларнын (мәсәлән, Сәгъди белән Заканинын) анлатмалы сүзлек алымыннан оста файдаланганлыгы билгеләп үтелде. Кабат шуны ассызыклыйбыз: бу хикмәтле, фәлсәфи, канатлы афоризмнар, акыллы чәчмә һәм шигъри гыйбарәләр — урта гасыр Шәрекъ һәм татар әдәбиятларында тамырлары тирән булган, безнен заманда исә архетип булып үсеп чыккан күп тамырлы әдәб әдәбиятынын бер тармагы. Аурупа һәм рус әдәбият белеме күзлегеннән караганда

бу гыйбарәләрне XX гасырда пәйда булган постмодернистик әдәбиятның бер юнәлеше — концептуализм күренеше итеп тә карарга мөмкин.

«Гыйбарәләр» китабындагы «Һәр хәрефкә — бер фикер» циклы авторның аксиологик кыйммәтләр турындагы уй-фикерләренең һәм хис-кичерешләренең гәүдәләнеше булып тора. Рухи кыйммәт — акыл белән җан диалектикасы (Ибн Сина) дигән фикерне ул «Р» хәрефеннән башланган «Рух» төшенчәсе ярдәмендә түбәндәгечә аңлата: *«Рух — кеше җанының, халыкның, кешелекнең халәте... Ул ике дөнья арадашчысы... Рух үлемсез»*. Кеше рухының, рухи кыйммәтләрнең үлемсезлеге турындагы бу фикер һәр заман өчен аксиома вазифасын үтәүдән туктамаячак.

«Гыйбарәләр» китабында Аллаһы Тәгаләнең «илаһи каләм» балкышыннан нур алган иҗат әһелләре эшчәнлегенә, аларның җир кешеләренең рухын яңартудагы миссиясенә югары бәя бирелә. Мөхәммәт Мирза фикеренчә, *«Чын Иҗат — Аллаһы рәхмәте һәм фатихасы, Аллаһы фатихасын алган иҗатчы — пәйгамбәр»*. Коръәндәге аерым сүрә һәм аятьләргә нигезләнеп, шагыйрьләрне пәйгамбәрләр белән янәшә кую урынлымы, әллә ширк эшме, бу турыда әледән-әле бәхәсләр дә туып тора. Авторның югарыда әйтелгән сүзләре дә шик-шөбһә тудырырга мөмкин. Әмма аның бу хакта үз фикере бар: *«Шагыйрьне олылау һәм пәйгамбәргә тиңләү — һич кенә дә икенчесен кечерәйтү түгел»*. Сүз сөрешен дәвам итеп, шагыйрь бу хактагы фикерен тагы да ачыклый төшә: «Пәйгамбәрләр мең елга бер генә туа. Үзеннән соң иҗаты йөз ел яшәгәннәр дә — пәйгамбәр!..». Бөтендөнья әдәбияты, шул исәптән, шәркый мөселман әдәбиятлары тарихында да «шагыйрь — пәйгамбәр» мотивы гасырдан гасырга, сүз сәнгате осталарының буыныннан буынына, үзебезнең Р.Фәйзуллин, Р.Гаташ, М.Әгъләмов, Зөлфәтләргәчә даими рәвештә кабатланып килә. Коръәндә исә «Мөхәммәд пәйгамбәр — шагыйрь түгел» дигән кире кагуга нигезләнгән аять гарәпләр тарихындагы ислам динен тарату өчен барган авыр һәм җаваплы заманда Аллаһының илчесен һәм Рәсүлен мәҗүси гарәпләрнең каһинлык, ягъни күрәзәчелек сыйфатлары булган шагыйрь-хатыйбларыннан аралау, Мөхәммәд пәйгамбәрнең бөек Ислахчы һәм Инкыйлабчы буларак азгынлык, бозыклык белән тулган бәдәви гарәпләр дөньясын рухи-әхлакый яктан «яңадан тудыру» миссиясенә аяк чалмау максатыннан әйтелгән (69:40). Гомумән алганда, Коръәндә шигърияткә каршы юнәлтелгән фикер юк. Анда бары тик бәдәви гарәпләренең исламга кадәрге поэзиясендә, мәсәлән, Имрәэл-кайсның кайбер шигырьләрендәгечә, тотнаксыз хисләрне чагылдырган әсәрләре генә кире кагыла. Мөхәммәд пәйгамбәр үзе дә шигъриятне тормыш тәҗрибәсе чагылышы, акыл җәүһәрләре хәзинәсе итеп караган. Аның бу фикере хәдисләрдә дә теркәлеп калган. Пәйгамбәребезнең шагыйрьләр арасында дуслары да булган. Кәгыб бине Зөһәйр исемле шагыйрь пәйгамбәребезгә «Бурда» касыйдәсен укыгач та, аңа үзенең бер төзәтмәсен дә керткән.

Мөхәммәт Мирзаның кайсы гына китабына күз салсак та, аларның һәркайсында ул акыллы сүз әйтү ысулы белән халкы, милләте алдындагы җаваплылыгы турында сүз алып бара һәм һәрвакыттагыча шагыйрьләрнең иҗтимагый-мәдәни яшәештәге вазифасын пәйгамбәрлек миссиясеннән аерып карамый.

Мөхәммәт Мирза шигъриятенең югары ноктасы — «Адәм баласы» дип аталган бишьюллыклар бәйләме. Соңрак бу цикл төрле телләргә тәрҗемә ителеп, аерым китап рәвешендә дә басылып чыкты. Әдәбият сөючеләр аны гаҗәпләнү катыш зур кызыксыну белән каршы алдылар. Бу нинди шигырьләр? Татар шигърияте өчен алар ачышмы? Әллә кайчандыр булган, әмма бүген онытылган шигъри традицияләрне заманга ярашлы итеп интертекстуаль алымнар белән яңартып кайтарып бирүме? Язучылар, әдәбият һәм фәлсәфә галимнәре бу хакта үзләренең игътибарга лаек байтак кына фикерләрен дә әйттеләр. Әдәбиятчы Фәридә Хәсәнова бу оригиналь бишьюллыкларның строфа төзелешендә япон танкасы жанры чалымнарын тапты, философ Айдар Юзиев исә аларның шәрекъ мөселман әдәбиятларындагы әдәб жанрындагыча фәлсәфи-дидактик фикер йөртүгә юнәлтелгәнлеген ачыклады. «Адәм баласы» китабындагы шигырьләрдә күтәрелгән мәсьәләләр, аларның әдәби-эстетик һәм этик табигате, жанры һәм строфа үзенчәлекләре турында мәкалә авторы да озак уйланды, Евразия халыкларының шигырь төзелешенә караган байтак хезмәтләр белән танышты.

Коръән өйрәтмәләре буенча, Адәм — җирдәге беренче Кеше һәм пәйгамбәр. Шайтан

коткысы аркасында Адәм белән Һава, Аллаһы кисәтүләрен онытып, мәңгелек агачы җимешләрен ашап, үлемсез булабыз дип, рухи һәлакәткә илтә торган явызлык агачыннан авыз итәләр, шул сәбәпле оҗмахтан куылалар, авыр сынауларга дучар булалар. Мөхәммәт Мирза иҗади шәрехләгән Адәм исә — кешелек җәмгыятенең җыелма образы.

Кешеләрне рухи камиллеккә чакыру, иҗтимагый һәм көндәлек яшәештә яңарырга өндәү — «Адәм баласы» китабының әйдәп баручы бер мотивы. Шуңа күрә дә аны урта гасырлардагы шәрекъ һәм татар әдәбиятларыннан XXI гасырга әйләнеп кайткан, патшалардан башлап сарай хезмәтчеләренең һәркайсы белергә тиеш әдәб әдәбияты традицияләренең Мөхәммәт Мирза иҗатында иҗади чагылышы дияргә мөмкин.

Изге Китаптагыча, шагыйрь «Адәм балалары» циклының үзәгенә изгелек һәм явызлык турындагы рухи кыйммәтләрне куя. Бишьюллы строфаның кыл уртасына Коръәннең 7 нче сүрәсендәге 26-27, 31, 35 нче аятьләрдә рефрен кебек кабатланган, гарәпчә «Иәә бәнии Адәмә» анафорасыннан алынган, татарчага «Адәм баласы» дип үзгәртелгән рефренны урнаштыра. Әмма академик М.Б.Пиотровский бу стилистик чараны анафора дип түгел, рефрен дип атый.

Гомумән алганда, Мөхәммәт Мирзаның «Адәм баласы» циклындагы алтышар иҗекле бишьюллыклар турында түбәндәге нәтиҗәне тәкъдим итәргә мөмкин: сәнгатьчә фикерләүнең яңалыгы белән укучыларның игътибарын җәлеп иткән, акыл-гыйлем культына корылган бу шигырьләр — гарәп-фарсыларның, төрки-татарларның дүртьюллыкларыннан, робагыйларыннан, мөрәббәгъләреннән үсеп чыккан, кешелек җәмгыятенә «адәм балалары» дигән шигарь-мөрәҗәгать белән матур билбаусыман строфа уртасына кертеп утыртылган, монарчы шигырь язу практикасында һәм теориясендә күзәтелмәгән рефренның яңа төре һәм дә зур гомумиләштерү көченә ия булган, Коръән тәгълиматына таянып, рухи Яңарыш идеяләрен, гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөргән, гуманистик эчтәлекле фәнни, фәлсәфи-эстетик, этик зарурияТләрне чагылдырган уникаль жанр һәм авторның олы ачышы.

Мөселманнарның үгет-нәсыйхәт белән бәйле әдәб әдәбияты традицияләренең һәм интеллектуаль башлангычның көчле булуы «Адәм баласы» циклындагы бишьюллыкларның эчтәлеген аңлауда киеренкелек тә тудырырга мөмкин. Гадәттә, мондый шигырьләр гасырлар алмашканда, дөньяга карашлар үзгәргәндә мәйданга чыга. Нәкъ менә шундый хәл XX гасыр башы татар әдәбият белемендә күзәтелгән һәм «Тукай шагыйрьме, түгелме?» дигән бәхәсләргә сәбәп булган иде. Дөньяны танып белүнең һәм сәнгатьчә гәүдәләндерүнең йә акыл, йә хис культына өстенлек бирү, йә булмаса, аларның һәр икесен дә аерылгысыз бербөтен итеп синтезлап, Гомәр Хәйям кебек үлемсез робагыйлар тудыру бөтендөнья әдәбиятының буеннан-буена дәвам итә. Шуңа күрә дә фарсы Яңарышының даһи шагыйре һәм гуманисты Сәгъди Ширазины салкын вәгазьләр сөйләүче, акыл сатучы дип, мөселман неоплатонникларыча мәхәббәт, табигать, шәраб культын мактаган Гомәр Хәйямгә һәм дә гүзәл хисси газәлләр авторы Хафиз Ширазига, йә булмаса, үзебезнең — татарның «мәхәббәт Мәҗнүн»нәренә каршы куйсак, һич кенә дә гадел адым булмас иде. Шуңа күрә тән — җан — акыл бәргәләнүләрендә туган, сүз сәнгатенең патшасы булган шигърияткә (Абай) һәрдаим игътибар һәм ихтирам сорала. Мөхәммәт Мирзаның да: *«Биш юлым — биш гөлем, / Сугарып үстердем. / «Адәм балаларым» / Ташлап китмәс, шөкер, / барысын үз күрдем...»* — дигән лирик җылылык белән өретелгән юлларын да шундыйрак мәгънәдә кабул итәргә кирәк.

**Резеда ГАНИЕВА**

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез Мөхәммәт Мирзага 2013 елның 3 гыйнварында 60 яшь тулды. Аны олы юбилее белән ихластан котлыйбыз, сәламәтлек, иҗат уңышлары теләп калабыз.*

# ТАТАРСТАНДА АЧЛЫК ФАҖИГАСЕ

*Шатлыкларны хәсрәт*
*алыштырган,*
*Булалмаган гел-гел шат кала.*
*Узган дәверләрнең фаҗигасе*
*Изге ташларында саклана.*

И.Юзеев

Татарстан автономияле республикасы төзелү белән үк анын өстенә төшкән бәла-казаларның иң дәһшәтлесе, мөгаен, 1920 елда башланган ачлык булгандыр. Бу ачлык афәте хакында тарихыбызда, әдәбиятыбызда бераз язылды инде, халкыбызның буыннан-буынга күчкән истәлекләре дә саклана әле. Чөнки ул — бөтенхалык хәсрәте, аны оныту мөмкин түгел һәм онытырга хакыбыз да юк. Әмма ачлыкның чын сәбәбен 1921 елда булган корылыкка, иген уңмауга гына сылтап калдыру һич тә дөреслеккә туры килми. Тарихчы галимнәребезнең биргән бәяләре башкача һәм аны белү безнең генә түгел, киләчәк буыннар өчен дә зарур[1]. Бу мәкаләне язарга алынуымның төп сәбәбе дә — әнә шул зарурлыкны күбрәк кешегә белдерәсем килүдән килеп чыкты.

Ачлык ни сәбәптән башланган һәм шундый коточкыч дәрәҗәдә таралган соң? 1921-24 елларда ТАССРның Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисе булып эшләгән Рәүф Әхмәтсабир улы Сабиров (1894-1937) үзенең «Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык» дигән мәкаләсендә болай дип яза: «Ачлыкның башлыча сәбәпләре ашлык уңмау, йогышлы авыру һәм сугышлар икәнлегендә шөбһә юк. Шулай ук мәмләкәтнең бәгъзе бер икътисади шартлары, халыкның фәкыйрьлеге, мәдәният ягыннан артта булуы, юлда нәрсә йөртү әсбапларының житешсезлеге һ.б. төрле күп кенә сәбәпләр хуҗалык эшләрен зәгыйфьләндереп, ачлыкның тизрәк килүенә ярдәм иттеләр»[2].

Хак сүзләр. Ачлык ул — фәкыйрьлекнең аерылмас юлдашы. Ә халыкны фәкыйрьлеккә дучар иткән сәбәп нигезендә рус хакимиятенең татар халкына карата гасырлар буе алып барган рәхимсез сәясәте ята. Ул хакта да ачыктан-ачык әйтә алган Рәүф Сабиров. «Әгәр дә без халкыбызның тарихын тикшереп карасак, татарларның искедән бирле зур бер кысынкылык астында яшәп килгәнлекләрен күрәбез. Иван Грозный тарафыннан Казан алыну белән татарлар үзләренең өсләрендә инде кысынкылыкның башланганын сизделәр. Идел, Кама буйларындагы әлегә кадәр биләп килгән мөнбит (уңдырышлы) җирләрен татарлар урысларның тәзаййыкы (кысуы) астында ташлап китәргә мәҗбүр булдылар. Җүнсез һәм унайсыз җир кайда бар — татарлар шунда утыртылды. Билгеле, бу хәл үзе генә татарларның икъдисади яктан начарлануына сәбәп булды»[3].

Ни кызганыч, бу сәясәт, бу кысулар һаман тагын да нечкәрәк, тагын да мәкерлерәк юллар белән дәвам итә.

Мисал өчен: «1861 ел Нигезләмәсе» буенча, Казан губернасында рус крестьяннары крепостнойлыктан азат ителгән вакытта, ревизия үткән һәр җан башына (на ревизскую душу) уртача 3-4 дисәтинә җир алалар. Шул ук вакытта дәүләт крестьяннарына җан башына бирелгән җир мәйданы уртача 5,23 дисәтинә тәшкил итә. Ә татар крестьяннарының иманасы ревизия үткән һәр җан башына 1 дисәтинә генә була. Моның өстәвенә, татар авылларында атлар саны азлыгын да күрсәтергә кирәк. 1884-91 елларда ук татарның 34,8 проценты атсыз, 46,2 проценты бер атлы һәм бары тик 14,8 проценты гына ике атлы була[4]. Шуның аркасында

[1] Кара: Таһиров И.Р. Гасырлар чатында. – Казан: Мастер-Лайн, 1998. –Б.236-245; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. – С.177-188; Вәлиев Р. Өзелгән дога. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б.23-30; Әхмәтҗанов М. Ачлык фаҗигасе // Мәгариф. – 2012. – №2. – Б.82-83.
[2] Безнең юл. – 1922. – №1. – Б.21.
[3] Безнең юл. – 1922. – №1. – Б.22.
[4] Таһиров И.Р. Юныс Вәлиди // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 1966. –№ Ç. – Б.75-76.

сөрүлек жир мәйданнарының күләме азая һәм икмәк тә житәрлек булмый. Өстәвенә татарларның урман, олы юл һәм елга буйларыннан куылуын, яшелчә һәм жимеш бакчалары үстерергә хокуклары булмавын, тереклек итәр өчен унайсыз урыннарга төпләнергә мәжбүр ителүләрен дә искә төшерик.

Жирсезлектән тилмергән крестьяннарның тормыш-көнкүрешен төрле-төрле салымнар да кыен хәлгә куя. Салымнарның түләнми калган өлеше — недоимкалар елдан-ел үсә. Аларны түли алмаганнарның терлеген, барлы-юклы игенен, актык мендәрен, самавырын тартып алалар. «Карьямездә ачлык көннән-көн көч алмакта, — дип яза «Казан мөхбире», — бала-чага, хатын-кыз ач тамак, ялан өс, суык өйдә калтырап, туңып утыралар... Өстәвенә, бу бичара ач крестьяннардан һәр көн имана сорыйлар»[5].

Ач-ялангач калган мескен крестьян иманасын ташлап шәһәргә эш эзләп китәргә мәжбүр була. Казан губернасындагы авыллардан эш эзләп читкә китүчеләр саны 1899 елда ук 154185кә житкән. «Авылларда барча ирләр диярлек Баку, Мәскәү, Идел буйларына хезмәт эзләп таралганнар. Авылда күбесенчә хатыннар калып, кыр эшләренең барысын башкаралар», дип яза «Әльислах»газетасы[6].

1914 елда башланган империалистик сугыш хезмәт кешесен тәмам бөлгенлеккә төшерә. Шушы бер ел эчендә генә дә Казан губернасында дүрт тапкыр мобилизация үткәрелә һәм барлык хужалык эшләре хатын-кызлар һәм яшүсмерләр кулында кала. Бу сугышка ялганып киткән Гражданнар сугышы татар халкын, аеруча татар авылларын аяктан ега. Чәчү мәйданнары тагын да кими, терлекләр саны бик нык кыскара.

Дөрес, халык хужалыгының шулай бөлгенлеккә төшүе Россиядә бер Казан губернасына гына хас күренеш түгел. Сугыш аркасында бушап калган иген кырлары, жимерелгән завод-фабрикалар, шахталар, тимер юллар, ягулык һәм сәнәгать өчен чимал житешмәү Россиядә яшәүче халыкларның хәлен чиктән тыш авырайта, бигрәк тә азык-төлек мәсьәләсе кискенләшә. Житештерелгән ашлыкны «бүлешүчеләр» дә күбәя. Ягъни нәкъ «Чапаев» кинофильмындагы кебек: «Белые пришли - грабят, красные тоже начали грабить». Инде мәгълүм булганча, ВЦИК (БҮБК)ның 1918 елның 13 маенда кабул ителгән декреты нигезендә авылларга икмәк жыю өчен продотрядлар жибәрелә. Ә 1919 елдан продразверстка планы кертелеп, икмәк крестьян хужалыкларыннан көчләп тартып алына башлый һәм бу талау галәмәте сугыш беткәнгә кадәр дәвам итә.

Октябрь инкыйлабыннан соң да татарларга караш унай якка үзгәрми. Совет дәүләтенең социаль һәм милли сәясәте нәкъ элеккечә, романовларча, ә бәлки тагын да мәкерлерәк төстә дәвам итә.

1920 елда, ниһаять, бик авыр сәяси һәм икътисади шартларда ТАССР төзелә. Әмма бу хәл шовинистик үзәккә, аларның бүлгәләп хакимлек итү максатларына һич тә туры килми. Республиканы төзү хакында сүз алып барганда ук, шушы 1920 елның башында Татарстанга 10 млн. 120 мең пот икмәк хәзерләү планы йөкләнә. Бу планның бинаһая зур булуы хакында Татарстан партия өлкә комитетының беренче конференциясендә бюро әгъзасы Иван Дерунов болай ди: «Әгәр дә без шушы 10 ярым миллион пот икмәк разверсткасын үтәргә тырышабыз икән, ачлыктан котылып булмаячак. Бу планны берничек тә үтәп булмый. Чөнки инде без авылның соңгы жебенә кадәр тартып-йолкып бетердек. Анда бер бөртек ашлык калмады. Республика составына кергән Минзәлә һәм Бөгелмә өязләре дә шушы ук авыр хәлдә. Алар да республика планын үтәрлек хәлдә түгел»[7]. Болай дип әйтүчеләр арасында бер Дерунов кына булмый.

Татарстанның шундый кыен хәлдә калуына карамастан, яңа оешкан хөкүмәт башында торган Сәхибгәрәй Сәетгалиев[8] һәм аның тарафдарлары Үзәктән төшерелгән планны аеруча үҗәтлек белән үтәргә керешәләр. Бик тиз генә крестьяннарга мөрәҗәгать әзерләнә. Мөрәҗәгатьтә разверстка планының берсүзсез үтәлергә тиешлеге, үтәмәгән кешенең җавапка тартылачагы әйтелә.

Мөрәҗәгатькә каршы чыгучылар да була. Мәсәлән, бу вакытта ВРК (Вакытлы революцион комитет) секретаре булган Шамил Усманов: «Мин халкыма чыгарылган үлем карарына кул куярга теләмим», — ди. Жир эшләре Халык комиссары Юныс Вәлидов та әлеге канэчкеч документка кул куймый.

[5] Казан мөхбире. – 1906. – №106.
[6] Әльислах. – 1908. – №29.
[7] Таһиров И.Р. Гасырлар чатында. – Казан: Мастер-Лайн, 1998. – Б.238.
[8] 1920-1921 елларда Вакытлы революцион комитет (ВРК) һәм Халык Комиссарлары Советы рәисе.

Мәскәү каршында яхшы исем казанасылары килгән сәетгалиевчеләр бу каршы чыгуларга колак салмыйлар. Республика гаять өлгерлек белән разверстканы үтәргә керешә. Тиз генә өч продтрибунал төзелә. Алар теләсә кайсы вакытта, теләсә кемгә хөкем карары чыгарырга вәкаләтле булалар. Разверстка планы һәр хуҗалыкка чәчү мәйданыннан чыгып таратыла, әмма гаиләдәге кеше саны исәпкә алынмый. Кем дә булса планын үтәмәсә, аны бөтен авыл халкы үтәргә тиеш була.

Крестьян бөтенләй хокуксыз бәндәгә әверелә, чөнки ул мәҗбүри хезмәткә тартыла. Һава шартлары, үз хәле, хуҗалыгы нинди булуга карамастан, ул теләсә нинди түрәнең әмерен тыңларга, теләсә нинди эшкә чыгарга мәҗбүр ителә. Бу ирексез чарадан хәтта дин әһелләре дә котылып кала алмый. Алардан юл салу һәм ремонтлау, утын хәзерләү, төяү һәм бушату өчен хезмәт батальоннары төзиләр. Күп кенә урыннарда мәчетләр эшләүдән туктарга мәҗбүр ителә.

Авыл халкына карата кабул ителгән карарлар коточкыч була. «Мондый хәлне бер ил дә, бер халык та, беркайчан да күрмәгән», — дип яза олуг галимебез И.Р.Таһиров[9].

Чынлап та, архивларда сакланып калган документларны укыганда, авыл халкының ыңгырашканын, җан газабын тойгандай, күз яшьләрен күргәндәй буласың. Кантоннардан килгән хәбәрләрдә продотряд кешеләренең аеруча кансызлыгы, явызлыгы хакында сөйләнә[10]. Бу миһербансызлыкка каршы ач үлемгә дучар ителгән крестьяннар баш күтәрәләр. Арча кантонының Арбор, Шубан, Әтнә, Кышлау крестьяннары, тартып алынган ашлыкны кире кайтарырга теләп, һөҗүмнәр оештыралар. Минзәлә, Бөгелмә кантоннарында тарихка «Сәнәкчеләр хәрәкәте» исеме белән кереп калган восстание башланып, тиз арада башка кантоннарга да җәелә[11].

Сүз дә юк, бу чыгышлар рәхимсез бастырыла. Балык Бистәсе районыннан алынган бер документта «чыгышларны бастырырга 3 взвод солдат һәм милиционерлар җибәрелде. Алар Масловка һәи күрше волостьтагы восстаниеләрне бастыруда зур активлык күрсәттеләр», — дип әйтелә[12].

1920 елның 1 декабренә разверстка планы 102 процентка үтәлә. Ашлыктан тыш, декабрь ахырларына крестьяннардан талап тагын 380 мең поттан артыграк ит, 1 млн. 652 мең пот бәрәңге, 17 миллион данә йомырка, 11 мең пот май, 8880 пот бал, 227344 данә тире, 13276 пот йон, 4838 пот житен, 4639 пот киндер сүсе җыеп тапшырыла[13]. Шулай итеп, крестьяннар киемсез калырга мәҗбүр була, Чөнки күп вакытта алар үзләре өчен кием-салымны мал тиресеннән, йоннан, киндердән эшлиләр. Республиканың тегү һәм аяк киемнәре хәзерләү предприятиеләре, булган запасларыннан, армия өчен кием-салым тегеп җибәрәләр. Бу хәлләргә карамастан, Бөтентатар гадәттән тыш комиссиясе (Всетатчека) рәисе урынбасары Аким Денисов җитәкчелегендә, көчләп җылы кием җыю кампаниясе җәелдерелә. Крестьяннарга азык-төлекне бары тик кибетләргә генә тапшыру рөхсәт ителә, базарлар ябыла. Ә кибетләрдә халыкка кирәкле керосин, тоз, шырпы, мануфактура товарлары бөтенләй диярлек булмый.

Өстәвенә, халыктан «чәчүлек орлыгын җыеп, җәмәгать амбарларына салабыз» дигән мәкерле сылтау белән, тагын 2 млн. ярым пот икмәк тартып алына[14]. Димәк, 1921 елга халык икмәксез, чәчүлек орлыксыз килеп керә һәм рәхимсез ачлыкка, ялангачлыкка дучар ителә.

Шәһәр халкының да хәле авырая. Сугышлар тынгач һәм хәрби заказлар туктатылганнан соң, сугыш ихтыяҗлары өчен эшләп килгән предприятиеләр дә туктап кала. Шулай итеп, меңнәрчә кеше урамга чыгарып ташлана, барлы-юклы тиеннәрдән дә мәхрүм ителә.

1921 елның кышы бик салкын килә. Ашарга эзләп чыгучыларның күбесе юлда катып үлә. Салкын кыштан соң коточкыч корылык башлана. Яздан бирле күктән бер тамчы яңгыр төшми, җирләр яргалана. Ашарга яраклы үләннәр корып бетә.

[9] Таһиров И. Гасырлар чатында. – Казан: Мастер-Лайн, 1998. – Б.240.
[10] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасвр., 110 эш, б.12, 51, 73; 104 эш, б.42; 197 эш, б.3, 17.
[11] Шунда ук, 197 эш, б.31.
[12] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасвр., 104 эш, б.141.
[13] Вәлиев Р. Өзелгән дога. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б.23.
[14] Шунда ук.

Кешеләр этләр, мәчеләр ашыйлар. Йорт хайваннарының саны бик нык кими. Идел буенда, чын мәгънәсендә ачлык, ялангачлык котырына.

Кантоннардан ачтан үлүчеләр хакында җан әрнеткеч хәбәрләр килә. «Җиде волостьтан алынган мәгълүматларга караганда, — дип хәбәр итәләр Чистай кантонынннан, — 1921 елның февраленә үлүчеләр саны — 50 мең кеше. Калган 18 волостьтан хәбәрләр килеп җитмәде»[15]. Мондый хәбәрләр Тәтеш, Спас, Минзәлә, Бөгелмә һәм башка кантоннардан да килә[16]. Мисал өчен, Спас кантонынннан килгән хисапта мондый саннар китерелә: Кантонда яшәүчеләр саны барысы 236606 кеше. Шулардан читкә азык эзләп китүчеләр саны — 23610, тулы ятим балалар — 3376, ярым ятимнәр 9385, ачлыктан шешенеп авыручылар — 25000. 1921 елның 4 августыннан 15 октябренә ачтан үлгән балалар саны - 4077, олылардан — 4808 кеше исәпләнә[17]. Ни кызганыч, мондый тетрәндергеч хәбәрләрне һәм үлүчеләр саны турындагы белешмәләрне Татарстан кантоннарыннан килгән мәгълүматларның барысыннан да укып була. 1921-22 елларда ВЦИК (БҮБК) каршында һәм РСФСР Милләтләр эше буенча Халык комиссариатында ТАССРның вәкаләтле вәкиле Али Гани улы Ганиевнең Үзәккә җибәргән хәбәренә караганда, халыкның 70 проценты ачлыктан үлү дәрәҗәсенә җиткән[18].

Ачлык үзе белән тагын бер афәтне алып килә. Ул да булса — тиф авыруы. Ачлыкка һәм ялангачлыкка дучар булган халык бу афәтне дә җиңә алырлык хәлдә булмый инде. Тифтан үлүчеләрнең саны 1920 елда ук 218 меңнән артып китә[19].

Бу вакытта крестьяннарны тәмам бөлгенлеккә төшергән бәлаләрнең тагын берсе — янгыннар. Корылыктанмы бу, әллә башка сәбәпләре дә булганмы — әйтүе кыен. Янгыннар коточкыч дәрәҗәгә җитә. Бу афәт барлык кантоннарда да күзәтелә. Тулы бер авыллар дөрләп яна. Янгын беркемне дә аямый. Мәсәлән, Минзәлә кантонының Сарсаз авылында янгын чыгып — 150, Клюково авылында 80 йорт кара кисәүгә әверелә. Арча кантонының Яңа Шимбер авылында 228 йортның 108е яна. Спас кантоны Тенишево авылында да 80 йорт янып бетә[20]. Янгыннарның бик тиз генә бөтен авылны камап алуы, бәлки, бер яктан, йортларның күпчелеге салам түбәле булу сәбәпледер. Икенчедән, ачлыктан интеккән кешеләрнең янгынга каршы торырлык көчләре дә булмагандыр дип уйларга да җирлек бар.

Халык тәмам куркуга төшә. Крестьяннар бу хәлләрне «коммунистлар сәясәте» дип уйлый[21]. Алар гомер иткән җирләрен, ата-баба туфрагын ташлап, кан-кардәш халыкларга — Урта Азиягә, Себергә барып сыенырга телиләр. Юллар мөһаҗирләр белән тула. Татарстанны бу чорда 232 меңнән артык кеше ташлап китәргә мәҗбүр була. Аларның язмышлары хакында Татарстан Милли архивында кайбер мәгълүматлар сакланган. 1921 елда Бөтентатар гадәттән тыш комиссиясенә бирелгән язма отчетында комиссия әгъзасы Семенов Александр Республикадан китәргә теләп юлга чыгучыларның хәлен болай дип күрсәтә. «На основании Вашего приказа произвел вторичный осмотр мест расположения беженцев и рабочих на станции Устье[22], отправляющихся в хлеборобные губернии по нарядам Наркомтруда. При въезде на Устье находятся 1200 чел. совершенно под открытом небом, а часть в самодельных палатках.

По правой стороны Устья тоже находятся под открытом небом 300 чел. и далее под навесом около тысячи чел. Среди них обнаружены разлагающиеся трупы.

На станции также обнаружены больные и под открытом небом до 1000 чел. Все просят не бросать их на произвол судьбы. Начался сильный дождь, ветер. У беженцев кроме тряпья, чтобы огородить себя от холода, ничего нет. Медицинская помощь им не оказывается. Трупов, хотя и обращались к милиции, никто не убирает...»[23]

А.Семенов тырышлыгы белән качакларны Игумный бистәсендәге бушап калган

[15] ТР МА, 128 ф., 1 тасв., 179 эш, б.1.
[16] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасв., 118 эш, б.5.
[17] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасв., 118 эш, б.19.
[18] Жизнь национальностей. – 1922. – №10 (16). – Б.8-9.
[19] ТСД ҮДА, 738 ф., 1 тасв., 219 эш, б.5.
[20] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасв, 197 эш, б.31.
[21] Шунда ук, б.3, 17, 40.
[22] Элек Казан елга порты Казансу елгасы тамагында урнашкан булган. Устье – шуны аңлата.
[23] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасв, 202 эш, б.79-80.

казармаларга урнаштырганнар. Тик аларның күпмесе исән калган, күпмесе үлгән — билгесез. Үзәккә бирелгән хисабында А.Ганиев мондый хәлләрне ачыктан-ачык күрсәтергә мәҗбүр булган. «Развитие тифа и смертность от голода среди беженцев не поддается сколько-нибудь даже приблизительному подсчету», — ди ул[24].

Әйтергә кирәк, ачлык афәте көннән-көн көчәя барып, масштаблары кинәйгәч, 1921 елның августында Совет хөкүмәте, В.И.Ленин үзе ярдәм сорап, халыкара хәйрия оешмаларына мөрәҗәгать белән чыгарга мәҗбүр була. Илнең билгеле, дөньякүләм танылган шәхесләре, җәмәгать эшлеклеләре чит илләрнең мәһшүр зыялыларына хатлар язалар. А.М.Горький Герберт Гувер (1921 елдан Американың сәүдә министры, 1929-1933 елларда - Президенты) аркылы Америка халкыннан ярдәм сорый, бигрәк тә ач балаларны коткарырга кирәклегенә басым ясый: «Ваша помощь будет вписана в историю как уникальное, гигантское свершение, достойное величайшей славы» — ди ул. Хатын-кызлар хәрәкәтенең күренекле җитәкчесе А.Коллонтай Норвегия галиме Фритьоф Нансенга мөрәҗәгать итә. Ниһаять, 1921 елның 18 июлендә БҮБК рәисе М.И.Калинин җитәкчелегендә Ачларга ярдәм оештыру буенча Үзәк Комиссия (Помгол) төзелә. Мондый комиссияләр тиз арада ачлыктан интеккән башка төбәкләрдә дә оештырыла. Татарстанда 28 июльдә төзелгән комиссияне Башкарма комитет рәисе Рәүф Сабиров җитәкли. Комиссия үз эшен ачларның төгәл санын исәпләү, нинди һәм ничек ярдәм оештыру хакында төгәл мәгълүмат булдырудан башлый. 1921 елның җәендә урыннардан алынган мәгълүматларга караганда, Республикада соң дәрәҗәдә ачыгучылар барысы 2 млн. 462599[25] кеше исәпләнә.

Бу факт ачлык 1921 елның көзендә башланган дигән фикернең ялгышлыгын раслый. Ачлык 1920 елда, әйтеп үтелгәнчә, разверстка планын үтәп, халыкны тәмам талап бетереп, икмәксез, азык-төлексез калдырган вакытта ук башлана.

Помгол ҮКы эшкә тотыну белән, Россиянең хәвеф-хәтәрсез, уңышлырак губерналарына ачлыктан һәм корылыктан аеруча интеккән өлкәләргә ярдәм итүне йөкли. Татарстан Петроград һәм Владимир губерналарына беркетелә. Моннан тыш Смоленск, Витебск, Кострома, Тверь, Псков, Ярославль, Пенза һ.б. — барысы 11 губерна үзләрендә булган икмәктән Татарстанга өлеш чыгарырга тиеш булалар. Украина белән Белоруссия дә бу эштә шактый яхшы ярдәм күрсәтә. Республикага барысы 3 млн. пот ашлык килә[26]. Әзәрбайҗан, Финляндия, Германия, Швеция кебек илләрнең ярдәмнәре дә килә башлый. Ниһаять, 1921 елның 3 сентябрендә Казанга Американың ачларга ярдәм комиссиясе (АРА) вәкилләре килә. Башында Г.Гувер торган бу комиссиянең ярдәме хакында бераз соңрак тукталырбыз әле.

Болардан тыш, РСФСР Азык хәзерләү халык комиссариаты 60 мең баланы тукландыруны үз өстенә ала. Аның акчалата ярдәменә 13100 пот икмәк, 5 мең пот он, 7450 пот ит, 14800 пот бәрәңге, 740 пот тоз алырга мөмкин була[27].

Татарстаннан разверстка белән тартып алынган азык-төлек күләме белән чагыштырып карасак, инде күрсәтеп үткәнчә, ачлыкка дучар булган 2 млн. 462599 кеше өчен әлбәттә, бу ярдәм бик тә аз була. Республикага килгән ашлыкның күп өлешен 1922 елның язына кирәкле чәчүлек материалы итеп тә салып куярга туры килә. Татарстанга чәчүгә яраклы бөртек Россия төбәкләреннән барлыгы 4414 мең пот, чит илләрдән 160 мең пот китерелә.

Ачлык башлану белән, эмиграциягә киткән татар зыялыларының илдә калган олы шәхесләребезгә ярдәм итүләре хакында да әйтеп китәргә кирәк. Бу эшне башлап йөрүчеләрдән Манчьжуриягә китеп урнашкан, 1915 елда Троицкида үз акчасына мөгаллимәләр хәзерли торган уку йорты ачкан игелекле жан Гайния Яушева һәм Вәли Апанаевларның исемнәрен атап китәргә кирәк. Алар, азык-төлек посылкалары салу өчен, исән калган зыялыларыбызның, укытучы-мөгаллимнәребезнең адресларын сорыйлар. Риза Фәхреддин аларга Сөнгатулла Бикбулатов, Борһан Шәрәф, Жамал Вәлиди, Фатих Әмирхан, Әхмәтһади Максуди, Зәкәрия Садретдинов, Гөбәйдулла Бубый, Ибраһим Терегулов, Габдулла Сөләйманов һәм Мөхетдин Корбангалиевләрнең адресларын җибәрә.

[24] Жизнь национальностей. – 1921. – №22 (120). – С.27.
[25] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасв., 197 эш, б.98.
[26] Шунда ук, 36 ф., 2 тасв., 3721 эш, б.280.
[27] Шунда ук, 202 эш, б.417.

Ачларга ярдәм оештыруда Диния нәзарәтенең нәтиҗәле эше аеруча игътибарга лаек. Нәзарәттә мөфти Г.Баруди житәкчелегендә халыкны ачлык афәтеннән коткару планы төзелә һәм Мәскәүдә өч кешедән торган Вәкаләтле комиссия оештырыла. Комиссиянең рәисе итеп Нәзарәтнең казые, халык арасында гыйлеме һәм әхлакый сыйфатлары белән зур хөрмәт казанган Кәшшафетдин хәзрәт Тәржемани билгеләнә. Ул бу Комиссиядә 1923 елның ахырына кадәр эшли. Г.Баруди 1921 елның 25 августында Милләтләр эшләре буенча халык комиссары И.Сталинга рәсми булмаган хат яза. Ул фажиганың нинди куркыныч күләмдә җәелүен һәм продразверстканы ачлыкның төп сәбәбе икәнен ачыктан-ачык күрсәтеп бирә.

Шулай итеп, Диния нәзарәте Үзәктә оештырылган комиссия (Помгол) белән бергәләп эшли башлый. Чөнки бары тик бу оешма аркылы гына чит ил мөселманнары белән бәйләнешкә керергә мөмкин була. Ярдәм комиссиясенә күренекле дин әһелләре дә чакырыла. Мисыр, Манчьжурия, Финляндия, Кытай, Әфганстанга ярдәм сорап үтенеч хатлары җибәрелә. Мөселман дөньясында зур абруй казанган дин галимнәреннән Таһир хәзрәт Ильяси, Гобәйдулла Бубый - Төркиягә, Садыйк хәзрәт Иманколый Урта Азиягә ярдәм җыярга китәләр. Әйтеп үтик: Төркия республикасы бу вакытта үзенең бәйсезлеге өчен Антантага каршы тигезсез сугыш алып барырга мәжбүр була. Шулай да, Т.Ильяси һәм Г.Бубый Төркиягә килеп житкәч, андагы газеталар: «Россиядән килгән диндәшләребез Әнкарага китә. Ачлыктан кырылучы шималь төркиләре өчен, Анталия мөселманнарының шәфкатенә өметләнеп мөрәҗәгать итәчәкләр», — дип язып чыгалар һәм халыкны ярдәм күрсәтергә чакыралар. Төркия халкы хәйрия җыя. Иң беренче нәүбәттә, азык-төлек тутырылган 125 посылка Татарстанның ач мөгаллимнәренә җибәрелә. Бер посылкада 2 пот ярым ак он, 5 кг кукуруз ярмасы һәм шул ук күләмдә шикәр һәм 20 банка куертылган сөт була[28].

Татар зыялыларының һәм бигрәк тә мәгарифенең ни дәрәҗәдә аяныч хәлдә булганын язу — үзе бер тема. Тик архивтагы материалларны кем дә булса киләчәктә өйрәнеп язып чыгар микән? Бөтен мәгариф хезмәткәрләре, уку йортлары өчен уртак булган бер генә мисал китереп үтәм. 1921 елның ахырында Мамадышта эшләп килгән педагогия курслары ябыла. Сәбәбе: укыту өчен әсбаплар, кабинетлар, мастерскойлар һәм иң мөһиме — педагоглар житешмәү. Күп кенә фәннәр бөтенләй укытылмый. Курсларны Алабугадагы шундый ук курсларга кушалар. Ә бу уку йортының да аяныч хәле хакында кантон мәгариф бүлеге отчётында мондый сүзләр язылган: «Курста укучыларның барысы да Татарстаннан, күбесе уңыш булмаган ач районнардан. Күпчелек укучыларның әти-әниләре ачтан үлгәннәр. Берничә укучыны хастаханәгә җибәрергә мәжбүр булдык, чөнки алар ачтан шешенделәр...»[29].

Татар зыялыларының хәле, аларга Помгол тарафыннан җибәрелгән ярдәмнең ничек барып житкәне хакында олуг язучыбыз Ф.Әмирхан истәлекләренә дә мөрәҗәгать итик. «Рамазан гаетенең өченче көнендә (9.X.1921) мина Г.Баембитов һәм милиция начальнигы Х.Габидуллин килгәннәр иде. Гыйлемдар.... сөйләде: «Мәркәз рус мөхәррирләрен яхшы тәэмин итә. Монда да әле карт рус журналистларыннан берсе мәркәзнең әмере белән КаПУдан (Казанское продовольственное управление) үзенә тәмам житәрлек микъдарда хосусый паек алып тора. Паегын алырга килгәндә сүз чыгарып, большевикларны, хәзерге властьны каты гына сүгеп, тәнкыйть итеп алырга да онытмый. Менә шундый бер тәэмин Тат. җөмһүрияттә татар мөхәррирләренә вә шул җөмләдән сина да ясалырга тиеш.

— Мин Совет мөәссәсәләренә (учреждениеләренә) йомыш төшеп барып, — дип яза аяксыз утырган татар классик язучыбыз, — бер нәтиҗә чыгаруның никадәр унайсыз эш икәнен һәм үз тәжрибәм һәм үземә мәгълүм башка кешеләрнең тәжрибәләре белән бик яхшы белгәнлектән, бу мәсьәләне кузгатырга уйлап та карамадым»[30]. (1921 елдан хәзерге көнгә кадәр рус һәм татар мөхәррирләренең хәлләре арасындагы аерма хакында фикер йөртүне укучыларның үз хөкеменә калдырам. — Т.Б.).

Ачыгучы башка өлкәләр белән чагыштырганда, Татарстанга күрсәтелгән ярдәм

[28] Кара: Биктимирова Т. Ил язмышын салып иңнәренә. – Казан: Алма-Лит, 2006. – Б.120.
[29] ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 394 эш, б.10.
[30] Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б.188.

хакында Мәскәүнең республикадагы чит илләрдән килгән оешмалар эшчәнлеген күзәтүче тулы хокуклы вәкиле В.А.Мускат, Үзәктәге житәкчесе А.В.Эйдукка 1922 елның 7 февралендә жибәргән доклад язуында бик ачык итеп болай дип күрсәтә: «Мин Сезгә ата-аналарның ачтан үлгән балаларын ашаулары хакында рәсми хисап жибәргән идем, — ди ул. — Мондый очраклар, безнең бәхетсезлеккә каршы, һаман күбәя. Бу хәл үзе генә дә Татарстандагы катастрофик ачлык үзенең иң соңгы ноктасына житкәнен күрсәтү өчен житмиме?

Минем Сезгә тагын мәгълүматларны саннар белән генә күрсәтәсем кала, ул саннар, өстәп бернинди аңлатмасыз да, чит илләрдән, Помгол һәм дәүләт тарафыннан Татарстанга күрсәтелгән ярдәмнең ни дәрәҗәдә мескен икәнен күрсәтерләр. Мин, аңлы рәвештә Татарстан республикасына дип ассызыклап әйтәм, чөнки Россиянең ачлык булган башка районнарына ярдәм күбрәк күрсәтелә. Татреспубликага жибәрелгән вәкил буларак, бу нормаль булмаган хәл турында әйтүне үземнең бурычым дип саныйм.

Әйе, Татреспубликада хәзер АРА эшли. Ә бүтән районнарга АРА шундый ук күләмдәге ярдәмне күрсәтмиме? Башка районнарда моның өстәвенә төрле-төрле башка ярдәм оешмалары, мисал өчен Нансенныкы, хәтта өлкәннәргә дә ярдәм итәләр. Татреспубликада мондый хәл бөтенләй юк.

Статистика мәгълүматларына караганда, Татреспубликада барысы 2797527 кеше исәпләнә, шуларның 969900ы — балалар. Ярдәм оешмалары күрсәтүенчә, шушы халыкның бары тик 3 проценты гына яңа уңышка хәтле ярдәмсез барып житә ала. Калганнары ач үлемгә дучар ителгән.

АРА 320000 баланы туендырлык азык бирә. Ә бит Чуаш өлкәсенә шушы паекларның 31000е, Мари өлкәсенә 16000е жибәрелә. Бу паеклар Татреспублика балаларына өстәмә ризык дип саналса да, аның бердәнбер, хәтта күп очракларда бөтен гаилә өчен икәне сер түгел.

Татпомгол, дәүләт рәсми оешмалары белән бергә, бары 254150 паек бирә. Алар исәпләвенчә, аның 75 проценты - балаларга, калганы — өлкәннәргә. Швеция оешмасының бөтен ярдәме 12 вагон он булды. Ул он Спас һәм Тәтеш кантоннарына жибәрелде. Германиянең Кызыл Хач оешмасы китәргә хәзерләнә, алар белән бергә Швециянеке дә китә. Димәк, бу аз гына ярдәмнән дә мәхрүм калабыз.

Күрәбез ки, 300000 бала бөтенләй ярдәм ала алмаячак, язмыш кочагына ташланган өлкәннәр хакында әйтеп тә торасы юк»[31].

В.А.Мускатны Татарстан халкына карата күрсәткән шушы кайгыртучан хисләре, борчылулары өчен рәхмәт белән искә аласы килә. Язмаларына өстәп ул тагын бер тетрәндергеч документ китерә. Анда 1922 елның 15-22 гыйнварында, ягъни бер атна эчендә үлүчеләр хакында кантоннардан алынган аянычлы мәгълүматлар теркәлгән[32].

**Таблица 1**

| Кантоннар исемлеге | Барлык ачыгучылар | Үлүчеләр | |
|---|---|---|---|
| | | Ачлыктан | Тифтан |
| Арча | 388735 | 30 | 15 |
| Бөгелмә | 240310 | 5110 | 3063 |
| Буа | 147428 | 57 | 10 |
| Мамадыш | 152935 | 2371 | 121 |
| Минзәлә | 175530 | 1928 | күрсәтелмәгән |
| Зөя (Свияжск) | 165309 | 100 | 40 |
| Спас | 158271 | 217 | 20 |

Документта бу саннарның әле тулы булмавы хакында да искәртелә.

Татарстан республикасында яшәгән балалар язмышына күз салсак та, шул ук фажигане күрәбез. Статистика мәгълүматларына карасак, 1920 елда республикада барлыгы 1208875 бала исәпләнә. (А.В.Мускат балалар санын 969900 дип күрсәтә.

[31] ТР МА, Р-128 ф., 1 тасв., 174 эш., б.1-2.
[32] ТСД ҮДА, 15 ф., 1 тасв., 197 эш, б.98.

Димәк, 1922 елның февраленә балалар саны 236875 кә кимегән дигән сүз). Балалар хәлен яхшырту буенча төзелгән комиссия отчетына караганда, ул балаларның 253892се — дәүләт органнары, 25080е — Мәгариф комиссариаты һәм 9000 бала — Сәламәтлек саклау комиссариаты карамагында булганнар. Барысы 287972 бала. Тагын Казанда 27 ашханә ачылып, анда көнгә бер мәртәбә 24000 баланы ашата алганнар. Дөрес, 1921 елда балаларны Россиянен икмәкле өлкәләренә озату өчен Мәгариф комиссариаты каршында эвакуация бюросы оеша. Анын житәкчесе итеп РКП(б) Өлкә комитетынын хатын-кызлар бүлеге житәкчесе һәм Мәгариф коллегиясе әгъзасы Зөһрә Әхтәм кызы Баимбетова билгеләнә. Урамнарда, пристань, вокзалларда, ишек алларында, олы юлларда аунап яткан ачтан шешенгән, ертык киемнәрдән, тәннәрендә жаннары көчхәл белән калган балаларга беренче ярдәмне күрсәтү өчен Казанда һәм кантоннарда 291 пункт ачыла. Әлеге пунктларда эшләү өчен хатын-кызлар бүлекләре вәкилләре жыелышлары әгъзалары һәм югары уку йортларында укучы студентлар тартыла. Алар эшне балалар өчен дарулар, кием-салымнар, ашханәләр өчен савыт-саба, кашык жыюдан башлыйлар (чөнки кайбер ашханәләрдә 80 балага бер кашык туры килгән). Нәкъ менә шул хатын-кызлар тырышлыгы белән балалар файдасына «Балалар атналыгы», «Кызыл Хач атналыгы», «Ачларга ярдәм атналыгы» h.б. оештырыла.

Икмәкле өлкәләргә озату өчен балаларны башта беттән арындырырга, мунча кертергә, өс-киемнәрә табарга, медицина ярдәме күрсәтергә кирәк була. «Үзләре дә ач хатын-кызлар балаларны коткару өчен чын көрәш фронты ачтылар», — дип яза хатын-кызларны оештыручы, танылган журналист Абруй Сәйфи[33].

Балаларны икмәкле өлкәләргә озату өчен махсус санитар поездлары оештырыла. Беренче поезд 1921 елнын сентябрендә китә. Түбәндәге таблицада шундый 19 поездда кайсы өлкәгә күпме бала озатылганы күрсәтелә.

**Таблица 2**

1921 елнын 6 сентябреннән 1922 елнын 19 маена кадәр
Казаннан озатылган ач балалар саны[34]

| Вакыты | Бару урыны | Барысы күпме | Шулардан | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | татар | рус | керәшен h.б. |
| 6.09.1921 | Петроград | 499 | 381 | 118 | |
| 8.09.1921 | Тверь | 412 | - | 412 | |
| 8.10.1921 | Тверь | 473 | 400 | 73 | |
| 23.09.1921 | Бологое | 443 | 272 | 114 | 50 |
| 8.10.1921 | Омск | 490 | 318 | 126 | 46 |
| 12.10.1921 | Витебск | 612 | 251 | 361 | |
| 18.10.1921 | Семипалат | 476 | 476 | - | |
| 21.10.1921 | Винница | 620 | - | 620 | |
| 6.11.1921 | Новгород | 588 | 244 | 344 | |
| 24.11.1921 | Баку | 460 | 422 | 38 | |
| 28.11.1921 | Харьков | 602 | - | 602 | |
| 4.12.1921 | Тула | 495 | 246 | 249 | |
| 10.12.1921 | Сәмәрканд | 300 | 287 | 13 | |
| 18.12.1921 | Винница | 550 | - | 550 | |
| 22.12.1921 | Семипалат | 601 | 245 | 356 | |
| 5.01.1922 | Гомель | 425 | 106 | 277 | 22 20 |
| 22.01.1922 | Винница | 590 | - | 445 | 113 32 |
| 25.04.1922 | Винница | 895 | 551 | 319 | 25 |
| 19.05.1922 | Гомель | 988 | 455 | 492 | 36 |

Татарстаннан барлыгы 30 меңнән артыграк баланы озату күздә тотылган. Ләкин архивларда озатылган 15 мең бала хакында гына мәгълүматлар бар.

Икмәкле өлкәләргә озатылган балаларның да хәлләре бик әйбәттән булмаган

[33] Сәйфи А. Татар хатын-кызлары азатлык юлында.- — Казан, 1927. — б.45.
[34] ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 356 эш, б.20-21.

икән. Балаларның кире ач Татарстанга әйләнеп кайтулары хакында хәбәрләр күп. Мисал өчен Татарстан Мәгариф комиссариаты күрсәткән саннарга карасак, 1922 елның сентябренә РСФСР өлкәләреннән 800 бала кире кайткан. «Бүгенге көндә балаларны коткару пунктларында 20000 бала бар, — дип күрсәтелә отчетта, — тик аларны киендерергә дә Комиссариатның мөмкинлекләре юк. Балалар 2 ай буе мунча кермәгәннәр, алар ач, туналар, өсләре ялангач диярлек»[35].

Шул ук отчетта Самара, Сембер, Гомель өлкәләреннән дә балаларның качып кире кайтулары хакында язылган. Бер бала хәтта Читадан кадәр кайткан. Сәмәркандтта балаларны «балалык»ка дигән булып, батраклыкка алу фактлары булган һ.б.[36] Республикада беспризорниклар (бөтенләй караучысыз балалар) 15 мең, «Эвакоприемникларда җыелган балаларның 14000е балигъ булмаганнар»[37].

1922 елда балаларны озату өчен җаваплы Зөһрә Баимбетова Бохара республикасына җибәрелә. Эвакуация комиссиясен Гришина Лидия Гавриловна җитәкли башлый. Аның ярдәмчеләре итеп И.А.Егоров, В.И.Никитский, И.Я.Чураев, Г.И.Иванов һәм С.М.Безсоновлар билгеләнә.

Нилектән бу балаларны озату һәм яңадан республикага кайтару бурычы йөкләнгән комиссиягә бер генә татар кешесе дә кертелмәде икән? Әмма аларның (хәзер мәрхүмнәр бит инде) татар балалары өчен җаннары кыйналмагандыр дип уйлыйм. Рухлары рәнҗемәсен. Кире кайтарылмаган бит күп кенә балаларыбыз! Алар хакында Зөһрә апа болай дип сөйләгән иде: «Мине Татарстаннан 1922 елда җибәрделәр. Бер дә китәсем килмәгән иде. Киткәч тә, үзем эвакуацияләгән балалар күз алдымда торды. Юкка булмаган икән. Берничә елдан, Кисловодскида ял итеп, Мәскәүгә кайтып барышлый, сеңлем белән вокзалда утырабыз. Безнең татарча сөйләшкәнне ишетеп, сәләмә киемле бер үсмер бала килде. Елый-елый: «Апа, сез Казандагы Зөһрә апаны белмисезме? Безне Казаннан җибәргәндә, кайтарам дип вәгъдә биргән иде. Кайта алмадык бит менә. Мин монда бер байда ялчы булып хезмәт итәм, туйганчы ашаганым да юк», — дип, үзегемне өзде. Кемлегемне әйтергә оялдым». Бу истәлек тә халкыбыз кичергән аянычлы фаҗига хакында сөйли. Ачлыктан үлгән 326 мең бала да шул дәһшәтле елларның онытылырга тиеш булмаган зур югалтуы[38]. Бу әле рәсми саннар. Рәсми булмаганын кем генә белде икән?

Эвакуацияләнгән татар балаларының бер өлеше Тулага элгә. Монда озата баручы Арон Әхмәтов тырышлыгы белән махсус татар балалар йорты ачылган. Өстәвенә, А.Әхмәтов аларга татар телендә белем бирүгә дә ирешә алган. Тик Татарстанга кайткач, сүзлекләр төзү буенча фәнни мәкаләләр язып та тарихыбызда үз эзен калдырган бу олы йөрәкле җанның гомер юлы 1936 елда ук өзелә.

Петроградка эләккән татар балаларының язмышлары бәхетле булган икән. Аларны урнаштыру, торак һәм мәктәпләр белән тәэмин итү эше белән шәһәрнең Милләтләр эше буенча комитеты шөгыльләнгән. Балалар барлыгы 13 йортка урнаштырылган. Мәктәпләрдә рус теле белән бергә татар теле дә укытылган. Җәй көннәрендә аларны хәтта дачаларга алып чыкканнар. Бу эштә Казан университетының медицина факультеты студенткасы Зәйтүнә Яфуняеваның тырышлыгын аерым күрсәтергә кирәк. Үзенә бирелгән характеристикада аның балалар яныннан бер дә китмичә, хәлсезләрен күкрәге белән җылытып, күтәреп йөрүе хакында әйтелә. Татар укытучылары ирле-хатынлы Мостафа һәм Васфия Айнижановалар да шундый ук фидакарь җаннар булганнар. Васфия Ростов-Дон шәһәрендә «Исламия» мәдрәсәсен бетергән. Сембер губернасындагы Красный Остров мәктәбендә укытучы булып эшләгәч, 1921 елда Петроградка килгән һәм татар балалар йортында эшли башлаган, аларга үз ана телебездә белем биргән. Мостафа Айнижан улы да хезмәттәшләре арасында «тәҗрибәле укытучы, намуслы тәрбияче» булып хөрмәт казанган. Тик шәхес культы елларында репрессиягә эләккән һәм гаепсезгә үлемгә хөкем ителгән[39].

Ленинградтан балалар 1925 елда кире кайтарылган. Кайберләре, туган җирләрендә якыннары булмау сәбәпле, рөхсәт алып, бөтенләйгә шунда торып та калганнар[40].

[35] ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 356 эш, б.35.
[36] Шунда ук.
[37] Шунда ук, б.38.
[38] История Татарстана. Учебное пособие для основной школы. — Казань:ТаРИХ, 2001. — С.347.
[39] Кара: Тагирджанова А.Н. Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках. Казань, 2010. — С.526-527.
[40] Жизнь национальностей. — 1922. — №10. — С.9.

1921 елнын 3 сентябрендә Казанга Американың ачлыкка каршы көрәш комиссиясе килгәнен күрсәткән идек. Комиссия әгъзалары, килү белән, балалар учреждениеләрен ныклы күзәтү астына алалар. «Американылар алып килгән азыкның беренче партиясе 50 мең баланы ашатырга житте, — дип яза «Жизнь национальностей» газетасы. — Тагын 10 мең балага житәрлек азык-төлек шушы елнын 1 октябренә килеп житәчәк. Моның өстәвенә, комиссия вәкилләре дарулар да китерәчәкләрен әйттеләр».

Американылар, республикадагы фажигане күреп, ярдәмнең күләмен арттырырга вәгъдә бирәләр һәм вәгъдәләрендә торалар да. Ә шул ук вакытта Үзәктән (Мәскәүдән) килергә тиешле ярдәм һаман тоткарлана. Баштарак ярдәм поездлары Мәскәү белән Казан арасын 5 көндә үтсәләр, соңрак 20-30 көндә дә килеп житә алмыйлар[41].

Американылар Тәтеш, Чистай, Чаллы, Минзәлә, Пьяный Бор кантоннарында булалар. Аларга Татарстандагы юлларның начар хәлдә булулары бик нык комачаулый. Шуңа күрә алар, язын юллар өзеклеге башланганчы ярдәмнәрен ничек тә ерак районнарга илтеп тапшыру өчен бик нык тырышалар. Урыннардагы хәлләрне үз күзләре белән күреп өйрәнгәч, азык-төлекне ерак районнарга да үзләре алып килгән автомашиналарга төяп илтәләр.

Американың ярдәм комитеты 1921 елнын октябрендә - 216031, ноябрьдә 574730 кешене туендырса, 1922 елнын гыйнвар аенда бу сан 1291168 гә каләр житә[42]. Һичшиксез, АРА оешмасы, ярдәм оештырганда, иң беренче нәүбәттә балаларны күз алдында тота.

Ә Татарстанның бу вакытта бары 25 мең баланы гына ашатып торырга хәленнән килә. Түбәндәге таблицаларда АРА оешмасы тарафыннан Татарстанга күрсәтелгән ярдәмнең кайбер саннары китерелә.

**Таблица 3**

1921 елнын сентябрь — декабрь айларында АРА тарафыннан Татарстанлыларга бирелгән азык микъдары (потларда һәм кадакларда)[43]

| Ашамлыклар | сентябрь | октябрь | ноябрь | декабрь |
|---|---|---|---|---|
| Какао | 374,20 | 880,09 | 437,02 | 1431,16 |
| Шикәр | 1315,04 | 6441,18 | 1866,23 | 6213,20 |
| Сөт | 2460,17 | 9325,33 | 3908,18 | 15791,14 |
| Он | 8230,16 | 30211,37 | 10396,18 | 40402,34 |
| Кузаклылар | 1632,07 | 6460,24 | 2454,03 | 6462,30 |
| Дөге | 2818,35 | 10361,30 | 4064,08 | 4787,21 |
| Туң май | 775,24 | 1612,19 | 843,29 | 2745,21 |
| Кузаклылар өчен ярма | | | | 8543,23 |

**Таблица 4**

Шул ук ашамлыклар 1922 елда да бирелгән (потларда һәм кадакларда)[44]

| Ашамлыклар | январь | февраль |
|---|---|---|
| Какао | 1918,04 | 636,38 |
| Шикәр | 7617,24 | 4120,19 |
| Сөт | 16662,17 | 10727,13 |
| Он | 40586,01 | 52203,13 |
| Кузаклылар | 719,11 | 994,37 |
| Дөге | 1093,17 | 22032,13 |
| Туң май | 4048,31 | 1179,03 |
| Ярма | 14035,30 | 2843 |

Ашамлыкларга өстәп 1243 пот 24 кадак сабын январьда, 323 пот 16 кадак сабын февральдә китерелә[45].

Болардан тыш АРА оешмасы балаларга кием-салым, дарулар, урын жир әйберләре белән дә ярдәм иткән. Таблицада ул ярдәм түбәндәге саннарда күрсәтелә.

[41] ТР МА, Р-128 ф., 1 тасвр., 211 эш, б.69.
[42] ТР МА, Р-128 ф., 1 тасвр., 174 эш, б.1-2.
[43] Шунда ук, б.14.
[44] Шунда ук, б.15.
[45] ТР МА, Р-128 ф., 1 тасвр., 174 эш, б.15.

**Таблица 5**

Балалар өчен җибәрелгән кием-салым[46]

| Кием-салым төре | 1921 елда | | 1922 елда |
|---|---|---|---|
| | Казанга | кантоннарга | |
| Ир балалар өчен костюмнар | 1039 | 3119 | 1077 |
| Кыз балалар өчен костюмнар | 1039 | 3119 | 1360 |
| Пальтолар | 510 | 7720 | |
| Аяк киеме | 1400 пар | 12012 пар | |
| Оеклар | 13412 пар | 11176 пар | 5491 пар |
| Свитерлар | | | 5447 |
| Панталоннар | | | 4748 |
| Кофталар | | | 2061 |
| Юбкалар | | | 2416 |

Моның өстенә Америка ярдәм оешмасының медицина бүлеге 1921 елның сентябреннән 1922 елның мартына кадәр 12 вагон дару һәм хастаханәләр өчен кирәк-яраклар да җибәргән. Шулар арасында 5280 җәймә, 3746 одеял, 3213 пижама, 6803 сөлге, 16894 пар йон оекбашлар һәм 3103 пот медикаментлар булган. (Отчетта дарулар һәм сабын 3103 пот дип күрсәтелә)[47].

Шулай итеп, Американың шәфкать оешмасы Татарстанның 1 млн. 200 меңнән артык кешесен ач үлемнән саклап кала. Бу сан республика халкының яртысын (!) тәшкил итә. Океан артыннан, ерак юллар аша Татарстан халкына ярдәм итеп, балалар оекларына кадәр китергән Америка халкына рәхмәттән башка сүз юк. Тик шунысы әрнетә: ни өчен безгә бу яхшылыкны онытырырга тырыштылар соң? Тарих дәресләрендә бу олы җанлылыкка гел кире бәя бирелде. Ә бит тарих шаһит, ни кадәр бозып, кирәгенчә төзәтеп язсалар да дөреслек бер калкып чыга ул. Ачлык башлану белән Мәскәүдән ярдәм сорагач: «Сез автономияле республика, үзегез турында үзегез кайгыртыгыз», — дигән җавап та архивта сакланып калган.

Тагын мен тапкыр рәхмәт Америка халкына. Ә менә тарихка Татарстанның ин беренче Министрлар советы рәисе булып кереп калган, хәзерге көнгәчә урамга һәм мәдәният йортына бирелгән исеме сакланган Сәетгалиев кайчан да булса вөҗдан газабы кичерде микән? Бу сорауны мин Мәскәүдә очрашкан вакытларда Зөһрә апа Баимбетовага (ул 1986 елда вафат булды) бирдем. Аның җавабы, үзгәртмичә бирергә тырышам, дәфтәремдә сакланган. «Җан газабы кичергәндер дип уйламыйм. Намуссыз кеше иде бит. 1921 елда Мәскәүдәге хатынын ике баласы белән ташлап (анысы татар иде), Казанда телеграфистка булып эшләгән Ольга исемле маржага өйләнде. Шәһәр уртасындагы «Совет» кунакханәсендә бик зурлап туй ясады. Татарстанда ул вакытта Запастагы армия дә бар иде бит әле. Туйга менә шул армиянең оркестрын чакырды. Тәрәзәләрне ачып куеп, кунаклар күнел ачты. Ә шәһәр урамнары ачлыктан шешенгән, кая барып бер телем икмәк табарга тилмергән халык белән тулы иде. Туйдан соң Мәскәү газитләре «Пир во время чумы» дип язып чыктылар. Хәтерем ялгышмаса, аны Татарстаннан куып җибәрделәр.

Мәскәү аның бу «тырышлыгын» бәяләп, алтын сәгать бүләк итте. Татарстаннан соң Кырым республикасына җибәрде. Кырымда да ул ачлык оештырды. Аннан да кудылар. Соңрак Мәскәүдә төрле оешмаларда эшләп йөрде. Бүтән кирәге калмагач, культ елларында юкка чыгардылар үзен».

Татарстан республикасы зур югалтулар белән ачлыктан чыга. 1923 елда хәл бераз җиңеләя төшә. Ләкин ярты миллионнан да артык (600 мең дип исәпләнә)[48] кешесен югалткан республиканың хәле авыр булган дип белик. 86 мең (!) крестьян хуҗалыгы бөтенләй юкка чыга. Бу саннар төгәл түгел дип уйларга да җирлек бар. Чөнки авылларда кабер казырга да кешеләр булмаганда, нинди йөрәк, нинди көч табылсын да, кем төгәл итеп саный алсын? Кем юлларда үлеп калучыларны барлап, санап йөри алсын? Шуңа күрә дә халкыбыз тарихындагы бу фаҗигале еллар һәрберебезне бик җитди уйландырырга, хаклыкны ялганнан аера белергә өйрәтергә тиеш. Туган җиребез өстенә төшкән афәтләр дә ачлык белән генә дә бетми бит әле...

**Тәэминә БИКТИМИРОВА,**
*тарих фәннәре кандидаты*

[46] ТР МА, Р-128 ф., 1 тасв., 174 эш, б.17.
[47] ТСД ҮДА, 36 ф., 2 тасв., 21 эш, б.62.
[48] Татар энциклопедик сүзлеге. — Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. — Б.53.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Зур Кукмара

Зур Кукмара авылы Кукмара районында, район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 3 чакрымда, Вятка Аланыннан 14 чакрым ераклыкта урнашкан.

Зур Кукмара авылы тарихи белешмәләрдә еш кулланыла.

А.Артемьев нәширлегендә бастырып чыгарылган белешмәдә (ул 1859 ел мәгълүматларын эченә ала) күрсәтелгәнчә, Норма суы ярына урнашкан Зур Кукмара авылының 99 хужалыгында 370 ир-ат һәм 411 хатын-кыз яшәгән, 1898 елда басылып чыккан белешмә мәгълүматларына караганда, Зур Кукмара авылында татарлар көн күргән.

Авыл матур һәм унайлы жиргә утырган. Авыл каршында тау. Тау астыннан авылны буеннан-буена инләп Норма суы ага. Норма елгасына чишмәләрдән жыелган Инеш кушыла. Аны Быргы чишмәсе дип йөртәләр. Быргы чишмәсенең тарихы кызыклы гына. Революциягә кадәр солдат хезмәте 25 елга сузылган. Егетләр 20 яшьтә китеп 45 яшьтә көрәктәй сакал белән кайтканнар. Солдатларны шушы чишмә янына ялга кайтара торган булганнар. Аларны халык зурлап, өй саен кунакка йөрткән. Кайткан солдатлар шул кечкенә чишмәләрдән жыелып аккан Инеш буенда, ямь-яшел чирәмлектә быргылар кычкыртып ял итеп ятканнар. Шуннан сон халык ул инешне Быргы инеше дип атый башлаган. Авыл уртасыннан тагын бер инеш ага, ул да чишмәләрдән жыйналган. Аның башланган урынын Солдат болыны дип атыйлар. 25 ел хезмәт иткән солдатларның гаиләләренә шушы болынны бүлеп бирә торган булганнар һәм шуннан аларга печән чабарга рөхсәт биргәннәр.

Зур Кукмарадан якын гына район үзәге — Кукмара эшчеләр бистәсе утырган. Хәзер яна өйләр күп салына, аларны үзара кушылып ук беткән дияргә мөмкин. Зур Кукмара авылы яныннан Норма суы агып үтә. Район үзәге шулай ук тау итәгенә урнашкан. Тау башлары нарат, чыршы агачлары белән капланган. Әле 20-25 еллар элек кенә берни үсмәгән таулар мәктәп укучылары, итек фабрикасы һәм тегү фабрикасы эшчеләре тырышлыгы белән урман үсә торган тауга әйләндерелгән. Жәен ул урманлыкта сандугачлар сайрый, гөмбәләр үсә.

Зур Кукмара элек бистәдән зуррак та булган, шуна аны Зур Кукмара дип йөрткәннәр. Ул хәзер дә үсүен дәвам итә. Бер яктан ул Кукмара бистәсенә барып тоташа, икенче яктан күрше Рудник авылына кадәр кинәйгән. Элек авылның ике ягында бәрәнге, чөгендер басулары булган, хәзерге вакытта бу басу жирләрендә яна хужалыклар барлыкка килгән, чөнки соңгы вакытларда авылга күчеп килүчеләр саны арта бара.

Авылдагы чишмәләр чистартылып, каралып тора. Авыл уртасында яна мәчет балкып утыра. Мәчеткә йөрүчеләр күп, бар да тырышып укый.

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

# Зур Солабаш һәм Кече Солабаш авыллары

Зур Солабаш авылы Биектау районында, район үзәге Биектау тимер юл станциясеннән 31 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Дөбъяздан — 6, Казаннан — 45, Кече Солабаш авылы район үзәгеннән — 28, Дөбъяздан — 3, Казаннан 42 чакрым ераклыкта урнашкан.

Сола суы ярына утырган Солабаш авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. Е.И.Чернышев хезмәтендә Солабаш атамасы теркәлгән. Казан өязе теркәү кенәгәләрендә (1602-03 еллар) Солабаш атамасы телгә алына. Зур Солабаш авылы зиратында XVI гасырның беренче яртысына мөнәсәбәтле өч кабер ташы табылган.

XVIII гасыр мәгълүматларын эченә алган Д.А.Корсаков жыентыгында «Олы Алат, шулай ук Салабаш, Шулабаш, Сулы суы башланган урындагы авыл» дип күрсәтә. Монда 96 ясаклы татар, Кече Солабашта 60 ясаклы, 6 йомышлы татар яшәгән. Авылларны исәпкә алган исемлекләрдә Зур Солабаш Олы Алат дип тә атап йөртелә.

Кече Солабаш кешесе Габдрахман абый безгә түбәндәгеләрне сөйләгән иде. Элек Зур Солабаш авылы Ашыт үзәнендәге Алат авылы янында булган, Рус Алатына килеп урнашкан руслар аларны көчләп китәргә мәжбүр иткәннәр. Менә ни өчен ул тагын Алат исеме белән аталган. Димәк, авыл халкы тарихи яктан, руслар килеп утырганчы оешкан Алат ханлыгы, Алат авыллары халкы белән бәйләнешле булган, тикмәгә генә ул Олы Алат дип аталмаган.

А.Артемьев хезмәтендә (XVIII гасыр) Солабаш авыллары болай сурәтләнә: Олы Алат (Солабаш) авылында 42 хужалык булып, анда 195 ир-ат һәм 220 хатын-кыз яшәгән, авылда бер мәчет булган.

Кече Солабаш, Айтуган пүчинкәсе, Шыгай чишмәсе авылындагы 11 хужалыкта 48 ир-ат һәм 46 хатын-кыз көн иткән.

Билгеле булганча, Казан ханлыгы егылганнан соң, буйсындырылган халыкны көчләп чукындыру сәясәте башлана. Бу сәясәттән Зур Солабаш авылы халкы да зур зыян күрә. 1866 елның 6 июнендә Зур Солабаш авылында Акулина Павлова вафат була. Аның ире Максим Федоров (татарчасы Ишимяр Ишимов) хатынын күршедәге рус авылы — Алат зиратына күмдермәс өчен аны үз ишек алдына вакытлыча жирли. Килгән тикшерүчеләр мәетне алып китәргә теләгәч, авыл хатын-кызлары кабер өстенә куелган такталарга ята. Кире исламга кайту өчен көрәш көчле була. Төрмәгә утыртулар, чыбык белән суктырулар, сөргенгә сөрүләр гадәти хәлгә әйләнә.

Зур Солабаш авылы халкы чукындырылганнан соң бирелгән ирләр һәм хатын-кызлар исемнәре дә бу чыганакта теркәлеп калган: Максим Федоров (Ишимяр Ишимов), Яков Алексеев (Тимергали Халитов), Федосья Семенова (Бибимәдинә Тахтарова), Акулина Семенова (Бибилатыйфа Халитова), Ирина Иванова (Бибифатыйма Халитова).

Зур Солабаш, Кече Солабаш, Дөбъяз, Чыршы, Тарышна, Суксу, Кондырлы, Сая, Өбрә, Абла, Зур Әлдермеш, Кече Әлдермеш авыллары халкы июль аеның беренче атналарында жыелып Биектау жыены үткәргән (Н.Борһанова).

Кече Солабаш — билгеле һәм күренекле авыл. Бу авылда татар халкының атаклы дин һәм жәмәгать эшлеклесе, тарихчы-галим, жәдитчелек хәрәкәтенең асыл вәкиле Хәсәнгата Мөхәммәт улы Габәши 1863 елда указлы мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Уку-язу, шәрык хәлләре һәм Коръән нигезләре буенча башлангыч дәресләрне ул заманның зыялылары булган бабасы Гобәйдулладан һәм әтисе Мөхәммәт хәзрәттән алган.

1891 елда Кече Солабаш авылында аның улы — киләчәктә татар халкының беренче профессиональ композиторы булачак Әхмәтсолтан (Солтан Габәши) дөньяга килә.

Солабаш авылы тирәсе элек калын урманнар белән капланып алынган булган. Билгеле, урманлы жир елга-күлләргә бай була. Заманында бу тирәдәге чиста сулыкларга аккошлар да килгән дип сөйлиләр.

## Ике Басу Арташ

Ике Басу Арташ авылы Саба районында, район үзәге Байлар Сабасы авылыннан 18 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Иске Икшермә авылыннан — 15, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән — 40, Балык Бистәсе пристаненнан 47 чакрым ераклыкта урнашкан.

Д.А.Корсаков белешмәсендә (XVIII гасыр) Ике Басу Арташ авылы үзенең төрдәше Кече Арташ атамасы белән теркәлгән. Анда 14 ясаклы татар яшәве күрсәтелгән. 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Ике Басу Арташ авылындагы 26 хуҗалыкта 78 ир-ат һәм 111 хатын-кыз көн иткән, мәчет эшләгән.

Авыл төз, матур чыршылар белән бизәлгән биек тау астыннан качып кына агучы инеш буенда урнашкан. Ул үзе дә ике яктан биек тау куенына кереп утырган кебек. Инешнең уң ягына утырган авыл озын гына бер урамнан тора.

Элек бу тирәләрдә, олылар сөйләвенә караганда, кара урман булган. Әле дә тау башларында чыршылар үсә. Көнбатыштан һәм төньяк-көнчыгыштан авылны урманнар әйләндереп алган.

Халык телендә Арташ атамасы артыш агачына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән дигән фикер яши. Башта биредә чәчүлек җирләре аз булган. Халык урман кисеп, агач төпләп, чәчүлек җир хәзерләгән. Авылның хәзерге кибет урыннарында һәм югарырак та зур күл булган. Урманнарны кискәннән соң ул күл кипкән.

Авыл үсә барган саен иген игү өчен чәчүлек җирләр күбрәк кирәк була башлый. Авылдан 5-6 чакрым ераклыкта урман эчендә алан була. Халык бу аланны да чәчүлек җиргә әйләндерә. Басуы ике урында булганга, авылны Ике Басу Арташ дип йөртә башлыйлар.

Авыл халкы иген игү һәм терлекләр үрчетүдән тыш, сәүдә эшләре дә алып барган. Барлык эшне кул көче белән башкарганнар. Авыл халкының эш кораллары агач сука, балта, пычкы һәм көрәк булган.

Элек авылга якын гына ике бай яшәгән, берсе Ибеки исемле, икенчесе Плаксин фамилияле булган. Кайберәүләр бу байларга ялланып эшләгәннәр.

Тора-бара авылда баерак тормышлы кешеләрнең саны арта. Алар мал-туарны күбрәк үрчеткәннәр, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр. Авылның Баһаветдин исемле кешесе Оренбургтан хуҗалык өчен кирәкле төрле әйберләр алып кайтып сата торган була.

Авылның көнчыгыш ягыннан инеш ага. Авылдан бер чакрым киткәч, ул Мишә суына кушыла. Инешнең бер ягында тау булса, икенче ягында матур булып зирекләр, таллар үсеп утыра. Көньяк урманыннан Ширбәт елгасы агып чыга. Ана шактый күп чишмә-кизләүләр килеп кушыла. Шуларның берсе — Бала чишмәсе. Ямбай авылы белән ике арада Ямбай чишмәсе бар. Бу чишмәнең исеме Ямбай авылы атамасына мөнәсәбәтле. Ямбай авылы халкы исә бу чишмәне Арташ чишмәсе дип йөртә. Моннан башка тагын Ширбәт, Кыйбла, Кирам һ.б. чишмәләрне атап әйтергә мөмкин.

Авылда өч зират бар. Берсе авыл уртасында, икесе авылдан читтә. Берсе иске зират, ә икенчесе җенле зират дип атала. Бу зират яныннан төнлә узып китим дигән кеше таң атканчы шушы зиратны әйләнеп йөри икән.

Авылда элек зур мәчет булган. Аның манарасы 1952 елда генә киселә. Манараны кисәргә беркем дә риза булмый. Аны күршедәге Әбдe авылы урыслары кисә. Айны авыл кешесе Фәсахетдин абзый ясаган була. Манара киселгәч, ул айны өенә алып кайтып саклый. Ул үлеп йорты сүтелгәч айны Закиров Әхмәтшәриф үзенә ала. Хәзер бу ай Саба район музеена куелган.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ЯРАТАБЫЗ СИНЕ, ӘЛФИЯ АПА!

Ничә генә яшен тутырса да, ул һаман яшь кызлар кебек дәртле, монлы, серле, кайнар. Ходай аны ничек яраткан булса, ул әле дә шундый — матур, чибәр, сөйкемле, ягымлы. Аның тавышы да тынгысыз елга сыман шаулап ага, кайчагында йомшак җәйге җил кебек исә, ләйсән яңгыр сибәләгәндәй иркәли, яшен кебек күкләрне инләп күкри. Шулай аны тыңлап гомер кичерәбез, тормыш дингезләрендә йөзәбез, жыр дулкыннарында чайкалабыз. Жырла, Әлфия апа, жырла — сина тиңнәр әле аз икән.



Чыннан да, жыр сәнгатендә Әлфиядәй колачлы жырчылар сирәк. Аның өчен Әлфия кебек михнәтле гомер кичерү кирәк микәнни? Яшьтән ятим калу бәрабәренә генә, интегеп, ач-ялангач яшәп кенә моң-сагыш тула микәнни ул үзәкләргә. Татар жырының таң атышларында Әлфиядәй кояш ник чыкмый? Гажәпләндерә.

Ул үзенең концертларын «Мәңге яшисе килә» дигән жыры белән башлап жибәрә. Сизелә, һәрвакыт башта бераз каушый, дулкынлана. Жыры тәмамлангач, акланып та ала: «Сигезенче дистәне тутырганда кем инде сольный концерт бирә? Жүләр! Моннан соң әзергә-бәзергә генә йөриячәкмен», — дип үзен тынычландыра. Янәсе, кем чакыра, шуның концертларында гына катнашачак.

Әлфия апа сөйләнә-сөйләнә жырлап ала. Жырлаган саен тавышы ачыла, үзенә-үзе ышанычы арта, кәпрәебрәк жиппәрә.

— Хәзерге яшьләр интегеп жырлап йөрмиләр (тавыш режиссерына күрсәтеп), тегендә «тегермән» (магнитофон) әйләнә. Салават белән әле күптән түгел кырыкка якын концерт куеп кайттым. Үземчә турыдан жырладым. Кәрим ике бармагы белән уйнап тора, минем бер шушы авызым яшәсен. «Таңда сүнсә, кич кабына» жырын янгырата.

— Әлфия апагыз әле ул таңда да сүнми, — ди дә, «Танец живота» ясап ала. Ничек эшли ул аны? Сиксән түгелме соң инде апакаема?.. Жырын бетерә дә, тагын кеше күңелен күтәрә.

— Әстәгъфирулла тәүбә! Дөньяны хатын-кыз баскан. Әйбәт түгел бу. (Залдан ирләр эзли) бер, ике бар икән. Берәгәйләләр, боларына каш сикертсәң дә ярый. Мин гомер буе биеп жырладым, хәзер бик биеп булмый, — дигән була. Үзе «Картаямыни соң йөрәк» дигән жырны кыстырып куя. Белеп жырлый, юри жырлый, тамашачыны әзерләп — оста инде!

*Картаямыни соң йөрәк,*
*Маңгайлар сырланса да.*
*Үтте яшьлек жүләрлек дип*
*Жырларда жырланса да.*

Жырын жырлады да, кинәт туктап, музыкантлары Кәрим Габидуллинга, Фәрит Хатыйповка Кирам Сатиевка «бәйләнә» башлады.

— Әй, әй, туктагыз әле, төрлегез төрле якка талкыйсыз бит!

Дөрес туктатты ул аларны. Шундый дәртле җырны иренеп кенә уйный башладылар бит. Дөресен генә әйткәндә, Фәрит белән Кирамга хас нәрсә түгел инде ул сүлпәнлек. Кәриме дә онытылып киткәнме? Әзгә кертте бит Әлфия апа боларны. Дәртләнеп уйнап җибәрделәр. Апабыз элеккечә канатланып җырлап бетерде һәм, билгеле, үзенең сөйләм телендә булган «козырь»ларына күчте.

— Мәскәүдә мишәрләр. Чәчәк бирәләр дә чәчәк бирәләр. Эх, мәйтәм, цәцәк янына «яшел кәгазь» дә кыстырсагыз, дим. Көләләр.

Мәскәүләрдә, тагын әллә кайларда бик озак гастрольләрдә йөреп кайттым. Эләктерде бит Путин, каптырды. Биш айга фатирга түләнмәгән. Судка бирмиләр әле. Бер унбиш көнгә төрмәгә кереп чыгам, мәйтәм. Исән булсак — түләрбез, булмасак — үләрбез.

Алты яшем тулмаган иде — әнием үлде. Үткен булып үстем. Безнең балачак сугыш елларына туры килде бит, шуңа күрә репертуарыма сугыш турындагы «Син кайтмадың»ны керттем.

*Сандугачлар килде, аккош кайтты,*
*Син кайтмадың киткән җиреңнән.*
*Аккош китәр урман, күлләреннән,*
*Син китмәссең минем күңелемнән...*

Әлфия кызганнан-кызды, тавышы һаман ачыла төшә. Американың Тернерлары бер кырыйда торсын, кая ул Хьюстоннарга аны узу!

— Тирләтә, — диган була Әлфия апа, — сез дә тирләмәдегезме, хөрмәтле тамашачылар? — ди. — Җырлыйм әле, җырлыйм.

*Сагындым авылымны,*
*Кайчан кайтырмын инде.*
*Сәлам әйт сөйгән ярыма,*
*Әткәем, әнкәемә,*
*Сәлам әйт туганнарыма!*

Кәрим, ничек звучание? Тамашачы ни ди? Колакларыгызны тондырмыйбызмы? Бераз кимет әле, Илфират, аппаратура тавышын. Халыкны саклыйк. Хөрмәтле тамашачылар, Кәрим, «нормальный», — ди. Безнең хәзер артистлар «заслуженныйны» бик тиз алалар — чибәр чакта, ә «народныйны» — ялагайланып — җаен табалар инде — оста бүгенге яшьләр... Төн чыкканчы — җон чыга.

Бик гайбәт эчендә яши Әлфия апагыз. Гомер буе обком юлында булдым. Чакыртучыларның күбесе үлде инде. Элекке бер министр үзе гүләйт итте. Аныкын күрмиләр. Минекен бөтен халык белә. Чибәрлегемне кая куйыйм — яшереп булмый бит бу гүзәллекне.

Әй бөтерелә Әлфия апа, әй сыгыла, сырпалана. Зайцев, Зверев модельерлары бер кырыйда торсын. Моны карарга кирәк, күрергә! Язып кына аңлатырлык түгел бу могҗизаны, осталыкны! Күзне ачып булмаслык яшьле шатлык. Бөтен зал шул халәттә. Әлфия бу — Авзалова! Ул беркавымнан безне яңадан сагышка батыра. Язмышы җырларында аның.

*Шатлыгымнан күбрәк хәсрәт килде.*
*Бөгелсә дә башым имәдем.*
*Соңгы чиккә барып җиткәндә дә*
*Туйдым синнән, дөнья, димәдем.*

*Мин нишләрмен, вакытыннан алда*
*Яшәр чәчәкләрем коелса.*
*Озайт, Ходай, бераз гомеремне*
*Яшиселәр килә шулкадәр.*

Аллага шөкер, еламыйм әле. Илһаметдингә килик инде. Житмеш яшенә чакырмады бит. Причинасы бар. Без аның белән яшь чакта бераз «сиптереп» алдык. Бергә булалмадык. Үпкәләгәндер. Үзенә багышлап жыр яздырган идем. «Соңлап килгән мәхәббәт» дип атала ул. Яратам мин аны чүтеки.


*Әлфия Авзалова кызы Зөлфия белән.*

*Соң булса да инде күрештек,*
*Бер-беребезгә вәгъдә бирештек...*

...Кыен елларда яшибез, туганнарым. Шәһәрдәгеләргә бигрәк читен. Алай-болай булса, эшләр начарга китсә, мин авылга чыгып жырлармын, сез ачтан үлә күрмәгез. Әй, сез (музыкантларга борылып), лыгырдатмагыз, ә, пожалысты! Гөлшат Зәйнашева сүзләре — «Юл жыры».

*Бар табигать жырлый башлый,*
*Кая гына бармыйбыз.*
*Жырлый-жырлый йөргәч, юлда*
*Армыйбыз без, армыйбыз.*

Барган һәр жиремдә кочаклап каршы алалар, хөрмәтләп озаталар. Мин рәхмәтле үз халкыма. Ходай Тәгалә безне бер-беребездән тиз генә аермасын иде әле. Жырлыйсым килә.

*«Ник моңаеп уйга калдың?*
*Аерылабыз, дисеңме?*
*Бәлки әле аерылмабыз,*
*Аерылмабыз шикелле.*

Аерылмабыз әле, Әлфия апа. Чөнки син әле һаман безнең жыр кояшы. Ул сүнсә, жылытмаса, караңгы булыр, тунарбыз. Күпләр сиңа тиңләшеп яши, синнән өйрәнеп ижатында юл яра. Бу концертыңда да сиңа тамашачың күп итеп сап-сары чәчәкләр бүләк итте. Сары — муллык билгесе. Синдә бар да мул, хәтта күнеленнән агылып, ташып тора. Шунадыр халык сиңа гаеп такмый. Бары тик сине «Үзебезнең Әлфия!» — ди.

Яратабыз сине, Әлфия Авзалова!

**Алмаз ХӘМЗИН**

---

## Әлфия Авзалова турында язалар һәм әйтәләр:

*...Иң якты йолдызлардан яралган, үзе дә сәхнә йолдызына әверелгән Әлфия Авзалова бар. Әлфия үз талантын ил-халык язмышы белән бәйләде. Хәзер инде татар тарихын Әлфия Авзаловадан башка күз алдына китерүе дә кыен...*

**Илһам ШАКИРОВ**

*...Читтә яшәүче милләттәшләребезнең һәрбер күзәнәгенә моң алып баручы илче ул...*

**Айрат АРСЛАНОВ**

*...Туктаусыз эзләнү, яңа җырлар өйрәнү, үз өстендә эшләү, ирешкән уңышлар белән тынычланып калмау — Әлфиянең иҗат принциплары...*

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА**

*...Әгәр Айда кеше яшәп, татар халкы анда барып чыккан булса, Сезне Айга да чакырмый калмаслар иде...*

**Харрас ӘЮП**

*...Татар халкында мәшһүр хатын-кыз җырчылар аз түгел. Әмма Әлфия Авзалованың мәшһүрлеге аерым бер могҗиза... Кайсы халыкта бар шундый могҗизалы җырчы?..*

**Рабит БАТУЛЛА**

*...Аның җырлары яшәргә көч бирә, иң авыр минутларда күңелләргә канат куя. ...Ул озын гомерле җырчы. Әлфия дигән исеме үзе үк «меңьяшәр кыз» дигән мәгънәне аңлата...*

**Рәшит САБИРОВ**

*...Җырчының осталыгы хакында күп язып булыр иде. Ләкин моның кирәге юк, чөнки артистка «күкләргә чөйгән» сүзләргә мохтаҗ да түгел...*

*Башкортстан. «Кызыл таң» газетасы.*
**Г.РАМАЗАНОВ** *мәкаләсе*

*...Своими истоками современная татарская песня исходит из народного творчества. И исполняя ее, Альфия Авзалова подчеркивает глубоко национальные, народные интонации...*

*Үзбәкстан. «Сельская правда» газетасы.*
**К.ГАЙДИНОВ** *мәкаләсе*

# ИЛДАР АБЫЙЛЫ ВАКЫТЛАР...

*Хуш инде. Мәңгегә*
*Хуш инде.*
*Китә яз, китә наз,*
*Кыш инде...*

И.Юзеев

2004 елның декабре. Бер суыта, бер җепшетә, бер буранлап ала, ара-тирә бар дөнья тынып та кала. Кәбисә ел булгангамы, көннәре дә бераз сәер, шомлы. Күңел нидер сизенәме, һаман саен тынычсызланып, арлы-бирле бәргәләнеп куя...


*Остаз һәм шәкерт. Илдар Юзеев һәм Ленар Шәех. 2003 елның 24 декабре*

Илдар абый белән күрешмәгәнебезгә бер айдан артты. Соңгы мәртәбә ноябрь башында Татарстан Язучылар берлеге бинасында очраштык. Ул, гадәттәгечә, эштә. Үзен балачакка алып кайткан «Сабантуй» газетасыннан киткәч, «Сәхнә» журналында эшли башлаган елы. Акча җитмәүдән түгел, гомере буе янып-көеп, җиң сызганып халыкка хезмәт иткән шагыйрь тик утыра белми, лаеклы ялны да лаеклы хезмәт итеп кабул итә иде. Минем, Казан дәүләт университетының өченче курс студентының, «Шәһри Казан» газетасында кайнап йөргән чак. Җомга санының шигърият битен мин алып баргалыйм. Менә Илдар абыйның хәлләрен белергә, шул унайдан шигырьләрен дә сорап карарга булдым, газетада бер шәлкем итеп чыгарырга кирәк.

Илдар абый:

— Ярый, син сораган өчен генә риза, киләсе дүшәмбегә хәзерләп алып килермен, — диде.

Ул дүшәмбе очраша алмадык, чәршәмбе көнне эшенә киллем, ләкин күрешеп булмады. Өстәлендә бары зур конверт тора. Тышына «Ленар Шәехкә» дип язылган, ә эчтә бер фото һәм алты шигырь... Мин Илдар абыйның шигырьләрен басмага әзерләп куйдым. Редакциядә, туган көне алдыннан, декабрьнең соңгы атнасында бастырырбыз, дип уйлаштык. Әмма шагыйрьгә бу көннәрне күрергә насыйп булмаган икән.

Ул елны, Казанның меңьеллыгына әзерлек уңаеннан, башкаланың Горький паркы тирәсен — Ершов урамын ремонтка япканнар иде. Шуңа без, студентлар, Гвардия урамындагы 5 нче номерлы тулай торактан университетка җәяү йөрибез. Ярымкараңгы Достоевский урамы аша узганда, әллә Илдар абый янына кереп чыгарга инде, дип уйлап куйгалыйм (Вишневский һәм Достоевский урамнары кисешкән чаттагы йортта яши иде ул). Хәлләрен сораштырырга, мине әдәбият мәйданына җитәкләп диярлек алып килгәне өчен чын күңелдән рәхмәт әйтергә... Ул елны мин яшь каләм ияләренең «Иделем акчарлагы» иҗат бәйгесендә шигърият буенча Гран-при яуладым. Илдар абый да бу хакта белә, ихластан сөенә иде, ләкин күрешергә өлгереп булмады.

Очрашырбыз, бер жае чыгар әле, дип уйлап йөри-йөри, бер мәлне күңелне ниндидер сиземләү, шомлы тоемлау, тынгысыз кыбырсу биләп алды...

20 декабрь көнне укудан ялгызым гына кайттым. Вакыт шактый соң. Туктаусыз эчем пошканга, туры юлдан түгел, ә караңгы урамнар аша узган урау сукмактан атладым. Минем күңелем соң чиккәчә житеп тартыла, үзенә урын таба алмый. Йөрәк кыса, жан уртасында борчулы аваз яңгырый:

*Ярымбушлык, ярымкараңгылык,*
*Йөрәктәге тирән ярам кебек.*
*Шул ярамны учлап барам кебек,*
*Болай бару соңгы чарам кебек...*
*Ярымбушлык, ярымкараңгылык.*

Икенче көнне иртә белән «Чаян»да журналның әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, танылган журналист Мәгъсүм абый Гәрәев белән сөйләшеп утырдык.

— Фото мәсьәләсен Яна елга калдырырга туры килер. Илдар абыең сырхауханәгә кереп яткан, — диде ул. (Мәгъсүм абыйның яна китабына өчәү бергә фоторәсемгә төшмәкче идек бит).

Бүген үк Илдар абый янына барып кайтырга кирәк. Нәрсә булды икән? «Чаян»нан чыктым. Тугызынчы һәм сигезенче катлар арасында, баскычта шагыйрь Роберт Әхмәтжанов кем беләндер сөйләшеп тора, күзләрендә тирән сагыш:

— Илдар үлгән бит, Илдар...

— Кайсы Илдар? Юзеевмы әллә?..

— Әйе...

— Ни сөйлисез сез?..

— Әйе шул, үлгән...

Бер мизгелдә күңелемнен әллә ничә кылы өзелде... Аякларым әллә атладылар, әллә юк...

*Башка төшкән кайгы-сагышларны*
*Әллә бүлешәбез, әллә юк...*
*Әллә күрешәбез, әллә юк...*

И.Юзеев

Күңелемдә кадерләп сакланган якты хатирәләр уяна.

2000 ел. Мин, Илдар Юзеевны әдәбият дәреслегеннән генә укып белгән, Минзәлә педагогия көллиятенең беренче курсында укып йөргән егет, аннан хат алгач, ничек сөенгән идем! Ял көннәренә авылга кайткач, ул хатны әнием тапшырды. Татарстанның Казаннан ерак бер почмагында туып-үскән ниндидер Ленарга халык шагыйре Илдар Юзеев үзе игътибар итсен әле!..

*«22 март, 2000 ел.*

*Ленар!*

*Шигырьләрең — басылырлык. Әмма үзеннән кем икәненне язмагансың. Синең балалар өчен язу сәләтен бар. Дәвам ит. Юморың да мөлаем. Әмма кайбер урыннарда рифмаларың ятышсыз. Бер строфада — төзәттем.*

*Өч шигырьне гәзиткә тәкъдим итәм. Тиз генә чыкмас та, бәлки. Чират зур.*

*Уңыш телим.*

*Илдар Юзеев».*

Арада тагын алты сәлам хаты — төпле киңәшләр, жылы теләкләр, зур таләпләр... Ярый әле ул мине күреп алды, югыйсә, кем белә, бәлкем бөтенләй башка сукмактан киткән булыр идем.

*«5 июнь, 2002.*

*Ленар!*

*Үзең язган шигырьләрең каләр жылы сәлам!*

*Язган материалларыңның әйбәтләрен «Сабантуй»да урнаштыра торабыз.*

*Хәзер синең бик җаваплы чорыңдыр. Минзәлә көллиятен тәмамлыйсың булыр. Имтиханнар вакытыдыр дип беләм. Әгәр быел тәмамласаң, укуыңны дәвам итәргә уйлыйсыңмы? Югары белем алырга теләсәң, университетның татар филологиясенә кер. Шигырь язуың комачау булмас дип уйлыйм. Без дә хәлдән килгән кадәр ярдәм — рекомендация бирербез.*

*Синең шигырь язу сәләтең бар, шуны үстерергә, белемеңне тирәнәйтергә кирәк. Яңа язмаларың булса, җибәрә тор. Туп-туры минем исемгә. Мин «Сабантуй»да, атнага ике тапкыр килеп, поэзияне алып барам.*

*Хәзергә хуш. Алдагы сынау, имтиханнарда сынатмассың дип ышанам.*

*Миңа атап язган шигырең өчен рәхмәт.*

*Сәлам белән: Илдар Юзәй».*

Әйе, ахыргы хатларында Илдар абый Казанга — университетка килергә үгетләде. Ә мин, алдан сизенгәндәй, башкала, шәһәр шаукымына күнегә алмыйча, ул кодалаган татар филологиясе һәм тарихы факультетына укырга керергә җыенып йөри идем.

Илдар абый янында узган һәр мизгел, һәр очрашу истә. Ул «Сабантуй»да эшли, мин аның янына гына киләм. Нинди дер магниты, ягымлы карашы белән үзенә тарта. Аның бүлмәсеннән сөенә-сөенә чыгасың, канатланып кайтып китәсең. Мактавы да, тәнкыйте дә эләгә...

Казан тикле Казанга да мине Илдар абый тартып китерде. Укуымны, дөньяга чыгуымны, ачылуымны, үсүемне теләде бит ул. 2002 елның сентябрендә беренче курска укырга килгәч, тәүге мәртәбә «Сабантуй»да күрештек. «Фотоңнан озын буйлы икәнлегеңне чамалаган идем. Кара, чынлап та шулай икән», — дип мине тагын да үстереп җибәрде. Шулай аралар якынаеп, җылынып китте. Әйбәт кенә укыйм, семестрны япкач, каникулга китәр алдыннан, махсус Илдар абыйның эшенә барам. Ә ул имтихан билгеләремне сорый да, гел «бишле»ләр булуын белгәч: «Ленар, син нигә минем оныгым түгел икән?» — дип әйтеп куйгалый. Үзе дә миңа дәү әтием кебек якын, кадерле. Бәлки, дәү әни белән генә үскәнгә шулайдыр... Оныкка бабай назы, аның акыл өйрәтүе, тормыш тәҗрибәсен биреп калуы да кирәк бит.

Илдар абый «Сабантуй»да ун ел эшләде. Ул газетадан киткәч, миңа авыр иде. «Идел-пресс»ка барам, ә анда — бушлык. Беркем көтми, берәүгә дә мин кирәк түгел кебек. Күзләр таныш йөзне, шагыйрьнең ихлас елмаюын, җан җылысын эзли, кырыс чынбарлыктан ышык көтә... Ул «Сәхнә» журналына күчкәч, очрашулар «Сабантуй»дагы кебек еш булмады.

Беренче карашка өлкән генә күренсә дә, Илдар абый күңеле белән яшь иде. Яшьләр кайда, ул шунда. Төрле әдәби конкурсларда, кичәләрдә... Яшь иҗатчыларның 2002 елгы «Иделем акчарлагы» бәйгесендә ул алгы сафта йөрде, ачылу тантанасында, әдипләр белән очрашуларда катнашты, мастер-класслар үткәрде. Илдар абый безнең «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенә дә кунак булып килде, без оештырган «Шигъри Сабантуй» бәйгесендә катнашучы шунын кадәр яшь шагыйрьне күреп: «Әдәбиятның киләчәге бар икән!» — дип сөенеп, бар залны яңгыратты.

Күңел тулы хатирәләр...

Беренче курста укыган вакытым. Илдар абый юмор шигыре язып карарга кушты, «Чаян» журналына биреп карарбыз», диде. Шулай итеп, минем «Бар бездә берәү!» дигән шигырем язылды. Ул безнең төркемдә укучы ун кыз һәм бер егет, ягъни минем турында иде. Илдар абый шигырьне карап чыкты, йомшак урыннарын төзәттерде һәм мине сигезенче катта урнашкан «Сабантуй»дан тугызынчы каттагы «Чаян»га алып менде.

Журналның әдәбият-сәнгать бүлегендә Мәгъсүм Гәрәев һәм шагыйрь Зөлфәт бер бүлмәдә утыралар. Илдар абый безне таныштырды һәм мине, беренче мәртәбә күргән кешеләрем янында калдырып, кабинеттан чыгып китте.

Еллар үткәч уйлыйм: димәк, остазым үзенең шушы гамәле белән мине бер баскыч югары күтәргән! Шуңа лаек дип санаган... Нәтиҗәдә «Чаян»ның актив авторына әйләнүемә сәбәпче булган.

Тагын бер кызык вакыйгага искә төште. «Чаян»га «кереп киткәч», «Татлы хыял» дигән шигыремне күтәреп, остазым янына кердем. Илдар абый «Сабантуй»ның

хатлар бүлегендә эшләүче Фәридә Вәгыйзова белән бер бүлмәдә утыра, язганымны карый. Шигырьгә эпиграф итеп: «КДУ татфагының 1135 нче төркемендә сигез генә кыз укый...» — дигән җөмлә куелган.

Очраган һәр сүзгә рифма табучы, әйтелгән һәр фикергә кызыклы мәгънә салучы Илдар абый түзмәде:

— Сигез кыз асраганчы, симез кыз асра, — дип куйды.

Фәридә апа да күп уйлап тормады, үзенчә:

— Симез каз яхшырак, — дип дәвам итте...

Илдар абый чын мәгънәсендә төртмә, үткен, җор телле шәхес иде. Берсендә «Сабантуй»га килгәч, теләсә-кайда очраган (мәсәлән, урамда) сүзләрне кирегә уку белән мавыгып йөрүе турында сөйләде. Минем исемне дә әйләндереп күрсәтте: «Ранел! Кара, болай да кеше исеме килеп чыга икән бит!» — диде ул.

* * *

Остаз тәрбиясен бик аз тоеп калдым. Чыныгу өчен, чын шагыйрьлеккә юл алу өчен, бәлки, шулай кирәктер дә. Аның хәер-фатихасы, еллар битендә язылып, күнелемә сеңеп калды. Кызганыч, үзе кереш сүз язган беренче китабымны күреп сөенә генә алмады. Анда мондый юллар бар:

*«...Гамил Афзалның туган авылы Такталачыктан шигырьләрен җибәреп торган Ленар башкалардан йөз саескан арасындагы сыерчык кебек аерылып тора иде. Үзенчә сайрарга омтылуы миндә өмет уятты. Ленар чын мәгънәсендә «Сабантуй»да туды. Минзәлә педагогика көллиятен тәмамлагач, хатларда язган кинәшемне тынлап, Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетына укырга килде.*

*Әлегә мин Ленарны, үзе язганча, «бөре ачкан зирек» халәтендә күрәм. Колач җәйгән зирекләрнең матур шаулавын еракларга ишеттереп, шигъриятнең авыр юлларыннан барасы да әле барасы!*

*Илдар Юзеев.»*

* * *

*...Үзегез дә яхшы аңлыйсыз ла –*
*Калдык инде Илдар абыйсыз да...*

Әйе, ул зур шагыйрь. Шигъриятә үз мәктәбен булдырган, җиләне астыннан йөзләгән шәкерт чыгарган олы, изге җан иде. Илдар абый балалар шагыйре дә иде. Аның «Сабантуй» битләрендә дөнья күргән дисталәгән шигырьләре, кечкенәләргә аталган «Бәби Ай», «Аю сатам, кем ала?», «Кар өстендә дөяләр» һ.б. китаплары — мона дәлил.

Илдар абый танылган драматург та иде әле. Ул гади сәхнә әдибе генә түгел, ә шагыйрь-драматург иде. Әсәрләре дә тирән фикерле, мәгънәле, хисле, күнелгә үтеп керә һәм төптән уйландыра торган... «Кыр казлары артыннан», «Сандугачлар килгән безгә», «Бәхетемнән узып барышлый» һ.б. драмалары, комедияләре, «Соңгы төн», «Очты дөнья читлегеннән», «Бәгырь», һ.б. шигъри трагедияләре... — барысы да халык күнелендә яши.

* * *

22 декабрь иртәсе. Әллә нинди боек, моңсу, сагышлы көн.

Мин, Камал театры эчендә, зур тәрәзәләрдән карый-карый, остазым белән соңгы күрешүне һәм ахыргы саубуллашуны көтәм. Салкынча җил дә инде басылды, тын гына, моң гына ябалак кар ява башлады... Театр фойесында бер җан әсәре дә күренми әле. Иртәрәк килдем бит, иртәрәк... Соңгарак калдым шул, соңгарак...

Әле уртада торган зур портрет-рәсемгә карап алам, әле үземне тынычландырырга, юатырга теләп, уйларым белән кабат яңа яуган кар эченә кереп чумам...

...Театр шыгрым тулы. Ул халык, ул кеше... Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев сөйли... Илдар абыйның «Таныш моңнар»ына

туктала, шагыйрьнең олы иҗат юлын, аның якты шәхесен зур хөрмәт белән искә ала.

*...Җирне сөеп бүтән җилләр исәр,*
*Башкаларга безнең җыр күчәр,*
*Ак каеннар язын яшелләнер,*
*Сандугачлар таңда чык эчәр...*

И.Юзеев

* * *

...Еллар әкрен үткән кебек тоелса да, барлап карасаң, шактый җыела икән. Узган гомер көннән-көн арта, күбәя генә. Әнә, бүген тагын ябалак-ябалак кар ява. XXI гасыр башы татар әдәбиятының Илдар абыйлы иң бәхетле вакытлары бер-бер артлы күз алдымнан йөгереп уза. Күңелне аркылыга-буйга монсулык айкый. Юксыну катыш сыкрану аша йөрәктән суырылып-суырылып моң ташый, моң агыла...

**Ленар ШӘЕХ.**

---

*Хәзер Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның гомеренең соңгы елларында язылган, беркайда да басылмаган шигырьләрен тәкъдим итәбез. Алар Татарстан Республикасы Тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивыннан,* ***Илдар Юзеев*** *фондыннан алынды.*

* * *

*Хәкимҗан Халиков истәлегенә*

**Безнең яшькә килеп җитмәүчеләр,**
**Сездән башка җанга авыр бит.**
**Күңелләрдән мәңге китмәүчеләр,**
**Сезне шундый–шундый сагындык.**
**«Җырмы, малмы?» диеп сорасалар,**
**Сез тик җырны сайлар идегез.**
**Шигырь булып, китап булып калды**
**Әйтеләсе кайнар сүзегез.**
**Без бит юлга күпләп чыккан идек,**
**Ник шулкадәр бик аз калганбыз?**
**Сездән башка бару җиңел түгел,**
**Әллә шуңа без дә арганбыз.**
**Бөтен өмет хәзер сездә, яшьләр,**
**Тырышыгыз ялгыз калмаска.**
**Бер–берегезгә аяк чалмасагыз,**
**Алга барып була аргач та.**
**Юлда югалтулар җәрәхәтен**
**Аңлатырга шигырь–сүз җитмәс.**
**Үз гомерем кыскаргандай була,**
**Каләмдәшләр, ташлап сез киткәч.**
**Инде васыятькә әверелгән**
**Әйткән сүзләрегез гел истә:**
**«Бер–беребезне ташламаска иде**
**Бу дөньяда, исән килеш тә...»**

*31 гыйнвар, 2003*

## Тирәкләрем, нигә боектыгыз?..

Тирәкләрем, нигә боектыгыз?
Язның сөенечле чаклары.
Якты моңга күмгән кошларыгыз
Чит җирләрдән кире кайтмады.
Куркытмаган асыл кошларымны
Юлларының хәтәр-авыры.
Кайтып барган чакта харап иткән
Ком-буранлы сугыш давылы.
Улын озатып калган аналарның
Йөрәкләре сизгер тоялар.
Сискәндерә элек сайрап торган,
Җырсыз калган салкын оялар...

*5 апрель, 2003*

## Югалтам...

Мин дә киттем, әнкәй, бәхет эзләп,
Ярты авыл читкә күченде...
Сирәк кенә кайтып күрү өчен,
Ташладым да киттем мин сине.
Телең-шигъриятең җанда калды.
Кирәк түгел миңа мең алтын.
Мең алтынга алыштырмас әнкәм,
Югалттым мин сине, югалттым.
Кала матурлыгы тартты безне,
Калдырдык та еллар авырын,
Кунак булып кына кайту өчен,
Ташладык та киттек, авылым.
Кечерәйгән инде, хәлсезләнгән,
Күреп калырга дип мин кайтам.
Тел байлыгын биргән туган авылым,
Мин югалтам сине, югалтам.
Якын күреп кабул итсәләр дә,
Ямансу да миңа, авыр да.
Мин гаепле кеше сыман йөрим
Телсез-моңсыз калган авылда...

*9 гыйнвар, 2004*

## Юату

Җан сөйгәнен югалтканнар,
Ярдәм итмәс юату.
Аңлыйм, дөньяда бу — сезнең
Иң-иң авыр югалту.
Узганны сагынып уйлану,
Үкенечле сызлану...
Картлыктамы, яшьлектәме,
Зур газап — ялгыз калу,
Төшеңдә генә булса да,
Бер күрергә тилмереп...
Мәңгелеккә аерылуга
Булмыйдыр ул күнегеп.
Тик бер генә сызлангыч уй
Күңелне юатадыр:
Җан сөйгәнен тапкан гына
Үз парын югалтадыр.
Гомернең гүзәл еллары
Яратышып узган ич.
Югалткан табалмас инде...
Тапмаганнар кызганыч...

*12 февраль, 2004*

* * *

Ниләр көтә алда бу дөньяны?
Тигез юлмы, әллә упкынмы?
Җил, давыл юк, сулар, юллар тыныч...
Ә йөрәгем нигә дулкынлы?
Куркытырлык ят авазлар килми
Кыйтгалардан кара җил белән.
Күкрәү дә юк. Күкләр — зәңгәр болыт.
Ә йөрәктә нигә зилзилә?

Арта төшә шөбһә–борчуларым,
Җир асларын тыңлап карасам.
Юрамыйм да, ятып еламыйм да,
Ник йөрәктә давыл — гарасат?..

*28 май, 2004*

* * *

Ни булды соң сиңа, татар җире,
Моны кичерүе бик авыр.
Агачларны тамырыннан йолкып,
Котны алып үтте җил–давыл.
Шашкан җилләр түбәләрне каера,
Күкләр яшьнәп суга. Су — ташкан.
Адәмнәрме акылыннан шашкан?
Табигатьме әллә саташкан?
Күрәзәче, әүлия да түгел,
Нигә шөбһәләрем расланды?
Күкләр–сулар хәбәр итмәделәр.
Давыл — йөрәгемдә башланды.
Көтмәгәндә түбәләрне каера
Җил — өермә булып килә дә...
Гамьсезләнеп әллә онытыкмы
Ниләр барын Күктә — түбәдә?
Давыл узды. Зыян күргәннәрнең
Тыңлап йөрим елау–зар–аһын.
Нишләдең син, Адәм, әллә бармы
Күкләр кичермәслек гөнаһың?

*1 июнь, 2004*

## Яралар

*Кайсыгызның кулы җылы,*
*Бәйлисе бар йөрәкне?*

Хәсән Туфан

Табиб түгелмен шул,
Яраларга
Нинди дәва кирәк — беләлмим.
Соң булса да, инде соң булса да,
Хәсән абый, җаным, кил, бәйлим...
Ак кулъяулык белән бәйләмәкче
Фатих абый, кызың бу — Ләйләң.
Яуда шәфкатьле җан табылгандыр...
Төрмә яраларын кем бәйләр?
Берлин төрмәләре тирәсендә
Муса абый кабере табылмас.
Шулкадәрле җан ярасы алган
Җирдә беркем бәгыре табылмас.
Шагыйрьләрнең башы исән калыр,
Милләтемнең рухы сау булса.
Күпме яра алган татар нишләр,
Җан бәйлисе куллар суынса?..

*13 август, 2004*

## ГУЛАГ тоткыны

Ни кызганыч, без белгән-күргәннәрне сез белмисез!..

Исән чагында аралашып яшәгән Сталин лагеренын тагын бер тоткыны хакында бәян кылам. Гәзитебезнен Мәрьям Дибаева житәкләгән информация бүлегендә эшләгән чагым. (2012 елда бу апабыз 96 яшенә чыккач вафат булды.)

Алтмышынчы елларда редакциябезгә, кулына авыр букча тотып, бер хәбәрче килеп йөри иде.

— Ә-ә-ә, тюрколог, әйдә, түрдән уз! — дип каршы ала аны мөдиребез. Хәл-әхвәл сорашалар, яшьлекләрен искә төшерәләр.

— Госман, Гарәфетдин абыеннның материалларын үзең генә карап жибәр шунда. Аны төзәтәсе юк, — ди Мәрьям апа, миңа күрсәтмәсен житкереп.

Ә менә табигать хикмәтләре, кош-кортлар, жәнлекләр тормышы турында язучыны ни өчен «тюрколог» дип йөртә, бүгенгәчә төшенә алмыйм. Хәер, үзләре беләдер ул кадәресен?! Хәбәрчебез гади генә автор түгел анысы. Язучы Гарәфи (тулы исеме Гарәфетдин) Хәсәнов заманында әдәбият мәйданында үз атын уйнаткан шәхес. Аның соңрак басылган «Кошларым-дусларым» дигән китабы автор имзасы белән архивымда әле дә саклана.

Инде кыскача гына үзе белән танышыйк. Гарәфетдин Казанда, аның да эшче-һөнәрчеләр белән кайнап торган атаклы Яңа бистәдә, һөнәрчеләр гаиләсендә туып-үсә. Шунда урта мәктәпне тәмамлый. Әдәбиятка бик яшьләй килә. Элек Мәрьям Дибаева эшләгән «Яшь Ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») гәзитендә басыла башлый. Унөч яшендә, Татарстан язучыларынын Беренче съездында (1934), яшь автор буларак, Корылтай мөнбәренә күтәрелә, анда балалар әдәбияты турында ялкынлы нотык тота. Кабатлап әйтәм: 13 яшендә! Соңыннан бу хакта Максим Горький үзе «Известия» гәзитендә язып чыга, яшь каләм иясен мактап телгә ала. 1938-1941 елларда яшь авторнын «Яр башында болан», «Чуар таракан фажигасе», «Печән өсте яки Зәңгәр чыпчык» һәм башка китаплары дөнья күрә.

ГУЛАГ жилләре аны читләтеп үтми, унтугыз яшьлек егет яманаты чыккан Пеләтән төрмәсенә килеп каба. Ул монда шагыйрь Хәсән Туфан белән бер камерада утыра. Кыйналган өлкән каләмдәшенең яраланган кулын үзенең күлмәген ерткалап бәйли. Шагыйрьне одеялына төреп жылыта. Болары тоткыннарның истәлегеннән дә мәгълүм фактлар. Камерадан вакытлыча котылган Г.Хәсәнов тизрәк Себер якларына чыгып сыза. Кызылъяр төбәгендәге бер авылда, ятим балалар йортында гади эшче, аннары тәрбияче булып хезмәт итә. Язмыштан узмыш юк, диләр бит. Башкаларның кайтыр вакыты якынлашкан мәлдә, инде 1952 елга аяк баскач, Гарәфи Хәсәновны тагын үзен сагалап торган ГУЛАГка илтеп тыгалар. Әмма абзыебыз, ни төпченсәк тә, андагы хәлләрне ачылып сөйләмәде. Авызына су каптырып жибәргәннәр, сүз куертмаска ант эчерткәннәр диярсең. Безгә шунысын гына ымлады.

Унөч ел утырганнан соң, иреккә чыгарылгач, Гарәфи Хәсәнов туган шәһәренә кайтып урнаша. Әйткәнемчә, редакциягә, яраткан темасына матур-матур хикәя-язмалар китерде. Мин аларны карап кына чыгам, әллә ни каләм тыкмыйча, шунда ук гәзитнең алдагы саннарына тәкъдим итәм.

Хезмәтен хөрмәтләгән редакторны кем яратмасын?! Гарәфи абзый туп-туры минем өстәл янына елыша, тормышым белән кызыксына, кайбер нәрсәләр хакында ихлас киңәшләрен бирә. Үзенең язасы планнары белән уртаклаша. ГУЛАГ аның рухын сындыра алмаган. Эчкерсез, ачык күңелле, җор телле булып калган.

Дөнья түгәрәк бит ул, егетләр! Берзаман Гарәфи абзыйның Себердә туган улы Аяз белән «Татарстан» журналында, берара Татарстан матбугат агентлыгында (ул анда баш мөхәррир иде) бергә эшләп алдык. Аяз әтисенә охшаган, ачык күңелле егет, табигать баласы. Талант ягыннан әйтүем. Яза торган темасы да табигать. Бүген ул берничә китап авторы. Шәхси гәзитен ачып җибәрде. 2004 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Улын беләсездер, ә менә Гарәфи Хәсәнов дигән ГУЛАГ тоткынын күрми калдыгыз. Анысы безгә насыйп булды!..

## Кактуслар патшасы

Дөньясы ямь-яшел! Тәрәзә төпләре, өстәл-урындыклар, киштә-шүрлекләр, идәннең дүрт почмагы — чәнечкеле кактуслар белән тулган. Хуҗа шуларга патшалык итә. Туганнан туган сеңлесе сүзләренә караганда, ялгызлыгы-буйдаклыгы да шуннан икән. Мин белмим. Әйе, бу замандашларының хәтеренә сеңеп калган тәҗрибәле табиб һәм талантлы драматург Шәриф Хөсәенов. Исән булса, үзе турында язарга рөхсәт бирмәс иде, мәгәр. Әйдә, сүзем дога булып ирешсен! Хикәятем болайрак башлана.

... Узган гасырның алтмышынчы еллары. Төгәлрәк дисәгез, 1963 елның җәе. Ике буйдак, мөхәррир кардәшем Фәсхи Шакир белән «Гостелло» теплоходында Идел буйлап сәяхәт кылабыз. Ульян причалыннан Мәскәүгә менүче безнекедәй «Карл Маркс» теплоходы кузгалып бара. Палубасына бер чибәр кыз чыгып баскан. Ычкына бит кызыкай!..

— Сез татармы?

— Мишәр кызы.

— Ни кызганыч!

— Әйе.

Атып калырга ашыгам:

— Казанга шылтыратыгыз. Телефоным — 64-68, алт-мыш дүрт, алтмыш си-геез...

Ял бетте. Күп нәрсә томанга төренде, чөнки колактан эшкә чумдык. Редакциядә эш дигәнебез төнге сәгать берләргә кадәр сузыла. Егерме өч сәгать — безнең өчен кечкенә вакыт ул. Телефоным чәрелдәде. Коммутаторның таләпчән боерыгы ишетелде.

— Сезне Мәскәү сорый, сөйләшегез!

— Алло, исәнмесез! Нишләп редакция?!

— Редакция бу. Сезне Гумеров тынлый, — дим.

— Гафу итегез, миңа «Гостелло» теплоходындагы егет кирәк иде.

Бер айдан соң Мәскәү чибәре Наза Нургалиева (кыз чактагы фамилиясе) белән әнә шулай телефон аша иплэп таныштык. Бичаракай өйгә шылтыратам дип уйлаган. Ә монда редакция. Каушады бераз. Кая инде ул чакта өй телефоннары! Аңлаштык. Кыз Щелково бистәсендә, Исмәгыйль бакчасы тирәсендә яши икән. Һөнәре буенча тегүче. Тагын шунысын да искәртте. Казанда әнисенең бертуган энесе, язучы Шәриф Хөсәенов яши, ди. Бик беләм, минәйтәм. Чөнки илленче елларда ук театрда аның «Профессор кияве» дигән комедиясен кат-кат караганым булды.

Шуннан ике арада хатлар китте. Төн йокысын качыра торганнарын урысчалап мин сырладым. Юк икән, машинкада секретаребыз, шундый ук мишәр тумасы Равилә Тәкәнәева басып бирде. Корректурасын да үзе

карады. Мәскәү кызына татарча язмыйлар бит инде.

Үтемле икән хатларым, кыз дөпелдәп Казанга кайтып төште. Кышкы гыйнвар суыгында. Фабрикалары янгач, чираттан тыш ял биргәннәр үзенә. Туташ белән Декабристлар-Восстание урамнары чатында очраштык. Чегән кызыдай серле, егылып китәрдәй чеп-чибәр икән москвичка. Үзебез дә төшеп калганнардан түгел: аякта җәйге туфли, бер кат чалбарның «стрелкасы» май кисәрлек, балактан жил шәп уйный. Теге бөтенләй хәтәр: болай да гәүдәле кыз биек үкчәгә менеп баскан, өстендә, ул чакта Казан кызларының төшенә дә кермәгән 25 мен сумлык юка эчле каракүл тун. Утыз-кырык градуста икәүләшеп дерелдибез, биибез...

Яшьлеккә кереп адаштым ахрысы, кыскарак тотасы иде шулай да. Кышын юньләп җылытмый торган «Костер» (исемен күр син анын!) кинотеатрында нииндидер фильм карап чыктык. Тагын урамда биибез.

— Киттек безгә, чатны гына борыласы, Шәриф абый Кызыл Байрак урамында яши, — ди кыз.

Яхшысынмадым. Икенче чат борылышында торучы повестем герое Сафа Галиннарга (китапта Гали Сафин дип бирелгән) алып кердем үзен. Кунакчыл гаилә. Төн уртасына кадәр утырдык. Шуның белән шул дисәң дә ярый. Дәвамы минем файдага түгел... Сонрак Наза Казанга күчеп кайткан. Шул чорда Г.Камал театрында Шәрифнең «Әни килде» драмасы зур уныш белән барды. Кыз көн дә спектакльгә йөргән, килгәндер дип, мине күзләгән.

— Гел жиденче рәттә утыручы (җитәкчеләр һәм олы кунаклар рәте) егет ул булды ахрысы, — ди икән «Азат хатын» журналисты Кояш Тимбиковага. Абыйсын да тинтерәтеп бетергән.

— Кояш, күрсәт әле шул егетне, — ди Шәриф.

— Өченче катка мен дә кара, Журналистлар берлегендә утыра, — дип җаваплый тегесе.

Минем ишекне ачып кына бага Шәриф. Икенче катка төшкәч, күнелендәген ярып та сала:

— Таныйм икән үзен. Озын өстәленең башыннан чак күренеп тора, Назаның яртысы гына, — ди болай да зәһәр телле, кактуслары шикелле чәнечкеле драматург. Әмма дөрес әйткән, бахыр.

Наза ханым, бу юлларны укып син дә бер елмай әле! Онытмаган булсаң яшьлекне...

Шәриф абыеңның теге «өстәл башыннан чак күренеп тора» дигәненә һич үпкәләмим. Дөресен чат ярып әйтә торган кеше иде бит табиб-духтыр, талантлы драматург.

## Татлы тәнкыйть

Чоры шул иде — тәнкыйть дигәннәре беренче нәүбәткә куелды. Газит битләрендә басылган мәкаләдән соң, күпләр урыннарыннан очты. Бу «төерне» йота алучылар яши бирде. Бәгъзеләре, тәмам шомарып, «кимчелекләрне вакытында ачып, зур ярдәм күрсәткән өчен», журналистка рәхмәт белдерергә ашыкты. Мондый хәлләр үзем белән дә еш кабатланды. Ә бер очрак бөтенләй киртәсеннән чыгып китә язды. Якташ абзый гына коткарды.

...Элеккеге Тукай районына (үзәге Олы Әтнә авылы), шикаять хаты нигезендә, терлекчелекнең торышын яктыртырга дип киллем. Ни сәбәптәндер, райкомның идеология секретаре Мөхәммәт Мозаффаровка (гадәттә турыдан-туры беренчегә юнәләбез) барып кердем. Түрә бик төксе каршылады, әллә кем булып кыланды, аркылы-торкылы сөйләште. Хат белән танышкач та: «Бездә андый хәлләр юк», — дип, кырт кисте.

— Күрербез. Колхозларга чыгарга атыгыз бармы соң? — дим.

— Минеке юк.

— Табылыр...

Шулай булмыйча! Республиканың төп газитеннән килдек ич. Сәфәргә райкомның беренче секретаре Хәниф Сафиуллин белән аның олы гәүдәле, урынында биеп торган «Орлик» кушаматлы (хәтердә калган тагын) алмачуар юртагында кузгалдык. Хуҗа кеше бер дә теге Мозаффаров шикелле итенми. Гади, игътибарлы, дустанә гәпләшә. Дөньяны күргәнгә ошый. Житмәсә, якташлар, икебез дә бер районнан икәнбез. Ул моңа балаларча куанды. Жылы мөгамәләсен сизеп, үземнең дә ачуым суына төште. Олы Мәңгәр, Бәхтияр авылларында фермаларны карадык, терлекчеләр белән очраштык.

— Күргәннәремне язарга туры килер, — дидем киткәндә беренчегә.

— Шулай да каты бәрелмә инде, якташ, обкомга барып житәрлек булмасын. Фермада тәртип ясарбыз анысы. Мәкаләнә җавапны Мозаффаровның үзеннән яздырырмын. — Хәниф Сафиуллин акыллы житәкче иде. Соңыннан республика «Сельхозтехника» берләшмәсендә озак еллар эшләде.

... Килде җавап хаты. «Иптәш Гумеров дөрес тәнкыйтьләгән. Бүгенге көндә хаталар төзәтелде, фермадагы кимчелекләр бетерелде. Тәнкыйть өчен тагын бер кат рәхмәт авторга!..» Чыннан да хатка Мозаффаров кул куйган иде. Болай озын итеп сөйләвемнең хикмәте бар. Берәр елдан Мөхәммәт Мозаффаров партия өлкә комитетының матбугат секторы житәкчесе урындыгына менеп кунакламасынмы.?! Шурләдем, әлбәттә. Ул бит сугышта катнашкан, яраланган, аксап ук калган, орден-медаль колодкалары гына да әллә никадәр. Шуңа да үзен һәрвакыт эре тота. Әйтмим, безнең җаваплы мөхәррир белән генә түгел, хәтта, турыдан-туры житәкчесе, обкомның Пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Николай Андрианов белән дә бармак аша гына сөйләште. Тәмам туйганнар ахрысы моңардан. Мине Татарстан журналистлар берлеге идарәсе секретаре итеп раслаган көнне үк Андрианов татарчалап (чуваш егете безнең телне хәйран гына сукалый иде) тәкъдим ясады:

— Ычкын, давай, партшколга, туры матбугат секторына кайтырсың!

Мозаффаров урынына димәде, әмма тел төбендә шул сизелде — секторга дип, атап әйтте. Теге чакта үземне мактап хат юллаган кешене ник батырыйм, ди. Районнарда зона семинарлары оештыру планнарымны карап кына чыга, хуплый. Чын дуслар без.

Алыштырмадым Мозаффаровны. Сезнең белән житәкчелек итәргә дә язмады. Югыйсә, обкомда бозыласым көн кебек ачык иде. Мозаффаровлар болай да күп иде ич ул чакта...

**Госман ГОМӘР**

***Редакциядән:***

*Озак еллар матбугатта эшләгән, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Юлбарыс тырнагы», «Мөһер» исемле детектив жанрдагы әсәрләр иҗат иткән, соңгы елларда журналыбызда атаклы шәхесләр тормышын шәрехләп язган язмалары белән еш катнашучы каләмдәшебез бу айда үзенең олуг юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, тыныч-имин көннәр, иҗади уңышлар телибез.*



Әлмәт төбәге якларында яшәп иҗат итүче язучылардан бер төркем. Бу фото 1994 елның апрель аенда төшерелгән. Арада вафат булганнары да шактый, шөкер, бүген дә исән-имин иҗат итүчеләр дә бар.



Татарстан фәннәр академиясенең беренче президенты Мансур Хәсәнов (1930 — 2010).



Язучыларыбыз телестудиядә. Сулдан уңга: Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза), Талгат Галиуллин, Ләбиб Лерон, Ленар Шәех. 2011 ел.



*Якташлар очрашкач. Сулдан уңга: Марат Кәбиров, Роберт Миңнуллин, Хәмит Латыйпов. 2003 ел.*



*Ульян шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрә Иделбикә (Лена Сабитова).*



*Аталы-уллы сынчы-рәссамнар: Альфрет һәм Гадел Әбдрәшитовлар. 2000.*

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ ҖЫЕНЫ

Казанда Бөтендөнья татар конгрессының V съезды булып узды. Анда 34 илдән, РФнең 61 төбәгеннән килгән 796 делегат, 300гә якын кунак, 100дән артык журналист катнашты.

Съездның пленар утырышының беренче өлеше М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында узды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миннеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, РФ тышкы эшләр министры урынбасары Григорий Карасин, БДБ эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе Константин Косачев, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле урынбасары Леонид Гильченко, Казан шәһәре башлыгы Илсур Метшин һ.б. рәсми затлар, министрлык, ведомство җитәкчеләре, әдәбият, сәнгать әһелләре, галимнәр катнашты.

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов үзенең сәламләү чыгышында Бөтендөнья татар конгрессының 20 ел эчендә республика белән бергә зур юл үтүен искәртте. Аннан соң съездда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров төп доклад белән чыгыш ясады. Съезд материаллары белән укучыларыбызны киләсе саннарда тулырак таныштырачакбыз.

## БЕЗ ТӨРЛЕ ДӘ, КӨЧЛЕ ДӘ

Казанда VI Бөтенроссия «Күптөрле Россия» ачык журналистлар конкурсына нәтиҗә ясалды. Бәйгене 2006 елда ТР Журналистлар берлеге, Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы гамәлгә куйган иде һәм ул Татарстан җитәкчелеге химаясендә үткәрелә. Быел конкурска Россиянең 52 төбәгеннән 739 хезмәт кабул ителде.

Бүләкләү тантанасында ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, «Россия телевидение академиясе» фонды президенты Михаил Швыдкой, ТР Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов, танылган тележурналистлар Владимир Познер, Антон Хреков, Арина Шәрәпова һ.б. катнашты.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Без бәйгенең бөтен илдән гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләрен җыюына сөенәбез, алар халыкка дөреслекне ирештерә, ышаныч уята һәм күпбизәкле Россия тормышын күрсәтә», — дип мөрәҗәгать итте. Ә Михаил Швыдкой мондый бәйгеләрнең журналист һөнәренең абруен күтәрүенә басым ясады.

Аннары җиңүчеләр бүләкләнде. «Күптөрле Россия» журналистлар конкурсы гран-приена Кемерово өлкәсеннән «Алга» мари район газетасы лаек булды, аларга Фәрит Мөхәммәтшин «Шевроле Лачетти» автомобиле ачкычын тапшырды. «Матбугат басмаларында язмалар сериясе» номинациясендә «Тюменьская область сегодня» бүләкләнде. «Таймыр» газетасы хәбәрчесе Ирина Аплесневага «Миләшле бәхет» очерклар җыентыгы өчен, шулай ук татар телендәге «Атна вакыйгалары» мәгълүмат блогына махсус приз бирелде. «Радиотапшырулар циклы» номинациясендә беренче урынга «Башкортстан» ДТРКсы чыкты, бүләк алучылар арасында Түбән Новгород, Бурятия, Екатеринбург, Ненец автономияле округыннан килгән иҗат төркемнәре дә бар иде.

## СТРАСБУРГ ТАТАРСТАН КӨННӘРЕНӘ ӘЗЕРЛӘНӘ

Киләсе елның мартында Страсбургта Татарстан көннәре узачак. Аның кысаларында Казанда булачак Универсиаданы да тәкъдим итәчәкләр.

Бу хакта Европа Советының Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессы бюросы утырышында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җиткерде. Утырышта катнашучылар исә аның бу тәкъдимен хуплады. «Универсиадага игътибарны ныграк җәлеп итәсе килә, - диде Ф.Мөхәммәтшин журналистларга. – Европа Советы аша исә без Казан, Татарстан һәм Россия хакында 40тан артык илнең вәкилләренә мәгълүмат җиткерә алабыз».

## ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ БӘЙРӘМЕ

Халыклар бердәмлеге көне унаеннан яңартылган Халыклар дуслыгы йортында «Татарстан — туган йортыбыз» дип исем-

ләнгән этнофестиваль булып узды.

Республикабыз җитәкчелеге исеменнән фестиваль кунакларын Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясе советы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

Фестивальне Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «Казан нуры» халык музыка уен кораллары оркестрына һәм берләштерелгән балалар-яшүсмерләр хорына кушылып җырлап, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Альберт Әсәдуллин башлап җибәрде. Концертта шулай ук Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле, Татарстанның атказанган артисты Владимир Васильев, мариларның «Кна-вел», удмуртларның «Сактон», чуашларның «Росинка», керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» фольклор ансамбльләре, грузин һәм төркмәннәрнең бию коллективлары, «Симха» ансамбле җитәкчесе Эдуард Туманский, әрмән диаспорасы вәкиле Аршак Алтунян чыгыш ясады. Сәхнәдә Татарстанда гомер кичерүче төрле милләт вәкилләренең тормышын чагылдырган видеофильмнар күрсәтелде. Алар бер үк вакытта сәхнә бизәлеше дә иде.

Бу бәйрәмгә шулай ук Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, Татарстан мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Президентның эчке сәясәт буенча департамент җитәкчесе Александр Терентьев, Дәүләт Советы депутатлары, Европа Советының җирле һәм төбәкләр хакимияте конгрессы почетлы рәисе Кейт Витмор, Казакъстан, Кыргызстан, Якут-Саха республикалары хакимияте вәкилләре дә килгән иде.

**ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ**

Фән һәм техника өлкәсендә 2012 ел өчен Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре лауреатлары ачыкланды. Табигый, техник һәм гуманитар фәннәрне үстерүгә, принципиаль яңа технологияләр эшләүгә һәм кертүгә зур өлешләре, фән һәм техника казанышларын куллану нигезендә алынган күренекле нәтиҗәләре өчен 8 хезмәт авторы, җәмгысе 45 кеше җөмһүриятебезнең мәртәбәле премиясенә лаек булды. Алар арасында тарих фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, әдип, археограф, журналыбызның даими авторы, редколлегия әгъзасы Миркасыйм Госманов та бар. Дәүләт бүләге аңа атаклы шәхесләр турында «Җыен» фонды тарафыннан бастырып чыгарылган җыелма әсәрләр сериясен әзерләгәндә тарихи-биографик хезмәтләр циклы һәм фәнни-мөхәррирлек эшчәнлеге өчен үлгәннән соң бирелә.

Лауреатлар арасында Санкт-Петербург шәһәрендә һәм Ленинград өлкәсендә Татарстан Республикасының даими вәкиле Шамил Әхмәтшин исеме дә бар. Дәүләт премиясенә ул «Татарлар Ватанга хезмәттә» дигән монографияләр циклы өчен лаек булган.

***

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге һәм хәзерге татар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен язучы **Мингалимов Рөстәм Гали (Рөстәм Мингалим) улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кыш.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы-галим **Дамир Исхаков**.

## Яңа китаплар




**Шанхай төрк-татар мәдәният җәмгыяте** (төз. Раиф Мәрданов. — Казан: «Милли китап» нәшр., 2012. — 184 б.

Китапта XX гасырның беренче яртысында Кытайдагы Шанхай шәһәрендә яшәгән татар мөһаҗирләренең сәяси тормышы тасвирлана, җәмгыять идарәсенең 40нчы еллардагы җыелыш беркетмәләре һәм шул оешма эшчәнлеген яктырткан язмалар урын алган.




**Наил Шәрифуллин.** Соңарган сөю: повестьлар, хикәяләр. — Казан: «Рухият» нәшр., 2012. — 360 б.

Наил Шәрифуллинның әлеге беренче китабы татар әдәбиятына үзенчәлекле фикерләүгә, стильгә һәм образлар системасына ия язучы килүен раслый. Автор үзенең әсәрләрендә максатчан, нык рухлы, хис-кичерешләргә бай, милләт язмышын үз күңеле аша үткәреп яшәүче заман герое тудырырга омтыла.



Дамир Исхаков

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)